
ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

10.2007




OCEANVS SCYTHICVS

# Казан утлары
# Qazan utları

2007

# 10

(1020)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*«Татмедиа» массакүләм коммуникацияләр буенча Татарстан Республикасы агентлыгы һәм Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Раиф Мәрданов, Рашат Низами, Рәдиф Сәгъди.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—541-38-77.
Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.
**Факс**—(843) 541-38-77.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Газинур МОРАТ. Хәтер көне. *Шигырьләр* ..... 5
Лена ШАГЫЙРЬҖАН. Туган Илкәй бар дөньяда. *Шигырьләр* ..... 47
Рәшит ЯГЪФӘРОВ. Калган хәтер—янган күперләр. *Шигырьләр* ..... 63
Мансур ШИҺАПОВ. Дөнья кырындагы юлларда мин. *Шигырьләр* ..... 107
Гөлзадә БӘЙРӘМОВА. Күзләргә кереп барыш... *Шигырьләр* ..... 109
Илдус ДИНДАРОВ. Күзге күкрәү. *Шигырьләр* ..... 112
Нурихан ФӘТТАХ. Аклан. *Хыялый роман* ..... 66
Дилбәр БУЛАТОВА. Туй. *Хикәя* ..... 52

ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Рабит БАТУЛЛА. Мур кырылышы. *Фаҗига-хроника* ..... 6

ДӨНЬЯ ӘДӘБИЯТЫ ҮРНӘКЛӘРЕ

Җаһит ЗАРИФОГЛУ. Йөрәк бабай белән падишаһ ..... 115

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Алинә КУРОПАТКИНА. Җан—күк кызы булганга. *Шигырьләр* ..... 132
Резеда ГОБӘЕВА. Тамчыдагы кояш нуры булып. *Шигырьләр* ..... 133

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Фәридә ХӘСӘНОВА. Кинаяле сүз уйнату ..... 134

ТАРИХ

Марсель ГАЛИЕВ. Татарны үз иткән немец ..... 142
Карл ФУКС. Казан татарлары ..... 144

ФӘН

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге ..... 155
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы ..... 160

ТЕЛ ДӘРЬЯСЫ

Тел-имла турында фикерләр ..... 168

ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР

Вакыйф НУРИЕВ. Соңгы йөреш ..... 173

Бер сорауга-бер җавап ..... 172
Безнең күргәзмә ..... 178
«Татар энциклопедиясе» битләреннән ..... 179
Юбилейлар! ..... 180
«Казан утлары» архивыннан ..... 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 188

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

Журнал выходит один раз в месяц


«Проза и поэзия»: стихи Г. МУРАТА, Л. ШАГИРЗЯН, Р. ЯГЪФАРОВА, М. ШИГАПОВА, Г. БАЙРАМОВОЙ, И. ДИНДАРОВА;
роман Н. ФАТТАХА «Аклан», рассказ Д. БУЛАТОВОЙ «Свадьба».
«Драматургия»: Р. БАТУЛЛА. «Исторические диалоги».
«Образцы мировой литературы»: Дж. ЗАРИФОГЛУ. «Дед и Падишах».
«Творчество молодых»: стихи А. КУРОПАТКИНОЙ и Р. ГУБАЕВОЙ.
«Литературная критика»: статья Ф. Хасановой «Ирония слов».
«История»: К. ФУКС. «Казанские татары...» (с предисловием М. ГАЛИЕВА).
«Наука»: А. ТИМЕРГАЛИН. «Словарь нации» (продолжение);
Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень» (продолжение).
«Рассказы из жизни»: В. НУРИЕВ. «Последний ход».
Страницы из «Татарской энциклопедии».
Слово читателя.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Древняя Казань»—работа Н. ХАЗИАХМЕТОВА; писательница С. ЗЫЯЛЫ.


## IN THIS ISSUE:

The magazine edits monthly


Prose and poetry: verses by G. MURAT, L. SHAGIRZYAN, R. YAGFAROV, M. SHIGAPOV, G. BAYRAMOVA, I. DINDAROV.;
Novel by N. FATTAH Aklan, story by D. BULATOVA Wedding.
Dramatic art: R. BATULLA. Historical diologues.
Samples of world literature: J. ZARIFOGLU. Grandfather and Padishah.
Youth creativity: verses by A. KUROPATKINA and R. GUBAEVA.
Literary critics: article by F.HASANOVA Irony of words.
History: K. FUX. Kazan Tatars... (with foreword by M. GALIEV).
Science: A. TIMERGALIN. Dictionary of nations (continuation);
F. GARIPOVA. History of our villages (continuation).
Life stories: V. NURIEV. Last course. Pages from Tatar encyclopedia.
Word of reader. From photoarchive of magazine.
Diary of social-cultural life. On our covers: Ancient Kazan work by N. HAZIAHMETOVA; writer S. ZYALY.



* Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
* Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
* Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 20.09.2007 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С–1176 Тираж 6451.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2



© «Казан утлары», 2007 ел.

Газинур
Морат

# ХӘТЕР КӨНЕ

…Тагын кемнәр бисмилласыз
Укый анда хәтемне?
Хәтернең дә хәтәре бар,
Хәтәрнең дә хәтере.

Хәрабәдәй пыскый хәтер,
Ханбикәдәй моңая…
Ходайның һәр бирмеш көне
Хәтер көне болай да.

Хәттин хәтәр хәтер көне
Безнең һәрбер көнебез.
Яндырылган дастаннарның
Ахак кузы, көле без.

Зилзиләдән гөлләр түгел—
Көлләр калган сибелеп…
Кем җиңелгән җиңә-җиңә,
Кемнәр җиңгән—җиңелеп.

Хәтәрдән дә хәтәр хәтер.
Ул—саваплы каргыш та.
Казый абзый шул хәтерне
Куйган, имеш, тавышка.

Тавышланып йөрмәсеннәр
Йөгәнсезләр, янәсе;
Хәтер түгел—хәмер кирәк
Сиңа, Ходa бәндәсе.

Җир сукала, иген ик син,
Йә аркан иш… комлыкта…
…Ә безгә шул тавыш-тынсыз
Качу кирәк коллыктан.

Безгә очып китү кирәк
Вакыт аккан уңайга.
Ходайның һәр бирмеш көне
Хәтер көне болай да.



Рабит
Батулла

# МУР КЫРЫЛЫШЫ

ФАҖИГА-ХРОНИКА

*(Бөек җиһангир Аксак Тимер белән Испания короле Һәнрих Өченче турында "Хәерче монахлар ордены" әгъзасы Руи һәм дон Олонсо хатирәләре.)*

*Бисмилләһ ир-рахмән ир-рахим.*

## Кайнарташ аланында очрашу

*Тау битендәге агачлар арасында, тын аланчык уртасында өстәл кебек тигез таш ята. Таш челлә кояшының җылысын үзенә җыйган.*

*Таш өстендә бөгәрләнеп кара җылан ләззәтле йокыга талган. Ул әле яңа гына урман тычканын йоткан иде. Таза дегет буяп куйган кебек, чем-кара җылан түгәрәге соры таш өстендә, тагын да ныграк каралып, елкылдап тора. Кара җыланны һичнәрсә, һичкем борчымый. Төрле төстәге күбәләкләр генә елкылдавыклы кара тәгәрмәч өстеннән очып-очып киткәли. Вак кәлтәләр йөгереп барган уңайдан кинәт туктап, таш өстенә басып җылынып алалар да житез генә чабып уза торалар. Кайнар таш кырына ук диярлек сәлви агачы ауган. Тау җәнлекләре агач аша атлап йөри-йөри, тояклары белән сәлвинең кабыгын куптарып, шомартып бетергәннәр.*

*Җил исеп куйды. Тамырлары белән кыя-ташларны кочып, җиргә береккән чыршы, нарат, имән агачларына ышыкланып үскән вак куакларга җил дулкыны төшеп җитмәде. Агачларны йокыдан уятырга теләмәгәндәй, җил ялкау гына узып китте. Агач очлары үзара ышылдашып-пышылдашып алды да тынып калды.*

*Аланчыкка бер кыз килеп чыкты. Кызның тулып пешкән чагы гына әле. Тауга менгәндә аның тыны капланган, ул еш-еш сулый, кулындагы чәчәк бәйләме белән үзенә һава җилләтеп ала. Аның йөзендә бетмәс сөенеч, чиксез мәхәббәт нуры балкый. Ул эчке куану илә тау астыннан менә торган сукмакка бага. Шул сукмактан аның сөйгәне килергә тиеш. Егетеннән хәбәр алгач, кыз түзмәде, юлга иртәрәк чыкты, килешенгән вакыттан алдарак аулак аланга менеп тә житте. Бераз хәл ал-*

Рабит БАТУЛЛА (1938) — *прозаик, драматург; күпсанлы китаплар ("Сөембикә", "Юл буйлары зәңгәр чәчәк" романнары, балалар өчен повестьлар, әкиятләр, һ.б.) авторы. Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

*мак өчен, ул озын күлмәгенен итәген жыя төште дә, кайнар ташка утырырга ниятләгән иде, таш уртасында йоклап ятучы жыланны күргәч, жинелчә генә кычкырып куйды. Баладән башаяк, жыланны борчымаска тырышып, читкәрәк китеп, ул ауган агач кәүсәсенә утырды. Бу—әле яна гына уналтысын тутырган сеньорита Беатриса иде.*

*Аулак аланчык аларнын яшертен күрешә торган урыны. Бу аланга, тау башындагы урманга менүчеләр бик сирәк.*

*Озак та узмады, кемнендер бу таба килгәне ишетелде. Килүченен дә сулышы кайнар, ул да еш-еш сулый. Аланчыкта буй житкән егет күренде. Кыз, кулындагы чәчәкләрне агачка куеп, егет тарафына атылды.*

—Руи!

—Беат!

*Алар тавышына йоклап ята торган жылан уянды, уянды да: мин сезгә комачауламыйм дигәндәй, горур гына шуыша-шуыша куаклар арасына кереп юк булды.*

Б е а т р и с а *(жыланга ишарә белән).* Үз урынынны безгә калдырганың өчен рәхмәт, дустым!

*Алар кочаклаштылар. Кызнын көрәнсу жирлектәге күлмәгендә ачык төстәге чәчәкләр булмаса, боларнын икесе дә кыз кеше, дип уйларга булыр иде. Егет тә озын итәкле, көрән чабу кигән. Бу—әле генә университетнын илаһият факультетын тәмамлаган яшь монах Руи иде. Анын озын күлмәге биленнән зәнгәр чуклы эзәр белән буылган. Егет белән кыз бер-берсен ашап бетерердәй булып, озак үбештеләр. Һәм, ниһаять, иреннәре аерылгач, кыз тынына капланып:*

—Руи!—диде.

—Беат!—диде егет.

—Дон Руи!—диде кыз.

—Сеньорита Беатриса!—диде егет.

*Алар тагын кочаклашып, үбешергә тотындылар. Күрешү кайнарлыгы бераз сүрелә төшкәч, алар ауган агачка таба киттеләр. Агачны узып, гашыйклар кайнар таш өстенә утырдылар.*

—Жаным, Руи,—диде Беатриса эчке бер дәрт белән.—Мин сине шундый сагындым, шундый сагындым, сине күрә алмам, дип көн-төн жыладым.

Руи бары тик:

—Беат...—дип кенә әйтә алды, куанычы кайнап торган кыз өзлексез такылдарга кереште:

—"Беат" дип назлап эндәшүенне көпә-көндез ишетәм, тик кешеләргә генә әйтмим; көндез төш күрә башлаган бу кыз, ул жennәр белән аралаша, дип инквизиция кулына тотып бирүләреннән куркам, сине күрмәгәнемә биш былтыр бардыр, мин сине юксынам, гел юксынам, Руи, син университетны тәмамлагач ешрак очрашырбыз, дип өметләнеп яшәдем, менә син университетны тәмамладың да... син шунда кафедрада каласын, дип ишеттем, шундый куандым мин, Руи, беләсенме, миннән дә бәхетле кыз юктыр, үләм мин сине яратып, сөям сине, кысып кочаклап, үбеп үтерер идем мин сине, Руи-Руи, кафедрада дин дәресләрен укытучы остаз, дин гыйлеме бакалавры дон Руи... бәрәчбәрәкәт, әле син һаман монах киеме киеп йөрисенме... ташла әле шул тула тунынны, женем сөйми кара киемле адәмнәрне, аларның эчләре дә карадыр сыман...

—Беатрис...—дип егет сөйгәнен туктатырга теләгән иде дә, кыз ана игътибар итмәде:

—... эчләре генә кара түгелләр, уйлары да карадыр ул каратун кигән бәндәләрнен... чиркәүдәге попларны гына ал, бррр, эпископ үзе кешенен гөнаһларын ярлыкый, үзенен алгысыган күзе чибәр хатында, чибәр хатын аңа бөтен эч серен сөйли, гөнаһларын әйтә, монах астан гына уйлый, әһә, бу чибәр хатын тегерменче белән йоклаган, нигә әле ул минем белән дә йокламаска тиеш, мин бит аның гөнаһасын тагын ярлыкыйм, дип мәкерле эш йөретә башлый, акча биргән кешенен әллә нинди гөнаһларын да ярлыкый икән бит ул монахлар, кызлар сөйләде: чүлмәкченен хатыны тимерче белән гөнаһлы булган. Шуннан бу безнен чиркәүдәге хәерче доминикан монахы янына барып, серен ачкан. Яшь хатынның гөнаһларын мо-

нах ярлыкаган, аннан соң: гөнаһларының ирена әйтәм дип, монах аны ирексезләп хөҗрәсенә алып кергән, бичара хатын нишләсен инде, бер тапкыр гөнаһ кылгач, икенчесен дә кылган, хәзер ул монах теге хатынның гөнаһларын атнага бер мәртәбә ярлыкый икән.

Руи тәвәккәлләргә булды, ахрысы, ул катырак тавыш белән:

—Беатриса! Туктале!—диде.

—Туктадым, Руи,—диде кыз.

—Беатриса...—дип Руи тирән сулыш алып, нидер әйтмәкче иде, кыз аңа сүз әйтергә ирек бирмәде:

—Мин шундый куандым, син мине таулар арасына чакырганыңа сөенеп үлә яздым, без менә шушында була идек, матур җирләр бу, Руи, шомлы кыялар, таулар, урманы серле шаулый, чишмәсе чылтырап ага.

Руи Беатрисаның ике беләгеннән тотып, сизелерлек итеп каты кысты:

—Беат! Мин университетта, кафедрада калмыйм!—диде.

—Калмыйсың? Ничек? Бакалавр дәрәҗәсе алгач, кафедра тикле кафедрада калмаган кеше буламы?

—Була, менә мин ул... Беатриса, бу—безнең соңгы тапкыр күрешүебез. Мин сине бәхилләшергә чакырдым.

Беатрисаны алмаштырып куйдылармыни, әле яңа гына чәтердәп торган чая кыз кинәт житди кыяфәт алды, ул:

—Димәк, син үзеңне барыбер Фәкыйрь монахлар орденына яздырдың?—диде.

—Мин—доминикан монахы!—диде егет.

—Йа, Изге Мария! Син чынлап әйтәсеңме?

—Минем кайчан шаярганым бар? Кыскасы, Беатриса, без кабат очрашмаячакбыз, сау кал, бәхиллә мине, миңа ачу-үч саклама, безгә аерылышырга кирәк.

Беатриса көтелмәгән бу яңалыктан каушап калды, ул ни әйтергә белмичә, аягүрә басып, аланчыкны әйләнеп чыкты. Таш өстендә утыра калган егет алдына килеп, тезенә төште, ярым-ялварулы тавыш белән ул:

—Руи!.. Мин сине өзелеп сөям,—диде.—Мин синнән башка ничек яшим? Син миңа шундый наз илә бага идең, син мине шундый кысып сөя идең, мин дөньямны онытып, синең белән күрешергә чабам. Синең белән күрешкәннән соң очып йөрим. Ташлама мине, Руи!—Беатриса чарасызлыктан, мәхәббәтенең җимерелүен сизенгәндәй, үзен-үзе кыздыра иде, ул шашкан кыяфәт ала бара, аның күз яшьләре тышка бәреп чыкты, әйтергә сүз табалмастан, гажизлектән ул үксеп җылый башлады.

Руи эшнең шулай булачагын алдан ук белә иде:

—Зинһар, җылама,—диде ул сабыр гына.—Син җылагач, аерылышуы читен булыр.

Беатриса кинәт җылаудан туктады, кырыс тавыш белән, егетен шелтәләгәндәй:

—Читен булса, ташлама мине!—диде.

—Хәл ителгән! Безнең юллар аеры! Син дөньяви ләззәтләр өчен яралтылган, мин аскет монах булыр өчен туган. Җылама, зинһар!

Беатриса күз яшьләре белән генә уңай нәтиҗәгә ирешә алмасын аңлаган иде инде. Ул юеш битен ике учы белән сөртеп алды да:

—Ярый, җыламыйм!—диде.—Сиңа миннән аерылуы авыр булмасын өчен, мин җыламыйм...—Ятып калганчы атып кал, дигәндәй ул соңгы тапкыр өмет белән сөйгәненә бакты.—Руи, нигә син монах зинданына ябылып, үзеңне әрәм итәсең? Мин сиңа өй тутырып балалар табар идем, синең университеттан кайтканыңны тәмле ашлар пешереп көтәр идем. Син бит мине ярата идең, хәзер дә яратасың, шулаймы? Яратасың, сөясең, үзең шул мәхәббәттән качасың, ни өчен? Алла дөньяви ләззәтләрне тыймый. Нигә син шул рәхәтлекләрне кырга куеп, ярымкараңгы, дымлы чиркәү хөҗрәсенә үзеңне ябып куясың?

—Алла өчен, Беатриса, Иисус Христос өчен, дин сафлыгы өчен, кешеләрнең рухын чистарту, аларның рухын гөнаһлардан коткару өчен мин дөньяви рәхәтләрдән ваз кичәргә тиеш, Беат. Кеше үзен эчтән тазартмаса, ул беркайчан да башкаларны тазарырга өнди алмый. Үзе гөнаһлы булып, башкаларны гөнаһ кылудан тыя икән, ул җәһәннәмнең түрендә булачак. Минем бөек максатым бар, ул католиклыкны, иң саф, иң гадел динне саклау, аны җәелдерү, кешелекне җир гөнаһларыннан саклау, кисәтү. Бу минем катгыян инанычым, шушы юлда мин ләззәтем-

не, жанымны фида кылырга да әзер.

—Ә мин? Беатриса нишләргә тиеш? Ярату, сөю, мәхәббәтне кая куясың, Руи-и?

—Изге максат алдында мин хәтта мәхәббәтемнән дә ваз кичәм. Бөек максатыма ирешер өчен мин ул ләззәтләрдән азат булырга тиеш. Шәраб та, хатын-кызлар да, балалар да максатым каршысында киртә булып тора алмый.

—Руи... Син ялгышасың, башкалар көрәшсен дин сафлыгы өчен! Башкалар аскет монах булсын! Син мәхәббәт өчен яралтылган зат, Руи! Жаным, Руи, зинһар, кире кайт уеннан. Кал университетта остаз булып.

—Әгәр дә мин көрәшмәсәм дин сафлыгы өчен, кем көрәшер? Мин фаш итмәсәм гаепләләрне, кем фаш итәр?

—Бәлки без яшертен генә очрашкаларбыз, ә?

—Юк, Беатриса, кылган гөнаһыбыз да житәрлек.

—Гөнаһ түгел ул, Руи. Сөю ул. Мәхәббәт ул. Мин сине сөйдем, сөелдем, мин беркайчан да бу эшем өчен үкенмәячәкмен. Әгәр дә сөю гөнаһ икән, Алланы сөю дә гөнаһтыр.

—Язык жыйма башына, Беатрис. Без синең белән менә шушында ничә тапкыр гөнаһ кылдык.

—Ә мин ул эшнең гөнаһ икәнен белми идем, димәк, мин гөнаһтан азат, син генә гөнаһлы булып каласың, синең ул гөнаһыңны епископ йөз алтын акчага ярлыкап бирер... *(Руи ризасызлык белән башын читкә борды.)* Ярар, синеңчә булсын, Руи. Без аерылышабыз, бәхил бул, мин сине шундый яраттым, шундый сөйдем, ул сөюем гомерлеккә миндә сакланыр. Жаным, Руи...—кыз егет муенына сарылды.

—Ярамый, Беат!

—Мин синең "Беат" дип наз белән әйткәненне син югында да ишетәм. Шунда мин дә "Руи" дип пышылдыйм. Руи, кабатланмас сөюемне кинәндер, зинһар.

—Ярамый, Беат... Гөнаһ...

—Бер тапкыр гөнаһ кылдың ни, ун тапкыр гөнаһ кылдың ни, мин сине сөям, Алла минем сөюемне гафу итәр, сине дә гафу итәр. Атабыз Адәм белән изге анабыз Һава гөнаһ кылмаганмы? Әйдә, алар гөнаһ кылган дип саныйк. Алар шул эшне башкарырга тәннәре белән әзер булган, Алла аларны шул эшкә жайлап, алдан ук берсен ир женес, икенчесен хатын-кыз итеп яралткан. Эчке дәртне кая куйсыннар алар? Берберсе белән кендектәш булмыйча, һәр икәвесе аерым-аерым үзләрен канәгатьләндерү белән шөгыльләнсеннәрме? Анысы тагын да олырак гөнаһ аның. Янында матур хатын-кыз женесе тора, Адәм агач түгел, ләбаса. Янында гайрәтле ир ята, син бер кырга барып, ялгыз йокла, имеш. Алла аларның бу гөнаһасын ярлыкаган, аларны гафу иткән һәм Адәмнән пәйгамбәр ясаган. Юк, алар гөнаһ кылмаган булып чыга... *(Кочаклаштылар.)* Руи... *(Беатриса монахның сул жинен сызгандырды.)* Мин синең беләгеңдәге шушы миненне үбәргә яратам! Бу—бәхет мине, Руи! *(Беатриса Руиның сул беләгендәге минен назлап үбә башлады.)* Бәхетле бул!

—Беат, кичер мине, бәхиллә...

—Кичерәм, Руи, бәхиллим, Руи... Бәхил бул!

—Бәхил бул, Беат!

*Алар шушы кайнар ташлы аланда соңгы тапкыр күреште. Аларның соңгы күрешүләре аллагыларыннан күпкә, бик күпкә кайнар булды.*

*Руи сукмак буйлап ашыгып аска төшеп китте.*

*Беатриса ике учы белән йөзен каплап, аланда калды. Ул озак жылады. Соңыннан ниндидер карарга килеп, күз яшьләрен сөртте, тирән сулыш алды да аска төшә торган сукмак буйлап кайтыр юлга атлады.*

## Инквизиторга—инквизиция

*Бөек Инквизитор сараенданиләр кылынганын беркем дә белә алмас иде. Бу сарай—аерым дөнья, аерым дәүләт. Сарайның эчке серләренә төшенәм, андагы акыл көрәшенең очына чыгам, андагы мажараларны, серле фетнәләрне беләм, дип әйтүче ата ялганчы булыр иде. Асылташлар белән бизәлгән тәхет, дисенме. Кардиналлар, сакчылар гаскәре өчен салынган йортлар, китапханәләр, сыннар, фрескалар, киң полотнолы картиналар өчен төзелгән музейларны күргән кеше*

*католикларның нинди кодрәткә ия икәнен аңлар. Әмма шушы байлык эчендә, шушы гүзәллек арасында ниндидер салкынлык, шом, кара дәһшәт мохите хөкем сөрә иде.*

*Кара киемле монахлар, кызыл чабулы кардиналлар әрле-бирле ашыгып уза торалар. Башка монахлардан кечерәк гәүдәле берсе шикле кыяфәт белән мәрмәр баганалар арасында йөренә, алак-ялак карангалый да кемнедер күреп, мәрмәр колонна артына поса.*

*Ниндидер кәгазьләр тутырылган букча тоткан Бонифаций күренде. Теге кечкенә монах аның каршысына чыкты. Бу—монах булып киенгән Беатриса иде. Ул сакланып кына йөзен ачты.*

Бонифацийның авызыннан:

—Беатриса?!—дигән аваз очты да чыкты.

—Руи!—диде яшь хатын.

—Беатриса, син ничек монда? Кайдан, ничек кердең?

—Монах булып киендем дә, яшелчә төялгән каплаулы арбага менеп качтым... Жаным, Руи, син нинди мәһабәт, сиңа Бөек Кардинал киеме бик килешә. Син барыбер үзеңнекен иттең, кардинал булдың, аннан Бөек Инквизитор итеп сайладылар. Мин бик шат, жаным. Синең исемең хәзер Бонифаций!

—Шул араларны узып, ничек килеп життең, тиле хатын?

—Мин синең күләгәңә ияреп килдем. Син баскан туфракны үбәргә дип килдем.

—Тиз кит моннан! Сине монда күрерләр, танырлар, монахлар башлыгына мондый гамәл һич килешмәс, Беатрис, тиз бул, чыгып кит син сарайдан, чыгып кит.

—Син монда урнашканнан бирле ничә тапкыр юлларыңны сагаладым, күрә алмадым. Жаным, Руи, мин сине сагындым, юксындым, тилерә яздым. Син мине ташлап киткәннән соң акылдан ычкынам дип торам. Ярый, Изге кыз Мариягә догалар укыдым, ул мине коткарып калды, шөкер. Руи, жаным, син аңламыйсың минем жанымны, мин бит сине һаман сөям...

—Монда кардиналлар килергә тиеш, вакытым тар, зинһар, син чыгып китә күр.

—Руи, Бонифаций, уртак балабыз хакына син мине яныңнан кума.

—Ни дидең, нинди уртак бала?

—Ул сиңа охшаган. Бик тере бала.

—Башың юктыр синең, ничек итеп син никахсыз бала табарга булдың? Бу бит христиан кануннарына сыешмый. Синең никахсыз бала тапканыңны белсәләр һәм ул баланың атасы Бонифаций икәнен сизенсәләр, беләсеңме инквизиция өчебезне дә учакка атачак.

—Ул баланың анасы мин, атасы син икәнен берәү дә белмәс. Мин синең улгың Салазарны...

—Салазар?

—Ие, Руи углы Салазар Кастилия короленең сараенда пажлар мәктәбенә тапшырылды. Беләсеңме, Бони, Салазарның сул кулында синеке шикелле коңгырт миңе бар. Могжиза!

—Зинһар, син балаң хакына ...

—Балабыз хакына!

—Балабыз хакына мине дә, үзеңне дә харап итмә. Син мине харап итәргә килгәнсең, күрәм, мин монда кардиналларны әхлаксызлыклары өчен хөкем итәргә жыенам, син монда килеп, никахсыз туган бала турында сөйлисең, чыгып кит, зинһар, Беат. Мин тәүбә иттем!

—Яхшылап үтен.

—Зинһар, үтенеп, ялварып сорыйм синнән, Беатриса, олы эшне харап итмә. Син женси ихтыяжларыңны канәгатьләндерер өчен теләсә ни эшли аласың, ләкин милләт өчен, христианнар өчен син төзәтә алмаслык хата кылган булырсың.

—Зинһар, кочакла мине...

—Мин тәүбә иттем! Хәзер монда кардиналлар жыелачак, утырыш башланырга тора, минем вакытым юк.

—Кочакла мине, кочаклап үп, аннан китәм.

—Беат!

*(Бонифаций алак-ялак карангалап алды да Беатрисаны кочаклап, үпте.)*

—Бони, баламның атасы, Бонифаций... *(Кат-кат үбә.)*

—Беат, булды, житте...

—Иртәгә, кояш чыгар алдыннан...

—Беатриса, һич була алмый бу эш.

—Килерсенме?

—Беатриса.

—Килерсенме? Вәгъдәнне алмый мин китмим.

—Килермен! Тик соңгы тапкыр!

—Анысын карарбыз!

*Беатриса Бонифацийны кочаклап үпте, кемдер аларның үбешкәнен күреп, кире чигенде. Бу—кардинал-инквизитор Караччо иде.*

Беатриса:

—Рәхмәт! Котәм!—диде дә ашыгып чыгып китте.

*Бонифаций чәчелгән кәгазьләрен җыештырып тиз генә китеп барды. Хезмәтчеләр йөгерешә. Ашчылар, табын карауччылар төпсә тотып чабыша. Шулчак ике кардинал килеп керде. Аларның берсе Ламброзо—сарайның хәзинәдары. Икенчесе—кардинал Караччо—инквизиция эшләре җитәкчесе, трибунал башлыгы.*

Караччо:

—Май кошым минем!—дип янынннан узып баручы чибәр кызның артына сугып калды.—Май кошым! Хөрмә җимешем син минем!

—Бөек Кардиналга җиткерсеннәр тагын!—диде Ламброзо.

—Җиткерми!—диде Караччо.—Хатын-кызга шулай ошый, үзе ачуланган була, үзе сөенә. Бу хатын беркайчан да: кардинал Караччо минем артыма сугып калды, дип Бөек Кардиналга барып әйтмәячәк. Аннан соң Бөекнең үзенең дә... мәгъшукалары бар, диләр. Төн уртасында ике каравыл арасында кара чикмән бөркәнгән ниндидер затлар эчкәрегә кергәлиләр, ди.

—Юкны сөйләмә!—диде дә Ламброзо як-ягына каранып алды.

Караччо да алак-ялак карангалап алды:

—Монах чагында Бонифацийны бер гүзәл сеньорина белән тау араларында еш күргәләгәннәр,—диде.

—Синең турыда да әллә ниләр сөйли монах халкы.

—Минем шәхесемә Папаның үзеннән башка кеше кагыла алмый. Минем вазифаларым чикләнмәгән. Әйттем исә кайттым, әле бая гына менә шушы урында икәү үбешеп тора иде. Берсе Бонифаций, икенчесе яшь монах иде шикелле. Минәйтәм, безнең яңа инквизиторыбыз ике яклы күтләк булып чыга түгелме соң? Ана хатыннар да ярый, ул малайлардан да баш тартмый.

—Син башың галерага—сөргенгә китәрлек сүзләр сөйлисең.

—Ни өчен мин инквизитор итеп куелган монда? Минем шымчыларым, җасусларым, әләкчеләрем җитәрлек.

—Ни йомышың? Хәзер кардиналларның ябык корылтае башлана, тиз бул.

—Кардинал Ламброзо, дустым, акча кирәк, бик тиз кирәк, бик күп кирәк, син казнадан алып, егерме биш мең алтын дукат бирмәссеңме? Диңгез буендагы сараем ярты юлда туктап тора.

—Нинди егерме биш мең алтын дукат сиңа?

—Исемдә, сиңа ике йөз мең көмеш реал бурычым бар, икесен берьюлы түләрмен. Кастилиядәге яһүдләр бай, христиан динен кабул иткән маврлар, яһүдләр кире үз диннәренә кайта башлаганнар. Алардан акча савып була. Гөнаһларын ярлыкаганым өчен мин алардан бурычымны түләрлек мая җыя алам.

—Рәхәт сезнең эш, инквизитор Караччо, шулай булса да акчагыз җитми. Чиркәүдән яшереп калдырган акчаларыгыз кая китә?

—Күп теленә салынып торма инде, әйтерсең лә, син моны белмисең, зинһар...

—Сабыр итеп тор, Караччо, бүгенге җыен узып китсен.

—Бүген җыен булырга тиеш түгел иде, ләбаса. Бу Бонифацийга ни булган?

—Яңа себерке яхшы себерә.

—Яңа дип инде, яңа түгел, икенче елын тәхетендә утыра, ләбаса.

—Ике ел буена ни кылды соң үзе? Һаман кәгазьләргә чумган килеш бүлмәсендә утыра. Кәгазьдән аерылуга биләмәләре буйлап сәфәр чыга. Ни кыла ул анда, эт белсен!

—Чиркәүләрнең, монастырьларның керемнәрен-чыгымнарын тикшерә. Кайсы регион кәгазьләрен карап чыга, шул якка китә. Тырнак астыннан кер эзлиме, әллә башка бер максаты бармы Бонифацийның?

—Уенны, шаяруны аңламый, әллә шулай каты куллы, кырыс, эшлекле бу-

лып күренергә тырышамы?

—Юк-бар белән шөгыльләнгәнче әнә Көнбатыш илләрендәге еретикларның үрчүен тыйсын иде.

—Анысын да тикшерә. Кайда нинди йола бозылган, кем нинди җәза алган, ничә еретик яндырылган, ничәсе асылган, ничәсе галерага аткарылган, ничәсе төрмәдә үлгән... Мин куркам, Караччо. Бик төксе кеше ул. Аның башында безгә карата ниндидер әйбәт булмаган уй бар.

—Иисусе Христосе, шом инде тирәякка. Төннәрен шикле шәүләләр йөри кебек.

—Анысы каравыл алмашынганы гына.

—Каравыл алмашу гына булса икән, Ламброзо. Кемнәрдер төнлә сарайга кереп, озаклап торып, килгәндәге кебек шым гына китеп баралар.

—Булмас! Сарайга кеше түгел, эт тә, җил дә үтә алмас.

—Әгәр алар Бонифацийның махсус рөхсәт кәгазе белән керсәләр? Ишеттеңме соң әле, кичә төнлә минем рөхсәтемнән башка Кастилия епискобы Фернандо Паллос кулга алынган.

—Булмас, Караччо! Ялгышасыңдыр!

—Булган шул инде.

—Хәерлегә генә булсын инде.

*Кардинал Бардини керә, бусы йолаларны саклау буенча Бөек Кардиналның ярдәмчесе. Ул үзен иркен тота, ләкин аның да күңеле тыныч түгел, ахрысы.*

Б а р д и н и *(ашчыларга, табын караучыларга).* Туктатыгыз! Табын мәҗлесе булмый. Барысын да кире алып чыгыгыз. Хәзер монда кардиналлар утырышы башланачак.

А ш ч ы. Җыелыштан соң сый мәҗлесе була торган иде бит.

Б а р д и н и. Әйткәнне тыңла! Кире ташыныгыз!

*Ашчылар, табынчылар тиз генә кире ташыналар.*

К а р а ч ч о *(янында узып баручы яшь кызның тагын артына сугып кала).* Май кошым, зәйтүн җимешем!.. Елга бер мәҗлес узгарамы дип торсам! Тефү! Ничек инде ул яшерен утырыш беткәннән соң табын мәҗлесе булмасын икән?

Б а р д и н и. Кая башкалар?

К а р а ч ч о. Бер елга бер утырыш та булмагач, үшәнләнгәннәрдер.

Б а р д и н и. Елга бер утырыш булмаса, хәзер бөтен булмаган утырышларның утырышын күрерсез.

Л а м б р о з о. Дустым, бөек кардинал Бардини, сер булмаса әйтегезче: бүген кардиналлар утырышының тәртибе нинди, ни турында булачак сөйләшү.

Б а р д и н и. Исәп-хисап тоту булачак!

Л а м б р о з о. Исәп-хисап? Кем каршында? Кем хисап тотачак?

Б а р д и н и. Анысын мин белмим. Бөтен кәгазьләр аның кулында. Ул хәзер монда булачак.

К а р а ч ч о. Син бит Бонифацийның әшнәсе, хәтта туганы да бугай әле.

Б а р д и н и. Юк, без әшнә дә, туган да түгел. Без бары тик сабакташлар гына. Сабый чак дуслары.

Л а м б р о з о. Әйт инде, кардинал Бардини. Ни буласын әйтер булсаң, мин синең алдагы бурычыңны да кичерәм.

*Кардиналлар җыела.*

Б а р д и н и *(яндагы хезмәтчеләргә).* Паланкин!

*Дүрт хезмәтче паланкин күтәреп, Бонифаций чыгасы тарафка чабалар. Бардини чыгып йөгерә. Тантаналы музыка. Бонифаций чыга. Аның ян-якларында—тән сакчылары. Арттарак кәгазьләр салынган букча тоткан сәркәтип йөри.*

Б а р д и н и *(паланкинга утырырга тәкъдим ясый).* Сир, зинһар рәхим итегез!

Б о н и ф а ц и й. Мин күтәрәмгә калганмы?

Б а р д и н и. Йола, сир, борынгы кардиналлардан калган йола.

Б о н и ф а ц и й. Йола түгел, гадәт. Гадәткә кергән гадәт. Христиан йоласы—ул мохтаҗларга игелек кылу, юксылларга ярдәм итү! Алыгыз бу табутны! Картайгач күтәреп йөрерсез мине!

Б а р д и н и. Алыгыз! *(Паланкин китә.)*

*Уңайсыз тынлык. Бөтен кардинал-*

*лар да каушап калган. Бонифаций алдан, бераз арттарак ике сакчы баскычлар буйлап тәхет янына менәләр. Бонифаций утырып тормый. Бөтен кардиналлар да аягүрә баса. Оркестр тантаналы музыка уйный башлый. Кул хәрәкәте белән Бонифаций музыканы өзә.*

Б о н и ф а ц и й. Бүген шатланырга, бәйрәм ясарга хакыбыз юк!.. Еретикларга җәза бирүче трибунал башлыгы кардинал Караччо!

К а р а ч ч о. Тыңлыйм сезне, Бөек Кардинал!

Б о н и ф а ц и й. Әйтегезче, кардинал-инквизитор Караччо, нәрсә ул инквизиция?

К а р а ч ч о. Сир, инквизиция латынь телендәге inquisito сүзеннән, ягъни католиклар чиркәве каршысында барлыкка китерелгән тәшкилат, бу тәшкилатның изге вазифасы: католиклар чиркәвенә каршы җинаятьләрне тикшерү һәм расланган очракта җинаятьчегә каты җәза бирү. Инквизициягә унөченче гасырда Рим Папасы Өченче Иннокентий тарафыннан нигез салынган.

Б о н и ф а ц и й. Бик дөрес, кардинал Караччо! Сез Кастилия епискoпы Фернандо Паллосны яхшы беләсезме?

К а р а ч ч о. Сир, мин аны бик яхшы беләм.

Б о н и ф а ц и й. Ул ниндиерәк епископ, аның эшләре белән кызыксынганыгыз булдымы?

К а р а ч ч о. Ул гадел хөкем йөртә алырлык гадел епископ.

Б о н и ф а ц и й *(сәркәтипкә ымлый, тегесе аның алдына кәгазь чыгарып куя).* Менә озак тикшеренүләрнең нәтиҗәсе, кардинал. *(Укый.)* Кастилия белән Валенсия арасындагы яһүдләр мәхәлләсендә епископ Фернандо Паллос котыртуы буенча яһүдләрне суеш булган. Бу яһүдләрнең маллары, акчалары таланган. Мәхәлләнең яртысы төрмәдә, өч кеше яндырылган, утыз кеше галерага аткарылган.

К а р а ч ч о. Бу гыйсъян, ересь, сир. Фернандо хаклы. Алар сугышны үзләре башлаган.

Б о н и ф а ц и й. Сугышны үзләре башлар өчен яһүдләр Валенсодан Толедога бармагандыр бит. Суеш Валенсода, яһүдләр мәхәлләсендә булган.

К а р а ч ч о. Сир, яһүдләр белән маврларның дине дөрес түгел, аларны тугры дингә, христиан диненә кертү, аларның җаннарын коткарып калу—безнен изге бурычыбыз.

Б о н и ф а ц и й. Әгәр дә алар христиан диненә күчмәсә, сез аларны яндырасыз, малларын чиркәү файдасына аласыз. Чиркәүгә ул акчаларның күбесе килеп җитми, юлда эреп югала. Чукынганнарын исән калдырасыз. Юк-бар хәйлә табып, христианлыкка күчкән яһүд яки маврны "еретик" дип игълан итәсез дә малларын талап, үзләрен утка атасыз. Христиан динен кабул иткән яһүдләрнең, маврларның христиан буларак хәлләре яхшырмый, киресенчә, начарайганнан-начарая бара. Без-христиannar христианнарны кимсетәбез, үтерәбез булып чыга. Якыннарыңны сөй, дигән христиан васыяте бозыла. Христианны үтерүче христианнан да олы мөртәт-еретик юк! Епископ Фернандо Паллос еретик! *(Шаулашып алалар.)* Менә кемне учакта, аутодафеда яндырырга кирәк! Христиан динен кабул иткән булып кыланучы яһүдләр белән маврлар яшеренеп кенә үз диннәрен тота, шулай итеп, кардинал-инквизитор җитәкчелегендә синкретик, ягъни катнаш дин, бозык дин барлыкка килә. Ирексезләп христианлыкка куып кертелгәннәр үз динен катнаштырып католик динен боза, пычрата, эчтән тарката. Менә кайда ята ересь!.. Кардинал-инквизитор Караччо!

К а р а ч ч о. Тыңлыйм, сир.

Б о н и ф а ц и й. Фәкыйрь монахлар ордены турында ишеткәнегез бармы?

К а р а ч ч о. Католик диненең дошманнары, еретиклар, мәҗүсиләргә каршы кырыс көрәш башлар өчен унөченче гасырда төзелгән орден.

Б о н и ф а ц и й. Бу орденның асылын аңлатып бирсәгезче!

К а р а ч ч о. Католик монахына шәхси тормыш кору, өйләнү, сөяркәләр тоту, байлык җыю, женси ләззәтләргә бирелү каттыян тыела. Ул фани дөнья рәхәтләреннән ваз кичәргә, халыкны дөрес дингә өндәргә һәм халык биргән хәергә җан сакларга тиеш.

Б о н и ф а ц и й. Кардинал-инквизитор Караччо, Кастилия короле Беренче Хуан тапшырган мәгълүматка караганда, хәерче монахлар ордены халык-

тан садаканы талау белән шөгыльләнә икән. Шулай итеп, диннен сафлыгын сакларга алынган монахлар динне пычрата. Пычратылган дингә чын күңелдән инану кими. Кастилия, Арагон, Валенсия илләрендә Папага каршы, явыз монахларга каршы баш күтәрүләр ешая бара. Шулай итеп, католиклык зәгыйфьләнәчәк. Католиклык зәгыйфьләнсә, дөньяны Ислам басачак! Хәер, Ислам безгә ул кадәр үк куркыныч түгел, католик диненең бозылуы безгә куркынычрак. Утырыштагы, ягъни кардиналлар корылтаендагы вето куллану мөмкинлегеннән чыгып, мин—Бөек Кардинал Бонифаций кардинал-инквизитор Караччоны ересь таратуда һәм сыныкка сылтау табып, гаепсезләрне утка ташлауда, рәхимсез җәзалауда гаепләп, кулга алырга, инквизиторга инквизиция узгарырга боерам. *(Хәрәкәт ясый, ике сакчы Каррачоны кулга ала.)*

К а р а ч ч о. Сир, бер генә кешене дә гаепсезгә утка атмадым. Аларның гөнаһлары исбатланган. Әнә, беркетмәләрне карагыз! Алар үз телләре белән ересьларын расладылар.

Б о н и ф а ц и й. Аягыңны-кулыңны шайтан тәгәрмәченә бәйләп каерып, чыбык белән мең тапкыр сугып, җәрәхәтләренә сидек белән тоз катнашмасы буталган агу сөртеп, тагын йөз чыбык суктырсалар, син дә "мин еретик" дип кычкырыр идең. Һәм сез чыннан да еретик.

К а р а ч ч о. Юк, сир, мин еретик түгел, мин инквизициягә тугры хезмәт итүче кардинал.

Б о н и ф а ц и й. Сез бүгеннән кардинал түгел, сез еретик.

К а р а ч ч о. Кардиналлыктан алыгыз, ләкин мин еретик түгел, түгел!

Б о н и ф а ц и й. Шайтан тәгәрмәчендә әйләндерегез! Борган саен: син шайтаннар белән аралашасыңмы, син сихерчеме, син еретикмы? дип сорагыз. Ничә әйләндерүгә түзәр икән кардинал—инквизитор.

К а р а ч ч о. Мина ни була! Сез мине нишләтәсез?

Б о н и ф а ц и й. Еретикларны нишләткән булсагыз, сезне дә шул хөкем көтә. Алыгыз!

*Караччоны алып чыгып китәләр.*

Б о н и ф а ц и й *(ерактан тоныкына акырган тавышлар ишетелә, бәрысы да куырылып килә.)* Тыңлагыз, сез музыка яратасыз бит, тыңлагыз еретикның ничек акырганын!.. Икенче тапкыр борыгыз! Караччо, син еретикмы? *(Акырган тавыш.)* Әйт, мин Иблискә җанымны саттым, мин халыкны таладым, мин еретик, диген. Өченче тапкыр борыгыз. *(Мин еретик, дигән өн ишетелә. Караччоны алып керәләр, аның киеме теткәләнеп беткән, бите-башы канга буялган, ул көчкә аягында басып тора.)* Кабатла!

К а р а ч ч о. Сир, мин Иблискә җанымны саттым, мин халыкны таладым, мин еретик!

Б о н и ф а ц и й. Гаебе исбатланды, ул үз теле белән еретик икәнен әйтте. Языгыз, кул куйдырыгыз! *(Кәгазь белән мәшгульлек.)*

*Кардиналлар арасында чышы-пышы:*

—Коточкыч!

—Ул Иблискә җанын саткан?

—Ул халыкны талаган...

К а р а ч ч о *(кәгазьгә кул куя, җылый, ярым шашкан кыяфәттә).* Мин еретик, мин җанымны Иблискә саттым, мин еретик...

Б о н и ф а ц и й. Элеккеге кардиналинквизиторның бөтен малы чиркәүгә күчерелсен! Зинданга ябыгыз! *(Караччоны алып китәләр. Шомлы тынлык.)* Аум мани падме һум! Епископларның, кардиналларның шәһәр саен алтынлап, асылташлар белән бизәлгән сарайлары нинди акчага салынган? *(Шомлы тынлык.)* Чиркәүләрнең казна акчасы эшләре буенча кардинал Ламброзоны тыңлап багыйк!.. Кардинал Ламброзо! Кайда ул? *(Кардиналлар икегә аерыла, уртада бавыр ягын тоткан Ламброзо иелеп басып тора, ул үзенә үзе пычак калаган. Ламброзо егыла.)* Аум мани падме һум! Монысы мәсьәләне ансат хәл итте! Алыгыз! *(Ламброзоның гәүдәсен алып чыгып китәләр. Кардиналлар арасында курку да, ризасызлык та сизелә.)* Аптырамагыз, кардиналлар! Мин вето ысулы белән эш башларга булдым. Әлбәттә, бу вакытлыча гына, католик илләрендә тәртип урнашканнан соң без янадан яшерен тавыш бирү юлы белән кардиналлар сайларбыз... Шушы ике вакыйга сезнең күбегезгә гыйбрәт булыр! *(Ишарә ясый, сәркәтип хаттатларга әмер бирә,*

*бернччә хаттат әйткәннәрне язарга әзерләнә.)* Мин, Бөек Кардинал Бонифаций, шундый фәрман чыгарам. Элеккеге инквизитор Караччо урынына кардинал Бардини билгеләнә, элеккеге акча эшләре канцлеры кардинал Ломброзо урынына кардинал Ланферо билгеләнә. Кардиналлар, мин һәркайсыгызның нинди хисапка сарай салдырганын да, яшерен эшләрегезне дә беләм, исемнәрегезне атамыйча гына, әйтәмен ки: *(хаттатлар яза.)* еллар буе казнадан алган акчаларны, ике ай эчендә казнага кире кайтарырга. Христосыбызның бер ябынчасыннан башка һичнәрсәсе дә булмаган! Остазыбыздан үрнәк алыйк. Шартлар үтәлмәгән очракта дәрәҗәләрегез, вазифаларыгыз өстегездән алына, малларыгыз чиркәү файдасына конфискацияләнә! Кардиналлар җыены тәмам, ике айдан соң икенче утырышка җыелырбыз!

*Бонифаций сакчылар һәм бернччә кардиналы белән бергә чыгып китә. Калган кардиналлар тарала.*

## Астыртын эшләр

*Резиденциянең матур бакчасы.*

*Кардиналлар утырышлар залыннан йөренергә чыккан. Аерым-аерым төркемнәрдә сөйләшәләр.*

**Беренче төркем** *(болар арасында Бардини да бар).*

Беренче кардинал. Шәп булды бу утырыш!

Икенче кардинал. Кардиналлар утырышыннан ач килеш таралган юк иде.

Бардини. Кардиналлар утырышында үзен-үзе үтергән кардиналның да булганы юк иде.

**Икенче төркем.**

Альварес. Болай булгач, безгә тормыш бетте! Нишлибез?

Дүртенче кардинал. Йортлардан колак кагабыз бит, нинди Иблис булды соң бу Бонифаций?

Бишенче кардинал. Гап-гади кардинал гына булып утырганда тавышы-тыны чыкмый иде.

Альварес. Мин дә Бонифаций тәхеткә утыргач, эшләргә тыкшынмыйча, рәхәт чигәр, дигән идем.

Дүртенче. Әйттем мин сезгә, сайлаганда әйттем, тымызык күлдә корт уйный, сайламыйк аны, дидем. Күрдегезме?

Бишенче. Юаштан юан чыгар!

**Өченче төркем.**

Алтынчы. Нишлибез, өстә кара болытлар куера!

Җиденче. Койрыклы йоллыз килә!

Сигезенче. Мин бар малымны алтынга әйләндерәм дә, чит илгә качам.

Алтынчы. Бөек Инквизиторның кулы чит илләргә дә җитә, дустым.

Җиденче. Нишләргә соң?

**Икенче төркем.**

Альварес. Харап итә бу безне мир каршында!

Дүртенче. Харап итте инде!

Бишенче. Нишләргә соң?

Альварес. Бер кардинал үзен үзе үтерде, ике кардинал зинданда ята.

Дүртенче. Йортларны, малларны кайтармасак, барыбызны да шул язмыш көтә.

**Беренче төркем.**

Беренче. Күптән кирәк иде бу фахешлекне җавапка тарту.

Икенче. Авыр эшкә алынды Бонифаций.

Бардини. Без аңа таяныч булырга тиеш!

Беренче. Ант эчик! Бонифацийны ташламаска!

Өчесе дә. Ант!

Икенче. Кайтырга вакыт, малларыбызны санарбыз, акчаларыбызны тойнәрбез. *(Беренче төркем китә, алар белән Бардини да китә.)*

*Калган ике төркем бергә кушыла. Яшерен сөйләшү.*

Альварес. Бөек Кардиналның куштаннары китте.

Дүртенче. Хәерче монахлар!

Бишенче. Шулай, кардиналлар, койрыкка ут төрттеләр.

Алтынчы. Бардинидан сак булыгыз, ул аның балачак дусты!

Жиденче. Бардини беркая да баралмый ул. Аны аударырга була.

Сигезенче. Нишләргә соң? Нишләргә? Ярдәм сорап, кемгә барырга?

Альварес. Нишләргә икәнен мин беләм!

Дүртенче. Ничек? Нәрсә?

Альварес. Башта уй бар. Ләкин ул мажараны башкарып чыгар өчен байтак акча кирәк.

Бишенче. Күпме?

Альварес. Күп! Дүрт йөз мең алтын дукат!

Барсыда. Иисусе! Шул кадәр акчамы?

Алтынчы. Жыешырбыз!

Жиденче. Изге эш өчен кызганмабыз!

Альварес. Әйдәгез!

*Ашыгып китәләр.*

## Алмашыныш

*Тау араларындагы шомлы тарлавык. Ян-якларда кыя-ташлар. Бу—фетнәчеләр ыстаны. Дүртенче, Бишенче, Сигезенче кардиналлар күренә, алар юл киемнәреннән, барысы да коралды.*

Дүртенче. Мүкле кыя шушы булыр. Жайлашыгыз. *(Дүртенчедән башкалары жиргә келәм жәеп, дәстархан кору белән мәшгуль.)*

Бишенче. Табын әзер, капкалап алыгыз.

Сигезенче. Бу бик уңай урын. Монда ике карета сыя алмый. Алга сакчылар узып китә. Карета борылмада арттагы сакчылар күзеннән югалып тора. Шул вакытта карета алдындагы ике сакчыны, арттагы ике сакчының тиз генә эшен бетереп, алар урынына үзебезнекеләрне куеп өлгерергә, Бонифацийны йолкып алып, монда урман арасына алып кереп авызын томаларга, Педроны каретага утыртып өлгерергә кирәк. Кучер үзебезнеке.

Дүртенче. Барысы да яхшы уйланылган.

Бишенче. Иисусе Христосе, ярдәм ит!

Дүртенче. Тсс! Күке кычкыра.

Бишенче. Нәкъ вакытында.

Сигезнче. Ике, биш... *(Биш тапкыр күке булып кычкыра).*

*Кыялар арасыннан дүрт кеше чыга. Болар киемнәрен үзгәрткән кардиналлар: Альварес, Алтынчы, Жиденче, урталарында Педро Бургос.*

Альварес. Эшегез уңышлы булсын!

Бишенче. Шулай булсын! Сезнең дә эш унган, күрәм.

Альварес. Менә, каршыгызда Аскалонның башкисәр юлбасары, Педро Бургос!

Педроны богаулардан азат итәләр. Ул Бонифацийга тач охшаш кеше.

Альварес. Бу кавалер, бөтен Урта диңгез көймәләрен, кәрван юлларын ун ел үз кулында тоткан атаклы юлбасар Педро Бургос булыр.

Бишенче. Ишеткән бар.

Альварес. Педродан да бай кеше соңгы биш-алты ел эчендә дөньяда юк иде. Ләкин бер рәхәтнең бер михнәте була бит аның. Ике тапкыр гомерлеккә хөкем ителеп, ике тапкыр үлемнән качкан, өченчесендә тагын үлем жәзасына хөкем ителгән, шөһрәт иясе Педро Бургосны мин сездән жыйган алтын дукатларга сатып алдым. Акчаң булса, әҗәл белән дә килешергә була. Төрмәгә кереп: йә, Бургос, сайла, дим: йә учакта яну, дим яки Бөек Кардинал тәхетендә байлыкка чумып яшәү, дим.

Педро. Ярый, кавалерлар, мин риза, ләкин ялган ачыла калса, миңа котылу булмаячак. Инквизиция бу юлы мине кичермәс.

Альварес *(кычкырып көлә дә Педроның аркасына каты итеп сугып*

*ала).* Дивана! Инквизиция синең кулда була бит. Без бит инде ул инквизиция. Синең эшең ашау-эчү. Кардиналлар җыенында тәхеттә утыру. Без сине бар җыелышларга да әзерләп кертербез, кирәксә, синең янда гына ике ышанычлы кинәшчең утырыр.

Алтынчы. Бүген эш унышлы чыкса.

Альварес. Унышлы чыгар, нигә шикләнәсез? Барысы да төгәл уйланылган.

Алтынчы. Унышлы чыккач, син, Педро, кардиналларның корылтаен җыясың... Син үз авызыңнан фәрманны укып чык, анда язылган ике ай эчендә сигез миллион алтын мараведи акчаны чиркәү сандыгына кайтарырга, диелгән. Акчаны кабул итәрсең. Ләкин ул акчаны син түгел, акча эшләре кардиналы үзенә алыр. Шуннан соң әкренләп-әкренләп ул акчаларны ияләренә кайтара барыр. Син хәзер Педро Бургос түгел, син Бөек Инквизитор Бонифаций!

Педро. Мин сарайдан чыгып йөри аламмы?

Алтынчы. Юк! Чыккан очракта да каты сак астында булачаксың. Сине башка кешеләрнең күрмәве хәерле.

Педро. Хатын-кыз мәсьәләсе ничегрәк булыр икән?

Алтынчы. Бу эш тә унай хәл ителәчәк. Барысы да безнең кулда.

Альварес. Барысы да сезнең кулда, сир Бөек Кардинал Бонифаций.

Бишенче. Бонифацийны киендерегез!

*Педро, Җиденче, Өченче куаклар арасына кереп китә.*

Алтынчы. Син иң хәтәр юлбасарлардан да бай яшәячәксең!

Бишенче. Валлаhи, аерып алгысыз охшашлык.

Алтынчы. Бонифацийга охшаган булсам, мин үзем ялган Бонифаций булыр идем. Уйлыйсы юк, эшлисе юк, бары тик ашау-эчү, хатыннар белән ләззәт кичү. Җәннәт! Бу җәннәтне үлемгә алыштыраламмыни!

*Бераздан Бонифаций киемендә Педро, Җиденче, Альварес чыга. Барысы да сокланып юлбасарга багалар.*

Альварес. Шаккаткыч! Коткаручыбыз син безнең.

Алтынчы. Бонинның үзеннән дә чынрак син, Педро.

Педро. Кардиналлар утырышында мин нинди телдә сөйләргә тиеш булам инде.

Алтынчы. О! Бик әһәмиятле форсат! Син нинди телләр беләсең соң?

Педро. Гарәпчә, төрекчә, итальянча, французча...

Алтынчы. Латынь?

Педро. Юк!

Алтынчы. Ярый, шушылары житкән. Утырышны итальянча, французча алып барырсың. Фәрманнарны без латынь белән үзебез язырбыз. Син имза гына салырсың.

Педро. Берәрсе шикләнә калса?

Алтынчы. Берни булмагандай күзенә туры кара, синең караштан шикләнгән кешенең шиге ыштан төбенә китәрлек булсын! Калганын үзебез рәтләрбез.

Дүртенче. Тсс! Күке кычкыра! Ике, биш, алты. *(Җавап бирә: алты тапкыр кычкыра.)*

Алтынчы. Урыннарыгызга! Педро, тефү лә, Бонифаций!

Педро. Тынлыйм, кардинал.

Алтынчы. Карета бушауга ук сикереп мен, калганы безнең эш! Карета әнә тегендә туктый. Син агач артына поскан җиреннән ишеккә чум! Аңладыңмы?

*Барысы да яшеренә.*

*Еракта карета тыкырдаганы, ат тояклары тавышы ишетелә. Бераздан ат кешнәгән тавышлар. Кучерның атларга кычкырган авазлары ишетелә.*

*Алгы сакчылар узып китә. Карета бер мизгелгә генә сакчыларсыз кала. Арткы сакчылар әле борылмада күренми.*

*Поскан юлбасарлар каретага һөҗүм итә. Чын Бонифацийны каретадан сөйрәп алалар да аннан бушаган урынга Педро Бургос сикереп менә. Кайнаш, буталыш. Ат кузгалган тавыш. Бонифацийны әсир алган Альварес, Бишенче керә. Бонифацийның авызы томаланган. Ул тартыша.*

Альварес. Тсс! Тынычлан, Педро Бургос!

*Атлар пошкыра-пошкыра, кешеләр сөйләшә-сөйләшә узып китә. Альварес кардинал Бонифацийның авызын чишә.*

Б о н и ф а ц и й. Каравыл! Кардинал Оранский? Каравыл!

*Альварес аның башына суга, Бонифаций аңын югалта.*

Б и ш е н ч е *(әйләнә-тирәне карап килә).* Исусе Христосе! Барысы да майлаган кебек килеп чыкты! Тарлавыкны чыгып киттеләр, тауга меңәләр.

А л ь в а р е с. Кардинал Оранский жирена житкезә белә ул! Кадеремне белегез!

Б о н и ф а ц и й *(аңына килә).* Ә? Мин кайда?

А л ь в а р е с. Син ышанычлы кулларда, сир.

Б о н и ф а ц и й. Кардинал Альварес Оранский...

Б и ш е н ч е. Менә хәзер кардиналларның сарайларын конфисковать итәргә фәрманыңны яз инде.

Б о н и ф а ц и й. Сез хыянәтчеләр, сез еретиклар! Сез моның өчен җавап тотарсыз!

А л ь в а р е с. Син бит Бөек Кардинал түгел.

Б о н и ф а ц и й. Кардинал Оранский! Бөек Кардинал булмый, мин кем булыйм, сез үзегез мине гомерлеккә сайлап куйдыгыз.

Б и ш е н ч е. Хәзер син ата баш-кисәр, юлбасар, харами Педро Бургос!

А л ь в а р е с. Бөек Кардинал алмашынды, Бонифаций тарлавыкны узып, Валенсия юлына төште. Ул анда эпископлар белән жыелыш узгарачак. Анда тәртип урнаштырачак.

Б о н и ф а ц и й. Ычкындырыгыз мине.

А л ь в а р е с. Син хәзер ычкына алмассың инде, юлбасар Педро Бургос. Без сине дүрт йөз мең алтын дукатка үлемнән сатып алдык. Син бездән талап аласы байлык бәрабәренә өч йөз-дүрт йөз мең алтын дукат безгә чүп кенә ул.

Б о н и ф а ц и й. Халык бар, еретик Оранский! Туганнарым минем урында башка утырганын тиз аңлаячак. Башыгыз икеме сезнең?

А л ь в а р е с. Барысы да уйланылган. Юлбасар Педро французча да, итальянча да, гарәпчә дә, төрекчә дә белә, латыньны өйрәтербез. Синең узган юлыңны да аңа ятлатырбыз. Ялгыш булмас!

Б и ш е н ч е. Без сине иреккә җибәрсәк, сине төрмәдән качкан Педро, дип тотачаклар да дарга асачаклар яки яндырачаклар. Сез ике тамчы кебек охшаш.

А л ь в а р е с. Иң яхшысы сине хәзер юк итү. Сайла! Кайсысы сиңа унайрак?

*Куаклар арасыннан Бонифаций янындагы сакчыларның берсе кача-поса килеп чыга. Ул хәнҗәрен Альвареска томыра. Альварес тавышсыз гына егыла. Бишенче нидер сизенеп артына борыла, сакчы белән күзгә күз очраша. Сакчы егылган Алвареснын кылычын тартып ала, сугыш башлана. Сакчы Бишенчегә кадый. Бишенче егыла. Сакчы Бонифацийны богаулардан азат итә.*

С а к ч ы. Сир, тизрәк моннан китик. Анда ике ат тора. Тиз булыйк.

Б о н и ф а ц и й. Гыйсъян, Бөек Инквизиторга каршы кардиналларның фетнәсе!

С а к ч ы. Тиз булыгыз, сир. Яхшы чакта качыйк.

Китәләр. Ат тоягы тавышлары ерагая. Ике кардинал кер. Алар мондагы мәхшәрне күреп шакката.

А л т ы н ч ы. Иблис! Бонифаций кардиналларны үтереп качкан.

Ж и д е н ч е. Куа чыгарга кирәк.

А л т ы н ч ы. Әгәр дә Бонифаций исән калса, куркыныч түгел. Мин—Бөек Инквизитор, дисә, аны, акылдан язган дип, тотып яндырачаклар. Төкер башына. Аны төрмәдән качкан Педро Бургос дип кулга алачаклар, аутодафедә аның башы бетәчәк.

## Җәза мәйданында булган хәл

*Берничә елдан соң Кастилиядә булды бу хәл, король сарае каршындагы мәйданда. Музыка, җыр-бию, урам тулы халык бәйрәм итә. Хөллә чабуын эт талаган* К а р а

*д ә р в и ш күренә. Бу—Бонифаций. Ул таякка таянган. Бер кулы юк, җиңе билбавына кыстырылган. Күрәсең, ул ерактан килә. Аннан бераз арттарак, Сакчы йөри, аның сыртында биштәр.*

К а р а д ә р в и ш. Аум мани падме һум! Килеп җиттек бугай. *(Сакчы капчыгын кочаклап бер кырга утыра.)*

*Баштан-аяк бөркәнгән бер хатын керә. Бу—Беатриса. Ул сөртенеп китә. Карадәрвиш аны терсәгеннән тотып кала. Беатрисаның хәле мөшкел. Ул аңын югалтыр дәрәҗәдә авыру.*

К а р а д ә р в и ш. Сак булыгыз, сеньорита.

Б е а т р и с а. Сеньора.

К а р а д ә р в и ш. Гафу итегез, сеньора. *(Хатынны бер кырга алып килеп яткыза.)* Менә шулай, сеньора.

Б е а т р и с а. Су! Тамак яна.

К а р а д ә р в и ш *(Сакчыга ымлый. Сакчы биштәреннән турсык чыгарып, хатын иренenә су тамыза).* Хәзер хәл керер. Син, бичара да король Хуаннан яклау эзләп йөрисеңме?

Б е а т р и с а. Руи? Бонифаций!

К а р а д ә р в и ш. Беатриса!

Б е а т р и с а. Руи!

К а р а д ә р в и ш. Тсс!

Б е а т р и с а. Аңлыйм! Син инкогнито! Син карадәрвиш кыяфәтендә биләмәләреңдәге тәртипне тикшереп йөрисең! Браво, Бони.

К а р а д ә р в и ш. Тсс!

Б е а т р и с а. Мин сине шундый сагындым, сине күрмәгәнемә тугыз ай тулып килә. Менә мондагы Бонифацийга да тугыз ай тула.

К а р д ә р в и ш. Ничек? Йа, Аллам, син ни сөйлисең? Без яшерен күрешкәннән соң күпме сулар акты, ничә еллар узды.

Б е а т р и с а. Аңлыйм, яшерен сер! Мин ике тапкыр гына яшеренеп, каравылларны алдап, синең янга кердем. Таулы урман аланында очрашырга вәгъдә иттең дә килмәдең. Аннан соң мин синең янга тагын качып кердем. Ләкин син бу юлы тупас кыландың. Син үзеңә охшамаган идең. Тавышың да, кыяфәтең дә шул ук, элеккеге Бонифаций, ләкин син нык үзгәргән идең. Бәлки син авырып киткән булгансыңдыр. Иярдән егылып, Бөек Инквизиторның зиһененә зыян килгән, ул вакыт-вакыт хәтерен югалта, дигәннәр иде.

К а р а д ә р в и ш. Аңлашылды, Беатриса! Синең карыныңда Бонифаций баласы түгел, карак, юлбасар Педро Бургосның баласы кыймылдый.

Б е а т р и с е. Кем баласы?

К а р а д ә р в и ш. Антихрист баласы!

Б е а т р и с а. Саташкансың син, Руи! Синең сул кулың кая китте? Тугыз ай элек кенә син ике куллы идең бит.

К а р а д ә р в и ш. Ялган Бонифаций белән ятакта аунаганда игътибар итмәдеңмени? Кабәхәт Педроның сул беләгендә миңе юк. Син бит минем сул кулымдагы көрән миңне назлап сыйпый идең, бу—бәхет миңе, дип әйтә торган идең.

Б е а т р и с а. Изге Мария! Синең сул кулың ак чүпрәк белән бәйләнгән иде. Нигә кулың бәйләүле дигәч, син әйттең: янгын чыкты да, шунда беләгем янды, диден.

К а р а д ә р в и ш. Мин әйтмәдем. Ул сүзләрне сиңа Ялган Бонифаций, башкисәр Педро Бургос әйткән.

Б е а т р и с а. Димәк, тәхеттә син түгел, сиңа охшаш җинаятьче утыра. Ул Бонифаций исеменнән фәрманнар яза. Салымнарны тагын да арттыра. Рәхимсез рәвештә гаепсезләрне утка ташлаттыра. Халык арасында имеш-мимеш йөри. Бонифаций гаделлек өчен көрәш башлады да, үзе рәхимсез түрәгә әверелде, имеш, син башың белән аттан егылып, шулай кинәт үзгәргәнсең, диделәр. Димәк, минем карында шул кабәхәтнең токымы ята. Үтерәм мин аны туута ук.

К а р д ә р в и ш. Кешенең җанын кеше кыярга тиеш түгел!

Б е а т р и с а. Ул кеше түгел! Ул—Иблис! Синең улыңны бер герцог аша король сараендагы пажлар мәктәбенә урнаштырдым. Сиздерми генә мин аны читтән генә күзәтәм. Гаҗәеп матур, акыллы углан үсеп килә. Аның исеме Салазар. Ләкин ул атасының Бонифаций, анасының Беатриса икәнен белми. Салазарның да сул беләгендә нәкъ синеке кебек миңе бар. Синең сул кулың кая китте?

К а р а д ә р в и ш. Педроның Ялган

Бонифаций икәнен исбат итә торган миң булганга күрә, аны чабып ташладылар.

*Бәйрәм итүчеләр Карадәрвишне урап алалар, аны уенга чакыралар, Беатрисадан читкә алып китәләр, бииләр. Карадәрвиш бәйрәм күтеп йөрүче Рамиро янына килә.*

К а р а д ә р в и ш. Нинди бәйрәм бүген? Нигә шатланасыз?

Р а м и р о. Бәйрәм бүген, мәйдан уртасында—аутодафеда еретикларны яндырачаклар.

К а р а д ә р в и ш. Ни өчен яндыралар? Аларның гаебе нидә?

Р а м и р о. Алар Бонифацийга тел тидергән.

К а р а д ә р в и ш. Бонифацига тел тидергән? Ничек?

Р а м и р о. Бөек Кардинал Бонифаций да, аның кардиналлары да—барысы да үзләре еретик, үзләре бозык, үзләре карак, дигәннәр.

К а р а д ә р в и ш *(үзалдына)*. Дөрес әйткәннәр ич! Бонифаций үзе карак! Башка Кардиналлар кешеләрнең акчаларын, җаннарын гына талый иде. Бу Бөек Кардинал кешенең исемен дә урлаган карак! Аум мани падме һум! Койрыклы йолдыз ажгырып килә җир өстенә. Афәт килә, ә сез кеше яндырганга куанасыз! Чума мурыннан Кытай ягында ундүрт миллион кеше кырылды. Шул яклардан килмешем. Калалар тулы өем-өем мәетләр, хайван үләксәләре аунап ята. Төрк-татар далалары тулы филләр, дөяләр, атлар, ишәк, кеше мәетләре күмелмәгән килеш ауный. *(Тиләләрчә көлә.)* Ха-ха-ха... Койрыклы йолдыз алып килгән афәтләр безнең өчен, христианнар өчен файда. Кытаенда меңләгән буддачылар кырылышып ята, Дәшти Кыпчак далаларында бихисап татар мәетләре ауный. Африкасында мавврларны—мөселманнарны мур кыра. Ха-ха-ха... Чума мурыннан котылыш бар. Ә менә мөселманнарның яулап алуларыннан котылыш юк. Чума мурыннан да, Койрыклы йолдыз афәтеннән дә, мөселманнарның яуыннан да хәтәррәк куркыныч бар—анысы төрекләр—татарлар афәте.

*Дөнья карангылана. Гөрелте ишетелә. Дөнья кинәт яктыра. Чалтыратып яшен суга. Күкләр күкри. Тагын карангылык. Сарайдан Канцлер белән ике сакчы чыга. Яктыра.*

К а н ц л е р. Йа, Иисусе Христосе! Бу гарасат илебезгә әҗәл алып килде. Сөекле королебез Хуан Беренченен йөрәге тибүдән туктады!

К а р а д ә р в и ш. Аум мани падме һум! Король Хуан вафат булдымыни? Ә мин аннан яклау сорап, ярдәм эстәп аны күрергә килгән идем. Йа, Христос, яклаучысыз калдым! Соңгы өметемнән, коткаручымнан мәхрүм калдым... *(Үкереп җылый.)*

К а н ц л е р. Бар, дәрвиш, халыкка җиткер, король Хуан вафат булды, диген. *(Сарайга кереп китә.)*

Б е а т р и с а. Изге Мария! Король Хуан вафат! Кем мине яклар. Уйнаштан туган баланы анасы белән бергә яндырачаклар бит.

К а р а д ә р в и ш. Король Хуан Беренченең җаны күккә-гарешкә очты китте. Корольләр арасыннан иң миһербанлысы, гадел хөкемдар Хуан, халык вәкилләренә сараенда урын биргән, бозык монахлардан динне сафландырырга алынган королебез вафат булды! Җылагыз! Кастилия гадел хөкемдардан мәхрүм калды! Җылагыз!

*Халык үкереп җылый.*

Р а м и р о. Король үлде! Синнән башка ни кылырбыз, Гадел Хуан?

И к е н ч е. Кемгә ташлап киттең безне, король Хуан?

Р а м и р о. Аның урынына кем булыр король?

И к е н ч е. Хуанның ир баласы калмады.

Р а м и р о. Королеваны тулгак тота, диләр.

И к е н ч е. Королева кемне табар? Тәхет варисымы, әллә кыз баламы пәйда булыр?

К а р а д ә р в и ш. Койрыклы йолдыз килгән елны бер изге кеше вафат булыр, дигән. Димәк, ул изге кеше король Хуан Беренче булып чыга! Димәк, быел дөньяга рәхимсез шәхес туачак? Йа, Иисусе! Кем булыр ул?

*Дөньяны тагын да каты гөрелте каплый. Шул гөрелтеләр арасында, җан*

*өшеткеч аваз янгырый, хатын-кызнын әче кычкырганы, яна туган бала тавышы ишетелә. Беатриса да кычкыра. Анын ягында да яна туган бала тавышы. Гөрелте тына. Бала жылый. Рамиронын хатыны Жозефина белән Карадәрвиш Беатриса янында чуала.*

Ж о з е ф и н а. Синьора, улын бар!

Б е а т р и с а. Бәхетсез бала! Ана Балтазар дип исем кушарсыз!

К а р а д ә р в и ш. Аум мани падме һум! Йа Илаһем, Койрыклы йолдыз узганда туган балалар бәхет ияртеп киләме дөньяга? Әллә афәткәме безне батырачак?

К а н ц л е р *(сарайдан чыга).* Бөек Кастилиянен башкаласы Толедода, король Хуан Беренче сараенда бердәнбер угыл, тәхет варисы дөньяга килде. Сөенегез! Дәрвиш, шатлыклы хәбәр сал халыкка!

К а р а д ә р в и ш. Аум мани падме һум! *(Шашкын кыяфәттә.)* Менә ул мессия! Менә кем коткарыр безне татар-мөселман мурыннан! Безне генә түгел, бөтен Ауропаны афәтләрдән коткарыр! Үтерелмәс өчен ул дошманын үтерер! Димәк, изге урынына изге килде! Изге һәм миһербанлы, гонаһсыз кыз—Мариянен галел хөкеме булсын! Аме-ен! Аллабызнын бөек данына күрә, ул дөньяга килде. Король үлде, король туды! *(Шашып чукына. Халык та чукына.)*

Р а м и р о. Король үлде! Жылыйбыз! *(Жылыйлар.)*

И к е н ч е. Король туды! Куанабыз! *(Артык шатланып кычкыралар.)*

Р а м и р о. Король үлде! Яшәсен король!

К а н ц л е р. Һәй, гавам! Һәй, сеньорлар, кабальерлар, һәй, рыцарьлар, мирасчы Һәнрих Өченченен дөньяга килүе шатлыгыннан бәйрәм башлана.

Ө ч е н ч е. Теге бичара хатынны ни өчен асмакчылар?

Р а м и р о. Ул хатын сихерче икән, ул хатын шайтаннар белән дуслашкан икән.

И к е н ч е. Анын шайтаннар белән дуслашканын кем күргән соң?

Р а м и р о. Ул үзе күршесенә сөйләгән. Имеш, абзарга керсә, абзар почмагында шайтан утыра икән. Хатын атылып, кычкырып урамга йөгереп чыккан да, абзарда шайтан утыра, дигән. Авыл кешеләре сәнәкләр белән абзарга кергән. Анда кәжә тәкәсе басып тора, ди. Кешеләр кәжә тәкәсен урамга алып чыгып, кыйнап үтергәннләр. Кәжәнен хужасы: ул нишләп шайтан булсын, безнен кәжә бит ул, дип караган, кызган халык аны тынлап тормаган. Хатынны кәжә үләксәсе белән монда алып килгәннләр, кәжәне яндыралар, хатынны асалар, ди.

*Шатлыклы музыка. Халык бәбәй туен бәйрәм итә. Бер почмакта Беатрисанын баласы жылый.*

К а р а д ә р в и ш. Беатриса, бар син кач, кит бу тирәдән. Баланны мин чиркәү ишеге төбенә куярмын. Юкса, сине инквизиция кулга алачак.

Б е а т р и с а. Үтер син аны! Юкса, мин үзем анын авызын томалыйм! Үтермәсән, ана Балтазар исеме куштыр!

*Беатриса иләс-миләс атлап чыгып китә. Шау-шу. Карадәрвиш биләү тотып, ни кылырга белми, йөренә.*

К а р а д ә р в и ш *(узып баручы монахка).* Падре, менә монда берсе бала ташлап киткән.

М о н а х. Гонаһка батып гарык булды дөнья. Анын анасы кем? Бу баланы кем уйнаштан тапты?

К а р а д ә р в и ш. Падре, зинһар, алыгыз бу жан иясен. Менә монда язуы бар.

М о н а х *(укый).* "Мин бу баланы гонаһлы уйнаштан таптым. Теләсәгез, аны утка атыгыз, теләсәгез алып тәрбия кылыгыз, баланын исеме Балтазар булыр..." Ярый, без ул уйнашчынын кем икәнен тиз белербез. *(Биләүле баланы алып китә.)*

К а р а д ә р в и ш. Балтазар! *(Көлә.)* Балтазар! *(Шомлы тавыш илә).* Койрыклы йолдыз Жиргә тияр-тимәс узып китте. Шөкер! *(Серле хәрәкәтләр ясап йөренә.)* Күрәзәчеләр, йолдызларга багучылар хәбәр итте: Исус Христос туганнан сон мен өч йөз житмеш сигез ел узгач, Кояш Аждаһа йолдызлыгында чакта, Койрыклы йолдыз узып киткәндә, христиан шәһәрендә бер ир олан—варис дөньяга киләчәк. *(Артык куаныч илә.)* Илаһи Мария исеме белән ант итәмен ки, бу шул ир бала! Христи-

ан дөньясының бөек каһарманы, Испания короле Һәнрих Өченче дөньяга аваз салды. Аум мани падме һум! *(Шомлана.)* Өченче мур килә мир өстенә. Монысы алдагыларыннан да хәтәррәк булырга ошый. Бу мур—католиклар китерәчәк мур. Имәнгеч бер сафсата: диннең сафлыгын сакларга алынган бөтен диннәргә дин—католиклар христиан дөньясына мөселманнардан да арттырып зыян салачак. *(Шашып үкерә. Саташа башлаган Беатриса чыга. Анын чәче тузган, киемнәренең рәте юк.)*

Б е а т р и с а. Койрыклы йолдыз узып барганда туган ир бала бәла була дигәнме? Кешеләр! Койрыклы йолдыз узганда туган ир бала бәла алып килерме, юкмы, әмма ул баланың атасы Бонифаций урынында утыручы ата карак, төрмәдән качкан башкисәр, юлбасар халыкка күп зыяннар салачак әле. *(Халык аптырап, Беатриса янына туплана.)* Ахмаклар сез! Бөек Инквизитор урынында юлбасар Педро утыра.

К а р а д ә р в и ш. Сеньора, сеньора, китегез моннан.

Б е а т р и с а. Аңламыйсызмыни соң сез, сарыклар? Ярый, мин бозык хатын, ди. Сезне монахлар бозмыймыни?

Ж о з е ф и н а. Сеньора, яхшы чакта кит син моннан.

Б е а т р и с а. Беркая да китмим. Мин монда король Хуаннан ярдәм сорап килдем. Якласын ул гөнаһсыз халыкны инквизициянең рәхимсезлегеннән. Коро-оль, хөрмәтле король җәнаплары Хуа-ан..

Ж о з е ф и н а. Король Хуан әле генә вафат булды.

Б е а т р и с а. Аны үтерделәр! Ләкин король Хуан үлемсез! Андый корольләр үлә димени, ахмак хатын. Король Хуан, коткар кешеләрне... Бөек Инквизитор урынында ата карак утыра.

*Ике кеше килеп, Беатрисаны туктатырга тырыша. Беатриса каты карыша.*

Б е а т р и с а. Динебез башында кабәхәт утыргач, халык кая барсын? Җибәрегез мине. Минем тәнем болай да ут яна. Минем тәнем гөнаһларымнан шулай яна. Мин инде әллә кайчан ут ялкынында. Хәзер мин ялкынны тоймаячакмын. Минем гөнаһлы тәнем пычак җәрәхәтен дә сизмәячәк. Рух җәрәхәте белән чагыштырганда нәрсә ул тән җәрәхәте! Чөнки мин мәет инде! *(Кардәрвишне күреп.)* Бу—Иисусе Христосе! Иисус, бәгырем, Магдалинаны ярлыкаган кебек, мине дә ярлыка, зинһар, Иисусе. Син бит кеше талаган юлбасарларны да ярлыкадың. Мин кеше талаучы түгел бит. Ярлыка син мине! Җаным, син дә Христос кебек җәфа чигәсең, сине дә голгофага алып баралар, сине дә агач хачка кадакларлар. Бәгырем, җаным Иисус, фәхешлекләр кылган Магдалинаны ярлыкап, син аннан изге ясадың. Минем дә гөнаһларым Магдалинаныкыннан артык түгел, ярлыка мине. Иисусе! Коткар халыкны кабәхәт Вельзевулдан. Дьявол! Иблис! Сатана баш дөньяга! Үтерегез мине шушында, утка атыгыз, җә ни карап торасыз, җәлладлар... Мин сөйдем Бонифацийны, өзелеп, шашып сөйдем, минем гөнаһым шулмы? Мин ялгыштым, хата ясадым, изге диеп мин юлбасарны кочтым. Кичер мине, җаным. Мин әзер синең каршыңда җавап тотарга, мин әзер... *(Ул кинәт кенә сакчыларнын берсеннән билхәнҗәрен тартып ала. Янаулы кыяфәттә.)* Китегез, нәҗесләр, китегез! *(Куркып артка чигәләр. Беатриса уртада кала.)* Сезме минем рухыма хуҗа? Сезме минем тәнемә баш! *(Шашып көлә.)* Ха-ха-ха... Минем җаныма беркем хуҗа түгел! Минем тәнемә изге Бонифаций гына хуҗа була алды. Минем бу гөнаһлы тәнемә ата карак Педро Бургос кына, хатам аркасында гына хуҗа була алды. Рухымны, җанымны мин Аллага тапшырам, мин үлгәч, мәетемә хуҗа булырсыз! Сез бит мәет каргалары, үләксә козгыннары! *(Сакчылар Беатрисага якынаялар.)* Мин сездән дә артык гөнаһ кылмадым! Мәетемне көчләгез, кабәхәтләр! *(Хәнҗәрен күкрәгенә батыра. Шәлперәеп төшә.)*

К а р а д ә р в и ш. Беатриса, кичер...

К а н ц л е р. Алып китегез бу хатын мәетен! Үлеп котылды. Ул Сатанага җанын саткан хатын! Аның мәетен яндырырга!.. Тәхет варисының бишек туе хөрмәтенә мәйданда—аутодафеда явыз еретикларны яндыру бәйрәме булачак. Бөек кардиналга тел тидергәннәрне Бөек инквизиция хөкем итәчәк. Яна туган сабый король Һәнрих Өченче хөрмәтенә бәйрәм башлана.

К а р а д ә р в и ш. Йа, Илаһым,

Исусе Христос. Тагын гөнаһсызлар харап була икән.

*Халык кеше яндыру бәйрәменә җыела. Кешеләр арасында шымчылар күренеп-күренеп китә. Алар тыннана, алак-йолак карана.*

Р а м и р о. Яшәсен тәхет варисы Өченче Һәнрих!

Е г е т. Яшәсен Бөек Инквизитор Бонифаций!

Р а м и р о. Яшәсен кардинал Бардини!

## Мордарлар

*Мәйданга атка атланган оранчы бәреп керде дә кешеләрне таптата язып, атын аягүрә бастырды. Айгыр чинап- кешнәп, шәм кебек төз басып, туктап калды, ат алгы аякларына төшкәч, оранчы тамак киереп кычкыра башлады.*

Ж о з е ф и н а. Әй, адәм таптатасың бит, хәерсез!

О р а н ч ы. Әй, кала халкы, колакларыгызны торгызыгыз! Мордарларны яндырабыз! Мордарларны утка атабыз!

Е г е т. Кемнәрне яндыралар бүген?

Р а м и р о. Аллага каршы чыкканнарны!

И р  к е ш е. Еретикларны!

О р а н ч ы. Мордарларны дөрләп янган учак көтә!

*Оранчы атын әйдәкләп, тагын кешеләрне таптата язып чабып китте.*

Ж о з е ф и н а *(җайдак артыннан кычкырып кала).* Женле күсәк!

Е г е т. Кемне яндыралар?

Р а м и р о. Берсе—яһүд, икенчесе баск кешесе, ди.

К а р т  к е ш е. Аларның гаепләре нидә?

*Сөйләшүчеләр янына шымчылар килә.*

Р а м и р о. Кыйнап, җәзалап та яһүд христиан динен кабул итмәгән. Шуннан аңа инквизитор әйткән: безнең дингә күчмәсәң, бөтен байлыгыңны чиркәү файдасына алабыз, үзеңне утта яндырабыз, дигән. Шуннан соң яһүд риза булган. Чукынган, чиркәүгә йөри башлаган. Ләкин аның рухы түзмәгән, ул католиклыгын ташлап, үз диненә кире кайткан. Епископ күрмәгәндә генә үз динен тота башлаган. Көндез, якшәмбе көннәрне ул гаиләсе белән чиркәүгә чукынырга йөргән була икән, төннәрен качып кына үз динен тота икән. Аның өендә Тәүрат китабының битләрен тапканнар.

К а р т  к е ш е. Баск ни кылган?

Р а м и р о. Бөек Бонифацийга тел тидергән.

К а р т  к е ш е. Нәрсә дигән?

Р а м и р о. Бөек Инквизитор үзе еретик, кардиналлар үзләре әхлаксыз, дигән.

Ш ы м ч ы *(атылып чыга).* Әһә, менә кем ул еретик! Каравыл! Алыгыз бу бәндәне, ул әле генә: Бонифаций—ул үзе еретик, инквизиторлар үзләре бозык, диде.

Р а м и р о. Мин алай әйтмәдем! Мин кеше әйткәнне генә шулай дип әйткән, дидем. Минем гаебем юк!

*Каравылчылар килеп, бәндәне өстерәп алып китәләр. Шымчы тагын иснәнә, тыңлана.*

Р а м и р о. Минем гаебем юк, мин алай әйтмәдем...

Е г е т. Бүген бәйрәм шәп булыр, ахрысы, учакка эләгүчеләр күбәя бара.

И р  к е ш е. Баскны яндырырлармы икән?

Е г е т. Дин тоту һәркемнең вөҗдан эше.

И р  к е ш е. Тсс! Учакка эләгәсең киләмени? Инквизиторларның шымчылары белән урам тулган.

Ш ы м ч ы *(Егетнең җиңеннән тота).* Эләкте инде! Каравыл! Бу бәндә ересь сүз әйтте. Дин тоту ирекле, инквизициянең башка диннәрне тыярга хакы юк диде. *(Сакчылар Егетне кулга ала.)*

Е г е т. Нишлисез сез?

К а н ц л е р. Бөек Бонифаций исеменнән, кардинал-инквизитор исеменнән, Исус Христос исеменнән: алыгыз бу еретикны! Аның урыны ялкын эчендә!

Е г е т. Кагылмагыз мина...

*Сакчылар аны өстерәп алып китә.*

К а р а д ә р в и ш *(алга чыгып, кулын күккә сузып).* Йа, Хода, кая бара дөнья! Аум мани падме һум! Иисусе Христосе! Күрәсенме, синең исемең белән нинди гаделсезлекләр кылына? Ишетәсеңме, минем исемнән—Бонифаций исеменнән гөнаһсызларны утка аталар? Кая бара дөнья! Кешеләр, ни эшлисез сез?

К а н ц л е р. Бәндәләр, бүген бөек бәйрәм! Тәхет варисы дөньяга килде! Еретикларны яндырабыз! Мәйданны бизәгез! Утынны, чыбыкларны мул ташыгыз! Бәйрәм бүген!

*Кешеләр бәйрәмгә әзерләнә. Шәһәрне бизиләр. Кешеләр кочак-кочак коры чыбык ташый. Музыка уйный. Бииләр.*

К а н ц л е р. Сеньорлар, сеньоралар, рыцарьлар, бикәләр, чүлмәкчеләр, тимерчеләр, сатучылар, алучылар! Бәндәләр! Мәйдан уртасындагы күтәртмәдә еретикларны яндырыр өчен барысы да әзер! Испания короле Хуан Беренченең варисы Һәнрих Өченченең тууы хөрмәтенә багышлап, бер еврей, бер баск һәм ике этруск кешесе утка атылачак! Динебезне сафландыру эшендә, Иисус Христос алдындагы бурычыбызны без әнә шулай үтибез. Бу дошманнарны хөкем итәргә Бөек Бонифаций үзенең ышанычлы кардиналы-инквизиторы Бардинины юллады.

*Тантаналы музыка. Сарайдан кардинал-инквизитор Бардини, биләүләнгән бала тоткан хатын—Дая һәм сарай әһелләре, сакчылар чыга. Халык баш ора.*

К а р т  к е ш е. Яшәсен кардинал, яшәсен тәхет варисы!

И р  к е ш е. Яшәсен Бөек Кардинал Бонифаций!

*Халык арасыннан бер яшь хатын—Жозефина атылып чыга. Аны сакчылар урап ала.*

Ж о з е ф и н а. Жибәрегез мине, сеньор кардиналга сүзем бар!

Б а р д и н и. Жибәрегез!

Ж о з е ф и н а *(кардинал алдына егыла).* Кардинал җәнаплары, минем ирем гаепле түгел, коткарыгыз, зинһар, безнең ике балабыз бар, сабыйларым хакына.

К а р д и н а л *(хатынга астыртын игътибар белән бага).* Анын ире ни өчен аутодафеда?

К а н ц л е р. Бөек кардиналым, аның ире ересь сөйли халык арасында.

К а р д и н а л. Нинди ересь сөйли ул?

К а н ц л е р. Шаһитләр сөйләсен! *(Шымчыга ишарә ясый.)*

Ш ы м ч ы. Кардиналым! Бөек Инквизитор Бонифаций да, аның кардиналлары да үзләре динне боза, алар үзләре әхлаксыз...

Ж о з е ф и н а. Әһә, менә ул еретик, кардиналым! Әнә, сезнең каршыгызда ул ни сөйләп тора! Минем ирем түгел, бу сүзләрне менә бу еретик әйтте.

Ш ы м ч ы. Мин ул әйткәннәрне генә кабатламакчы идем...

Ж о з е ф и н а. Минем ирем дә башкалар әйткәнне генә кабатлаган иде.

К а р д и н а л *(Канцлерга).* Алыгыз бу еретикны! Голгофага аткарыгыз!

Ш ы м ч ы. Кардиналым, минем гаебем юк. Мин еретик сүзләрен кабатлаучы гына.

К а н ц л е р. Алыгыз! *(Сакчылар шымчыны алып китә.)*

К а р д и н а л *(эчке кытыклану илә).* Бу хатын төшеп калганнардан түгел.

К а н ц л е р. Шәһәребезнең гүзәле, кардиналым.

К а р д и н а л. Бар бит бәхетле ирләр.

К а н ц л е р. Сез дә бәхетле булыгыз, кардиналым.

К а р д и н а л. Иренең байлыгы, малы күпме?

К а н ц л е р. Ире хәерче, алар ике бала белән алачыкта яшиләр. Ире муеннан бурычта. Тапкан малларын икәүләп туздыра баралар.

Ж о з е ф и н а. Кардинал-инквизитор, сабыйларым хакына, зинһар, гөнаһсыз иремне коткарыгыз!

К а р д и н а л. Димәк, аларның чиркәү файдасына конфискацияләнер малы юк?

К а н ц л е р. Юк, кардиналым!

К а р д и н а л. Анын ирен голгофадан алып, аерым ябыгыз, тикшерүне

канунлаштырырга кирәк. Ә бу хатын бәйрәм азагында хөкем бүлмәсенә керсен. Һәр яклап тикшерергә, шаһитләрдән сорау алырга. Шунда иренен язмышын хәл итәбез. Канун буенча, гадел эш йөртергә бурычлыбыз.

К а н ц л е р. Хатын! Ирен голгофадан алына! Гаделлек кануны буенча без аның җинаятен тикшерергә бурычлыбыз. Гаебе расланмаса, азат кылыныр. Ә син хәзер хөкем бинасына кереп, кардинал-инквизитор каршында җавап тотарга тиешсен!

Ж о з е ф и н а. Рәхмәт, кардиналым!

*Жозефинаны сарайга таба алып китәләр. Сакчылар Рамироны дарагачтан алып, икенче як бинага алып баралар.*

Ж о з е ф и н а. Җаным, сеньор кардиналга рәхмәт укы!

Р а м и р о *(артык буйсынган булып).* О-о, җиде кат күктән чиксез рәхмәтләр яусын Бөек Бонифаций белән кардинал-инквизитор Бардини җәнапләренә! Гаепле кешене голгофадан коткарырга кардиналның хакы юк. Димәк, мин гаепле түгел. Гаебем булмаган килеш мине ялкында чытырдап янудан коткарганы өчен инквизиторга Иисус Христос яше санында рәхмәтләр! Димәк, мин кардиналга бер мен дә өч йөз җитмеш сигез тапкыр рәхмәт кычкырам! Рәхмәт, рәхмәт, рәхмәт...

К а н ц л е р. Теленә салынма!

Ж о з е ф и н а. Җаным, без озакламый күрешербез! Түз, күп сөйләнмә!

Р а м и р о. Мин түзәрмен, ә менә син Гадел Хөкем йортында ничек түзәрсен икән? Рәхмәт, рәхмәт, рәхмәт...

К а н ц л е р. Алыгыз икесен дә.

Р а м и р о. Рәхмәт, рәхмәт, рәхмәт...

*Сакчылар Рамироны зинданга, Жозефинаны Хөкем Сараена алып кереп китәләр.*

## Ахирәт дуслар

*Ратуша мәйданында халык бәйрәм дуены куптара. Каралэрвиш шау-шуга игътибар итмәстән, бер почмакта чүгәләп утыра. Кардинал Бардини дәрвиш ягына карый, теләнче кыяфәтендәге дәрвишкә нык лап игътибар итми.*

Б а р д и н и. Сабый корольне дарагач янына алып барыгыз! Аның беренче көне мордарлар белән күрәшүдән башлансын! Күрсәтегез сабыйга, кереп калсын аның миенә: аны алда әнә шундый корбаннар көтә!

*Дая сабыйның йөзен ачып куя. Кешеләр чиратлап сабыйга багып, мәйданга таба йөриләр. Караләрвиш тә сабыйга бага.*

К а р а д ә р в и ш. Аум мани падме һум! Бөек Алланың исемен данлыймын! *(Үл кулы белән сабыйның башын тотмакчы була, аның кулына сакчы суга. Дәрвиш таягын төшереп җибәрә. Кардинал кинәт Карадәрвишкә игътибар итә.)*

Б а р д и н и. Бу нинди шәүлегән? Нигә аны корольгә якын җибәрдегез?

К а н ц л е р. Мәхлукъ Алла бәндәсе, хәер соранып килүеләр.

Б а р д и н и. Сарай янында хәер сoранмыйлар. Сарайга, кардиналга хәер китерәләр, бәндә!

*Карадәрвиш сынар кулы белән таягын ала алмыйча азаплана, Кардинал сырт якасыннан тотып, дәрвишне калкыта, чыраена бага. Як-ягына каранып ала да, кардинал Карадәрвишне аулакка алып чыга.*

К а н ц л е р. Барыгыз да дарагач янына, еретикларны яндырганны карарга барыгыз!

*Кешеләр җәза мәйданына таба китәләр.*

Б а р д и н и. Чулак Дәрвиш?! Син каян килеп чыктың монда, Тере Мәет?

К а р а д ә р в и ш. Койрыклы йолдыз ташлап китте, кардиналым!

К а р д и н а л. Бөек Бонифацийнең әмре илә син үлемгә хөкем ителгән бәндә!

К а р а д ә р в и ш. Мин үземне үзем үтерергә әмер биргән булып чыгам түгелме, кардинал?

К а р д и н а л. Син Бөек Инквизитор түгел!

Карадәрвиш. Күземә тугры кара, Бардини! Карый алмыйсын! Чөнки син ата җинаятьче! Чөнки син карак! Син урладың минем исемемне, җисемемне. Мин—чын Бонифаций!

Кардинал. Сиңа кем ышансын хәзер! Син—Чулак Дәрвиш!

Карадәрвиш. Син мине чулак ясаган кеше, Бардини. Син Ялган Бонифацийга минем кулны чабарга киңәш биргән бәндә, Бардини! Чөнки син мине сабый чактан ул белә иден, без синең белән аерылмас дуслар идек. Без ант эчтек, гомергә дус калырга, беребез бәлагә очраганда икенчебез аңа ярдәм итәргә бурычлы булдык. Мин сине су астыннан тартып чыгардым. Мин сине маврларның зинданыннан коткарып калган кеше, син төрекләргә әсир төшкәч, сине төрек солтаныннан сатып алган кеше мин. Син белә иден бит, ул түгел Бонифаций, мин Бонифаций. Минем урында ялган карак утырганын белмисендер дип, хәерче кыяфәтенә калган дәрвиш буларак, мин сине эзләп таптым: коткар мине, дустым, мин сиңа күпме игелекләр кылдым, син дә миңа игелек кыл, кайтар мине үз тәхетемә, дидем. Минем исбатым бар иде, дидем. Сул кулымның беләгендә зур гына көрән миңем бар, дидем. Сул беләгемдәге миңемне атам-анам, туганнарым, дусларым күрә белә иде. Карак Педроны фаш итәр өчен халыкны җыеп, минем миңле беләгемне генә күрсәтергә кирәк иде. Ялган Бонифаций минем арттан шымчылар җибәреп, сул кулымны чаптыртты. Педро үзенең сул кулын үзе яндырып, исбат җирлеген калдырмады.

Кардинал. Бонифацийның сул кулы янган, аның сул кулындагы миңе дә янган. Өйдән сабый балаларны коткарганда янды Бонифаций.

Карадәрвиш. Нинди янгын, нинди бала? Сез ул янгынны махсус оештырдыгыз. Имеш, шул янгында Бонифацийның сул беләге янган, беләгендәге зур көрән миңе дә янган! Гомерлеккә сайланган Бөек Кардинал булып, байлык, муллык, ләззәт эчендә утырыр өчен сул беләк кенә кызганыч түгел.

Кардинал. Дустым! Бу сөйләшүнең сиңа ни файдасы бар? Син еретик. Син католикларга каршы хәрәкәт итүче гыйсъянчы, син дененнән язган нәҗес. Синең урының учакта!

Карадәрвиш. Син бит миндәйләрне хөкемгә тартмыйсын, чөнки минем таларга малым юк. Сез бит бөек кардинал-инквизиторлар, бай яһүдләрне, бай маврларны, бай баскларны гына талыйсыз. Әнә, син гаепсезгә голгофага бастырган бу егетне коткармакчы, чөнки аның малы юк, аның каруы гүзәл хатыны бар. Ул хатынга кендектәш булганнан соң син аны да, ирен дә коткарачаксың. Син аңа күз ташладың. Аутодафеда яһүдне яндырганнан соң ала торган байлыгы бар. Гаебе булмаса да, син аны гаепле итәчәксең. Бичара баскның ни гаебе бар? Аның да гаебе бай булуда. Аның мул көтүлекләре, шәһәрдәге, авыллардагы таш йортлары һәм чибәр кызлары бар. Шул ләззәтләр өчен син хакыйкатьне, Бөек инквизиторны, динне, Христосны саттың!

Кардинал. Житте! Чулак Дәрвиш! Син ересь сөйлисең!

Карадәрвиш *(усал көлә).* Бөек Кардинал үзе карак!

Кардинал. Тсс! Кеше ишетсә, мин сине утка атарга мәҗбүр булачакмын! Тсс!

Карадәрвиш. Иблис токымы католиклыкны эчтән җимергәндә харап була христианнар, харап була Аурупа. Бернинди Хач-тәре сәфәрләре дә коткара алмый безне. Чөнки ул сугышлар безнең тарафтан гадел түгел иде, безне татар-мөселман, мавр мөселманнарыннан берләшү генә коткара ала. Католиклар үз кешеләрен яндырганда дөнья татарларга калачак. Коткар дөньяны, коткар христианнарны. Әйт син ышанычлы кешеләреңә: сарайда Ялган Бонифаций утыра диген, чын Бонифацийның миңле кулын чаптылар, Ялган Бонифаций сул кулын үзе көйдерде, хәзер чын Бонифацийны үтеререгә әмер бирелгән, диген.

Кардинал. Исбатың кайда? Исбат кирәк. Синең миңле кулың юк. Бонифацийның сул кулы янган. Бетте дәлил. Шайтан тәгәрмәче гамәлгә куелган, Иблис тегермәне тарта башлады инде. Инквизицияне туктатып булмый, инквизиция, дустым, ул бөек рухның чиксез гайрәте. Бу гайрәт хәрәкәткә китерелде, бу хәрәкәт рухның куәтен арттырганнан арттыра бара, шулай итеп, инерция барлыкка килә. Инерцияне туктата алырлык көч дөньяда юк, мин

алардан куркам, мин аларга каршы бара алмыйм.

Карадәрвиш. Әле соң түгел, туктагыз, туктатыгыз!

Кардинал. Артка борылганчы— алга, тагын да күбрәк корбаннар аша алга барырга кирәк.

Карадәрвиш. Ә мин, канун тарафыннан сайлап куелган чын Бонифаций ни кылырга тиеш?

Кардинал. Синең язмышың хәл ителгән, син рух тегермәне куласасына килеп кысылган мәхлук. Синең исбатың юк.

Карадәрвиш. Исбатым бар минем!

Кардинал. Нинди исбат?

Карадәрвиш. Фаш итә торган кәгазьләрне, кисек кулымны ышанычлы урынга куйдым, мине үтерә калсагыз да юлбасар фаш ителәчәк, аның белән бергә сез үзегез яккан учакта чытырдап яначаксыз. Хуанның шикле үлемендә Ялган Бонифацийның да, синең дә турыдан-туры катнашың бар түгелме? Чөнки ул сезнең койрыкка баса башлаган иде. Хуанның агуланган икәнен исбат итү бик җиңел бит, Бардино.

Кардинал. Тсс!

Карадәрвиш. Кыскасы, мин әле сезнең белән көрәшәм, яхшы чакта көч минем якка.

Кардинал. Синең якка күчеп, син җинсәң, мин байлыгымнан колак кагаммы? Син бит фәкыйрь монахлар ордены яклы.

Карадәрвиш. Сиңа җитәрлеге калыр.

Кардинал. Мин инде бай тормышка күнеккән.

Карадәрвиш. Тегермән ташын бер ялаган эт тегермәнгә яңадан килми калмый. Кыскасы, син әлеге гүзәл хатынны, аның ирен хәзер үк ирекккә чыгарасың, чөнки аларның гаебе юк. Әгәр дә син ул хатынга кул салсаң, аның ире бөтен көчен синнән үч алырга куячак. Дарагачы янындагыларны син хәзер үк, сафсатага корылган нотыгың белән аклыйсың яки җинелчә генә җәза биргән булып, аларны коткарасың!

Кардинал. Бөек Инквизитор алдында мин ни дип җавап бирермен? Яһүдне, баскны яндырып, мин ул процесстан кырык мең алтын реаль, егерме мең мараведи алып кайтырга тиешмен.

Карадәрвиш. Гаепләре дә акчалары да, маллары да юк иде диярсең! Җә!.. Яки бөтен җыйган байлыгыңны алтынга әверелдереп, Англиягә качарсың.

Кардинал. Бөек Инквизиторның кулы Англиягә дә җитәрлек озын. Дөнья тулы аның шымчылары.

Карадәрвиш. Алайса, Кордовага, Гранадага, Мавританиягә кач. Гарәпләрдә инквизиция юк. Вакыт чыкты, Бардино!

Кардинал. Барысын да коткарам, тик яһүдне коткара алмыйм. Трибуналның абруе югалачак.

Карадәрвиш. Аның акчасы күп шул, малы бихисап. Аның гаебе шунда.

Кардинал. Хатынны, ирен чыгарыгыз!

Канцлер. Жозефина! Рамиро! Чыгарыгыз!

*Рамиро белән Жозефина атылып чыга. Кочаклашалар.*

Жозефина. Рамиро!

Рамиро. Хатын! Рәхмәт, мең туксан тугыз, рәхмәт, ике мең рәхмәт...

Жозефина. Гомерем буе онытмам, сеньор кардинал, рәхмәт!

Кардинал. Мохтаҗларга ярдәм итү—изге бурычыбыз. *(Ир белән хатын җитәкләшеп бәйрәмгә кушыла. Канцлерга.)* Яһүдтән, шайтан хатынынннан башкаларын җибәрегез!

Карадәрвиш. Ул хатынның ни гаебе? Кәҗәдән курыккан. Нинди шайтан булсын ул?

Кардинал. Тегермән әйләнә. Кешеләр җеннәр белән аралашкан хатыннан котылырга тели. Аны кәҗәсе белән бергә яндыру минем халык каршындагы изге бурычым.

*Канцлер дарагач ягына китә.*

Канцлер. Бөек Бонифаций һәм дә инквизиция трибуналы җитәкчсе кардинал Бардини исеме белән гаепсезләр аклана. Ата еретик Мушаро Хайме яндырыла.

*Анда шау-шу. Кемлер шатлана.*

Кемдер. Нигә ул еретикларны азат иттегез, яндырыгыз!

Б а ш к а с ы. Яшәсен кардинал, ул гөнаһсызларны азат итте.

Б ү т ә н е. Яһүднең гөнаһасы күп булгандыр шул.

К е м д е р. Янсын рәхәтләнеп. Шул кирәк ул еретикларга!

Б ү т ә н е. Җенле хатынны да яндырыгыз!

Тантаналы музыка уйный. Ялкын күренә. Шатлык, бәйрәм, бию. Кулына биләүле бала тоткан Дая кайтып килә. .

К а р а д ә р в и ш *(сабыйга карап ала да дога укый башлый).* Аум мани падве һум! Минә кем безне бу афәттән коткарыр. Шушы сабыйда бөтен ышаныч, өмет, куанычлы көтү. *(Дая бала белән сарайга уза.)*

К а р д и н а л. Мин сине Кастилиядә күрмәдем. Ләкин икенче тапкыр юлымда очрасаң...

К а р а д ә р в и ш. Куч минем якка, Бардино! Үзеңне дә, илне дә афәттән коткар.

К а р д и н а л. Артка юл юк, бары тик алга! Без—кардиналлар Христосның ярдәмчеләре! Дустым, син Италия, Испания, Франция кебек илләрнең чик буена да килмә. Сине аутодафедан коткарып, мин дуслыгыбыз каршындагы бурычым үтәлгән, дип саныйм. Хуш! *(Сарайга кереп китә.)*

К а р а д ә р в и ш *(мыскыллы рәвештә).* Рәхмәт! Чиксез күп рәхмәтләр, сезгә кардинал-инквизитор Бардини. Бу яхшылыгынны мәнге онытмам! *(Мәйданда бәйрәм дәвам итә.)* Койрыклы йолдыз узып китте. Җаннарны кыеп китте. Йа, Иисусе Христосе! Күрәсеңме син, ишетәсеңме син! Синең исемнән, син күтәргән байрак астында нинди җинаятьләр кылына. Әллә соң Мөхәммәд пәйгамбәр хаклы булып чыктымы? Әллә чыннан да, Ислам дине иң дөрес динме? Тефү-тефү, җылы авызымнан җылы җил алсын! Мин дә ересь сөйләп торам түгелме? Изгеләрнең изгесе, миһербанлыларның миһербанлы кызы Мария гадел хөкем чыгарсын! Аме-ен!

С а к ч ы. Сир, сезгә монда калырга ярамый. Бардининың кире уйлавы да бар.

К а р а д ә р в и ш. Җир йөзендә менә ниләр кылына. Күк йөзендә ниләр кылына? Алланың хөкеме кайчан иңәр? Дөрес, Олонсо! Бер син калдың миңа тугры булып.

С а к ч ы. Сир, кардиналларның, Педро Бургосның котырган чагы. Юкка чык син, сир. Киттек Кордовага, аннан Гранадага, анда инквизиция юк.

К а р а д ә р в и ш. Әйттем исә кайттым, мөселман илләренең берсендә дә инквизиция юк! Бу—аларның какшамас ныклыгы. Вакытлыча без юкка чыгыйк!

## Җинаятьчене эзлиләр

*Бөек Инквизитор Бонифаций дәрәҗәсе алган дон Руи Карадәрвиш кыяфәтендә, үзенең җан дусты сагында илдән илгә каңгырып йөрергә дучар ителде. Руи чыннан да фәкыйрь монах хәлендә иде. Алар икесе: Карадәрвиш белән аның тугры сакчысы Олонсо илдән илгә, каладан калага йөри киттеләр. Ислам илләрендә йөри торгач, Карадәрвиш Коръәнне шундый итеп өйрәнде ки, аның аһәңен, аның мәкамен ишеткән мөселманнар гына түгел, башка дин әһелләре дә сокланып туя алмый иде.*

*Диңгез буе шәһәрләренең көймәләр туктый торган урынындагы каһвәханәләргә, сыра-шәрабханәләрнең диварларына Педро Бургосның исемен ябыштырып: ата җинаятьче, өч тапкыр үлемгә хөкем ителеп тә тагын зинданнан качкан юлбасар Педро Бургосның кайдалыгын әйткән кешегә 500 000 алтын дукат биреләчәк! дип язып куйганнар.*

*Кая гына бармасыннар, алар шушы игъланга юлыга тордылар. Кемдер нәкъ Бонифацийга охшаган юлбасарның сурәтен дә ясап ябыштырган иде.*

*Киндерә белән аркылы-торкылы бәйләнгән башмак кигән аяклар юл тузанын ерып каядыр бара.*

*Сакалга баткан Карадәрвиш белән Сакчы көчкә атлый. Сакчының аркасында юл биштәре.*

*Офыкта ниндидер бер шәһәрнең шәүләсе күренә.*

*Ком өстендә дүрт аяк эзе офыкка хәтле сузылып калган.*

*Юлчылар шәһәр урамы буйлап бара. Манаралардан йөз тавышлы азан яңгырый.*

*Мөселманнар мәчеткә ашыга.*

*Юлчылар жыелган халыкка якын килә.*

*Мәчет капкасы янында имам басып тора, ул кулына төрелгән киндер тоткан.*

И м а м. Мөселман кардәшләр! Аллаһ исеме белән әйтәмен ки, башкисәр, юлбасар, талаучы Педро Бургос әле һаман да ирektә, кешеләрне талап йөри! Каракны тотарга ярдәм итү—һәр мөселман кешесенең изге бурычы! Шәһәр диварларына аның исеме ябыштырылган. Кем дә кем юлбасар Бургосны тотарга ярдәм итә, аның кайдалыгын әйтә яки аның мәетен күрсәтә, шул кеше безнең падишабыздан гына түгел, башка илләрнең патшаларыннан да олы бүләкләр алачак!

*Кулындагы киндерне сүтеп жибәрә. Киндердә Карадәрвишка тач охшаш Педро Бургос сурәте күренә.*

*Арткы рәттә басып торучы Сакчы эшне аңлап, тиз генә кесәсеннән каралып беткән чүпрәк чыгарып, Карадәрвишнең бер күзен бәйләп куйды.*

С а к ч ы *(пышылдап)*. Тәкъсирем, тизрәк китик моннан.

*Тагын аяклар атлый. Һәр капкадан, һәр дивардан аларга Педро Бургосның чырае карап тора. "500 000 алтын дукат!"*

*Арыган булсалар да, алар йөгерә башладылар. Шәһәр читенә чыгып егылдылар.*

К а р а д ә р в и ш. Фу-у, монда да миңа көн юк икән. Кастилиядә Ялган Бонифаций мине эзәрлекли. Монда мине юлбасар буларак таптыралар.

*Аяклар тагын юл тузанын туздыра. Иреннәр чатнап кипкән. Ачлык аларның йөзенә чыккан. Еракта таулар күренә.*

*Юлчылар тауларга якыная.*

## Уяу чабан

*Тау чишмәсе шаулап ага. Чишмә суы астагы уйсу жиргә жыелып, буа хасил иткән. Шул буа янына куй көтүе тупланган. Чабаннар малларның су эчкәнен күзәтә. Чабаннарның иң яше, бер үсмер баядан бирле аты өстеннән сәер юлчыларны күзәтә.*

*Юлчылар су кырына жайлашып ала. Сакчы капчыгыннан савыт чыгарып, су ала да иң башта Карадәрвишкә бирә. Дәрвиш йотлыгып су эчә. Калган су белән битен юа, күзендәге чүпрәкне алып, рәхәтләнеп башын юа башлый.*

*Үсмернең аптыраган йөзе. Аның бу кешене кайдадыр күргәне бар кебек. Ә-ә, стан янындагы баганага ябыштырылган сурәттә шушы юлчы ясалган ләбаса. Бу кабәхәтнең кайдалыгын хөкемдарларга әйтеп, ул каһарман булачак, баеп китәчәк!*

*Үсмер атын кинәт борып, жан-фәрманга чабып китте.*

*Юлчылар хәл алгач, кузгалалар. Олы юлга чыгалар.*

*Шәһәр ягыннан тузан күтәрелә.*

*Юлчылар акрын гына атлый.*

*Атларын яндырырдай булып чабып килеп, үсмер чабан әйдәвендә унлап нөкәр юлчыларны урап алды.*

Ч а б а н. Әнә ул, юлбасар Педро Бургос! Мин аны таныдым! Аның күзе сукыр түгел, ул үзен танытмас өчен чүпрәк бәйләгән.

Н ө к ә р л ә р б а ш л ы г ы *(бөереннән чыккан тавыш белән юлчыларга)*. Кузгалмагыз! Хәзер багарбыз. *(Ияреннән сикереп төшә, Карадәрвишнең күзендәге чүпрәгнен салдырып ташлый. Кулындагы киндерне сүтә, киндердә Бургос сурәте.)* Охшаган! Шул! Бу Педро Бургос... Алыгыз! *(Нөкәрләр юлчыларны чолгап ала.)* Рәхмәт сиңа, жегет! Әйдә безнең белән хөкемдарлар янына, сиңе анда олы бүләкләр көтә!

*Ике юлчыны да атларга атландырып, нөкәрләр шәһәр тарафына чабып киттеләр.*

## Бимазалар

*Шәһәр урамы. Куллары артка каерып бәйләнгән Карадәрвишне атка таккан-нар. Халык ана таш атып кала. Ара-тирә нөкәрләр анын аркасына камчы оралар. Карадәрвишнең әрнүле чырае.*

Т а в ы ш л а р:

—Кәрваннарны талаучы, корабларны яндыручы Педро Бургосны тагын тотканнар.

*Шәһәр читендәге ярым җимерек саман йорт хәрабәләре арасында Сакчы йоклап ята иде. Аны сөрән тавышы уятты.*

С ө р ә н ч е. Хөрмәтле шәһәр халкы, ике атнадан соң урта мәйданда Педро Бургос атлы ата карак, юлбасарны җәзалап үтерү мәрасимы булачак. Күрми калмагыз, ишетми калмагыз, килми калмагыз!

*Урам буйлап Сакчы бара. Капкаларда Бургос сурәтләре. Халык һәр сурәт янында тукталып гәп кора.*

С а к ч ы. Мөселманнар! Зиндандагы кеше юлбасар түгел! Ул Педро Бургос түгел! Аллаһ исемен әйтеп ант итәмен! Валлаһи, анын гаебе юк! Ул карак түгел!

С ө р ә н ч е. Аттыр моннан, хәерче! Кит яхшы чакта!

С а к ч ы. Әгәр дә сез гөнаһсыз кешене җәзалап үтерәсез икән, үзегез гөнаһка батачаксыз!

С ө р ә н ч е. Каһәр суккан бугазыннан тагын бер сүз чыкса, мин синең үзеңне зинданга атачакмын! *(Камчысы белән Сакчынын сыртына сугып, китеп бара.)*

*Сакчы ярасын тотып, рәнҗү катыш нәфрәт белән иелеп төшә.*

*Мәчет капкасы янында Сакчы басып тора. Ул кулын алга сузып, хәер эсти. Кемдер аңа бер кыерчык икмәк бирә, кайсыдыр алма суза, кемдер анын учына бакыр акча салып китә. Нөкәрләр аны мәчет яныннан куып җибәрә.*

—Китеп олак моннан, әрәмтамак!

*Бичара Сакчы—Олонсо моннан кусалар, тегендә барып басты. Ары чапты, бире чапты, тоткынны якларга алынучы табылмады. Олонсо хәер сорашып җыйган бар ризыгын зиндандагы дустына—Карадәрвишкә илтә китте.*

*Зиндан капкасы. Баштанаяк коралланган нөкәрләр, кешеләрне капкага якын китерми. Кулына төенчек тоткан Сакчы—Олонсо килә. Ул кыюсыз гына капкага якыная.*

С а к ч ы. Бургос исемле бичарага мин бераз гына тәгам китергән идем.

Н ө к ә р. Кит моннан! Тоткыннар белән күрешү, аларга ризык ташу тыела!

С а к ч ы. Бу нинди ил инде? Ә шәһәр әһелләренең хокуклары кайда? Ул гаепле булган очракта да, анын кешелек хокуклары юкмыни бу илдә? Анын ризык кабул итәргә, тәгам ашарга хокукы бар, лабаса!

Н ө к ә р. Әйтелде бит: ярамый!

С а к ч ы. Әгәр дә ул ашамаса, зиндан идәненә сузылып җан тартса, ике атнадан соң сез кемне җәза мәйданына алып барырсыз икән соң?.. Шәһәр халкы олы бәйрәмгә, кеше үтергәнне карарга әзерләнә. Әгәр ул бәйрәмгә хәтле үләсә, сез шәһәр халкын олы ләззәттән мәхрүм итәчәксез! Халык моны гафу итмәс! Баш калкытыр!

*Нөкәрләр үзара киңәшә. Нөкәрләр башлыгы:*

—Әйдә, кыерчыкларын алыгыз да, юлбасарга кертеп бирегез!

Н ө к ә р *(Олонсо янына килеп).* Кая, нәрсә синең анда?

С а к ч ы. Бер бөтен ипи дә ике алма, әфәндем.

*Нөкәр төенчекны алып, зиндан капкасыннан кереп китә.*

## Сөннәт

*Зиндан эче.*

*Карадәрвиш калтырана-калтырана сынар кулы белән түөнчекне чиште. Ипине сындырды. Ипи эченнән бер пәке белән кәгазь килеп чыкты.*

*Карадәрвиш авызына ипи тутыра, кәгазь тотып, язуны укырга маташа. Чәйнәвеннән туктап, язуны кат-кат укый.*

*"Сир, син Гарәбстанда Коръәнне яттан өйрәнеп, хафиз булдың. Синең кебек Коръәнне моңлы мәкам белән укучы юк. Сине мөселман кешесеннән аерып булмый. Менә шушы пәке белән син үзенә үзең сөннәт яса. Ярасы төзәлеп беткәч, кычкырып азан әйт, моңлы итеп Коръән укы. Мәйданнарда йөреп мин синең юлбасар түгеллегең, мөселман кешесе икәнлегең турында кычкырырмын. Валлаһи, мин сине зинданнан йолып алачакмын! Синең Сакчың."*

*Тоткынның йөзе тантаналы рәвештә яктырып китте.*

*Бармаклары белән пәкенең үткенлеген тикшереп бакты.*

*Карадәрвишнең киеренке йөзе чалшаеп килде: ул сынар кулы белән интегә-интегә булса да үзен үзе сөннәтләде.*

## Моңлы азан

*Базар мәйданындагы калкулыкка басып Сакчы халыкка эндәште:.*

—Мөселманнар! Минем юлдашым харами Педро Бургос түгел! Ул чын мөселман кешесе, әлхәмдүлиллаһ. Аның һичбер гаебе юк, әфәнделәр. Барып карагыз зинданга, ул чын мөселман кешесе буларак, кечкенәдән сөннәткә утыртылган. Сез беләсез карак Педро ул чын христиан иде, сөннәтсез иде. Бургос ике куллы иде. Бу бичараның бер кулы юк!

Т а в ы ш л а р:

—Ул Педро белән бер чыбыктан сөрелгән!

—Аттыр моннан, килмешәк!

—Чыннан да әллә ялгышлык бармы бу эштә?

*Сакчы шәһәрнең үзәк мәйданына барып тагын сөрән салды:*

—Мөселманнар! Аның гаебе юк, ул Бургос түгел, аның исеме Исрафил, ул чын мөселман кешесе! Аның сөннәте бар, әфәнделәр!

*Сакчы Хөкемдарлар йорты каршында да шул ук сүзләрне кабатлады.*

*Таң алды. Мөселман шәһәренең манзарасы: мәчетләр, кәрвансарайлар, базарлар.*

*Зиндан капкасы. Зиндан эченнән азан әйткән ишетелә. Бу—Карадәрвиш тавышы. Ул көчле матур аһәң белән азан әйтә.*

*Башка манаралар аңа кушыла.*

Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр,
Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр!

*Мөселманнар мәчеткә җыела. Бөтенесе дә туктап азан тынлый.*

*Имам сәерсенгән, каушаган.*

И м а м. Гаҗәеп матур тавыш! Каян килә бу азан? Кем, кайсы мөәззин шундый могҗиза ясый?

*Азан дәвам итә.*

Әшһәдү әллә иләһә иллаллаһ,
Әшһәдү әллә иләһә иллаллаһ.

*Голамә соклянудан гаҗиз булган, барысының да йөзе балкый иде.*

—Бу теге зиндандагы тоткын Педро шулай азан әйтә диләр.

—Бургос түгел икән лә ул, аны ялгыш тотканнар, ди бит. Бу Педрога охшаган мөселман кешесе, ди.

*Сакчы тараткан хәбәрдән соң халык фикере икегә аерылды. Баш казый үлем җәзасын кире какты. Бераз сабыр итәргә боерды.*

Әшһәдү әннә Мөхәммәдү рәсүлуллаһ,
Әшһәдү әннә Мөхәммәдү рәсүлуллаһ!

*Зиндан капкасы янына азан тыңларга халык җыелган. Халык арасыннан бай киенгән бер сәүдәгәр килеп чыкты.*

Хәягалел ссәлах,
Хәягалел ссәлах!
Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр,
Лә иләһә иллаллаһ.

Сәүдәгәр. Гаҗәеп мәкам! *(Сәүдәгәр янына Сакчы килә. Кызып-кызып аның колагына нидер сөйли. Нөкәрләр башлыгына.)* Хөрмәтле тәкъсир, гаделлекне якларга алынган адәми зат, бу мөәззин белән күрешергә рөхсәт итче!

Башлык. Ярамый!

Сәүдәгәр *(яшертен генә Башлыкның учына акча сона).* Зинһар, тәкъсир...

Башлык *(сакчыларга).* Үткәреп җибәрегез бу әфәндене!

*Сәүдәгәр капкадан уза.*

## Идел буе сәүдәгәре

*Мәхкәмә Йортындагы тәбәнәк өстәлчекләр янында хөкемдарлар утыра. Сәүдәгәр керә. Хөкемдарларга тәгъзим ясый.*

Сәүдәгәр. Әссәләмү галәйкүм!.. Мин постаулар, киек-җәнлек тиреләре белән сәүдә итүче алтын тәхетле Җуси Олысының ватандашы буламын. Азиядә, Фрәнк илләрендә, Һиндстанда сәүдәм бар. Исемем Турай. Хәзерендә минем Хаҗга китеп барышым. Хаҗ юлында йөргәндә минем бер колны азат итәсем килә.

Хөкемдар. Машалла, бик хуп, алтын тәхетле Җучи Олысының сәүдәгәре Турай хаҗи, машалла.

Сәүдәгәр. Сезнең зинданда бер тоткын бар. Аны юлбасар, ата җинаятьче Педро Бургос, дип атыйлар...

Хөкемдар. Әйе, ул юлбасарны без бер атнадан җәза мәйданында...

Сәүдәгәр. Тәкъсирем! Ул Бургос түгел, аның исеме Исрафил! Тәртипләп сөйләргә рөхсәт итегез, зинһар.

Хөкемдар. Дәвам ит, Турай сәүдәгәр.

Сәүдәгәр. Беренчедән Педро христиан кешесе. Мәгълүмдер ки, христианнарның барысы да сөннәтсез, хөкемдарларым. Мәгълүмдер ки, Бургос зинданда утырганда Коръән уку түгел, гел атасы-анасы белән сүгенеп, көфер сүз кычкырып яткан. Мин бичара Исрафилның ничек итеп гүзәл мәкам белән Коръән укыганын тынлап килдем. Һо-о, тәкъсирем!

Утырышчы. Искиткеч матур тавыш!

Икенче утырышчы. Сирәк очрый торган мәкам!

Өченчесе. Чыннан да ул мөселмандыр, мөселман булмаган кеше шулай итеп, үзәкләргә үтәрдәй итеп Коръән укый алмас!

Сәүдәгәр. Мин дөньяны әйләнеп чыккан кеше. Бер җирдә дә болай итеп, матур, куәтле тавыш белән азан әйткәннәрен ишеткәнем булмады... Хөкемдар әфәнделәр, чыгарыгыз аны иреккә, аның гаебе юк!

*Урамда җыелган халык шаулый:*

—Исрафил хәзрәтләрен азат итегез!

—Ул Бургос түгел! Ул мөселман кешесе!

—Исрафилны иреккә чыгарыгыз!

Сәүдәгәр. Ишетәсезме, халык таләп итә!

Хөкемдар. Сез аның сөннәтен тикшердегезме?

Утырышчылар. Тикшердек, тәкъсир.

Хөкемдар. Ничек соң?

Утырышчылар. Һо-о, әлхәмдүлиллаһ, Исафил хәзрәтләре сөннәтле!

Хөкемдар. Ярый, Турай сәүдәгәр хәзрәтләре, без Исрафил мөәззинне сезнең карамакка егерме мең алтын бәрабәренә зинданнан чыгарабыз.

Сәүдәгәр. Шөкран! Тәшәккүр, тәкъсир! Аллаһ сезгә юлдаш булсын!

# Юлдашлар

*Идел дәрьясы ярларына якын уза торган юл өсте. Яр буйлатып ике дәрвиш бара. Аларның берсе мөселман чалмасы ураган Карадәрвиш, икенчесе—Сакчы, ул да суфилар киемендә, аның сыртында һаман шул биштәр. Туктыйлар. Капчыгыннан каты-коты чыгарып, Сакчы табын әзерли. Дәрвиш гыйбадәт кыла. Аның гыйбадәте башта намаз укуга охшый, аннан ул йогаларча аяк бөкләп утыра. Кулында тәсбих. Карадәрвиш башта кычкырып, сонра пышылдап дога укый.*

—Аум мани падме һум! Йа раббым, җиһанны афәттән коткар, дөньяны мурдан коткар. Аум мани падме һум... *(Гыйбадәтен тәмамлый.)* Борынгылар анлаганнар бит, нәрсә ул Алла? дигән сорауга: Алла—ул Хакыйкать, Игелек һәм Гүзәллек, дигәннәр. Алла ул ялганчы була алмый, Алла—үзе Хакыйкать, дөреслек. Алла яманлык кыла алмый, ул миһербан иясе. Алла ул ямьсез була алмый, ул гүзәллекнең үзе.

*Сакчы сүзгә катнашырга ният кылды:*

—Муса пәйгамбәр,—дип башлады ул сүзен.—Синай тавында: йа Иляһем, сине күрәсем килә, күрен мина, дип Аллага ялвара. Алла ана күренми. Минем барлыгыма шикләнсән, әнә тауга бак, ди. Шул чак тау калтырый башлый. Муса иман китерә. Димәк, Алла гүзәллекнең үзе булгач, Мусага гүзәллек күренсә, Муса егылып үләчәк. Гүзәллек кешене үтерәмени?

*Карадәрвиш тирә-якта җан иясе булмаса да, карангалап алды:*

—Кастилиядә, Римда булсаң,—диде ул ярымпышылдап,—сине шундук утка ыргытырлар иде бу ересең өчен. Сафсата! Гүзәллек кеше үтерми. Аллаһны күреп, танып белергә адәмнең зиһнияте, бәдәнияте әзер түгел. Аум мани падме һум. Гыйбадәт—ул, дустым, мәнгелекне тою, мәнгелекне анларга, анлатырга тырышу. Ихлас гыйбадәттә гүзәллек, мәхәббәт, әзләнү тәвәккәллеге, батырлык, корбан булырга әзер тору, максатка тугрылык, үҗәтлек тупланган. Әгәр дә син курка-курка гыйбадәт кылсаң, икеләнеп кенә инансаң, ул гыйбадәт булмый, сүзләрең дөрес булса да ул ялган аллаларга сихер догасы уку гына булып калачак. Вәхши, кыргый кеше, надан бәндә үзе өчен генә гыйбадәт кыла. Ана гына савап булсын, аның гаиләсенә генә әҗер булсын. Зиһенле адәм бөтен дөнья өчен гыйбадәт кыла. Кыргый, надан, тупас бәндә белән мәдәниятле адәм арасында аерма шул.

*Карадәрвишнең бу сүзләрен башында пешерә иде, ахрысы, Сакчы шөгыленнән туктап, бер ноктага карап бераз уйланып утырды. Ул Карадәрвишнең фикере белән килешкәнлеген раслагандай:*

—Хуш!—диде дә янә табын янында әвәрә килүен дәвам итте.

*Карадәрвиш тирән сулыш алып, нотыгын алга сөрде:*

—Адәми затның иң зур дошманы—курку! Курку—йогышлы авыру. Я-анаабы-ыз, дип кычкырсаң, мәчеттә яки чиркәүдә гыйбадәт кылучы меңнәрчә кеше янгыннан түгел, берсен-берсе таптап, сытылып һәлак булачак. Кеше үзенә бәла килер, дип куркып яшәсә, ул бәла аңа һичшиксез киләчәк. Бу бәлане чакырып китерү, афәтне теләү булачак. Бәс, куркуны җинәргә кирәк. Менә без синең белән мөслеманнардан куркуыбыз аркасында батырга әверелеп, куркынычның уртасына, татарлар-мөселманнар арасында йөрибез. *(Ул үз фәлсәфәсеннән арып, башына ял бирү ниятеннән, торып киерелде, калтыранып алды, тирә-якка күз салды.)* Нинди гүзәллек бу якларда, Олонсо.

—Кастилия гүзәл түгелме, сир?—диде сакчы.

—Гүзәл! Тик монда, Идел буенда, тугайларда, урманнарда аерым гүзәллек. Йомшак гүзәллек. Кастилиядә кырыс гүзәллек...

—Гүзәллек дип, сир, табигать гүзәллеге турында гына әйтәсеңме? Әллә...

—Хатын-кызлар турында да әйтәм. Болгар-татар кызларында яшерелгән гүзәллек, серле гүзәллек, Олонсо.

—Аскет монах Руиның дөньяга карашы алышына барамы?

—Көл әйдә, көл, Олонсо. Мин көләргә лаек бәндә. Язмыш мине ниләр генә кыландырмый. Дин факультеты студенты, аннан "Фәкыйрь монахлар

тәшкилаты" әгъзасы, аннан кардинал, аннан Бөек Инквизитор, аннан хәерче дәрвиш, хәзер инде мөселман суфые.

—Сәедләр токымы шәйхелислам!.. Сүз иярә сүз чыккач әйтим: Аксак Тимер сәедләрне аеруча хөрмәт итә, аларны хөкүмәт тәэминендә тота икән. Синең токым хәзер сәедләрдән үк килә бит. Шәҗәрәңне барлап чык.

—Шәҗәрәм әзер, Олонсо.

—Әйе, татар кызларының гүзәллеге турында аскет монахның фикерен тыңлап бетермәдек бит әле,—диде Сакчы.—Аһ, Бөек Болгар ханы Габдулланың кызы Гайшә тутай, аһ-ваһ-ваһ, сир... Менә кайда ул тыйнак гүзәллек.

—Гайшә тутай гүзә-әл...—дип җөпләде Карадәрвиш,—Ләкин Кастилиядә бер гүзәл калды...

—Аскет монах үзенең дәртен үтереп бетермәдемени әле?

—Гөнаһлы булдым, Олонсо... Женси хисләр алар, дустым, бер генә женескә ябыштырып куя торган хисләр түгел. Ир кешегә женси ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен теләсә кайсы хатын да ярый. Бу—мәхәббәт түгел. Хатын кеше дә теләсә кайсы ир белән кендектәш була ала. Бу да мәхәббәт түгел. Мәхәббәт ул—танып-белү сөреше, ул ике женесне якынайта, берсе икенчесенең каршында җанын ача, рухын чишендерә. Алар бер-берсе аша күктән иңгән рухи гайрәтне танып-беләләр. Мәхәббәт ул милләтне, ыругны сафландырыр өчен яралтылган хис. Мәхәббәт—ул сайлап алу ысулы. Мәхәббәттән туган балалар нәселле, пакь, сәламәт һәм матур булалар. Мәхәббәт ул милләтне горур, куәтле итә. Мәхәббәтсез генә, бары тик женси хисләрне канәгатьләнерү өчен генә кешеләр өйләнешсә, милләт, ыруг зәгыйфьләнә, тора-бара юкка чыга. Ир белән хатын мәхәббәт аркасында ярашканлык хасил итсә, ул җинелмәс бөек кодрәткә әверелә. Ир кеше акыл белән сөя, хатын-кыз серле сөю аша зиһниятле була. Хатын-кыз дөньяның иң серле заты. Ул дөньяның тоткасы. Кешеләр мәхәббәтне бәдәни-женси бушануга гына кайтарып калдырдылар. Мәхәббәт—ул галәмнәрдән алган куәт, галәмнәргә таралачак кодрәт булырга тиеш. Фикерләре бозык ирләр хатын-кызга гөнаһ кылыр өчен савыт, дип кенә карый. Бу хәлне дә шулай кирәк, дип аңлатып була. Монда да табигый мөнәсәбәтләр хөкем сөрә.

—Сир, аскет монах эчендә шундый дәрт һәм тирән фәлсәфә посып ятканын белмәгән идем,—диде дә Сакчы ризык саласы савытларны яшел үлән учмасы белән сөртә башлады.

—Көл әйдә, көл!—диде Карадәрвиш.—Көлү—ул тормышның тоткасы... Ләкин мин син уйлаганча ук аскет түгел идем.

## Мәхәббәт ничә була?

*Сакчы хуҗасының бик тә әһәмиятле нәрсә турында сөйләргә җыенганын чамалады. Ашыктырсаң, сөйләмәс дип куркып, тын калуны хуп күрде. Янәсе, аны монахның фикерләре кызыксындырмый.*

*Сөйләргәме, сөйләмәскәме, дигәндәй, Карадәрвиш икеләнеп, туктап калды. Бер карарга килеп, тирән сулыш алды. Аягүрә басып озын һәм әһәмиятле нотык сөйләргә җыенды. Ул инде үзе сөйләячәк дөнья мохитенә барып керде кебек.*

—Дөньядагы вакыйгаларны, диннәрне, гөнаһ кылучыларны күзәтә-күзәтә мин башкаларга сөйләнергә тиеш булмаган нәтиҗәгә килдем, Олонсо. Ләкин мин аны сиңа сөйләмәсәм, тыныч кына яши алмамдыр, шәт. Мәхәббәт, ярату, сөюләр төрле була. Аллаһка мәхәббәт, пәйгамбәргә мәхәббәт, ата-анага мәхәббәт, хатынга мәхәббәт, балага мәхәббәт, ватанга мәхәббәт. Жиденче мәхәббәт барына мин ышанмаган булыр идем...

Беатриса миңа мәхәббәт ләззәте бирде. Шул мәхәббәттән ваз кичеп, мин аскет монах булдым. Аскетлыгым ватаныма, милләтемә, динемә булган мәхәббәтем аркасында. Шуның аркасында хәзер карадәрвиш чапаны бөркәнеп илдән илгә кангырып йөрмеш көнем. Шуның аркасында мин маглар, йогалар, гурулардан дәресләр алдым. Шул мәхәббәтем аркасында мин Самофракиянең салкын, юеш мәгарәләренә төштем, Пирамидаларның серле баскычларыннан фиргавеннәрнең табутларын төшеп карадым. Мин үлем белән

йөзгә-йөз мен мәртәбәләр очраштым. Монахлар, еллар буе зинданда утыручы җинаятьчеләр, хәтта затлы нәсел саналган зыялылар арасында да ир белән ир арасындагы мөнәсәбәтләрне мин ишетмәмешкә, күрмәмешкә салыштым. Ләкин Изге китапларда хәбәр ителгән күтләклеккә, хәтта ир белән ир арасындагы сөю хисләренен булуына мин ышандым.

*Сакчы хуҗасынын әллә кайларга алып китәчәк нотыгыннан риза түгел иде, ахрысы, чирәм учмасын бер кырга атып, савытын җәймәгә ташлады.*

—Ул сөю түгел, сир, бозыклык!—диде Сакчы.

*Анын ризасызлыгы Карадәрвишкә бик тә кулай иде, ул яна көч белән нотыгын дәвам итте:*

—Ни өчен табигать ир кешеләргә ике имчәк башы биргән? Нигә кирәк булган ул? Димәк, ул имчәкләр кайчандыр ир кешегә кирәк булган, ягъни ул бала имезгән. Яки ул имиләр киләчәктә кирәк булачак, бала имезергә. Икесенен берсе. Ир кешегә хатын-кыз башлангычы да салынган булып чыга.

*Сакчы түзеп утыра алмыйча, сикереп торды да:*

—Бөек Инквизитор үзе ересь сөйли!—дип кычкырды.

—Еретик булмас өчен зиһен чарлау бу, Олонсо!—диде Карадәрвиш тыныч кына.—Хатын кеше беркайчан да ир зат була алмый. Ир кеше ир кешегә хатын сыйфатында була ала. Ахырзаман алдыннан бер иргә кырык хатын туры киләр, дигән. Евнухларга, хатыншак ирләргә дә ир кирәк бит. Алар да хатыннар исемлегендә тора. Шулай булгач, бүген бер иргә утыз хатын туры килә.

*Сакчы—Олонсо үзе дә сизмәстән остазынын фәлсәфәсенә кереп бара иде, ул тынычлана төшеп, нотыкчынын каршысына утырды.*

—Дөнья бетәргә күп калмаган икән. Яшәп калыйк,—диде ул җәймәгә җайлап утыргач.

—Иисус Христос авызыннан хатын-кызны кимсеткән бер генә сүз дә чыкмаган. Бары тик Христосның апостолы Павел үзенен васыятьләрендә, вәгазьләрендә хатыннарны түбәнгә куя. Әнә шул апостол Павелнын хатасы хатыннарны җәберләү өчен канун буларак христиан диненә кабул ителгән. Бәлки Павелнын язганнарын дөрес тәрҗемә итмәгәннәрдер, бәлки шәрехләүчеләр хатыннарны коллыкта тоту өчен, ул сүзләрен изге китапка махсус өстәп куйганнардыр. Изге Климент Александрийский, апостол Иоганнын шәкерте үзенен язмаларында болай язып калдырган. "Сора син, Соломея, Аннан *(Хриcтостан)*: синен хакимиятен кайчан килер? дигән. Иисус Христос җавап биргән: кайчан икәүвесе бер булыр, ир хатынга, хатын иргә әверелер һәм ир башлангычы да, хатын башлангычы да калмагач."

—Сир, сез артык тирәнгә киттегез бугай. Кире чыга алмабыз бит без бу суфилар чонгылыннан.

—Бу фәлсәфәнен беренче өлеше ир белән хатын бер-берсен анлап, бер фикердә булып, ярашып яши башлагач, дип анлап була. Ә икенчесен ничек анларга, ничек анлатырга? Илаһият факультетында бу турыда берәү дә сөйләмәде. Мин бу турыда Копт монастырындагы китапханәдә укыдым. Стоматра, өченче китап, сигезенче бүлекнен туксан икенче бите. Ир башлангычы да, хатын башлангычы да калмагач, кайсы вакыт була сон ул, сеньор Олонсо? Бу ирләрнен хатын ягына күчеп беткәнен анлатмыймы?

—Сир, сез минем башымны бутап ташладыгыз. Минем башка шул гына җитмәгән иде.

—Коръәнне күзенне ачыбрак укы, анда язылган: Лут пәйгамбәр өендәге ике мәхәббәт егетне көчләргә бөтен шәһәр ирләре ажгырып килеп җитә. Лутнын гүзәл кызларына ирләр борылып та карамыйлар. Кызларын үзенә булсын, котыласын килсә, безгә син бу чибәр кунак егетләренне бир,—дип акыралар.

—Шуна күрә, Аллаһ аларны юкка чыгара да, сир.

—Димәк, киләчәктә бүгенге кебек ир—ир зат, хатын—хатын булып кала алмый. Аларнын аермалары бетәчәк. Алла Аләмне балчыктан ясаган да җан өргән, хатын кирәк булгач, Аләмнен кабыргасын сындырып алган да анабыз Һаваны барлыкка китергән. Димәк, ир Аләм ана булган.

—Тефү, әстәгыйфирулла! Кастилиядә моның өчен икебезне дә утка атачаклар бит. Сезне—сөйләгәнегез өчен, мине—тыңлаганыма күрә, яндырачаклар.

—Шуңа күрә, мин бу сүзләрне Толедода сөйләмим, татарлар җирендә сөйләп торам.

—Сир, ватанга кайткач, Ялган Бонифацийны фаш иткәч, сез янадан Бөек Инквизитор булгач, бу фикерләрегезне кардиналларыгызга, шәкертләрегезгә җиткерерсезме?

—Тәртип урнашкач, ягъни, бөтен кардиналларым да минем белән теләктәш, фикердәш булгач, һичшиксез, сөйлиячәкмен... *(Тирән сулыш алгач.)* Һу, Аллага шөкер, мин бушандым.

*Икесе дә тынып калды.*

## Сәйф Сараи ересь сөйләгәнме?

*Карадәрвиш чыннан да мордар китәрлек сүз сөйләде. Бераз уйланып утырганнан соң, Сакчы әйтеп куйды.*

—Хәзер минем бушанасым калды,—диде.

*Карадәрвиш аның ачыктан-ачык сөйләшүен күптәннән тели иде:*

—Сизеп йөрим,—диде ул аны хуплагандай.—синең башыңда ниндидер авыр уй бар. Әйтергә телисең, әйтмисең. Кыстамадым, өлгерсең әле, үзе сөйләр, дидем. Мин ком чүленә Копт монастырьлары ягына кереп киткәч, сиңа нидер булды. Мин кайтканда син бик пошаманда идең.

*Сакчы тирән итеп сулыш алды:*

—Мисырда,—дип башлады ул авыр нотыгын.—Әзһәр университетында мин татар шагыйре Сәйф Сараи белән табындаш булдым. Һо-о, менә кайда галим, менә кайда шагыйрь, менә кайда галәмче. Сараи 1321 елда Идел буендагы Камышлы каласында туган. Куәтле шәхес. Ул Аксак Тимер белән тыныша алмыйча, Мысырга һиҗрәт иткән. Аның иң күркәм әсәре "Сөһәйл белән Гөлдерсен". Ул Аксак Тимернең Гүргәнечне җир белән тигезләве турында нәфрәтләнеп яза. Гүргәнечнең шаһзадәсе Сөһәйл Аксак Тимергә әсир төшә. Җәллад аны базга, зинданга ябып тота. Әмир Тимернең иң сөекле кызы Гөлдерсен әсир баһадирга гашыйк була. Кыз зиндан ишеген ача, алар икәүләп чүлгә кереп качалар. Кыз сусаудан хәлсезләнеп чүл уртасында җан тарта. Аның җансыз гәүдәсе янында Сөһәйл үз хәнҗәрен күкрәгенә батырып, һәлак була.

*Соңгы сүзләрне әйткәндә Сакчының тавышы калтырап куйды. Аның тамагына әче төер килеп тыгылды булса кирәк. Ул хикәясен тәмамлап, башын читкә борды.*

*Карадәрвиш соклануын яшерә алмады:*

—Гүзәл әсәр!—дип куйды.

*Бераздан, тынычлана төшкәч, Сакчы Олонсо нотыгын дәвам итте:*

—Ләкин эш Сәйф Сараиның шагыйрьлегендә түгел. Аның галәмче булуында, сир. Мин Сәйф Сараиның зиккуратына мендем. Ул анда зурайткыч пыялалар белән күкне, йолдызларны, Айны, Кояшны тикшерә. Егылып китмәгез, сир. Мин шундый ересь әйтәчәкмен, Аллам сакласын. Сәйф Сараи әйтә: Кояш Җир тирәли түгел, Җир Кояш тирәли әйләнә, ди. Һәм ул аны әсәренә дә керткән: кыз әйләнде бу яшь батыр тирәли, Җир әйләнгән кебек Кояш тирәли!

*Бу юлы Карадәрвиш тораташ булып каткандай булды, сүз табалмыйча ул ике кулын да сакчысы ягына болгап, чебенне куарга теләгәндәй, әле генә әйтелгән фикерне кабул итмичә:*

—Тефү-тефү, авызыңнан җил алсын!—дип кычкырды.—Ничек? Каян килеп? Библиядә дә, Коръәндә дә андый сүз юк! Бу ересь. Моны сөйләү түгел, бу турыда уйларга да ярмый. Син тилергәнсең, Олонсо.

*Җиңү чираты Сакчыда иде:*

—Димәк, Сәйф Сараи да тилергән!—диде нотыкчы.

*Карадәрвиш әле һаман айный алмый иде:*

—Бу яналык кинәт башыма китереп орды, сабыр ит, мин бераз бу гадәттән тыш сүзләргә күнегим. Форсат бир, зинһар. Башым чуалды. Бу ересь, Олонсо.

*Сакчы берни булмагандай сабыр иде һәм ул фикеренә мөһер суккандай итеп:*

—Бу—Аллаһның кодрәте, сир!—диде.

*Тагын тынлык урнашты. Ара-тирә Карадәрвиш кенә һаман кемгәдер ачулана: кеше ышанмас сүзне сөйләргә рөхсәтем юк, дип сөйләнеп алгалый.*

—Ә мин ана ышандым!—диде юлдаш.—Коръәндә бар бит шуна киная, сир. Ул бик гади анлатыла бит. Коръәнне сез яттан беләсез ич. Анда әйтелгән: Кояш Аллаһ тарафыннан куелган юл белән, үзенә билгеләнгән урынына таба очар. Айга да без төгәл тугым һәм фасыллар тәгаенләдек. Ул янадан тал чыбыгы кебек булып әйләнеп кайтыр. Тал чыбыгы кебек булганда анын олы өлешен Кояш белән Ай арасындагы Жир каплый. Жир шул араны узып китә, димәк, Жир Кояш тирәли әйләнә булып чыга. Кояш тотылганда Жир белән Кояш арасына Ай керә, анысы Жир тирәли әйләнә. Жир белән Ай икесе бергә Кояш тирәли йөри.

—Жир Кояш тирәли йөриме?—дип сорады Карадәрвиш.—Птолемей кая карый? Ул, даһи Птолемей нииндидер бер татар галиме Сәйф Сараидан да ахмаграк булып чыгамыни?

—Ахмак түгел ул Птолемей, анын зиһене өлгереп житмәгән.

—Булды! Хәттин ашмыйк. Бу фикерләр шушында, Идел буенда калсын. Безгә ияреп йөрмәсен... Сәяхәтебезнен бу өлешенә йомгак ясыйк... һәм сафсатадан хакыйкый хәяткә кайтыйк... Азияне, Ауропаны үз кулында тоткан төрек солтаны Баязид Елдырымнын мөхтәшәм сараен син күрден, Олонсо. Баязидның миллион кылычы булуын да белден. Якын тирәдә ана каршы торырлык көч юк.

—Бар, сир. Московия, Балкан, Кастилия, Франк, Герман берләшсә...

—Берләшеп карадылар бит инде. Күпме булды хач-тәре сәфәрләре. Алтын Сарайнын алтын тәхетендә утыручы бөек Туктамыш хан белән әмир Идегәй икесе дус булганда Алтын Урданы беркем дә алалмас. Ана каршы торырлык көч юк тирә-якта. Бөек шәхесләр. Идегәй үзен хан дәрәжәсенә куйган, кәттә әмир. Болгардагы көчне күрдек. Таш калалар, таш мәчетләр...

*Ул арада сакчы табын өлгертте.*

—Боерыгыз, сир!—диде ул юлдашына.

—Капкалый тор, Олонсо,—диде Дәрвиш.

—Һич юк, сир. Сез башлагыз!

*Карадәрвиш тәяммум тәһарәте алганнан соң табын янына елышты. Тәгамгә үрелгәндә:*

—Бисмилләһ ир рәхмән ир рахим. Житештек, Олонсо,—диде.

*Сөйләшмичә генә капкаладылар.*

—Гарәп телен, Коръәнне өйрәнәөйрәнә, мөселман илләрендә: Һиндстанында, госманлыларда йөри-йөри чын мөселман булып барасыз бугай, сир,—диде кече юлдаш.

*Карадәрвиш сонгы чәйнәм ризыгын йотып, бераз утырганнан сон, ике учын күтәреп дога укыды.*

—Субханаллаһу вә әлхәмдүлиллаһи вә ләә илаһә иллалаһу вә аллаһу әкбәр. Вә ләхәүлә вә лә куате, илла билилләһи галиел газыйм.

*Сакчы ана сокланып карап торды да:*

—Сир,—диде,—сез чын мөселманнан да саф укыйсыз Коръәнне. Сезне сәедләрдән аерып булмый, валлаһи.

—Матур сүзләр! Вакыты-вакыты белән мин үземне мөселман буларак хис итәм. Ислам белән христиан дине игзәк туганнар бит. Әллә син дә мөселманлыкка күчәсенме?

—Сир, сез мөселман динен кабул итсәгез, мин дә күчәм.

—Коръәннән мин бик күп нәрсәләргә өйрәндем. Аллагысын Алла белә, әгәр дә мин чын христиан ата-анадан яралмаган булсам, һичшиксез, Исламны кабул иткән булыр идем. Ләкин мин христиан, христианнын да католигы. Католикнын да Бөек Инквизиторы!

—Сез мен тапкыр хаклы! Дин алыштыру ул денсез калу, сир.

## Кайсы дин дөньяга баш булачак?

—Динсезлектән денсезлеккә бер адым,—дип кабатлады Сакчы.

*Карадәрвиш көлә башлады, кинәт туктап, җитди сүзгә күчте.*

—Хәтерлисеңме, Тәбриз каласындагы кәрвансарайдагы гауганы? Анда азау ярган суфыйлар, монахлар, раввиннар җыелган иде. *"Иң яхшы дин ул—Ислям!—дип кычкыра чалмалы дәрвиш.—"Мөселман кешесе чиста, итагатьле, миһербанлы була. Исламны кылыч белән кертмәгән Мөхәммәд. Мәҗүсиләр үз теләкләре белән мөселман булды. Ә Христиан дине ул бары тик үтереш-суеш белән ирексезләп чукындыруга гына корылган. Христос әйтә: кем минем белән килешми, шуны өстерәп минем янга алып килегез дә, таш белән бәреп үтерегез, ди. Шулмы миһербанлы дин? Шулмы Иисус Христосыгызның игелеге?"*... Шуннан христиан карты торып басты. *"Христиан дине Ислямнан өлкәнрәк, дип башлады ул. Ислям сурәт ясарга рөхсәт итми. Шуна күрә, Ислям илләрендә бөек рәссамнар юк. Мөселман кешесе авыз ачып җырларга курка. Шуна күрә, сездә авызы ачылмый торган җырчылар гына. Мөселман аракы эчми. Эчә башласа, динен дә, телен дә, исемен дә сатып эчә... Мөселман дуңгыз ите ашамый. Исерткеч эчкәч, үзе дуңгызга әверелә."*... Шуннан өченче берсе калыкты: *"Будда диненә җитми инде, мосафирлар. Ислям да, Христианлык та алдауга корылган, җәмәгать. Аларның икесе дә халыкны булмаган оҗмах белән алдый, ымсындыра. Шуңа ышанып, кара халык шуларга бил бөгә. Янәсе, киләчәктә шуның өчен аңа җәннәт булыр. Тоттырдылар ди сиңа җәннәт! Җәннәт булса, бу дөньяда сине кол итеп чыбыркылаган бай, иң башта үзе түргә менеп утырачак, тагын сине чыбыркылаячак. Будда ичмасам алдамыйча гына барысына да күнәргә куша. Изел, түз, ләкин киләчәктә түләү сорама!.."* Шуннан мин дә бәхәскә кушылдым. Аларның һәммәсе дә үзенчә хаклы иде. *Дөрес, христианнар баш булган илләрдә бөтен төр сәнгатьләр дә чәчәк ата. Дөрес, Будда илләрендә дә шулай ук гүзәл биналар күп. Дөрес, Ислямның да мәһабәт мәчетләре кешеләрне чиксез сокландыра. Ләкин могътәбәр Олонсо вә мосафирлар, диннәрне сәнгатькә юл бирәме, юкмы, дип кенә карау, сукыр суфилык булыр иде. Диннәрне менә бу тарафлап карап тикшерергә кирәк, юлдашлар. Үзенең фикри куәте белән, зиһеннәрне үзенә буйсындыра алуы белән бер-берсеннән аерыла диннәр. Диннәрнең кайсы көчле, кайсы дин әһеленең рухы нык? Кайсы диндәге халык баш булыр дөньяга? Мин сезнең каршыгызга менә шундый сөаль ташлыйм, мосафирлар. Сез җавап бирегез мина, дөнья гизгән укымышлы дәрвишләр! Кайсы диндәге ил дөньяны яулар?..* Китте гауга, китте җәнҗал. Кайсы: Ислям баш була, ди; кайсысы: яһүдләр, кайсысы: Будда баш була, ди. Ләкин аларның берсе дә хаклы түгел иде. *Дөньяда иң гади билгесе булган дин калачак, суфыйлар. Мөселман тамгасы яңа туган ай—Һилял. Ай гашыйкълар билгесе. Хыялый кеше рәхимсез дөньяга баш була аламы? Беркайчан да дөнья шагыйрь кулында булачак түгел. Буддачыларның тамгасы торараташсын. Таш сын ясап гомер уздырган рәссам беркайчан да оста сугышчы була алмый. Яһүдләр күп почмаклы йолдызга табына. Йолдыз чүпләп яшәгәннәр дә ерак баралмас. Иң гади, иң куәтле билге—хач! Хач дөньяга баш булачак, мосафирлар!.. Телисезме, теләмисезме, хач дөньяның тоткасы. Илләр гизеп, мин Ислямны да, Будданы да, Тәүратны да—барысын да өйрәндем. Шунда бер бөек хакыйкатькә төшендем. Дөньядагы халыклар хачтан башка яши алмый. Тартма ясарга да аркылы агач, ягъни хач кирәк. Күпер салырга да аркылы бүрәнә, ягъни хач кирәк. Кием тегәр өчен кайчы, ягъни хач кирәк. Утын кискәндә дә без бүрнәгә аркылы салып, пычкы белән хач хасил итәбез түгелме? Мөселман карты таянып йөри торган таяк та аркылы агачка корылган—хач! Мөселман яугиренең кулында хач шәкелле кылыч булыр. Хач—христиан билгесе! Хач җирдә генә түгел, һавада да очып йөри. Кошларга карагыз сез, алар да хач сурәтендә оча. Ислям кешесе дә, буддачылар да, үзләре*

*дә сизмәстән, һәр йорт нигезенә христиан билгесе, хач салып калдыра. Шулай булгач, дөнья хачка-тәрегә табыначак!*

*Яшьрәк юлаучы елмаеп куйды да әйтте:*

—Шуннан китте мәхшәр, мосафирлар шаша-шаша чукына башладылар... Сез үтә ышандырырлык итеп сөйлисез.

—Син, сеньор Олонсо, Бөек Инквизитор сакчысы вазифаларыннан азат! Бар, кайт үз иленә, доганда мине дә онытма, минем өчен Аллаңнан ярдәм сора.

—Сир, мин сезне ташлый алмыймын. Ярдәмчесез, дуссыз калган кешене ташлап китү гөнаһ.

—Рәхмәт, Олонсо! Син азат, теләгән чагыңда син минем яннан китә аласың. Син ирекле!

—Сир, мин сезне Ватанга кайтып Ялган Бонифацийны фаш итеп, аның урынына утырганчыга кадәр саклармын. Менә шуннан соң мин азат булып, илемә кайтырмын, иншалла!

—Бирсен Ходай!..—диде Карадәрвиш, аннан соң янә табигать манзарасына бакты.—Карале, гүзәл, бай җирдә яши бу татарлар. Болгар искиткеч шәһәр. Ана кызыкмаган патшалар юктыр!

—Кызыгалар икән, аны барыбер басачаклар *(Касәгә чәй сала)*. Боерыгыз, сир.

*Карадәрвиш:*

—Үзең дә житеш,—диде.

—Сир, сез капканнан соң...

—Ташлале шул гадәтеңне, сир да мир. Лә иляһә иллалаһу, Мөхәммәде рәсулуллаһ, дип әйткәч, мин мөселман булдым, син мөселман, мин мөселман, мөселман белән мөселман арасы тигез. Мөселманга икенче мөселман боерыкчы була алмый, безнең боерыкчыбыз бер Аллаһу Тәгалә. Без тигез, мин кардинал түгел, син аның тән сакчысы түгел. Бисмиллаһ ир-рахмән иррахим! *(Чәй уртлый.)*

—Бу дөньядан үз әҗәлең белән китәргә язган булса, һичшиксез, сәгадәтне күрәчәксең. Үтерелмәс өчен үтерә-үтертә син Жир өстендә җәннәт корачаксың.

—Ул җәннәттә барысы да тигез булыр.—диде Сакчы.—Җәннәтнең биек вә бөек гөмбәзе астында христиан кешесе үзенең Библиясе белән, Будда кешесе үзенең Трипитакасы белән, индус кешесе үзенең Ведасы белән, мөселман кешесе үзенең Коръәне белән, яһүд кешесе үзенең Тәүраты белән вә башка диндәгеләр үзләренең китаплары белән һич каршылыксыз-тату яшәячәк, чөнки бу китапларның барысы да бөек Рухтан—Илаһыдан ингән.

—Дөрес, шәкерт! Син дәресеңне яхшы үзләштергәнсең!—диде остаз.

*Карадәрвиш капчыгыннан шахмат тактасы чыгарды, фигураларны тезеп куйды.*

—Карале, Олонсо, монысы менә бу шакмакта тора идеме? Дөрес тезелгәнме?

*Сакчы шакмакларга карап:*

—Дөрес, сир!—диде.

—Башланган уенны тәмамлыйк, сеньор Олонсо! Нидән бәхәсләшкән идек әле без?

—Мин жинсәм, без Болгардан Сәмәркандка—әмир Аксак Тимер тарафына китәчәкбез. Сир жинсә, Болгардан урыс христианнар ягына юл тотачакбыз.

—Менә мин болай йөрим.

*Сакчы табын жыештырган жайдан гына фигураларны күчереп куя.*

—Сир, королегезне саклагыз!—диде табынчы.

—Дөрес, корольне сакларга кирәк! Син шаһ куйдың, Олонсо. Мин капландым. *(Сакчы йөри.)* Мат?

—Мат, сир. Димәк, без Аксак Тимер җәнаблары янына барабыз!

—Шаккаткыч! Мин университета укыганда шахмат батыры идем, мине жингән кеше булмады. Син Гарәбстанда да батырларны жиндең, Мисырда да, хәтта Болгар әмире Абдулланы да жиндең. Син моның серен, сихерен беләсең булыр. Ярар, киләсеңдә мин жинәм. Синеңчә булсын, киттек без Сәмәркандка.

—Хәерле юл!

—Бирсен Ходай! Киттек, Олонсо! Алда безне юл көтә... Болар кыргый татарлар түгел, дустым Олонсо. Аурупа

берни дә белми икән татарлар хакында. Татарлар кыргый түгел, татарлар батыр сугышчылар, матурлык, гүзәллек сөяләр, алар бу байлыкны, бу гүзәллекне ансат кына ятлар кулына бирмәс! Ә безнен кардиналлар тәхет өчен талаша, халыктан мал талый, бер-берсен утка ташлый. Менә кайда кыргыйлык, Олонсо. Азия кыргый түгел, Аурупа кыргый.

—Сәмаркандта бөек хаким Аксак Тимер, диләр, сир.

—Ярый, Аллага тапшырдык, баргач үз күзләребез белән күрербез. Болгар илен калдырып, Сәмаркандка—әмир Аксак Тимергә йөз тоттык, сеньор Олонсо!

—Ислам илендә мин сеньор Олонсо түгел, Мостафа дәрвиш.

—Һәйдә, киттек, Мостафа дәрвиш!

## Аксак Тимер янында

*Сәмарканд манзарасы. Шаһ Тимер сарае.*

*Аксак Тимернен чит ил кунаклары алдында горурлана торган тәхетханәсен сурәтләр өчен сурәтләү чаралары житмәс иде. Уң якта алтын батырып, кызыл агачтан ясалган, затлы тартма. Бу ышкафка да, зур сандыкка да охшаш тартмада көмеш савыт-саба саклана. Бу сандык алтыннан эшләнеп, эмаль белән бик матурлап бизәлгән, шулар өстенә ул асылташлар белән чуарланган, энже белән асылташлар арасында, урталыкта әстерхан чикләвеге кадәрле алмаз беркетелгән. Тартмага тезелгән алтын каймалы көмеш савыт-саба күренә. Тартмадан астарак кечкенә алтын өстәл тора. Анын биеклеге ике карыш, ягъни кырык сантиметр чамасы булыр. Ул да бик күп асылташлар белән бизәлгән. Өстәл өстендә зур гына зөмруд ташы балкый. Бу өстәл янында алтыннан эшләнгән, кеше буендагы имән агачы басып тора. Анын яфраклары зөмрүд ташыннан, жимешләре бирәзә, кызыл алмаз, сапфир, сайлап алынган эре-эре дингез энжеләреннән эшләнгән. Анда-санда ботакларда эмальдән ясалган кошчыклар утыра. Аларнын кайсылары канат кагына, кайсылары канатларын жыеп утырган, кайсылары томшыкларына алмаз, мәржән, энже бөртекләре капкан.*

*Ян-якларда алтын ука белән чигелгән мендәрләр, идәндә ачык төстәге келәмнәр жәелгән.*

*Түрдә асылташлар: ахак, алмаз, мәржәннәр һәм фирүзә белән бизәлгән тәхет. Шәм куелган алтын шәмдәлләр өстә, түшәмнән эленеп тора. Башта карнайлар, быргылар, бәрабаннар тавышы, сонра кыллы уен кораллары хиссиятле аһәң янгырата.*

*Яраннары белән әмир Тимер чыга. Ул жинелчә генә уң аягына аксый. Анын өстендә алтын ука белән чигелгән хөллә. Башында эре алмазлар белән бизәлгән таж. Тәхетенә утыра. Эшләрне оештыручы башкарачы Күгелташ өч тапкыр кул чаба. Бию музыкасы башлана. Уртага биюче кызлар чыга. Әмир Аксак Тимернен игътибары биюче кызларда түгел. Анын уе әллә кайда, читтә, сугыш кырында, ахрысы. Ул ишарә белән оркестрны туктата. Жепләре ташланган курчаклар кеби, кызлар ишелеп төшә. Күгелташ кызларны залдан чыгара. Шулчак матур аһәң белән Коръән укыган тавыш ишетелә. Бу—Коръәннен егерме сигезенче сүрәсеннән алтмышынчы аять сүзләре:*

Үә мәә үүтиитүм миң шәй-иң
фәмәтәгъүл-хәйәәти-ддүнйәә
үә зиннәтүһәә үә мәә
гыйндә-ллаһи хайрууүә әбкъаа
ә фәләә тәгъкыйлүүн.
Сезгә бирелгән һәр нәрсә
фани дөньяда алдавыч бизәк кенә
һәм бик тиз үтеп китүчедер.
Аллаһ хозурындагылар исә тагын да хәерлерәк.
Моннан соң да акылыгызга килмәссезмени?

К ү г е л т а ш. Әмир сарае каршысында укынып утырмаса, урын беткәнме? Куыгыз шул йолкыш дәрвишләрне!

Т и м е р. Тсс, Күгелташ, кем ул шундый мәкам белән Коръән укый?

К ү г е л т а ш. Бу, тәкъсирем, бер мосафир, үзенең юлдашы белән. Имеш, ул сәедләр нәселеннән, дип сөйләнә икән.

Т и м е р. Сәедләр нәселеннән?.. Кертегез сез аларны монда...

К ү г е л т а ш. Дәрвишләрне монда алып керегез! *(Йомышчы чыгып китә.)*

Т и м е р. Күпме ил гизеп мин мондый моңлы мәкамне ишеткәнем булмады.

К ү г е л т а ш. Ул дәрвиш бик күпне күргән, күпне белгәнгә охшаган, тәкъсирем. Ябалдаштау итәгендә аның янына бик күп халык җыелган иде.

Т и м е р. Ни сөйләгән ул анда Ябалдаштау итәгендә?

К ү г е л т а ш. Ислам хөкемнәре вә пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салаллаһу галәйһи вә сәләм турында.

*Карадәрвиш белән Сакчы керә. Алар ун тезләренә төшеп, ун кулларын йөрәк ягына куеп, баш иеп сәлам бирә:*

—Әссәләмү галәйкем, әмир җәнаплары.

Т и м е р. Вә галәйкем әссәлам, мосафирлар. Калкыныгыз. Минем сезнең йөзегезне күрәсем килә. *(Мосафирлар башларын калкыта.)* Кем сез, кайдан, кая бармыш көнегез?

К а р а д ә р в и ш. Тәкъсир, без ерактан. Диңгез кырыендагы илдән, Кордова—Ислам дәүләте, Гранада—Ислам дәүләте белән күрше. Аларга күрше дәүләтләр: Кастилия, Португалия, Валенсия... Мин үзем Гранада әмиратының әмире Бишенче Мөхәммәднең өлкән кардәше, атым Исрафил. Бу минем хезмәтчем Мостафа.

Т и м е р. Димәк, син хәлифләр каныннан?

К а р а д ә р в и ш. Бу хакыйкать, тәкъсир.

Т и м е р. Әмир каршысында хәлиф тез чүкмәс! Аяклан, хәлиф Исрафил. *(Карадәрвиш аяклана.)* Ни өчен син—өлкән кардәш тәхеттән баш тарттың да дәрвишлеккә күчтең?

К а р а д ә р в и ш. Мин тәхет адәме имәсмен, тәкъсир. Мин дин юлындагы кеше. Мин гыйлем сукмагындагы Аллаһ бәндәсе, мин фәлсәфә суфые.

Т и м е р. Хуп! Шәҗәрәңне анлатып бир. Сәедләр һәрчак минем канатым астында.

К а р а д ә р в и ш. Тәкъсирем, Аллаһу Тәгалә синнән разый булсын. Минем шәҗәрәм будыр ки, Кораешлар нәселеннән Әбү Бәкер, беренче мөселман хәлифәсе, җиде йөз җитмеш өч сәнәсендә борынгы бабаларыбыз өммәте Гранаданы, Кордованы яулап алганнар, шул вакытта җиденче буын вәкиле—Габбас углы Хәйран, углы мин—Исрафил. Кордовадан, Гранадага, аннан Мавританиягә, аннан Мысырга, аннан Багдадка, аннан Һиндстанга, аннан Тәбризгә, аннан төрек Солтанаты, аннан Әстерханга, аннан Алтын Урда Сараена, аннан Болгарга, аннан менә сина килеп егылдык, тәкъсир.

Т и м е р. Хуш! Бая мин синең мәкаменне ишеттем. Бер-ике сүрә укып бирсәнче... Күгелташ!

К ү г е л т а ш. Тәкъсир!

Т и м е р. Коръән бирегез сәед мосафирга.

*Күгелташ кемгәдер ишарә ясый, тәрәкле китап алып чыгалар.*

К а р д ә р в и ш. Мәшәкатьләнмәгез, тәкъсир...

*Кул ишарәсе белән китапны кире кага. Ул яттан берничә кыска сүрә укый. Тимер аны йотлыгып тыңлый. Аның күңеле тула.*

Т и м е р. Сөбханалла! Каян килә бу мәкам? Нинди гүзәл сүзләр, нинди мәһабәт фикер! Күгелташ!

К ү г е л т а ш. Әмерең, әмирем.

Т и м е р. Мосафир сәедләр углы сәед Исрафил хәзрәтләренә фирүзә сандыкны китер.

К ү г е л т а ш. Әмерең, әмирем *(Китә.)*

Т и м е р. Сәедләр токымы Исрафил хәзрәт бу минем сина һәдиям.

*Күгелташ белән хезмәтче керә, хезмәтченең кулында кечкенә сандык.*

К а р а д ә р в и ш. Тәкъсир, мин

байлыкны, тәхетне ташлап дәрвишлеккә киттем, миңа синнән берни дә кирәкми. Зинһар, миңа берни дә бирмәгез, юкса, мин аны кая куйыйм?

Т и м е р. Байлыгы булса, куяр урыны табылыр. Юксылларга өләшерсең!

К а р а д ә р в и ш. Тәкъсирем, мин сорануючыларга хәер бирүгә каршы кеше бит.

Т и м е р. Ничек? Сез үзегез дә хәер соранып тамак туйдырасыз, хәер эстәп, кәрваннарга тагыласыз, хәер соранып, кәвансарайларда нотык сөйлисез.

К а р а д ә р в и ш. Кәрвансарайларда нотык сөйләгәнгә әҗер бирәләр икән, бу хәер түгел, сөйләүченең сәләте, акылы, зиһене өчен түләү. Кемдер думбыра чиртеп, үләң әйтеп, кемдер рәкыс кылып-биеп күрсәтсә, аларга бирелгән акча да хәер, садака түгел, пирем. Алар эшләп, хезмәт итеп тамак туйдыра. Берни кылмыйча, бары тик фәкыйрь булганга гына аларга акча бирү, теләнчеләрне арттыру, аларны үрчетү, эшләмичән дә яшәп була, дигән зарарлы теләккә, зыянлы фикергә китереп чыгара. Кулы-аягы исән таза ир кеше хәер сорарга тиеш түгел. Аллаһ Тәгалә бәндәләренә ризыгын үз аягы белән эзләп табарга кушкан. Мин үзем дә теләнчеләргә хәер бирмәс идем, киңәшчемә дә хәер бирергә рөхсәт итмәс идем.

Т и м е р. Аллаһу Тәгалә саранлыкны хупламый.

К а р а д ә р в и ш. Саранлык түгел бу, бәрәкәтлелек, тәкъсир. Коръәни Кәримнең өченче—Гыймран сүрәсен ачыгыз да, аның йөз дә сиксәненче аятен укып багыгыз: *"Аллаһтан нигъмәтләр алып та, саран булган кешеләр: саранлыгыбыз үз файдабызга, дип уйламасыннар, киресенчә, бу саранлык алар өчен бик тә начар булып чыгачак. Саранлыкларына күрә, җыелган маллары Кыямәт көнендә аларның муенына чорналачактыр"*... Хәләл көче белән баеган адәмнең юксылларга, сәләмәт теләнчеләргә мул итеп тарата торган садакасы савапли имәстер, тәкъсир. Бу юмартлык түгел, бу саранлыктан да яманрак гадәттер, пирем. Бу—ялкаулыкка өнди торган гамәл. Садака, хәер мохтаҗларга, гарипләргә бирелергә лязымдыр, әмирем. Коръәни Кәримнең унҗиденче сүрәсе, ягъни Исра сүрәсенең егерме тугызынчы аяте ни ди? *"Кулыңны муенына бәйләмә, ягъни саран булма, кулларыңны артык җәеп тә җибәрмә, ягъни артыгын юмартланма. Ахырда саран диеп сине ачуланырлар, малыңны туздырып, син бичара хәлдә калсаң да сине сүгәрләр."*

Т и м е р *(сокланып, дәһшәтле көлеп)*. Кызыклы фикер әйттең әле син сәед Исрафил хәзрәтләре. Дөрес бит, голамә! Яздырт, Күгелташ: бүгенге көннән илемдә хәер сорану, теләнчелек бетсен! Акылы, бәдәне сәләмәт мөселман кешесе теләнчелек юлына басса, җәзага тартылачак... *(Затлы сандык әле һаман хезмәтче кулында.)* Колымның куллары талды, зинһар, сәед Исрафил, һәдиямне үз кулларың белән кабул кыл.

К а р а д ә р в и ш. Әмирләрнең әмире Тимер хәзрәтләре, байлыгы булган кешенең йокысы кача, минем тыныч йоклыйсым килә.

К ү г е л т а ш. Әмирең бүләген кире кагу килешмәс, хәзрәт.

Т и м е р. Монда синең гомереңә, балаларыңа житәрлек хәзинә. Ал, Исрафил хәзрәт.

С а к ч ы. Әмирләр әмире, ханнарга хан, падишаһларга падишаһ кулыннан бу һәдияне алыш кирәк, хуҗам.

Т и м е р. Акыллы хуҗаның киңәшчесе дә акыллы була! Ал, Исрафил хәзрәтләре!

К а р а д ә р в и ш. Бу изге эшегезне онытмам, тәшәккүрләрем сезгә!

*Карадәрвиш сандыкны ала, сандык Сакчыга күчә.*

Т и м е р. Минем илемдә сәедләр өчен махсус салынган бистә бар, ул гөлбакча эчендә, агачлар, җимешләр арасындагы арыкларда челтер-челтер су ага, кошлар сайрый, мин сиңа шуннан бер хөҗрә бирсәм...

К а р а д ә р в и ш. Ходай Тәгалә мине дәрвишлегемнән аермасын, тәкъсир.

Т и м е р. Күптән түгел генә минем иң якын киңәшчем, иң сөекле ярдәмчем, сәед имам Бәрәкә вафат булды.

К а р д ә р в и ш. Урыны җәннәттә булсын!

Т и м е р. Амин?

К а р а д ә р в и ш *(бер сүрә көйләп укый. Тимер, хискә бирелеп, сокланып*

*тынлый).* Иннә лилләһи вә иннә иләйһи рәжигун.

Т и м е р *(нен күнеле тулган, ул сиздермичә генә күз яшен сөртеп ала).* Әгәр дә мин сина сөекле имамым Бәрәкә вазифасына кинәшче һәм рухан житәкчем буларак урын тәкъдим итсәм, ни әйтерсен?

К а р а д ә р в и ш. Һу-у, тәкъсир. Бер тәхеттән качып, икенчесенә менеп утырыйммы? Бу минем мәсләгемә кәтгыян туры килми.

К ү г е л т а ш. Алдында, мосафир, Чыгытай илен, Хорасанны, Гөлстанны буйсындырган әмир Тимер хәзрәтләре торадыр. Шушындый да кодрәт, шушындый да гайрәткә ия әмир Тимернен сүзен аяк астына салырга жөрьәт итәрдәй кеше булмады, очрамады юлыбызда. Очраган булса да ул яшәмәс иде.

Т и м е р. Әмма мин мосафир Исрафил хәзрәткә тырнак очы белән дә кагылмаячакмын. Чөнки ул сәедләр токымы. Исрафил хәзрәт, мин сина боерык бирмим, әмирнен амиранә әмеренә сине рәнжетмәсен. Тик үтенеп сорыймын, вакытлыча гына, мәрхүм имам Бәрәкә рухы өчен генә, син анын урынын алып тор, зинһар. Юкса, мәрхүм имам Бәрәкәне уйлап, кулымнан эш төшә. Ашаганым аш түгел, эчкәнем шифа түгел. Зинһар, разый бул, Хода бәндәсе! Бу—минем сонгы сүзем! Уйлый тор, сәед хәзрәт Исрафил!

*Дәһшәтле тынлык урнашты. Сакчы башкаларга сиздерми генә Карадәрвишнен янбашына төртте, янәсе, риза бул, ди. Шулчак Сакчы биштәрен төшереп жибәрде, анын шахматлары чәчелеп китте. Әмир Тимер анын шахмат жыеп маташканына көлемсерәп карап тора иде.*

Т и м е р. Машалла! Сез икмәк урынына биштәрегезгә шахмат тутырып йорисезмени? Машалла! Алышабызмы? Әллә салышабызмы, мосафирлар?

С а к ч ы. Алыштан булса, жинүче ала. Салыштан булса, жинелгән сала.

Т и м е р. Алыштан булсын, салыштан булсын. Шартын нидән?

С а к ч ы. Әмирдән уздым юк! Әмир башта үз шартын әйтсен.

Т и м е р. Мин отсам, сәед Исрафил хәзрәт белән анын хезмәтчесе Мостафа мосафир сараемда хезмәттә калалар. Ризамы?

С а к ч ы. Хужам ни әйтер?

К а р а д ә р в и ш. Вакытлыча хезмәткә мин риза!

Т и м е р. Шартын, мосафир Мостафа?

С а к ч ы. Әгәр мин отсам, әнә шул яу бәрабаныгызны сонарсыз.

Т и м е р. Ха! Ана минем яу бәрабаным кирәк булган икән! Бу бәрабаннын бәһасы юк, мосафир. Бу бәрабан белән мин ничәмә-ничә баһадирларны жиндем. Мина аны сәед Бәрәка үзе бүләк итте. Юк! Башка нәрсә сора! Сугыш бәрабаны комар уенына куелмый.

С а к ч ы. Алайса, син мина аранында бәйдә торган яу айгырыгызны—Акбәкәленне бирерсен!

Т и м е р. Алла-а диген, мосафир. Тузанлы юл дәрвишенә андый йөрге айгыр әрәм. Андый атны комарга салалармыни, дәрвиш! Ул мине ничә тапкыр үлемнән алып чыкты. Ул атнын бәһасе юк, мосафир, башка нәрсә сора!

С а к ч ы. Тәкъсир, алайса, билегездәге затлы хәнжәрегезне салырсыз.

Т и м е р. Исрафил хәзрәт, синен юлаучыннын күзе очлы, ул мал таный белә.

К а р а д ә р в и ш. Әле кем отасы нә мәгълүмдер.

Т и м е р. Куям билхәнжәремне! Бу хәнжәр уртача бер мәмләкәтнен еллык keremenә бәрабәр. Тезегез!.. Күгелташ!

К ү г е л т а ш. Тәкъсирем?

Т и м е р. Уеннан сон, кем жинүгә карамастан, дәстархан булсын!

К ү г е л т а ш. Дәстархан булыр, тәкъсирем! *(Китә.)*

*Шахмат ханәкәсе.*

*Яраннар шахмат тезү белән мәшгульләр. Алар түрдә шахмат уйный башлый. Тәхетханәдә биюче кызлар пәйда була. Кемдер шахмат уенын тамаша кыла, кемдер музыка тынлый, биючеләргә бага.*

*Сарай ишегалдындагы ачык һавада ашханә.*

*Ашчылар ары чаба, бире чаба. Ашчыларнын барысы да ир-егетләр. Аларнын сакаллары ак ефәк белән бәйләнгән. (Сакал төкләре ашка төшмәсен өчен.)*

*Озын-озын өстәлләрдә тау-тау булып*

*туралган кишер, суган, ит өелгән.*

*Олы-олы казаннарда май кайный.*

*Йөзләре жинелчә каплаулы хатын-кызлар бөртекләп дөге чистартып утыра.*

*Шахмат бүлмәсе. Сакчы оттыра бугай. Тимернең канәгать йөзенә тантаналы елмаю чыккан.*

Т и м е р. Мат!

К ү г е л т а ш. Котлыйм, тәкъсир!

Т и м е р. Кызык, кызык, дәрвиш Мостафа! Ләкин мин синең хәйләңне алдан ук сизендем. Шулай итеп, без жиңдек!

С а к ч ы. Хак, галиҗанәбләр жинде! Кызык, минем бу хәйләмне әле монарчы берәү дә сизенмәгән иде. Сез—беренче! Котлыйм, тәкъсир!

Т и м е р *(горур елмаю илә)*. Ә без аны Сәмаркандта аңладык. Минем чиксез кыйммәт хәнҗәрем үз янымда кала, шөкер. Аллаһ миңа һәрвакыт җиңү китерә. Шулай итеп, сез минем хозурымда каласыз!

К а р а д ә р в и ш. Мәйлең, ихтыярың, тәкъсир! Ләкин озакка түгел, өч ай, күп дигәндә ярты ел шарт белән!

Т и м е р. Күгелташ, фәрманымны язсыннар!

*Күгелташ ишарәсеннән соң хаттатлар керә. Алар келәмгә утырып, ике тез башына такталар куя, кара савыты, очланган каурый каләмнәрен жайлый.*

Т и м е р. Без—Сарбедарлар падишаһы, Хәрәзм шаһы, Мәвәрәэннәһер солтаны—Барлас токымлы әмир Тимер Барс елының жиденче аеның унынчы көнендә сәедләр токымы Хәйран углы Исрафил хәзрәтне үзебезнең янныбызга дин эшләре вәзире итеп алабыз. Үзенең нөкәре Мостафа белән ул дәүләт тәэминиятенә алына. Яраннарым! Аларның гозерен минеке кебек төгәл үтәргә!

К а р а д ә р в и ш. Шөкран, тәкъсирем! Без сезнең дәүләтегез файдасына хыянәтсез хезмәт итәрбез!

Т и м е р. Күгелташ!

К ү г е л т а ш. Әмирем?

Т и м е р. Минем яңа яраннарымны дәстарханга чакыр!

## Коръән ачтыру

*Бакчадагы җимеш агачлары күләгәсендә корылган дәстәрхан тәйарланган. Күренми торган мотрибчылар талгын аһәң уйный. Кәнизәкләр бию башлый, аларны кылычлы яугирләр алмаштыра.*

*Тимер алдан, аннан арттарак Карадәрвиш, Күгелташ, аннан арттарак Сакчы керә. Карадәрвишнең өстендә затлы чапан, затлы башлык. Сакчы да бик кәттә киенгән.*

Т и м е р. Сезләр сәед Исрафил хәрзәтләре, уң ягымнан урын алырсыз!

К ү г е л т а ш. Сәед Исрафил хәзрәтләре, төрк падишаһлары иң хөрмәтлеләргә уң тарафыннан урын бирә.

К а р а д ә р в и ш. Чиксез рәхмәтләрем булсын!

*Карадәрвиш Тимернең уң ягына утыра. Сакчы аннан бераз читтәрәк урын ала.*

*Иң башта әмиргә касә белән чәй бирелә. Тимер сак кына, үз дәрәҗәсен белеп кенә касәне ике куллап ала. Бер уртлап, җиңелчә генә баш иеп, касәне ике куллап күршесе—олы кунагы, олы вәзире Карадәрвишкә суза. Тегесе дә җиңелчә баш иеп, ике куллап касәне ала. Барысына да чәй таратыла, барысы да чәй эчә.*

*Зур төпсәдә кыздырылган ит китерәләр. Тимер әмир үз пычагы белән кисәктән бер калҗа кисеп, авызына каба да, төпсәне Карадәрвишкә бирергә куша. Барысының алдына аерым төпсәләрдә ит китерелә. Барысы да үз пычаклары белән кисеп ит ашый.*

*Тәмләткечләр белән пешерелгән, борычлы шулпа китерелә.*

*Пылау чыгарыла. Олы касәгә өелгән кып-кызыл җиләкне Тимер алдына куялар. Ул аерым бер ләззәт белән сабыр гына пылауны шул җиләкләр белән бизи. Саргылт булып пешкән дөге тавы өстендә кып-кызыл йолдызлар кабынгандай була. Шул пылауны табагы белән Карадәрвишкә суза. Барысы да куллары белән пылау ашый башлый.*

*Кувшиннар белән кымыз чыгарыла. Тимер иң башта бармак очы белән кымыз тамчысын читкә селти, монысы—*

*Тәнрегә, аннан соң кымызны үзе татый, аннан соң башкаларга да коеп чыгалар. Барысы да кымыз эчә. Төпсәләргә салынган җиләк-җимеш чыгарыла. Аннан соң тагын чәй китерелә. Чәйдән соң тәгамгә дога кылына.*

## Тәхетханә

Т и м е р. Исрафил хәзрәтләре!

К а р а д ә р в и ш. Әмирем, диккатем!

Т и м е р. Күзгә күз сөйләшсәк иде!

К а р а д ә р в и ш. Мәйлең, әмирем. *(Сакчыга ишарә ясый. Сакчы арты белән чигенеп чыгып китә.)*

Т и м е р *(Күгелташка ымлый, тегесе китә).* Пирем!

К а р а д ә р в и ш. Әмерең, әмирем!

Т и м е р. Мин үземне Аллаһу Тәгаләнең Җир йөзендәге үҗәт колы, дип саныймын. Мин Җир йөзендәге бер генә халыкка да зыян салмадым. Кеше малына хуҗа булу, башкалар хисабына мал-мөлкәт туплау минем уема да керәп караганы юк. Мин беркайчан да, бер генә кешегә дә кызыкмадым, алардан көнләшмәдем. Минем яуларым бары тик җиһад вә яки гаделлекне торгызыр өчен кылынды. Беркайчан да яуга чыгар алдыннан, берәр кешегә үлем җәзасы бирер алдыннан якыннарым вә сәедләр белән киңәшми гамәл калганым юк. Мин кяферләр, мәҗүсиләр, монафикъләр белән дин өчен көрәшәм. Мин Аллаһ юлында шәһид булырга әзер. Мин пәйгамбәребез Мостафа салаллаһу галәйһи вә сәлам юлыннан барам. Моңа кадәр минем иң олы киңәшчеләрем сәед Зәйнетдин Әбүбәкер хәзрәтләре булды. Иң әүвәлге яуларым аның фатихасы белән башкарылды. Аллаһның ярдәме белән мин җиңүләр яуладым. Аннан соң минем иң якын киңәшчем мәрхүм шәех Бәрәкә булды, урыннары җәннәттә булсын!

К а р а д ә р в и ш. Иннә лилләһи вә иннә иләйһи рәҗигун.

Т и м е р. Мин бүген киңәшчесез калдым. Минем яу агаларым, акча эшләре буенча казначым да, ясак җыючы, салым артыннан йөрүче баскакларым да бар, шөкер. Ләкин минем бүген рухи ярдәмчем, дин эшләре буенча киңәшчем юк иде. Аллага шөкер, анысы да булды. Аллаһ ярдәме илә мин Мәвәрәеннәһерне, Хорезмны яуладым. Мин тыгыз ил—солтанат кордым. Минем тәкъва булуым зур җиңүләргә ирештерде. Мин сәгадәт патшалыгы төзедем.

К а р а д ә р в и ш. Котлыйм сезләрне, әмирләрнең әмире. Ләкин сезнең шушы изге эшегезгә комачау кылырга теләүчеләр аз түгел. Иң беренче сезгә Алтын Урда патшалыгы куркыныч. Анда коточкыч куәтле хан утыра—Туктамыш. Сезләр аңа күпме яхшылыклар кылдыгыз, сез аны тәхеткә утырттыгыз, ләкин ул—итагатьсез, рәхмәт укыйсы урында, сезгә каршы яу әзерли. Әйе, сезнең гаскәрегез аныкыннан ким түгел, ләкин бит аның сәгадәтле иленезгә басып керүен "ярһәмәкаллаһ" дип көтеп ята алмыйсыз. Ул өлгергәнче сез өлгерергә тиеш.

Т и м е р *(аптыраган).* Сез минем уемнан алда барасыз, хәзрәт.

К а р а д ә р в и ш. Минем вазифам шул, әмирем.

Т и м е р. Ләкин мөселманның мөселман иленә басып керүе, мөселман канын кою, мөселман җанын кыю мөселманга тыелган, хәзрәтем.

К а р а д ә р в и ш. Туктамыш хан—бөек хан, тәкъсирем. Аның кул астында Болгар дәүләте, элеккеге Хазар җирләре, Каф тауларының аргы ягы, бөтен Идел буе, Чулман иле, чуаш, чирмеш, урыс иле аның химаясендә. Ул Ак Урданың хуҗасы. Синең ут күршең. Ут күрше бит ул сиңа тоз, он бирер, әмма ут күрше йортыңа ут сала да белер.

Т и м е р. Менә шул борчый мине, хәзрәтем. Нишлим? Синең киңәш кирәк.

К а р а д ә р в и ш. Коръән ачтырыгыз, әмирем.

Т и м е р. Мөхәммәд пәйгамбәрнең торыны, сәедләр нәселле, шәех имам Исрафил хәзрәтләре, бу эшне мин сиңа тапшырыр идем. *(Коръән суза.)*

К а р а д ә р в и ш *(Коръән ача).* Мөлек сүрәсе, бишенче аять: хактыр ки, сезгә иң якын күкне кандилләр белән бизәдек. Аларны *(йолдызларны)* шайтаннарга ата торган итеп ясадык һәм шайтаннарга ялкынлы ут газабы әзерләдек.

Т и м е р. Бу ни, шәех хәзрәт?

К а р а д ә р в и ш. Бөек әмирем, Коръәни Кәрим шайтаннарга сезнең кулыңыз илә җәза бирә.

Т и м е р. Кем ул шайтан?

К а р а д ә р в и ш. Шайтан ул—Туктамыш, Туктамышның халкы. Беренчедән ул ант бозучы.

Т и м е р. Хак!

К а р а д ә р в и ш. Икенчедән Туктамыш илендә динне дөрес тотмыйлар!

Т и м е р. Ничек? Алар мөселман халык бит!

К а р а д ә р в и ш. Туктамыш илендәге мөселманнар яшереп кенә мәҗүси йолаларын тота, әмирем.

Т и м е р. Ничек?

К а р а д ә р в и ш. Үзем ишеттем, үз күзләрем белән күрдем, Идел буе татарлары яңа туган йөзенче ир угъланга кыл салалар... Әмирем, сөннәтче баба сөннәт ясаганнан соң һәр йөзенче баланың кәлләсенә ата-бабасына күрсәтмичә генә кыл сала. Бала сия алмыйча үлә. Мөселман бабасы мөселман баласын шулай таш балбалга—ясалма аллага корбан итә.

Т и м е р. Әстәгъфирулла! Бу ни гадәт! Бу нинди кыргый йола! Әгәр дә ул атаанасының бердәнбер баласы булса?

К а р а д ә р в и ш. Бердәнбер булса да кыл салынырга тиеш. Мәҗүси йоласы шулай куша, тәкъсирем. Кыл салмаса, сөннәтче бабаның үзенә зыян киләчәк.

Т и м е р. Бу кыргый йола, бу Исламны какшата торган йола! Моны тамырыннан корытырга кирәк.

К а р а д ә р в и ш. Коръән дөрес әйтә, шайтаннарга ук атарга кирәк!

Т и м е р. Дөньяда күрелмәгән кыргыйлык!

К а р а д ә р в и ш. Монысы әле аның чүп кенә. Болгарлар, Габдулла хан илендә ире, хатыны, баласы-чагасы Иделдә бергә көпә-көндез су коена.

Т и м е р. Чынлапмы?

К а р а д ә р в и ш. Валлаһи, менәтрә! Үз күзләрем белән күрдем. Ялангач килеш коеналар.

Т и м е р. Ислам дәүләтендә? Ире, хатыны, бала-чагасы ялангач килеш бергә су коеналар? Лә хәүлә вә лә куәте. Кая карый мәчет? Кая карый имамнар? Кая карый Габдулла хан? Тугыз йөз егерме икенче елда Исламны рәсми төстә кабул иткән Болгар дәүләтендә Ислам кануннары үтәлмиме?

К а р а д ә р в и ш. Үтәлми! Алар Исламны эчтән какшата, тәкъсир. Башка илләрнең илчеләре барысын да күрә бит. Алтын Урда белән Болгарда Ислам—бозык Ислам, тәкъсир!

Т и м е р. Күгелташ!

К у г е л т а ш *(керә)*. Тәкъсирем, әмерен!

Т и м е р. Хәбәр сал! Бөтен даругалар, барча илчәләр, барча төмәннәр гаскәр белән тиз арада бирелә туплансын! Без Җиһад өчен, дин сафлыгы өчен яуга чыгабыз!

К у г е л т а ш. Башым өсте, йөзем түбән. *(Китә.)*

Т и м е р. Исрафил хәзрәт, сез дә минем белән яуга барырсыз, сез мине рухландырып торырсыз!

К а р а д ә р в и ш. Башым өсте, йөзем түбән, тәкъсирем!

*Кинәт, дөньяны сискәндереп гаугa бәрабаннары дөнгерди башлый, жиз тәлинкәләр чартлап бер беренә бәрелә. Кәрнайлар дәһшәтле көй уйный.*

*Ахыры киләсе санда.*



## Лена Шагыйрьҗан

### Туган Илкәй бар дөньяда...

Бер ханга да, патшага да,
башкага да карамастан,
Туган илкәй бар дөньяда—
ыруг чәчәк аткан бөстан.

Туган Илкәй—исе таныш,
төсе таныш, бишек—камыш...
Төнен—байгыш, көнен—аккош,
иртә-кичен хуш-ис аңкыш...

Тирәкләре, тубыллары,
чыпчыклары, былбыллары,
көчекләре, сыерлары—
сиңа—җирдәш, якташ—бары.

Кышларын—ак бураннары,
чеметеп ала торганнары,—
үзеңнеке, сүзеңнеке—
болын-кыры, урманнары...

Атлауларым шул җир буйлап,
язлар киләсене уйлап,
кышлар чыккач, язылып бер
кинәнәсен—сабантуйлап.

Оҗмахларга эләксәң дә,
Туган Илкәй калыр җанда...
Ул ич сиңа өлеш биргән,
барлыгыңны сугып санга.

Сусаганга теләк телим:
«Чишмәләрдән су алгыры!»
Яман теләк яный кемгә?—
«Илсез-ватансыз калгыры...»

«Глобальләшә дөнья» дип
ишетсәк тә дошман-дустан,
Кече Җир бар Олы Җирдә—
үзебез туган куыш, ыстан...

Шөкер итәм, әрнесәм дә
тарих тулы үкенеч-зарга,
Әткәм-әнкәм, әби-бабам
гомер иткән Ил-җир барга...

*2006*

### Шагыйрь юлы

Бәгыреңнән тамган моң тамчысын
Җыр итәргә күпме кирәген
Белим, дисәң, дустым, колак сал син,
Тыңлап кара шагыйрь йөрәген...

---

Лена ШАГЫЙРЬҖАН—*шагыйрә; «Иман әлифбасы», «Боҗра вә Хөҗрә», «Сагынмаклык» һ. б. китаплар авторы. Татарстан Язучылар берлегенең Һ. Такташ исемендәге премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Башын уйга салган шагыйрь ирләр
Әйтер сиңа шунда үз итеп:
Җиңү-җиңелүләр белән тулы
Гомер юлын җырлы сүз итеп—

Җиткезергә кеше күңеленә
Кеше булып калу шарт икән.
Бер карасаң, шагыйрь—бер шук малай,
Бер карасаң—зирәк карт икән...

Моңлы бер җыр эзләп барган чакта,—
Ташны ярып үскән гөлләргә
Күзләреннән тамса кайнар яше,
Гаепмени шагыйрь ирләргә?..

Хисләр йөге арта барган саен,
Шагыйрь юлы авыр, катлаулы.
Житез генә җилдерүне түгел,
Сорый—хәлдән таеп атлауны...

Шагыйрь юлы сорый адым саен
Тәвәккәллек, корбан итүне...
Үрмәләүне—үрләр менгән чакта,
Менеп җиткәч—очып китүне...

*1995*

## Фаный дөньяның бакый кануны...

Керфек очымнан яшьләрем тама,
Каләм очыннан уйларым ага:
Ела-елама, уйла-уйлама,
Рәнҗү харамдыр фаный дөньяга...

Булдыңмы әллә «дөнья кендеге»,
Кемнәр тарайтты күңелең киңлеген?
Бик тиз киптеме шатлык яшьләрең—
Хуплагандагы фикердәшләрең?

Шулмы рәхмәтең фаный дөньяга,
Сөеп туймаслык җаный дөньяга?!
Җыен алдавыч кысыр ташларын
Тондыр упкынга, тот та—кыядан!..

Нәрсә дип әле күзең шар ачып,
Өметсезлеккә табан төбәлдең?
Югалтып тәмам бетергән сыман
Үзең биләгән тормыш төбәген?..

Тарат горурлык бөтен тәнеңә,
Сөенеп торыр хәтта Тәңрең дә.
Иблис көлә дип, егылып үлмәбез,
Мәңге уртак ич хәят бүлмәбез...

Торма боегып—качар бәхетең,
Иҗат кыясы—синең тәхетең...
Ач тәрәзәңне, күтәр пәрдәңне,
Үзеңнән үзең эзлә ярдәмне...

Күрче, җаһилләр, сизеп көчеңне,
Тишек-ярыкка кереп качканнар.
Ачык җиһанның бикле серләрен
Шагыйрь җаннар ич җирдә ачканнар.

Керфек очымнан күз яшем тама,
Кәгазь битенә уйларым ага:
Яшәргә кирәк, түзәргә кирәк,
Килгәнсең икән фаный дөньяга...

## Мәхәббәт турында җыр

Тормышта да, Уенында да,
Әкиятендә дә, Чында да—
Мәхәббәттән мөһим бернәрсә дә
Юк икән бит соң бу дөньяда...

Мәхәббәттән—кояшлана көн,
Мәхәббәттән—төннәр айлана.
Мәхәббәттән—ярлар сайлана,
Мәхәббәттән—дөнья җайлана...

Мәңге яшәр Җирдә мәхәббәт,
Өзелмәсә, күңел кыллары.
Җир кызлары белән җир уллары—
Шул бер хиснең уртак коллары.

Мәхәббәттән—битләр аллана,
Мәхәббәттән—ирен баллана.
Мәхәббәттән—иелә кыялар,
Мәхәббәттән—үрелә оялар...

Кемне генә айкалдырмаган
Дулкыннары шул хис-дәрьяның.
Сөюдән дә изге яңалыгы
Юк икән бу иске дөньяның...

Мәхәббәттән илең ямьләнер,
Мәхәббәттән—телең тәмләнер.
Мәхәббәттән—чәчләр бәйләнер,
Язмышлар бәхеткә әйләнер...

Чынында да, Уенында да,
Уеңда да, куенында да—
Мәхәббәтеңнән дә мөһимрәк
Берни дә юк икән дөньяда...

Мәхәббәткә торам таң калып,
Мәхәббәттән үзем яңарып,—
Өр-яңадан күреп куанган күк,
Күктә кояш белән ай барын...

## Такташ хаклы, дөрес аңласаң...

*«Хатыннарның бөтен матурлыгы,*
*Бөтен күрке ана булуда...»*

Һ. Такташ

«Хатын-кызның» димәгән шул Такташ,
«Хатыннарның» дигән, бик белеп:
Ир хатыны булса, бала тапсын,
Ана булсын, багып—бил бөгеп...

Такташ—бөек... Сүзе—көлеп тора,
Әйтелсә дә усал төрттереп...
Хәзергәчә ләкин бу даһиның
Аңлап бетермиләр тел төбен...

...Яшьлегемдә бер ир тапсам шунда,
Буласы ла икән бик әйбәт.
Бер багалма табып, багалмадым,
Ирсез калгач, нишлим? Бигайбә!..

Эзли белмәдек шул борынгыча
Чиләгенә таман капкачын...
Бер мин генәмени—ой борынча
Ачалмаган никах капкасын...

Безгә насыйп ярлар тумый калган…
Түгел идек кияү чыкмаслык.
Ирләрнең дә, бәлки, бөтен күрке—
Ир булудыр утка тыкмаслык…

Гаилә корган шагыйрәләрнең дә
Үкенечле бик еш тәкъдире:
Йә иреннән рәхәт күрми алар,
Яисә үлеп китә шәп ире…

Такташ йөз кат хаклы: хатыннарның
Матурлыгы—ана булуда.
Тик нигә соң бик күп яшь аталар
Чыгып тая, бала туугa?..

Хыянәтләр, ятим калулардан
Саклаганмын гүя үземне…
«Шагыйрәгә харам әйбәт ир» дип,
Алдан күргән күңел күземме?..

…Ирдән уңган бер шагыйрә бар да,
Кыеп бетмим «даның сатарга»…
Торган җире—Мәскәү,
Ире—яһүд,
Каны—ярымкатыш татарга,
Сүзе, җыры—бөек рус телендә,
Үзен—белмим, кем дип атарга…

…Әйе, хатыннарның бөтен күрке,
Матурлыгы—ана булуда.
Шагыйрәнең исә бөтен бәхете—
Җыры саен Яңа булуда…

*2006*

## Үз-үзеңә тоткын булып...

Тоткын сыман утырам өйдә,
газап йотып, газап косып.
Беркем тотмый—уй-шигырь ул,
кысласыман алган кысып…

Тоткан кысып, җибәрми һич,
кояшлы ни, яңгырлы ни—
чыгармый ул сине көнгә,
китми тор, ди—яңгырыйм ди…
Яңгырыйм, ди синең рухтан,
синең йөрәк, синең телдән.
Яралыйм, ди синең гөлдән,
яңарыйм, ди синең көлдән…

Ычкыныйм, ди синең бәйдән,
котылырсың аннан үзең …
Шигырь тәмен тәүге тапкыр
татыганга илтим сүзең.

Илтим сүзең, ике күзем,
күзге язым, язгы көзем,
исәр башым, кырыс назым,
күктән төшкән кыргый казым...

Үз-үзеңә, үз сүзеңә
әсир төшкән хөр колым, дир.
Синең өчен үзем, әйдә,
чиксезлеккә ыргылыйм, дир...
Кал өеңдә үз көеңә.
Сүз көенә булмый яшәп...
Уйларыңнан ут кабынып,
утыр янып, утлы чәчәк...

...Оча тора читлегемнән,
вата-җимерә тозакларын,
Күңелемнең хөр кошлары—
хөрлегемнең «йозаклары»...

*1998*

## Моңсу шаяру

Үз җаным белән тартышам: Ут вә Су күк, Төн вә Көн...
Бер бөтенгә укмашып беттек, дисәк, булмый ләкин...

Тәнемә төпләнгәндер, дисәм Җанымны,—ул икән
Санга да сукмый «оясын»,—бик иркле «кол» икән...

Үлсәң дә, буйсынмам сиңа, бел—очармын күккә, ди.
Түзәр хәлем юк монда, инде чыдадым күпкә, ди...

Нишләрсең күкләреңдә, дим, миннән башка син, ятим?
Сиңа мин булдыммыни соң бу Җирдә тик бер «тәти»?!.

*2005*

## Үземчәрәк итеп үзгәртеп...

*(М. Цветаевадан)*

Чишмә суы белән саф һаваның
кадере арткан кебек,—
бер заманны
Минем Шигыремә дә артыр бәя:
йотып туйгач гаммә һәр арзанны...

Китапларымны да—сусап беткәч,
эзләп табып укырлар беркөнне:
Эчалмый башлагач—«бака суын»,
сулап аргач, һава дип—төтенне...

*2001*

*Хикәяләр конкурсына*

Дилбәр
Булатова

# ТУЙ

Кызыл балчыклы яр астында чишмә челтери. Нәни генә, гади генә. Идел дә юл алмый анардан, Чулман да, Агыйдел дә... Әмма шомарып беткән ташлар арасыннан тыелгысыз, ашкынулы бер дәрт белән тибүендә шундый куәт, шундый ныклык бар! Үҗәт булмаса, көчле булмаса, ничек ярып чыгар иде ул бу биек ярларны?

Кулым белән чишмә типкән урынны каплап торам. Салкыны җелекләргә үтәрдәй су бармак араларыннан саркып ага бирә. Нинди кодрәт, нинди гайрәт синдә? Җир астында нинди юлларың бар? Күзгә күренмәгән нинди серләрең бар? Төптә ташлар арасына кысылып калган көмеш тәнкәләр ялтырый. Кемнәр нинди уйлар белән килде икән сиңа?

Ага да ага чишмә. Челтер-челтер... «Килерләр дә китәрләр дә... Ак уйларын күкрәгемә алам, караларын күңелләрдән юам... Ыгы-зыгылардан арып, иркен итеп һавамны сула, ю битеңне чиста суым белән, сөйлә сүзең, алып китәм үзем белән»,— дисеңме?

***

Әсмабикә апа, Гарифҗан абзый, Луиза өчәүләп кичке ашны ашап утыралар иде. Кызлары уйламаганда-көтмәгәндә яңалыгын ярып салгач, ата белән ана капкан ризыкларын йота алмый аптырап калдылар. Луиза үзе, көн дә сөйләнә торган гадәти хәбәр әйткәндәй, тавык ботын кимерүен дәвам итте.

—Бәй, бәй, кызым, бер дә сөйләнгәнең юк иде ләса!—Иң тәүдә Әсмабикә апа һушына килде.— Кемгә? Шакир малаенамы?

—Шуңа.

—Кайчан чыгасың инде?

—Августта—туй!

Гарифҗан абзыйның сул кашы сикереп куйды. Ана кеше шаккатып бот чапты.

—Әтәйдән сорау юк, инәй белән киңәшләшү юк! Ходайның бирмеш бер көнендә тот та «кияүгә чыгам» дип әйт, имеш! Аны уен эш дип беләсеңме әллә? Кая ашыгасың? Егермең яна тулды. Апаларың әнә соңрак чыгышып та: «Иртә чыкканбыз кияүгә, азрак торасы булган»—дип үкенеп бетә алмыйлар!

Әнкәсенең бер тезә башласа, тиз генә туктый алмасын белгән кыз каршы төште.

—Алия апаның да, Кадриянең дә зарланганнарын ишеткәнем юк әле. Элек атна саен кайтып урыйлар иде, кияүгә чыккач, эзе-юллары да юк, отпускыларында да ирләрен саклап яталар.—Аннары әткәсенә карады:

—Син нәрсә дисең соң, әткәй?

Гарифҗан абзый бер әйтсә, берәгәйле әйтә торган кеше, аның һәр сүзе гаиләдә закон иде. Ул ашыкмады. Тәлинкәсендәге ашын ашап бетерде. Кулларын тастымалга сөртеп, амин тотты.

Луизаның бите ут капкандай кызыша башлады. «Йә инде,—дип уйлады ул, сабырсызланып,—әйт инде бер сүз!» Эчендәге ялкынга түзә алмыйча, сикереп торып, бушаган савыт-сабага тотынды.

—Шакирлар туганлашмаслык нәсел түгел,—диде әткәсе һәм, элгечтәге түбәтәен алып, чыгып та китте.

Әсматтәйнен үз кайгысы кайгы: авызы ерылган кызга сынаулы караш ташлап сорашырга кереште:

— Нигә ашыгасың соң, кызым, тагын берәр ел эшләмисен? Өс-башыңны да карар иен. Илшатыңның да укып бетерергә ике елы бар. Егетләргә ни аларга, өйләнергә кирәк инде. Башыңны әйләндергәндер. Ә дөнья көтә башлагач, бөтен авырлык хатын-кыз җилкәсенә өелә. Әнкәй әйткән ие диярсең әле менә! Кайда яшәргә уйлыйсыз? Шакир малаена дип өй сала икән дигән сүз йөри дә ул, алдагысын Алла белгән. Бианай белән яшисең киләмени? Нинди әйбәт бианай да үз анаң кебек була алмый инде ул...

Аннан тавышын акрынайтып:

—Ул-бу булдымы әллә, кызым? Сөйлә, курыкма!—диде.

—Ничек инде «ул-бу»?!

—Андый-мондый хәл дим...

Әнкәсенең ни әйтергә теләгәне кызга көчкә барып җитте. Үпкәләп, рәнҗи язып:

—И әнкәй, бигрәк инде син!—диде дә юа башлаган калак-чәнечкеләрен ташлап чыгып йөгерде.

—Шөкер,—дип җиңел сулады Әсмабикә апа. Кызының күнелен кырсакырды, аның каравы җаны тынычланды. Кыз бала—учтагы утлы күз, авылда, әнә әле берсенен, әле икенчесенен яманаты чыгып кына тора, бер карасаң, китүе хәерле дә. Шул малай белән әллә җиде, әллә сигез ел йөриләр бит инде. Ярар, җүнле ата-ана баласы. Шакир—лесник, Фәйрүзәсе хисапчы булып эшләп, пенсиягә чыкты. Дөньялары, йорт-җирләре җитеш. Һәммә кеше тигез дип өйрәтсәләр дә, бер кемнен дә газиз баласын нигезсез, көнсез-җирсез гидайга биреп җибәрәсе килмәс. Балалар йөрешә башлаганнан бирле сынап, искә алып килә, начар сүз ишетелгәне юк алай. Өч чакрымга сузылган авылның төрле башларында яшиләр, әмма авыл авыл инде—югары очта төнлә «уф» дисәләр, иртәнгә үк түбән очка ишетелә. Очрашырга туры килсә, Фәйрүзә үзен корырак тота-тотуын да, ярар, малай инәсе шулайрак була инде. Улныкы—гөбернатор, кыз инәсе качып ятыр, диләрме әле?

Әсматтәйнең йөгерек уе шунда ук туй кирәк-яракларына күчте. «Ярар, без дә төшеп калганнардан түгел, сынатмабыз, Аллаһы боерса. Сандыгы тулы инде, кибеттә эшләгәндә тауар очсыз, акча бар чакта ук тутырыпхәстәрләп куйдым, башым эшләп. Шулай да тагын биш-алты метр ситса, ике-өч метр сатин, ефәк күлмәклек алганда мишәйт итмәс. Кодагыйга бүләккә күлмәк кырына затлы яулыкмы, шәлме дә куярга кирәк. Ни дисән дә, Илшат—төпчек малай, бергә яшиселәр. «Институтны бетерәм дә, әтәй урынына, үзебезнең урманга кайтам»,—дип әйтә диләр бит. Югары сорт оны азайды, шул кирәк. Бәлешкә һәйбәт дөге, күрәгә-йөземен, сары майларын әзерлисе бар. Йомырка җитмәсә, сатып алырга туры килер. Иткә кытлык юк, сугымлык башмаклары бүген тотып суярлык, ана тимәсәләр дә аптырыйсы түгел, бүлтерекләре өчәү-дүртәү, үрдәк-казы, күркә-чебешләре ихата тулы, августка кадәр вакыт бар, менә дигән симерерләр, Аллаһы боерса!

Һи-и-и, менә исенә төште. Сания карчыкка хак биреп, нечкә генә йоннан бер-ике пар пирчәткә дә бәйләтеп алырга кирәк—шоферларның ничәү буласы тәгаен билгеле түгел, запас зыян итмәс. Хәзер яшьләр бәйләнгән пирчәткә киюен кими дә инде, әйдә, бездән калмасын, гадәте шулай булгач. Тагын нәрсәләр? Ярар, тора-бара хәтерләр әле, шөкер, беренче кыз бирүләре түгел ләса, төпчекләре канатланырга тора. Олы кызлары күз тимәсен, матур гына яшәп яталар, бая телгә алуы сүз уңаеннан гына иде, кайтып зарланганнары

юк алай. Үзләре исән-сау чагында Луизаларын аткара алсалар—бик һәйбәт, бик хуп, мая бар чагында тәвәккәлләргә кирәк».

Әсмабикә түти шкафтан хат язарга дип саклап тоткан дәфтәрен, конвертлар алды: «Бүгеннән дә калмый кызларга хат язарга кирәк»,—дип уйлады ул.—Туй көне билгеле түгел, шулай да читләтебрәк, уратыбрак белдереп кую зыян итмәс. Ишетә, әзерләнә, җыена торулары хәерле».

## II

—Сөйләштеңме? Ризалармы?—Кичен клубта очрашкач, Илшатның башлап әйткән сүзе шул булды.

Луизаның аны үчеклисе килеп китте. Кайгылы төс белән башын иде.

—Нәрсә? Каршылармыни?—диде коты очкан егет һәм аны җилтерәтеп дигәндәй тышка алып чыкты.—Нигә риза түгелләр? Йә, сөйлә инде!

Луиза кәефе бозылган Илшатка елмаеп карап торды-торды да кычкырып көлеп җибәрде.

—Исәркәем, нишләсеннәр инде риза булмыйча, ризалар, ризалар!

—Ну сине!—Илшат куанычына чыдый алмый, кызны кочаклады.—Алдашып торганың өчен нишләтергә сине? Күтәреп, әнә тегендә-ә, буага алып барып ыргытыйммы? Бакалар янына, кашыкбашлар оясына?

—Хатынсыз каласың килсә, ыргыт!—диде Луиза, көлеп.

—Юу-ук инде, әй, хатынсыз булмый! Хатын кирәккәнгә өйләнәбез бит! Ярый алайса, җәзасы соңрак, яме, туйдан соң!—Ул кызның колагына нидер пышылдады.

Луиза егетне этеп җибәрде:

—Абау, оятсыз! Кияүгә чыгам диген инде менә шушыңа!

—Ярар, ярар, шаяртам гына бит,—диде Илшат һәм аны яңадан кочагына алды. Луиза да карышмады. Шуны гына көткән егет:

—Ә мин шаяртмыйм!—диде. Икесе дә көлеп җибәрделәр.

—Син үзеңнекеләр белән сөйләштеңме соң?—диде Луиза, бераз тын торгач.

—Беләсең бит, алар үзләре үк мине өйләнергә кыстыйлар иде. Әйтүем булды—әни шатлыктан чүт еламый, әти дә риза. Мине шәһәрдә бозылып, эчәргә сабышыр, йә берәр марҗага күзе төшәр дип куркалар. Киленнәрдән бәхет бар бит аларның.

—Нигә?

—Куй, күңелсез нәрсәләр хакында сөйләшмик, матурым! Синең «дипломатический переговорлар» ничек үтте—шуны сөйлә.

— Ничек курыкканымны белсән?! Әйткәч тә, башта аптырап калдылар. Әнкәй сораша инде, әткәй эндәшми. Нәрсә дип әйтә дип йөрәгем туктый язды. Әткәйнең холкын беләсең ләса!

—Минем бабай нәрсә диде соң?

—«Туганлашмаслык нәсел түгел»,—диде, әйкәем.

—Һа-а, бабай үзе шулай дип торганда, ничек чыкмыйсың инде миңа, ә? Беләсең килсә, авылда бер егетне эләктерәсең!

— Шулай, шулай. Бераз мактанчыклыкны исәпкә алмасаң, бөтенләй шәп! Кайда яшәрбез, шуны уйлыйсыңмы, яшь кияү?

—Әйттем бит, бүлмә булачак дидем. Комендант үзебезнеке. Күз алдына китерәсеңме, икебезгә—бер бүлмә! Туй акчасына ки-иң караватсатып алабыз. Төне буе кочагымнан чыгармыйм бит инде сине, йә?

— И-и шушыны,—диде кыз.—Караватка хәтле суыткыч алыр идек әле. Һәм, гомумән, хәзер без туй турында уйлый башларга тиеш. Ә синең башыңда гел тузга язмаган нәрсәләр! Миңа—күлмәк, туфли, сиңа—костюм, йөзекләр, кыңгыраулар, тасмалар, шарлар, шаһитлар, плакатлар, лотереягә—вак-төяк.

—Житте, житте!—Илшат Луизаның авызын каплады.—Табарбыз, матурым, алырбыз, бар да булыр. Юкка кайгырма. Тирә-якта бер туй ясарбыз! Һәм гомумән, үзең әйтмешли, шатлан, сөен—безнең гомернең иң ямьле вакытлары

әле, әйеме? Әнә, сандугачларны тыңла әле—ничекләр өзderәләр!

Аның шулай дию булды, буада саташкан бака бар дөньяны сискәндереп бакылдап куйды. Яр буендагы өянкегә сөялгән яшьләргә бу бик кызык тоелды, ахры, жылы июнь төненең бәрхет караңгылыгы эченнән аларның көлешкән тавышлары әле шактый ишетелеп торды.

## III

Бер-ике атнадан: «Шакир малаена Гарифжан кызын сөйләшкәннәр икән, туйны август ахырына билгеләгәннәр, зурдан купмакчылар икән»,—кебегрәк хәбәрләр телгә менде. Чынлап та, ике гаилә дә төпчекләрен башлы-күзле итәргә жыена, елның да кулай вакыты: саранланмыйча, мул, иркен кыланып, яшерен ярышта кайсысы да ал бирмәскә ниятләп, утау-печәннәрне тиз-тиз аткарып, көн йокламый, төн йокламый туйга әзерләнә башладылар.

Авылда иң биек өй Шакирныкы иде, туй алдыннан түбә калаен ялтырап торган ап-ак буяуга буяп жибәргәч, ул тагын да биегәебрәк, күркәмләнебрәк киткән кебек булды. Хужага болар гына аз тоелды, ул тирә-якта булмаганча иттереп тәһарәтханә ясады, аның бер ягын ирләргә, икенчесен хатын-кызга тәгаенләп, ике бүлемле итте, электр үткәрде, өй күтәрмәсеннән ак плитәләрдән юл-сукмак сузды—патшалар да жәяү йөри торган жиргә ялан тәпи барырлык булды. Гарифжан абзый киләсе елга дип уйланган мунчасын быел күтәрде, урам якка тимер баганалар утыртып, яна капкалар эшләтте. Луиза капканы ачык зәңгәр төскә буяды, уртага пар ак күгәрченнәр төшерде.

Аналарның мәшәкатьләре исә тавык чүпләсә дә бетәрлек түгел, тагын да күбрәк, тагын да борчулырак, жаваплырак. Эш күп, әмма Илшатның әнисе Фәйрүзә апа шатлыгыннан кая басарга белми, туй хәбәренә иң сөенгән кеше дә, бәлки, ул булгандыр. «Шул кызның аяк атлашларына хәтле яратам, бигрәкләр дә сөйкемле сөяк»,—дип жае чыкканда сүз кыстыра килгәләүләрнең, теләгән теләкләренең дә файдасы тигәндер. Күз алдында үскән тыйнак, басынкы кызны Илшаты белән йөри башлаган чаклардан ук үз итеп, балаларга күңеленнән генә фатихасын биреп куйды ул. Сизә: Луиза аның улына акыллы хатын, үзләренә итагатьле килен булачак. Күрше-тирә, кеше арасында әйбәт, тату итеп яшәүгә, шаулатып-гөрләтеп туен үткәреп, кода-кодагыйларың белән аш-суга йөрешүгә ни житә! Өч баласын башлы-күзле итеп тә, кода-кодагыйлардан унмадылар алар. Бердәнбер кызлары дөнья читенә, Камчатка урысына кияүгә чыкты. Анысы гына житмәгән, егерме сигезгә житеп дә өйләнми йөргән уллары сенелесенең туенда кодача маржага күзе төшеп, ике-өч ай дигәндә, өйләнешеп тә куйдылар. Яшәүләре ярыйсы инде, шунысы йөрәкне кыра: елына бер кайталар, рәхәтләнеп сөйләшеп тә утыра алмыйлар. Фәйрүзә апа урысча белми түгел, бөтен Марианна, Тропиканкаларны карап барган кеше ул, тик сөйләшә башласаң, кирәк сүзе искә төшми дә куя бит, каһәрең, торасың аннан: «Невестушка, принеси из мунчы кисәү деревосын»,— диеп.

Әмма жанын иң әрнеткәне, шырпыдай кадалганы—уртанчы уллары Айрат белән килене Розаның тормышлары—шуларны уйлап агармаган чәче калмагандыр. Хәзер килеп, Илшатның туена чакырыргамы-юкмы дип башы катты. Туй тиклем туйга чакырмасаң, килешми, чакырсаң, нинди жәнҗал чыгарырлар дип дер калтырыйсың. Шәһәр кызы Роза танышырга кайткан көннән үк холкын күрсәтә башлаган иде, әле дә һич ипләнердәй күренми. Аена берме-икеме кайтып китәләр, шунда да бер-бер мөгез чыгармый калмый инде ул. Йә пешергән ашны ошатмый, калагын ыргытып бәреп, торып китә, йә һич сәбәпсезгә үпкәләп бүлмәсенә бикләнә. Фәйрүзә апа аның жаена да торып карады: «Болай булмый бит, кызым, мин сезгә катышмыйм, эшләгән эшеңне яманламыйм, явыз уем юк, әйбәтләп кенә яшик әле»,—дип әйтеп тә карады, юк инде, ана сөте белән кермәгәнне, тана сөте белән керәчәк башы юк. Ахырда Шакир абый Айратның үзен генә туры китереп әйтте: «Булмаса,

еш кайтабыз дип этләнмәгез, улым,—диде.—Сез китү белән әниегез урынга егыла, минем дә кулдан эш китә. Күрше-күләннән яхшы түгел. Рас үзең сайлагансың, икегез килешәсез икән, шул шәһәрегездә яшәгез инде, без сезнең арагызга керергә теләмибез»,—диде. Менә шул сөйләшүдән соң әллә үпкәләделәр, ике-өч айлап күренгәннәре дә юк, хат та язмыйлар.

Фәйрүзә апа белән Шакир абый хәтсез генә баш ваткач уйлашкач-киңәшләшкәч, чакырмасаң, илдә юк эш, дип, бөтенләй бозылышып бетүдән куркып, туй хәбәрен җиткереп хат язып салдылар.

## IV

Туйга көне туры килде дә соң! Чалт аяз, чеплә кызуы сүрелгән, елак көз юлга чыккан гына әле, җәй ахырында була торганча йомшак җылы; каяндыр сизелер-сизелмәс кенә алма иске аңкый, ындыр табагында ашлык суккыч машиналарның бероэзлексез тонык гүләве ишетелә; бакча тулы көз явын алыр чәчәкләр, түтәл тулы саргая башлаган кыярлар, сабагында пешеп утырган помидорлар...

Иллә кешеләр дә тырышты! Соңгы ике көндә туй йортларында төнлә дә утлар сүнмәде. Кодагый чәкчәкләрен подносларга эскертләп, ярты метрдай биеклеккә өйделәр, өсләренә кәнфит сибеп, яна киптергән какларны каплап, төреп-хәзерләп куйдылар; икмәкләр күпереп унды, табынга биреләсе тавыклар харап зурлар, симезләр иде. Луизаның бирнә әйберләре сандыкка гына сыймыйча, кибеттән чемодан да сатып алырга туры килде; мендәрләренең җиңеллеге, йомшаклыгы, көянтә-чиләкләрнең чәчәкле-бизәклелеге, кодачаларга атап тегелгән алъяпкычларның матурлыгы, бүләкләрнең затлылыгы шаккатмалы иде. Шәһәрдән кайткан туган апалар, җиңгиләр, чибәрәни-зурәниләр әллә нинди күз күрмәгән азыклар әзерләп, йөз төрле камыр ашлары пешереп, җиләк-җимешләрне таудай өеп, дүрт-биш өстәллек табынны тутырдылар.

Кияү ягы сәгать уникегә килеп җитәргә тиеш дип сөйләшенгән иде. Иртән үк торган, әмма ары сугылып, бире сугылып һаман киенә алмаган Луиза белән шаһит кыз Айгөлне җәйге өйгә куып чыгарып, тизрәк бизәнергә-төзәтенергә куштылар.

—Куркасыңмы?—диде Айгөл, кәләшнең чәчен тарый-тарый.

Соңгы арада тартылган, ябыккан, үзен көткән яңа тормышны, котылгысыз үзгәрешләрне уйлап шөбһәләнгән Луиза кулын селтәде:

—Сорама да инде!

—Барыбер бәхетле син,—диде Айгөл.—Без егетләр белән йөрү турында хыяллана гына идек, ә сез бөтенесен көнләштереп, шундый матур итеп йөри башладыгыз. Армиядән дә көтеп алдың. Хәзер бит алай йөрүчеләр сирәк.

—Уф, Айгөл!—дип, Луиза ахирәтен кочаклап алды.—Туй әйбәт кенә үтеп китсә, сина миннән бер торт! Шундый куркам, беләсеңме? Туйны бит тавышсыз булмый диләр.

—Тиләләнмә әле,—дип көлде тегесе,—үтәр дә китәр, нигә кайгырасың. Уйлап карасаң, бер формальность инде.

—Син үзең формальность!—Луиза ачуланып Айгөлне чеметеп алды.—Туй гомердә бер генә була торган нәрсә. Менә үзең кияүгә чыгып кара әле, белерсең аннан! Әйдә, җәһәтрәк кыланыйк, яшеренәсе дә бар.

Бик күнелле башланды туй. Усал кодачалар, үткер кызлар кияүне капкадан үткәрми җәфаладылар, акчаның әле яшелен, әле кызылын сорап интектерделәр, бирсә—«очып китте», бүләк-фәлән сузса—«кесә тишек, төшеп китте»,—дип ирештерделәр. Кияү балакай шактый этләнгәч кенә, кайчыга хуҗа булып алган агайга бер «ак»ны биреп, капкага тартылган ал тасманы кисә алды. Кызлар шунда ук верандага, өй ишегенә йөгерделәр. Монда инде кызган кияү аларга Луизаның аяк үлчәмен дә, әбисе белән бабасының туган көннәрен дә әйтеп тормады, егетләре белән ишекне каплап баскан кызларны

берәм-берәм күтәреп, читкә алып куйдылар да, дәррәү ябырылып өйгә кереп киттеләр. Әлбәттә, кызны аннан таба алмадылар. Бик кыйбатка төшкән келәт йозагының ачкычы шулай ук файдага ярамады. Эзли торгач, кәләшне печәнлектән барып таптылар һәм биш яшьлек нәни кодага пәке биреп, «сатып алдылар».

Ул арада никах ашына карчыклар җыелып өлгерде. Һәммә кеше өйгә керде, кодаларны түргә утырттылар, кыз ягы ишек төбенәрәк урнашты, яшьрәкләрнең кайберсе басып торды. Авыл мулласы Локман бабай дога кылып ашны башлап җибәрде. Никах укыр алдыннан хатын-кызларга башка бөркәнү кирәклеген искәртте. Шунда ук яулыклысы яулыгын төшеребрәк бәйләде, яулыксызы түбәсенә кульяулык булса да куйды.

Беренче чатаклык шунда килеп чыкты. Роза кодача Әсмабикә кодагый сузган яулыкны алмады.

—Кирәкми!—диде күзләреннән ут чәчеп.—Мин әби что-ли!

Бу сүзләрдән Фәйрүзә апа белән Шакир абзый, бозлы җил килеп бәрелгәндәй, сискәнеп, калтыранып куйдылар. Табындагылар ишетсәләр дә ишетмәгәнгә салыштылар, Локман бабай Коръән укый башлады.

Түрдә утырган Луиза, кызыксынып, булачак килендәшенә карады. Чибәр иде ул. Затлы киенгән, бизәнгән, алтынга чумган—әллә каян ялтырап күзгә ташлана. Ходай биргән чибәрлектән үзенә кирәккәнчә файдалана белүчеләр затыннандыр, бар кыяфәтеннән үз бәһасен үзе белүе сизелеп тора. Гади ромашкалар, пәйгамбәр тырнаклары, кашкарыйлар арасына ялгыш килеп эләккән роза чәчәгемени! «Боз королевасы!»—диде Луиза эченнән генә, бәләкәй чакта укыган әкиятен хәтерләп. Чынлап та, Розадан ниндидер салкынлык бөркелгән кебек иде, ана төбәлгән карашларда да сокланудан бигрәк сагаю һәм шөбһә күбрәк булгандыр.

«Бу карчыклар, тоныкк тавышлы мулла, әллә нинди аңлашылмаган нәрсәләр уку нигә кирәк инде?—Роза исә шулай дип гасабыйланды.—Бөтенесе дә тынлаган кыяфәт чыгарып утыралар бит әле!»

Аның уенча, туй мәһабәт никах сараенда ук булмаса да, һич югы клубта башланып китәргә тиеш иде. Аларның үзләренен туе шәһәрдә үтте. Айратның туганнарын чакырып алдылар һәм ресторанда бәйрәм иттеләр. Культурно һәм цивилизованно!—Ә монда—хан заманындагы гадәтләр! Күпме эш! Кичә көн буе аш-су хәзерләште, кечкелеккә хәлдән тайды. Ярый, анысына тешен кысып түзде инде. Бүген иртән кәефе чынлап торып бозылды. Дингез дулкыны төсендәге кыйбатлы импортный күлмәген шундый ашкынып киеп чыккан иде, юк инде, кая ул комплимент ишетү, игътибарлап карамадылар да. Авыл урамында без үкчәле туфлиләре батып тагын эче пошты. Ичмасам, Айраты да эндәшми йөргән була бит әле аның. «Бозау! Идән мунчаласы!» Шушында кайттыларммы, үзгәрә дә китә инде, шулай итеп «тегеләргә» («тегеләр» дип ул иренең ата-анасын атый иде) ярарга тырыша бугай. Ә өйдә ничек юхаланырга, сырпаланырга белми. Әнә, утыра бит, у-у, күзле бүкән, хатыны әллә бар ана, әллә юк!

Роза шулвакыт үзенә кемнеңдер текәлеп карап торуын сизде. Күнегелгән гадәт белән башын нәзакатьле генә борып, керфекләрен матур итеп сирпеп җибәрде һәм ана карады. Урта яшьләрдәге, чәк кенә корсак үстерә башлаган, таза гәүдәле, ут күзле, яхшы киенгән чибәр ирнен йотардай булып карап торуын күреп, хатынның йөрәге еш-еш тибәргә тотынды. «Һмм, интересный мужик»,—дип уйлап куйды ул.

## V

Никахтан соң культура сараена ЗАГСка, аннан туган тиешле кешеләргә ашка бардылар, кичке ашка төп йортка кайттылар. Луиза белән Илшат гүя төш күрәләр иде, котлаулар, теләкләрдән аларның башы әйләнә, бер тамчы шәраб капмасалар да, зур тантана шатлыгыннан исерә язганнар, өстәлдәге

тәгам-нигъмәтләрнең исеннән, күренешеннән үк тамаклары туйган. Алар башкаларның майлы калҗаларны ничек тәмләп согынуларына, тәлинкә-тәлинкә шулпаларны, таба-таба бәлешләрне ничек ялтыратуларына, «шайтан суы»н хәтсез эчүләренә гаҗәпләнебрәк тә карыйлар иде ахры. Авызлары ерык, алар бүген бәхет диңгезендә йөзә, Җир шары бүген алар тирәли әйләнә! Алар өчен күпме халык җыелган, күпме туганнары ерак аралардан кайткан. Ә котлаулар, телеграммалар, берсеннән-берсе матуррак теләкләр, сүзләр, бүләкләр—ничек башың әйләнмәсен ди инде... Җырлары соң! Алар әти-әниләре шулкадәр күп җыр беләдер дип башларына да китермиләр иде. Апа-абыйларының туенда йомышка йөгерепме, искә алмаганнардырмы, хәзер килеп кайсыбер җырларны гомерләрендә беренче ишетеп, хәйран калып утырдылар. Мәҗлес бик шәп, бик күтәренке, хәтта мәңге йомык Гарифҗан да ачылды, Шакир кодасы белән кочаклашып җырлап, бар табынны көлдерделәр: «Дус яшик, кода, бергә-бергә яшик»,—дип, бер-берсеннән аерыла алмый, салалар да эчәләр, салалар да эчәләр болар, Әсматтәй кысылмаса һич туктар чамалары юк иде.

Бүген кыз ягы аяк өстендә. Сыйлыйлар да соң кодаларны! Тегеләре ялындыра, болары исертеп аяктан егарга тырыша. «Мисбах җизнинең тавышы бигрәк моңлы,—диде Луиза Илшатка.—Кара, ничек суза!»

> Һаваларда җидегән йолдыз,
> Ничә санасам да күчәдер.
> Ничә генә айлар, ничә еллар
> Гомеркәйләр ялгыз кичәдер—

дип җырлап, Алия апасының ире Мисбах Роза кодачага тулы чәркә бирде.

«Сүзләре нинди матур! Тукта, ә нигә «гомеркәйләр ялгыз кичәдер?» Ә апа, балалар? Луиза сагаеп бу икәүне күзәтә башлады. «Розага җизни өлеш бирде. Гадәттә, ир белән хатынга парлап бирәләр. Минем кайнага кайда соң? Ә-ә-ә, булган икән! Булуы житкән— башын өстәлгә салып, әвен базарына киткән. Ә соң «җинги» татарча җыр белә микән?» Шуңа җавап биргәндәй, Роза торып басты.

—Мин ведь жырлый белмим,—диде. Нечкә бармакларына чеметеп кенә тоткан чәркәне кызыл иреннәренә якын китерде.—Болай гына эчәргә можномы?

Аш ахырына якынлашкан, күп кеше исереп беткән, кайсы йоклап утыра, кайсы үзара сөйләшә иде. Ишеткәннәре:

—Юк, юк, алай ярамый, нинди җыр җырласаң да ярый,—диештеләр.

—Хет әтәч булып кычкыр!—диде кайсыдыр усалы.

Роза уйлагандай башын кырыйга салып торды да, елмаеп, матур гына тавыш белән, сүзләрен урысчарак яңгыратып:

> Сандугачлар ияляшкан
> Су ичярга миляштан,
> Кайгыларым битяр иде,
> Сине кюреп сюлашсам,

—дип җырлады. Җырлаганда сыгылмалы гәүдәсе өзлексез боргаланды, сыргаланды, иң кыланчык артистлардай кыланды. Ни хәл итәсең, бу да килешә иде ана, каһәргә! Җырны күтәреп алдылар. Розаның яңгыравык тавышы әллә каян аерылып торды.

> Эх, тала, тала, тала,
> Тала минем билягым,
> Нигя тала, нигя яна,
> Икян мине юрягым?

Жыр тәмамлану белән зал ишегеннән зур, биек торт күтәргән Алия белән Кадрия күренде, һәммәсе «аһ» итеп тортка карадылар. Ул арада кысыла-кысыла Роза кырына ук үткән Мисбах анардан буш чәркәне алды һәм колагына: «Сюляшербез, сюляшербез!»—дип пышылдады. Моңа җавап итеп Роза серле-вәгъдәле итеп елмаеп куйды.

Бу күренешкә бердәнбер шаһит—кәләшнен—йөзенә кара йөгерде. Нәкъ шул вакыт кинәт уянып киткән Айрат күзләрен ачты, аптырап тирә-ягына карады һәм, йодрыгы белән өстәлгә сугып: «Горька-а!»—дип кычкырды да башын кире өстәлгә салып, йоклап китте. Яшьләрне саный-саный үтызга кадәр үбештерделәр. Моның нәтиҗәсе шул булды: ике бите мәк чәчәгедәй янган Луизаның күнелсез уйлары юкка чыкты. «Жырның ертыгы юк, кода-кодачалар арасында андый гына шаярышу, тәртмә сүзләр була инде»,—дип үз-үзен тынычландырды ул.

Төн урталарына кадәр сузылган мәҗлес ахырына якынлашып килгәндә, Алия апасы Луизаларга эндәште:

—Акыллым, интегеп утырмагыз, иртәгә иртән торасыгыз бар, җәйге өйгә урын җәйдек, капкаларга да илттек, барыгыз, ял итегез!

—Без утырып торып каян арыйк инде—менә сезнең һушлар беткәндер инде,—диде Луиза аны җәлләп.

—И, апаем, мондый көнне аруны сизмисен ул,—дип, матур итеп елмайды Алия һәм сенлесенең аркасыннан яратып куйды.

Кәләш, кияү, шаһитлар—дүртәүләп бакча түрендәге җыйнак кына җәйге өйгә киттеләр. Болдырга менгәч, Луиза Илшатны туктатты:

—Азрак һава сулыйк әле, Илшат!—диде.

Төнге җиләслектән калтыранып китеп, кәләш белән кияү бер-берсенә сыендылар, эре-эре йолдызлар янган,ипи кебек түп-түгәрәк ай йөзгән күккә карап, тын тордылар.

—Без инде егет белән кыз түге-ел...—диде Луиза, моңсуланып.

—Син шундый матурсың бүген,—дип кайнарланып пышылдады Илшат.—Туй күлмәге бик килешә үзенә!

— Рәхмәт... Хәзер сиңа комплимент әйтәм, яме?.. Беләсенме, син миңа карата шулкадәр игътибарлы, кайгыртучан булдың...—Мин азрак куркып та куйдым, үзгәрерсен, бергә яши башлагач, икенче кешегә әйләнерсен дип.

—Нигә алай дисен? Нишләп үзгәрим ди мин?

—Минем сине өч, биш, ун елдан соң да бүгенгедәй ягымлы, әйбәт итеп күрәсем килә. «Егетләр йөргән чакта гына бер алдына, биш артына төшә, ә яши башлагач, кем икәннәре беленә»,—диләр бит белгән кешеләр!

—Әллә без аз йөредекме, Луиза? Җиде ел эчендә бер-беребезне аңлап бетермәдекме икәнни? Кара, әллә елый инде? Исәркәем! Андый уйлар башыңа каян килә? Елама, матурым! Хәзер үк тукта. Күзләрең шешенеп бетсә, иртәгә кешеләр нәрсә дияр? Ачуланам хәзер үзенне. Бик беләсен килсә: «Бөтен этлекнең башы хатын-кызда»,—диләр. «Кызларның барысы да яхшы, явыз хатыннар кайдан килә икән?»,—дигәнне ишеткәнең юкмыни? Шулай диеп, мин дә елыйммы соң хәзер?

—Бетте, бетте,—диде Луиза, яшь аша елмаеп,—елый күрмә!

—Әйдә, керик,—диде Илшат, кызны җитәкләп.—Сәгать дүрт тула бит.

Луиза алмагачлар аша үрелеп өйләренә карады.

— Безнекеләр йокламый... Утлары яна.

—Сезнекеләр котыла-а,—диде Илшат.—Иртәгә безнекеләрнең бисе бар!

Шулвакыт машина тавышы ишетелде. Ак автомобиль аккош сыман салмак кына капкадан үтте дә, ындыр артындагы олы юлга төшеп, күздән югалды.

—Күзгә күрендеме, чын булдымы бу?

—Мисбах җизнинең «девяткасы» бит, танымадыңмыни?—дип җаваплады Илшат.—Берәр йомыш-фәлән килеп чыкты микән?

—Белмим, белмим...—дип җилкәсен җыерды Луиза. Тавышы тоныкһәм таркау иде. Илшат гаҗәпсенеп кызга карады, тик эндәшмәде.

## VI

Икенче көнне иртүк уяулы-йокылы каләш белән кияүне кыз мунчасына озаттылар, кайткач, кыстый-кыстый тәбикмәкләп чәй эчерделәр, чөгендердәй кызарган кияүнең беренче тәбикмәкне ашап бетерүен искә алып, карап тордылар. Бу вакытта Луизаларга кардәш тиешле көчле, калын тавышлы агай җырлый-җырлый кодаларны уята башлаган иде. Берәм-берәм уята торды, «башларын төзәттереп», «таксига»—түшәк-мендәрләр түшәлгән бәләкәй арбага утыртышып мунчага җибәрә барды. Ике егет, кыска араны озын итеп, ихатаны кат-кат әйләнеп, кодаларны мунчага ташыдылар, аннан шау-шу куптарып, чын атлардай кешнәшеп, яшьрәкләрен ега-аудара алып кайттылар. Илшатның бизнесмен агасына үзен күрсәтергә җай чыкты: теге егетләргә икесенә дә мул гына акча төртеп, өйгә кадәр үк күтәрттереп керттерде. Мунча шау-шулары тәмамлангач, күрше генә өйгә ашка кереп чыктылар да кыз ягындагы соңгы ашка—«ыступай» шулпасына—җыелдылар.

Илшатның ашыга-каударлана башлаган туганнарына карап, арудан, төн йокламаудан күз төпләре шешенеп киткән апаларының, әнкәсенең үзенә ничектер сәеррәк, җәлләгән сыманрак карауларын сизеп, Луизаның күңеле тулды. Туй мәшәкатьләренә чумып, моңа кадәр уйламаганмы, уйларга теләмәгәнме—иң ахырда аны япа-ялгызын чит өйдә, ят кешеләр арасында калдырып китәчәкләрен, туй дигән бу бәйрәмнен дә эчтәлеге шул—аны, Луизаны, гамьсез кыз вакытларыннан, әткәсе-әнкәсеннән, өеннән аеру икәнен бөтенләй оныткан иде. Машинага утырып, озатырга җыелган күршеләргә акча сибеп, үзе буяган зәңгәр капкалардан чыгып киткәндә, күзләренә яшь тыгылды. Бер-ике көнгә бакчага бәйләп куелган Актырнакларының шыңшый-шыңшый өрүен ишетеп, түзә алмады, яшьләре тәгәрәшеп итәгенә тамдылар.

—Артына борылып карый күрмә, Луиза, ярамый,—дип акыл өйрәткән Илшатка хәтере калды, үзен ярдәмчесез, ялгыз, язмыш кулындагы бер уенчыктай тоеп, каршылыклы, аңлаешсыз тойгылар буранында адашты.

—Карагыз әле, килен балакаебыз елый!—Айгөл шаталакка житә калды, кычкырып көлеп җибәрде.—Ничек еламаска кирәк—ны-ык еракка, авылның теге-е-е очына ук китә, әйбит, Илшат?

— Еласын, еласын, туйда еласаң, соңыннан еламыйсың,—дигән шаһит егеткә дә пырылдап каршы төште:

—Кит, борынгы заман түгел инде хәзер! Фәйрүзә апа белән Әсматтәйнен инде җиде ел «кодагый» диешеп йөргәннәрен белмисеңдер шул!

Шулвакыт юлларына дәү трактор аркылы төште. Илшат белән шаһит егет «юл басучылар» белән сөйләшергә киттеләр. Килешеп, кузгалып киткәннәр иде, тагын туктаттылар.

—Безнең очларның балдызны җибәрәселәре килми-и,—дип сузды руль артындагы Мисбах җизниләре. Илшатның бизнесмен агасының «Мерседес»ы ватылыбрак тора, шуна күрә яшьләргә «девятка»га утырырга туры килгән иде.

—Сонга калганнар,—дип көлде Илшат.—Сандугачларын лачын эләктерде.

—Һай, бажа!—Мисбах та көлеп җибәрде.—Сүзен дә табасың, әй? Ничек әле, «Яшәгән ди өч бажа... »мы әле? Өч бажа булдык шулай итеп. Шә-әп! Ничек, йокы туйдымы соң?

—Яшь чакта кеше йоклап торамы? Бигрәк тә өйләнгән төнне,—дип үткен телләнгән Илшатны бүлеп, Луиза сүзгә кысылды:

—Ә синең, жизни, йокың килмиме? Әйбәт йокладыңмы?—Мисбах көзгә аша ялт итеп, Луизага карап алды.

— Мине картка чутлыйсыңмыни, балдызым-йолдызым? Хе-хе... Алия апаң белән икебезгә житмеш кенә яшь бит әле!

Илшат, Айгөл, шаһит егет машина салонын тутырып көлештеләр. Мисбах магнитофон кабызды, күнелле музыка яңгырады...

Капка төбенә җыелган каршылаучыларга чәк-чәкләрен сибеп, килен төште. Кияү кәләшне машинадан күтәреп алып, күтәрмәдәге ап-ак мендәргә бастырды. Фәйрүзә апа, хәзер инде Луизаның бианасы, теләкләрен телители балаларга бал-май каптырды, килен он аягыннан атлап, кияү йортына аяк басты. Ихатада мут кодалар, уенлы-чынлы сатулашып, кызның сандыгын, урын әйберләрен, ияреп килгән малларын саттылар. Бераздан өйдә Коръән ашына җыелган күрше-тирә, әбиләр, олы кодаларга бирнә күрсәтү башланды. Луизаның апалары тәрәзә-ишек пәрдәләрен, чыбылдыкларны, карават-мендәр япмаларын күрсәтеп-күрсәтеп куйдылар, тастымал-сөлгеләрен элделәр, тагын әллә нинди «тиеш»ләрне җиренә җиткерделәр.

Луиза боларны күрмәде дә, белмәде дә, аның бөтен кайгысы су юлы иде. «Суым чайпалмаса гына ярар иде»,—дип тели-тели чәчәкле чиләкләрен бизәкле көянтәсенә элде. «Икенче көянтә белән кем барыр, гадәттә, бу эшкә җиңгиләрне кушалар. Кайсысының кулыннан килерлек—марҗа җиңгинеме? Розанынмы?» Луиза гына түгел, су юлын күрсәтергә баручылар да шулай уйладылар. Шул чак һәммәсен дә аптыратып, Роза үзе үк чиләкләргә барып тотынды.

—Арысам, күтәрешерләр әле,—диде ул, як-ягына шаян караш ташлап.

Ул кызыл өрфия күлмәк кигән, бөдрәләткән чәченә алсу чәчәк кадап куйган—бу каракучкыл йөзенә, кап-кара күзләренә бик килешә, бик матур иде ул бүген.

Луиза ялт кына капка төбендәге кешеләрне күзеннән кичерде. «Кем күтәрешер икән соң? Айрат кайнагам күренми ләса, һаман айнымаганмы?»

—Күтәрешми димени инде, кодача, күтәрешербез! Өшемисеңме соң, юка киенгәнсең? Җилләп тора,—диде Мисбах җизнәсе.

Луиза Алия апасына карады. Коймага сөялгән апасы беләкләре белән үзен кочаклаган да җиргә төбәлгән, йөзенә карап берни белерлек түгел. Аның өстендә дә юка гына җинел күлмәк, янакларына каз тәне дә калкып чыккан иде хәтта.

«Ишетмисеңмени, апа-җаным? Күрмисеңмени?—дип эченнән үртәлде кыз.—Шул юханың чәченә ябышасы урында торасың мәлҗерәп! Ник гомер онытмаслык иттереп сабагын укытмыйсың? Син аның кебек артык чибәр дә, нечкә билле дә түгелсен, тик син иреннең законлы хатыны! Кеше алдында ник үзеңне мыскыл иттерәсең?»

Ниһаять, җыелышып, бала-чагаларны ияртеп, су юлына баручылар урам буйлап, гармун уйнап, авыл очындагы чишмәгә юнәлделәр. Алар китеп кенә өлгерде, ихатада шау-шу купты. Кыз ягында кичке ашны йоклап уздырган Айратны, Фәйрүзә апаның кисәтеп куюына карамыйча, ничек кирәк, алай уятып, «Син бит Илшатның бертуган агасы, йоклап яту килешми, табын карашырга, сыйлашырга кеше кирәк»,—дип торгызганнар иде. Яхшылыктанмы-явызлыктанмы, холкын белепме-белмичәме, кайсыдыр «акыллы башы» Розаның иркен кылануы хакында «тишкән», төнлә югалып торган машинаны күрүчеләр дә булган, бу хәбәрне Айратка китереп җиткергәннәр. Айнык чагында юаш кына ир артыграк эчеп алса, алыштырып куйгандай була, күнеленә җыелган бөтен ачуын берьюлы чыгарып түгә, ачуярсуын шулай тыя алмый, кыза торган гадәте бар иде.

— Кая Роза? Кайда ул шайтан хатын? Кайда йөргән бүген төнлә? Мина ничек тагылганын оныткандыр! Күрсәтәм мин ана хәзер. Тагын элекке гадәтенне куа башладынмы, у-у, өстерәлчек,—дип җенләнеп, ихата бетереп хатынын эзләгән Айратны тынычландырырга тырышсалар да, файдасы булмады. Бу вакытта өйдә Коръән ашы бара иде, тизрәк Шакир абый белән Фәйрүзә апаны чакырып чыгардылар.

«Бөтен туйның ямен җибәрә, күпме халык, кодалар алдында аләм хуры

ясый инде»,—дип, коты очкан Фәйрүзә иренә ялынды:

—Син ата кеше бит, тый малайны, бәйләп келәткә булса да ташлагыз!

Дөнья күтәргә, эшкә бик маһир, әмма йомшак күңелле Шакир абзый кулларын җәеп:

—Ничек алай итәсен инде,—дия генә алды.

Бу хәлләр йөрәгенә капкан ана йөгереп өйгә керде. Кулына беренче эләккән касәгә куе чәй салып, плитәдән чажлап торган чәйнекне алды, кулы пешүен дә сизми кайнар су агызды да, Айрат кырына чыкты.

—Улым, куе гына итеп чәй ясадым, мә, эчеп җибәр әле, йөрәгең басылыр,—дип, тузынган Айратка тирән касәне сузды.

— Чәй кайгысымыни! Хатын кайда, хатын?—дип дулады улы.

—Ай!

Фәйрүзә апаның кулыннан чәе төшеп китте, кайнар су Айратның аягына түгелде. Ир кыргый тавыш белән кычкырып җибәрде:

—А-а, пеште, аяк пеште! Скорый! Дүртенче степень ожог! А-а-а!

Әнисе катык алырга кар базына төшеп китте, тизрәк фельдшерга кеше җибәрделәр. Айрат кечкенәдән үк чирдән, аз гына авыртудан да бик курка иде. Шуна да, пешүе әллә ни зыянлы булмаса да, район үзәгендәге шифаханәгә барырга кирәк дия башлады. Аннан: «Юньле врачлары да юктыр әле анда, шәһәргә китәбез ожоговый центр тәүлек әйләнәсенә эшли»,—дип, машиналарына кереп утырды. Ул арада Розаны да чакырып алдылар. Фәйрүзә апа тиз-тиз туй күчтәнәчләрен төяде, кием-салымнарын җыйнады.

—И -и, җайсыз булды, балакайларым, кем уйлаган, бәла аяк астында дип дөрес әйтәләр шул, тизрәк терел инде, гаепләп китмәгез инде,—дип, озатып калды.

Тәнәфескә, саф һавага чыккан кодалар, кунаклар Айратның аягы пешү хәбәрен ишетеп кызгандылар, туйны күрми дә калды, дип җәлләделәр, аннан: «Туйда андый гына хәлләр була инде»,—диешеп, Фәйрүзә апаны юаттылар.

***

Тау астындагы чишмәдән килен балакай су ала. Эре-эре ташлар арасыннан йөрәк сыман бертуктаусыз бүлк-бүлк сулкылдап саркылган суны кушучлап ала да, өр-яңа чиләкләренә сала.

Вакыт туктаган. Дөнья тын. Су гына челтер-челтер... Ак күбек күлмәкле яшь киленме, әллә аларны гомерендә бик күп күргән борынгы чишмә үземе, яшел чирәм ябынган тау битеме, сирәк-мирәк йомшак болытлар йөзгән аяз күкме—акрын гына моңлы көй көйли, изге теләкләр тели кебек.

Салкын суың авыз итим, көмеш чишмә! Авыр уйларымны агызып китче, йөгерек чишмә; пакъләнсен күңелем, җиңеләйсен җаным; фани дөнья сынавына бирешмимче, олуг чишмә; син өстеннән аккан ташлар сыман, таш булыймчы төшкән җиремдә; сиңа килер идем, битем юар идем, бөреләнсә чәчәк күкрәгемдә; пар чиләкләрем мөлдерәмә итәм салкын суың белән, бәхетебез булсын диеп шулай, теләк теләп; яман күздән, ялган сүздән, явыз уйдан сакласаңчы, изге чишмә; башын иеп тезен чүккән балаң синең алда, күрче, чишмә...

Дөнья тын... Чишмә генә—челтер-челтер, челтер... Яшь киленгә су юлы күрсәтергә төшкәннәр.

♣



Рәшит
Ягъфәров

# КАЛГАН ХӘТЕР—ЯНГАН КҮПЕРЛӘР

## «Көрәшчеләр»

Без бит көрәшчеләр токымыннан,
Без өйрәнгән һәрчак җиңәргә.
Җиңәр өчен без үләргә әзер
Һәм гомергә иза чигәргә.

Дошманнарны—дошман, дусларны без
Дошман ясыйбыз да кайчакта,
Көрәшәбез һәм җиңәбез аны—
Адәм көлкесенә калсак та.

Җимерәбез дә, аны торгызырга
Яңа көрәш фронты ачабыз.
Торгызгачтын шушы алгарышны
«Юабыз» һәм күңел ачабыз.

Эчкелеккә илне сабыштырып,
Аңа каршы көрәш ачабыз.
Халыкларга сугыш ачабыз да,
Кычкырабыз: «Тыныч яшәгез!»

Туп типсәк тә, ни типсәк тә безгә
Җиңү кирәк,—
Шунсыз инде яши алмыйбыз.
Ә тибәргә хәлдән килми икән,
Җиңешергә негр яллыйбыз.

Башта бик тырышып илне-көнне
Батырабыз да рухи сазлыкка.
Аннан кычкырабыз дөнья ярып:
«Көрәш ачтык әхлаксызлыкка!»

...Җиңәбез дип адарынып йөрдек
Килмәсме дип илгә җиңеллек.
Җиңгән саен тормыш арбасына
Ат шикелле үзебез җигелдек.

Рәшит ЯГЪФӘРОВ (1946)—*галим, фольклор белгече, җәмәгать эшлеклесе; «Тулпарларым», «Тулпар моңы» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

Җиңелгәннәр күптән җиңеллектә
Көн күрәләр кадер-хөрмәттә.
Алар алган зур-зур биеклекләр
Кул җитәрлек түгел үрелеп тә.

Бәлки инде Рәсәй дигән илдән
Җиңешүләр чоры киткәндер.
Бәлки инде җиңү чире белән
Көрәшергә вакыт җиткәндер?!

## Җирдән килгән, җиргә китәргә тиеш

*Илдә җирләнмәгән мәетләр күп,*
*Зилзиләләр шуңарга бетми.*
Әбием сүзе.

Җирдән килгән җиргә китү тиеш,
Гафу итми җир-су хилафны.
Җирдән килгән, җиргә китү тиеш
Саилчеме анда, хәлифме...

Илгә-көнгә кайгы, афәт килсә,
Кирәк түгел аны гаепләү.
Фронт-фронт булып җирдә ята
Сугышлардан калган мәетләр.

Чекерәеп күккә карап ята
Күмелмәгән кеше башлары.
Нишләсен соң шунда табигатьнең
Зилзиләсе, бозы, ташлары?!

Яшерергә тели ул аларны
Туфрак белән, кар-боз, таш белән,
Түләмәсен өчен бу гөнаһны
Без—адәмнәр кайгы-яшь белән.

...Ник бәрәкәт килсен бу илгә?
Нигә бәхет иңсен бу җиргә—
Афәт теләп барлык җиһанга,
Мәет яткач Үзәк мәйданда...

## Мөдәррис үлеменә

*29 ноябрьдә М. Әгъләмне җирләгән вакытта*
*мин хастаханәдә ята идем. Төш күрдем.*
*Ул минем караватта ята имеш.*
*Мин әйтәм: «Мөдәррис, син үлдең бит,*
*сине бүген җирләделәр», дим.*
*Мөдәррис әйтте: «Мин түгел ул!»—диде.*

Бөекләр дә китә дигән сүзгә,
Ник ышанмый икән бу күңел.
Төшләремә кереп әйтте рухың:
«Мин түгел ул, дустым, мин түгел».

Төшләремә кереп пышылдыйсың,
«Мин үлмәдем, тере мин!» дисең.
Рухың исән, күктән атылып төште
Әгъләм атлы сәйяр бер җисем.

«Мин китә алмам,—диеп җырладың син,—
Милләтемә хөрлек килмичә».
Җаның йөрер инде илләр буйлап,
Китә алмассың «шуны белмичә».

...Мин төшемдә хакыйкатьне күрдем,
Бу төшемдә юктыр ялган һич.
Күк йөзендә сәйяр йолдыз аткан
Син түгелме ул, дустым Мөдәррис?!

## Янган күперләр

Гомер узды, туннар тузды инде,
Сикәлтәле юллар үтелгән.
Яшьлек ярларына кайтыр күпер
Сүтелгән шул инде, сүтелгән...

Бәгырьләргә тулып күпме өмет,
Күпме хыял җанда йөртелгән.
Кайсы калган, кайсы мәңгелеккә
Хәтер битләреннән сөртелгән.

Туйлар узган, туннар тузган инде,
Башка төште күпме хәтәрләр!
Пыскып ята җанда, көйрәп ята
Калган хәтер—янган күперләр.

Бу гомерләр безнең җаннан җанга
Күпер сала-сала үтелгән.
Алда юл өзеге, ә артымда
Янган күпер ята төтенләп.

Гомеркәйләр күпер салып үтте
Хыял кая дәшә—шул якка.
Салган күперләрем янып ята,
Сират күпере инде чиратта.

## Ахырзамангача барырбызмы?

Монысы татар, монысы башкорт диеп
Бүлгәләмик әле бер йортны.
Бөек башкорт һәрчак татарлы ул,
Бөек татар—һәрчак башкортлы.

Бөеклекләр чиктән аша кайчак,
Гәп корабыз, минме, кем бөек?
Июләр юк башны бер-беребезгә,
«Хәлең ничек, туганым», диеп.

Даулашабыз, шаулашабыз кайчак:
Тукай—кемнең, кемнең—Кол Гали?
Сабан туе кемнең, Карга туе...
Шул хакта да бәхәс булгалый.

Без ике кош Рәсәй урманында—
Яшәвебез мисле Сак та Сок:
Империя атлы үги ана
Безне каргаганы ап-ачык.
Шул анабыз җимнәр сипкән була,
Шуны бүлеп,
Чукышабыз менә чат та чот.
Чукышулар түгел, кавышулар,
Елашулар кирәк кочаклашып...

Күпме чәйнәрбез соң
Җим дип сипкән
Империя алдау-чәерен.
Ахырзамангача барырбызмы
Мәңге бергә, мәңге аерым?!

... Монысы—безнең, монысы сезнең, диеп
Бүлгәләмик әле бер йортны.
Бөек башкорт—һәрчак татарлы ул,
Бөек татар—һәрчак башкортлы!



Нурихан Фәттах

# АКЛАН

ХЫЯЛЫЙ РОМАН

*Язучы Н. Фәттахның бакый дөньяга күченүенә дә өч елдан артык вакыт үтте. Минем өчен ул һаман да исән кебек, чөнки өйдә кая карасаң да аның төсен саклаган әйберләр, китаплар...*

*Мәрхүмнең хатыны буларак, Нуриханның архивын барлаганда мин моңа кадәр беркайда да басылмаган, ләкин очланмаган өр-яңа романга тап булдым. Бу роман авторның мәңгелек хыялы—Атлантида турында. Атлантида бик күптән юкка чыккан серле җир. Нуриханның тел төбеннән аңлашылганча, безнең иң-иң борынгы бабаларыбыз имеш шунда яшәгән. Утрауны көчле вулканнан соң җир йоткан, ләкин кемдер исән калган, гасырлар буе күченә-күченә аларның нәселләре безнең көнгә кадәр килеп җиткән. «Безнең милләт кешеләре арасында европеид типлар булган кебек, негроидлар да очрый»—дип Нурихан еш кына кешенең йөз-кыяфәтенә, баш сөяге төзелешенә минем игътибарны юнәлтә торган иде. Әсәрне мин «хыялый роман» дип атап, авторча басылып чыгуын теләр идем.*

*Безнең шәхси китапханәдә «Казан утлары» журналының 1950 еллардан башлап чыккан барлык саннары кадерләп саклана. Н. Фәттахның һәр яңа әсәре әлеге журналда дөнья күргән. Шуңа күрә ошбу романны да «Казан утлары»на тәкъдим итүем үзеннән-үзе аңлашыла дип уйлыйм.*

**Руфина ФӘТТАХОВА,**
*ТРның атказанган врачы.*

—Алар изгеләр булганнар. Аларны туфан харап иткән. Өйләре, байлыклары җир астына күмелеп калган. Балталары, пычаклары җиздән булган. Тимер шеш белән җиргә төртеп карадың исә, шыкы-шыкы иткән тавыш килә ди. Теләсә кемгә ишетелми икән. Ятим балага гына ишетелә ди. Әткәй сүләй торганые, элек җиз табаклар, алтын-көмешләр тапканнар дип...

*Буә буенда, Очлы тау башында Изгеләр чишмәсе янында Урта бабай Мәхмүтҗан белән сөйләшүдән.*
*1961, 30 апрель, Яңа Уртавыл.*

***

Борын-борын заманда, җир белән күк бер-берсеннән аерылып, якты дөнья туып килгән бер вакытта, Аклан утравының үзәгендә—Үзән уртасындагы Түгәрәк тау башында ирле-хатынлы ике кеше яшәгән. Дөньяда болар ин

беренче, ин әүвәлге кешеләр булганнар. Аларның тагын Дикә исемле кызлары булган. Кыз буйга үсеп житкәндә, ирле-хатынлы кешеләр бер-бер артлы дөнья куйганнар. Бөтен тау башында, бөтен үзәндә, хәтта бөтен дөньяда кеше затыннан булган Дикә бер үзе торып калган. Ул бик кайгырган, курыккан һәм ничек тә үзенең куышыннан чыкмаска тырышкан. Ләкин эчендә жаны булган таза кеше куышта гына ята алмаган. Әледән-әле аңа чишмәгә—суга, урманга—утынга барырга туры килгән. Чишмә шактый еракта, тау астында булган, урман да бик үк якын түгел икән. Урман ягында аеруча куркыныч тоелган. Караңгы төшү белән анда берсеннән берсе ямьсез тавышлар ишетелгән, кемнәрдер сугышкан, чинаган, үкергән. Шатыр-шотыр китереп юан агачларны сындырганнар, акыртып-бакыртып кемнәрнедер бугазлаганнар да, шомлы рәвештә кинәт тынып калганнар. Кайчагында дөп-дөп басып, якыннан гына, куыш яныннан гына иләмсез зур филләр, арысланнар, юлбарыслар узып киткән.

Төннәрен ялгыз Дикә рәтләп йоклый да алмаган—тирә-якка колак салып, куркып, дер-дер калтыранып чыккан. Куышта, идән уртасында өзлексез ут янган. Ялгыз Дикә ничек тә шул утны—әтисеннән-әнисеннән калган бердән-бер дустын, булышчысын, яклаучысын сүндермәскә тырышкан. Куыш эчендәге чокырда аның тагын әтисеннән-әнисеннән калган арпасы, бодае, борчагы булган. Арпа да, бодай белән борчак та ул вакытларда кыргый үлән белән аралашып үскән. Арпа, бодай, борчак үсә торган жир аста, тау итәгендә булган. Шуңа күрә Дикә, тау астына төшәргә куркып, чокырдагы арпасын да, бодаен, борчагын да саклап кына тота икән.

Түгәрәк тау башындагы ялгыз куышта шулай яшәштереп ятканда, көннәрдән бер көнне, язга таба, диңгез уртасындагы Аклан утравына каяндыр бер ялгыз кәмә килеп туктаган. Калку борынлы жинел кәмәдән озын буйлы яшь бер жегет төшкән. Үзе шундый чибәр ди, бер бите ай, бер бите кояш кебек балкып тора ди. Унике толымга үрелгән чем-кара чәчләре артыннан жилбердәп, тирбәнеп, сузылып килә ди. Кулына бу көмеш жәя тоткан, биленә кызыл садак таккан, садагы тулы—бөркет каурыйлы алтын ук ди.

Кәмәдән төшкәч тә бу каядыр яр буйлап китеп барган. Көне буена бу яшь аучы үзәндә кошлар, киекләр атып йөргән. Кичкә таба, арып-алжып, янадан кәмәсе янына килгән, ярдан беркадәр читтәрәк учак ягып кошларын, үрдәкләрен кыздырып ашаган. Кәмә туктаган жирдән якындарак челтерәп чишмә агып ята икән. Тамагы туйгач, ят аучы иелеп чишмәдән су эчкән дә, чишмә буендагы чирәмгә башын төртеп шундук йокыга талган.

Икенче көнне иртән, таң атып кояш чыгу белән, түгәрәк тау башындагы Дикә чишмәгә суга дип киткән. Үз күнелен үзе күтәреп бу жырлый-жырлый бара икән. Жыры бик тә моңлы да, дәртле дә икән. Ул чакларда әле иген игү булмаган кебек, житен игеп, киндер сугу да булмаган, агач-таштан, балчыктан савыт-саба ясау да булмаган. Дикә үлән сабакларыннан үрелгән чыпта сыман алъяпкыч бәйләп куйган икән дә, кулына эче алынган зур гына кабак тоткан икән. Чыпта алъяпкычы да, суга йөри торган буш кабагы да, моңлы жыры да Дикәгә, әлбәттә, әнисеннән калган булган.

Дикә бик чибәр булган. Ялгыз утрауда ялгыз башы яшәп ятса да, бераз гына көяз дә икән. Ул да озын кара чәчләрен өч толымга үреп, толымның икесен күкрәгенә, берсен аркасына салындырып куйган. Ике яклап чигәсендә беркадәр көдрә чәч бөртекләре калдырган ди. Нәфис муенына—диңгез буендагы асыл ташлардан тезелгән муенса, нәни генә колакларына ялт итеп торган бакыргыч алкалар таккан ди. Сызылып киткән нәзек кашлары кара, иреннәре яңа өлгергән чия кебек, ике як бите—кызарып пешкән алма кебек ди.

Батыр аучы йокы аралаш Дикәнең җырын ишеткән дә, уянып киткән. Түгәрәк тау өстеннән төшеп килүче ике аяклы, ике куллы яшь кызны күреп, аучы җегет бик гаҗәпләнгән. Ул, күрәсең, бу утрауда адәм затыннан беркем юк дип исәпләгән. Кыз да моны күреп алган. Күреп алган да, искәрмәстән кычкырып җибәргән. Әтекәем-әнекәем! Бу ни бу? Дөньяда аңа, аның мәрхүм әтисенә-әнисенә охшаган башка җан ияләре дә була микәнни? Әнисеннән бигрәк ул Дикәнең әтисенә охшаган. Нишләп йөри ул? Ни кирәк аңа монда?

Куркудан кызның кулындагы буш кабагы төшеп киткән, аяк астындагы, очлы ташка туры килеп, кабак ярылган. Дикә моңа, әлбәттә, бик кайгырган— куышта аның бүтән савыты булмаган. Иелеп ярылган кабак кисәкләрен бер-берсенә беркетмәкче булып азаплана икән бу. Кабак кисәкләре бер-берсенә берекмәгән. Дикә җыларга тотынган.

Яшь аучы карап торган-торган да, кызның күз яшьләрен күреп, аягына баскан, Дикә янына килә башлаган. Кыз исә, ватылган кабагын ташлап, куркып, куышына таба йөгергән.

—Дикә, курыкма миннән!—дигән шул чакны яшь аучы телгә килеп, чын безнеңчә, лелегчә итеп.

Ул моны шундый ягымлы итеп, якын итеп әйткән, үзе дә сизмәстән Дикә туктап калган, борылып караган.

—Каян беләсең син мине?—дигән ул шаккатып.

—Беләм инде,—дигән аучы.

Аяк астында аунап яткан кабак кисәкләрен кулына алган, ике кисәкне бер-берсенә якын китергән, беркеткән дә, бөтен килеш кызга биргән. Янадан элекке хәленә кайткан кабак кисәкләренең ялганган җирендә җөе дә калмаган ди хәтта. Сөенеченнән Дикә көлеп җибәргән.

—Син... кем?—дигән ул яшь аучының йөзенә туры карап.

—Мин,—дигән аучы.

—Син шул, син!—дигән Дикә—Мин синең исемең ничек димен.

—Мин,—дигән аучы, күзләреннән шаян нурлар сирпеп.

—Нишләп йөрисең монда... минем утрауда?—дигән кыз, ачуланасы килеп.

Ул, билгеле, ачулана алмаган. Юри генә ачуланган булып күренергә тырышкан. Кызлар бит гел шулай: аларның ачулы сүзләре дә яшь җегеткә мактау булып ишетелә.

—Нинди чибәр син, Дикә!—дигән яшь аучы да, соклануын яшерә алмыйча.

Иплән кенә ул кыз янынарак килгән, аның кулыннан тотып алган. Шул чакны ятимә кыз Дикәнең күңеленә гыйшык уты үрләгән. Куанып ул тагын көлеп җибәргән. Якында гына сандугачлар сайраган, аяк астында кызыл гөлләр калкып чыккан. Күктән исә, сөенеп, мәңге яшь, мәңге тере кояш көлеп торган.

Шуннан соңмы? Шуннан соң ни булганын Акланда белмәгән кеше юк. Шуннан соң ту анабыз Дикә үзенең олы кунагын чыбык белән терәлгән, балчык белән сыланган ярлы гына куышына алып кайткан. Шунда алар бергә-бергә тора башлаганнар. Үзен Мин дип атаган кунак көн дә ауга йөргән— урманнан киек, күлдән кош-корт, диңгездән балык алып кайткан. Ул кайтуга Дикә Ут-учакта ашарга пешергән, өен бизәгән, үзен бизәгән. Ул үзендә гаҗәеп бер үзгәреш барлыкка килүен сизгән. Дөньяда бар нәрсә аңа хәзер искиткеч матур һәм ягымлы булып тоелган. Ул инде хәзер беркемнән, бер нәрсәдән курыкмаган да, шикләнмәгән дә. Урман ягындагы төрле тавышлар да, якын-тирәдә лап-лоп килеп, чинап, үкереп, йөгереп йөрүләр дә үзеннән-үзе тынып калган. Дикәнең гел җырлыйсы, көләсе, елмаясы гына килеп тора икән.

Үзендә генә түгел, бөтен тирә-якта, бөтен тау башында гаҗәеп үзгәрешләр күреп, анабыз Дикәгә әледән-әле тан калырга туры килгән.

Бер көнне иртән торып тышка чыкса, куыш янында гына пешкән җимешләрен көчкә күтәреп, зәйтүн агачы үсеп утыра икән. Икенче көнне исә, зәйтүн агачы янында кузы, чикләвек, инҗир куаклары үсеп утыра имеш. Өченче көнне торып караса, элек ниндидер ташлар аунап яткан ташландык бер җирдә, яшел яфраклар арасында, кыяр, карбыз, кавыннар тәгәрәшеп ята ди. Тагын беркадәр вакыттан соң анабыз Дикә кабак савытын күтәреп, тау астындагы чишмәгә суга дип барган икән, кабакка чишмә суы ага башлау белән, күз алдында савыт ялтырап торган, чынлап торган көмеш чүлмәккә әверелгән ди.

Икенче көнне бу көмеш чүлмәген тотып янә суга киткән—ике кеше булгач боларга хәзер су элеккегә караганда күбрәк кирәк була башлаган. Куышыннан чыгып җырлый-җырлый тау астындагы чишмәгә төшеп килгәндә, анабыз Дикә якында гына, аяк астында гына, челтерәп аккан чишмә тавышын ишетеп, туктап калган. Караса, монарчы барлыгы-юклыгы беленмәгән куышлы бер җирдән, ак, кара ташлар арасыннан, гөлдер-гөлдер көйләп, сөйләнеп чишмә агып ята ди. Анабыз Дикә көлеп җибәргән, башта чишмәнең суын эчеп караган. Аннан көмеш чүлмәген тутырып алган да, куышына кереп китмәкче булган. Кайту ягына борылу белән, сукмакның икенче ягында тагын бер чишмә күреп, анабыз Дикә тәмам аптырап калган. Кызыксынып ул икенче чишмә янына килгән, эчеп караган. Монысының суы кап-кайнар ди, төмендә дә ниндидер ят, сәер тәм бар ди. Шулай да тәмсез түгел икән.

«Менә кызык!« дип уйлаган анабыз Дикә үз алдына. Салкын сулы көмеш чүлмәген куышына алып кайтып куйган да, «Туктале, кайнар су да алып кайтыйм« дип уйлаган. Шулай дип уйлап бетермәгән, салкын сулы көмеш чүлмәк янында икенче бер савыт барлыкка килгән. Монысы саф алтыннан ди, эче буш ди. Шулай итеп, алтын чүлмәген алган да, анабыз Дикә кайнар су алырга киткән. Чишмәдән кире борылып, үзенең ярлы, тәбәнәк куышына керим дисә, ни күрсен—түгәрәк куыш урынында матур итеп киселгән, юнылган, кызыл таштан төзелгән ике катлы биек сарай калкып утыра ди. Чишмәләр ягыннан сарайга кадәр аяк астына тигез итеп ак һәм кара ташларны аралаштырып таш җәелгән ди. Сукмак буенда, як-якта таш савытларда ят гөлләр үсеп утыра ди.

Бу юлы анабыз Дикә гаҗәпләнмәгән. Ул бары сөенгән генә. Үзәндәге, тирә-яктагы үзгәрешләрнең барысы да иренең хикмәтләре булырга тиешлеген ул инде күптән сизенгән. Чыннан да аның серле һәм куәтле ире—кеше кыяфәтенә кергән дингез алласы булган.

Алар бик дус, тату яшәгәннәр. Яшь хатынын яратканга, атабыз Мин аның барлык теләкләрен үтәргә тырышкан. Анабыз Дикәнең күңелендә берәр төрле теләк, хыял туып өлгерү белән, атабыз Мин аны шундук тормышка да ашыра икән. Үзләренең Түгәрәк тау башындагы куышларын-сарайларын гына түгел, бөтен Аклан утравын атабыз Мин дөньядагы барлык утраулардан яхшырак, күркәмрәк һәм Адәм затындагы кешеләргә яшәү өчен җайлырак итеп үзгәртергә тырышкан.

Аклан утравы җылы дингез уртасында утырса да, элегрәк көзен-кышын анда да салкын җилләр үтеп кергән. Салкын җилләр белән бергә, салкын болытлар ияреп килгән, шул чагында күктән өзлексез яңгыр коярга тотынган. Мондый чакта мәңге яшел агачлар, үләннәр бөрешеп калганнар, гөлләр саргайган, сайрар кошлар каядыр качышып беткәннәр, хәтта киекләр, җырткычлар да урман-тау араларында тынып торганнар.

Шундый бер кичне анабыз Дикә, инбашына каплан тиресе ябынып, учак

янында жылап утыра икән, көнеленнән үзе: кайчан жылы язлар житәр дә, кайчан гөлләр чәчәк атар, дип уйлана икән. Шул төнне көтмәгәндә нишләптер бик каты күк күкрәгән, жир селкенгән. Кайдадыр ялт-йолт килеп яшен яшьнәгән. Анабыз Дикә уянып киткән, куркып, шомланып тирә-якка колак салып яткан да, озакламый тагын йокыга талган. Иртән торып тышка чыкса, күктән коеп янгыр да яумый, күк тә күкрәми, жир дә селкенми икән. Зәнгәр дингез өстеннән балкып кояш чыгып килә, таш савытларда елмаеп аллы-гөлле гөлләр үсеп утыра, куакларда шатланып кошлар сайрый икән.

Сөенеченнән анабыз Дикә көлеп жибәргән, жырлап жибәргән һәм сарайдан тиз генә көмеш чиләген алып, чишмәгә суга килгән. Чишмә ягына борылганда утрауның төньягында башлары күккә тигән нидидер тауларга, кыяларга күзе төшкән моның. Аклан утравының уртасындагы Түгәрәк таудан башка элек монда бернинди тау да, кыя да булмаган. Димәк, атабыз Мин ул тауларны-кыяларны бер төн эчендә шулай үстереп, күтәртеп куйган! Ни булса булган, шул төннән соң беркайчан утрауга салкын жилләр дә үтеп кермәгән, күктән салкын янгыр да яумаган. Жәй көнендә монда эссе, коры булган, йомшак кына жылы янгыр яуган, дингез ягыннан шифалы, талгын жилләр искән. Шулай итеп, Аклан утравында мәнге кояш, мәнге жылы, рәхәт булган. Ел тәүлеге буена агачларда татлы, туклыклы жимешләр өлгергән, аяк астында яшелчәләр үсеп утырган, үзәндә, тау буйларында арпа, тары, бодай, борай ише игеннәр житешкән.

Анабыз Дикә иң әүвәл ике игезәк бала тапкан. Балаларның икесе дә ир затыннан булган. Икенче мәртәбә анабыз Дикә янә дә ике игезәк тапкан. Балаларның болары да ир затыннан булган. Барлыгы анабыз Дикә биш игезәк ир бала китергән. Малайлар бик таза, көр булган, ай үсәсен көн үскәннәр, ел үсәсен ай үскәннәр, аталары белән бергәләп ауга йөргәннәр, аталарыннан, бер-берсеннән күрмәкче төрле өнәргә өйрәнгәннәр.

Уллары үсеп житү белән, атабыз Мин, ауга йөрү, иген игү эшләрен тулысынча аларга тапшырган да, үзе исә ал-ял белми, утрауны тәртипкә китерә башлаган. Иң элек ул арык жибәреп Үзән уртасындагы түгәрәк тауны су божралары, жир божралары белән әйләндереп алган. Су божралары өч, жир божралары ике булган. Жир өемнәрен атабыз Мин таш киртәләр белән ныгыткан. Түгәрәк тауга кадәр дингездән турыга тагын бер арык ерган. Тау башында сарайлар, каравыл өйләре, корбан, садака өйләре салган һәм шуларның барысын да алтын койма белән әйләндереп алган. Бит ул заманнарда алтынны да, көмешне, жизне, бакырны да каяндыр таулар арасыннан эзләп табарга, ташлар ватып, кайнатып, эретеп табарга кирәк тә булмаган—барысы да аяк астында аунап яткан!

Озакламый Акланның даны чит жирләргә, чит илләргә таралган. Аклан турында ишетеп, төрле яктан кешеләр килә башлаган.

Бу вакытта инде игезәкләрнең беренчеләре үсеп буйга житкәннәр. Аларның да үзләренә аерым жир алып, сарай салып, башкаланып яшиселәре килә икән. Иң беренче улы Атласка атабыз Мин Кәми кызын, икенче улы Кадиргә Мис сары кызын алып биргән. Икенче пар игезәкләрнең өлкәненә атабыз Мин Кар кызын, кечерәгенә Луки сар кызын алып биргән. Өлкән улы Атласка атабыз Мин түгәрәк тауны, андагы барлык байлыкны мирас итеп калдырган. Кадир улына, башка барлык улларына Үзәндә жирләр—сулар бүлеп биргән дә, әйткән: «һәркайсыгыз үз жирегездә үзегез баш, барыгызга да агагыз баш», дигән. Аннан соң тагын шундый сүзләр дә әйткән: киләчәктә кинәясегез килсә, һәркем үзе торган жирдән турылап читкә китсен, яңа жир ачсын, жир эшкәртеп иген иксен, мал-туар асрасын, дигән.

Шуннан соң атабыз Мин Түгәрәк утраудагы, алтын койма эчендәге сарайлар, каравыл өйләре янына, иң калку жиргә биек таш утыртып куйган,

ташны уеп, киләчәк буыннанр өчен үзенең изге сүзләрен—юсык-юрык кагыйдәләрен язып калдырган. Акланның киләчәк сарлары, аксөякләре, кара сөякләре әлеге ташка уеп язылган, өстенә кайнар жиз коеп мәңгеләштерелгән изге сүзләргә ярашлы рәвештә яшәргә тиеш булганнар.

Бүгенге лелекләр менә шул аллабыз Мин белән жир кызы Дикә анабызның уллары. Лелекләр дөньяда иң изге кешеләр, лелекләр дөньяда иң өлешле, иң батыр, иң бай һәм куәтле кешеләр. Тора-бара мака сарның да, аның энеләренең дә биләмәләре арткан, халкы күбәйгән. Житез кәмәләргә утырып алар дингезнең әллә нинди жирләренә барып чыкканнар, якын-тирәдәге утрауларны, төньяктагы, көньяктагы, көнчыгыштагы, көнбатыштагы кыргыйларны үзләренә буйсындырганнар. Лелекләр—кояш уллары бер генә сугышта да җиңелмәгәннәр. Алар һәрвакыт җиңүче булганнар. Шуңа күрә дә барлык кыргыйлар—барбарлар алардан куркып, котлары алынып торалар. Шуңа күрә дә алар лелекләргә баш ияләр, көнләшәләр, сокланалар. Шуңа күрә дә Атлантита утравына төрле яктан көне-төне кәмәләр килә, кәмәләр белән мал-туар килә, коллар килә, байлык килә, алтын килә.

Боларын да Акланда белмәгән кеше юк. Тик шулай да монда әле беркем белмәгән-күрмәгән, белеп-күреп тә, күптән инде онытылып беткән нәрсәләр дә җитәрлек.

Атабыз Мин белән анабыз Дикә нәселеннән булган мака сарлар Түгәрәк тауны, Акланны бизәү, матурлау өчен шактый көч куйганнар. Ата сүзен истә тотып яңа юллар ясаганнар, арыклар ерганнар, елгалар аркылы күперләр салганнар. Утрауның әле бер төшендә, әле икенче төшендә жир ачып, таштан, агачтан йортлар, туралар төзегәннәр. Вакыт узу белән утрауда, биләмәләрдә кеше дә күбәйгән. Игенчеләр иген иккән, терлекчеләр мал-туар асраган, чүлмәкчеләр чүлмәк ясаган, тиречеләр тире иләп күн ясаганнар. Таш баганадагы изге сүзләрне истә тотып, изге сарлар Акланнан читтәге, ерактагы җирләргә күченеп утырганнар. Яңа җирләрдәге кыргыйларны өнәргә, анбелемгә үрәткәннәр.

Аклан кешеләре бик тырыш һәм эшчән булганнар. Ләкин алар гел эш белән генә дә мавыкмаганнар. Буш вакытларында жыйнаулашып күңел ачканнар—жырлаганнар, биегәннәр, каравыл эйләрендә, келәү эйләрендә изге Атабызга, изге Анабызга багышлап корбан биргәннәр, садака биргәннәр. Ятсалар да, торсалар да аллаларга, изгеләргә зекер әйткәннәр, үзләренең барлык эшләрен, барлык уй-теләкләрен атабыз Мин һәм анабыз Дикә сүзләренә ярашлы рәвештә башкарганга күрә, бер яктан ун агай-эне—мака сарлар, сакалар, икенче яктан ил-көн һәм каралар арасында беркайчан, берниндн дошманлык булмаган. Аклaндагы, биләмәләрдәге һәркем үз язмышыннан үзе риза булып, дөньяда үзен иң бәхетле, иң өлешле кеше диеп исәпләгән. Ул чакларда, имеш, кешеләр арасында авырулар да, ялгы һәм гарипләр дә булмаган. Ызгыш-талаш, ялган сөйләүне, комсызлыкны, җәбер-золымны әйткән дә юк. Берсе дә булмаган!

Бар бозыклык, комсызлык һәм җәбер-золым... сарлардан башланган. Әйе, әйе, дөньяда алла урынына калган мака сарлардан башланган. Моңа хәтта ышанасы да килми, ләкин ышанмыйча да булмый, чөнки дөресе шулай.

Кемнең нинди бозыклык эшләве турында сүз чыкканда иң элек мака сар Карунны искә төшерәләр.

Мака сар Карун эретеп кайнар жиз коелган таш баганадагы алла сүзләрендә монарчы беркем күрмәгән бер ни тапкан—тыелган нәрсәләрне бер-бер артлы тезеп саный барганда, изге атабыз Мин, әллә онытып, әллә башка бер сәбәптән, байлык жыюның язык икәнен әйтми калдырган.

Мака сар Карун моны күреп алган, уйлана башлаган һәм уйлана-уйлана,

тиешле нәтиҗә дә ясаган. Башкаларга сиздермәскә тырышып, мыштым гына бу алтын-көмеш, затлы ташлар җыярга тотынган. Алтын-көмешне, затлы ташларны, билгеле, элегрәк тә җыйганнар, ләкин булган берен кирәккә тота барганнар. Мака сар Карун болай гына, кызык итеп кенә җыйган. Аның бу кыланышы күзгә чалынмый калмаган, әлбәттә. Баштарак моңа кешеләр көлеп кенә караганнар. «Тиле таш җыяр!« дигәннәр. «Бала-чага да матур ташларга кызыга» дигәннәр. Кайберәүләр куркып: «Безнең сарның акылы җинеләймәде микән?» дип уйлаганнар. Мака сар Карун чынлыкта комсыз, хәйләкәр һәм бар нәрсәне алдан уйлап эшли торган аек акыллы кеше булган.

Белгәнебезчә, элегрәк дөньяда иң кадерле, иң кыйммәтле таш—көмеш булган. Алтын көмештән арзанрак саналган. Алтынны борынгылар җизнең бер төре дип белгәннәр. Шуңа күрә алтыннан савыт-саба, корал, кирәк-ярак эшләгәннәр. Мака сар Карун алтынның көмештән затлырак, кыйммәтлерәк икәнлеген аңлаган. Иң зур бозыклыгы аның менә шул булган ахрысы. Бер елны, илдәге юсыкны үзгәртеп ул, казнага бирелә торган һәртөрле салым, түләү өчен көмеш урынына алтын сораган. Монарчы көмеш таба алмый интеккән кешеләр бик теләп, сөенеп үзләрендәге барлык алтыннарын мака сарга ташый башлаганнар. Сарайдагы амбарлар, базлар алтын табаклар, чүмеч, тарак, аел, шөлдер ише нәрсәләр белән тулган.

Мака сар Карун ярым караңгы, салкынча, тын амбарларында, базларында, үзенең алтынын, затлы ташларын карап йөрергә ярата икән. Шулай бервакыт монын күнеленә: «Аклandагы барлык алтын-көмешне, җиз-бакырны, затлы ташларны үз кулыма алсам, нинди бай булыр идем мин!« дигән уй килгән, имеш. Алтын-көмеш матур гына, чыдам гына түгел, анда көч-куәт бар. Алтын-көмешең, затлы ташларың күп булса, корал кулланмыйча, теләсә кемне буйсындырып, теләсә кемне яулап, юк итеп була. Иң элек буйсынмас, баш бирмәс аксөякләрне буйсындырасың, аннан соң туганнарынны, тора-бара ерактагы күршеләр—чит илләр ягына да күз атарга була!

Менә шундый көннәрнең берсендә мака сар Карун сараена таякка таянып бер саилче карт килеп кергән. Чынлыкта ул саилче дә булмаган, Карлы тау келәүлегендә, изге тау куышында аллаларга зекер әйтеп яшәүче, күктәге айның, кояшның, йолдызларның күченешен өйрәнүче олы галим Сабир ата булган. Аның инде күптән ил башы мака сар Карун белән күзгә-күз очрашып сөйләшәсе-аңлашасы килә икән. Үзенең кемлеген һәм ни өчен килүен әйткәч, сарай сакчылары аны туп-туры Карун янына алып барганнар. Аллаларга якын изге кеше буларак, Сабир ата иң элек мака сар алдында бил бөккән, кулларын күтәреп, илгә-көнгә, мака сарга иминлек теләгән һәм тәхеттә кукраеп утырган Карунның таштай йөзенә туры карап:

—Син бик зирәк булып чыктың, мака сар,—дигән.

Мака сар Карунның беркайчан Сабир ата белән очрашканы булмаган. Беренче караштa ук саилче аңа ошамаган—әрсез, оятсыз һәм комсыз бер бәндә булып тоелган. Бит сарлар, көч-куәт ияләре үзләренә охшаганнарны да, охшамаганнарны да яратып җиткермиләр. Ләкин саилченең мактау сүзләре Карунның күнеленә сары май булып яткан. Ул шундук көлемсерәп куйган, ләкин ниндидер өтәләнгән, чыныккан саилче алдында йомшаклык күрсәтеп, байлыгыма зыян килмәсен дигәндәй, йөзендәге елмаюын яшергән дә бу, теләр-теләмәс кенә:

—Минем зирәклегем нидә күренә?—дигән.

Карун чыннан да үзен дөньядагы барлык кешеләрдән акыллырак, зирәгрәк дип уйлаган. Шулай да хәзер аның үзенең зирәкме-түгелме икәнлеген беләсе килмәгән, хәзер аның бу картны кыен хәлдә калдырып, түбәнсетеп, сараеннан тизрәк куып чыгарасы килгән. Бит бер оятсызга юл куйсаң, аның артыннан

икенчесе, өченчесе килеп чыгарга, сина төрле мактау сүзләре сөйләгән булып, синен серенне алырга, базына, амбарына кулын сузарга да күп сорамаслар. Ләкин, никадәр акыллы һәм зирәк булмасын, Сабир атага сорау биреп, ул инде «әрсезләргә», оятсызларга кин юл ачуын Карун сизмичәрәк калган.

—Син аны беләсен, мака сар,—дигән Сабир ата бирелгән сорауга жавап итеп.—Белмәсән,—син зирәк түгел, белеп тә белмәмешкә салынсан, син—икейөзле.

Мондый сүз ишетеп Карун корт чаккандай сикереп торган, ярсып, ачуына буылып:

—Син!.. Син!..—дигән.

Саилчегә анын нинди дә булса усал, ямьсез сүз әйтәсе килгән, ләкин үз алдында иелгән башны күреп, тынычлана төшкән. Каяндыр таш арасыннан, тау куышыннан килеп чыккан, акылга таман сынык картка ачулану, тупас сүз әйтү бөек сар өчен түбәнлек булыр иде, әлбәттә.

—«Мин»—кемме, нәрсәме?—дигән Сабир ата, мака сар тынычлана төшкәч.—Ялган сөйләсәм, башымны чаптыр, ялган сөйләмәсәм,—әйтәсе сүземне тынлап бетер, мака сар!

—Сөйлә,—дигән мака сар, ачуын йотып.

—Изге Карлы тау келәүлегендә, исәпсез-хисапсыз тау куышларынын берсендә бер таш такта бар. Тактага язу язылган,—дигән Сабир ата.—Анда әйтелгән: Аклан илендә йөз елга бер корылык, корылыктан соң ачлык килә, диелгән. Ачлык өч елга, хәтта жиде елга сузыла, диелгән. Корылык булыр алдыннан илдә каерылып иген унар, жыеп алган ашлыкны кая куяр урын табылмас, диелгән...

—Тукта!—дигән мака сар Карун, бөтен йөзе белән балкып.

—Әйттем бит, син зирәк кеше, бөек сар!—дигән Сабир ата чын күнелдән сөенеп һәм башка берни әйтмичә, борылып, чыгып китмәкче булган.

Хәзер инде мака сарнын моны тиз генә чыгарып жибәрәсе килмәгән.

—Ашыйсын, эчәсен киләдер, саилче ата?—дигән ул үтә дә ягымлы итеп.

—Мин сина ашарга-эчәргә килмәдем—серемне әйтергә килдем,—дигән Сабир ата түбәнчелек белән Карун алдында бил бөгеп.

—Ул борынгы тактадагы борынгы язуны синнән башка тагын укыган кеше бармы?—дигән Карун.

—Миннән башка аны беркем укый алмый, мака сар,—дигән Сабир ата, уйлагандай итеп.

—Андагы син әйткән сүзләрне тагын берәрсе беләме?—дигән Карун.

—Белә. Ул—син,—дигән саилче ата.

Мака сар Карун жинел сулап куйган. Беркадәр эндәшми торганнан соң әйткән:

—Минем сарайда да бер язулы таш такта бар. Беркем укый алмый. Шуны син укый алмассын микән, Сабир ата?—дигән Карун.

Беренче мәртәбә ул ана шулай исеме белән олылап «Сабир ата» дигән.

Язулы таш турында сүз чыккач, Сабир ата икеләнеп калган. Баш тартса, мака сар анын башын чаптырачак, баш тартмаса, анысын әлегә белеп булмый. Сабир ата шулайрак дип фикер йөрткән һәм:

—Син миннән дә зирәгрәк, мака сар,—дигән көрсенеп.

Мака сар усал итеп көлемсерәп куйган.

Шул ук көнне Карун очсыз гына бәягә икмәк сатып ала башлаган. Бөтен илдән—ерактан, якыннан башкалага ашлык төялгән кәмәләр, олаулар агылган. Мака сарнын амбарлары, чокырлары, базлары ашлык белән тулган. Тиз арада Карун тагын бер амбар салдырган. Бер айдан анысы да тулган. Кешеләр гажәпкә калганнар. «Әле таш жыя, әле икмәк жыя—чыннан да акылы жиңеләйгәндер монын»—дип уйлаганнар Аклан кешеләре. Ни өчен дигәндә,

алар бит үзләрен беркайчан кайгы-хәсрәт, ачлык булмый торган илдә яшибез дип уйлаганнар. Йөз ел элек илдә корылык булуын, ачлык булуын алар, билгеле, башларына да китереп карамаганнар.

Икенче елны бәхетле Аклан иленә корылык килгән. Ул елны кыш көне дә, яз көне дә күктән бер тамчы яңгыр төшмәгән. Әүвәлгечә көн-төн кояш кыздырган. Елгалар, инешләр саеккан. Чәчкән иген тишелеп чыккан да, үсеп буйга китә алмыйча, катып калган. Корылыктан болыннарда үләннәр саргайган, агач яфраклары бөрешеп, куырылып калганнар. Беренче елны ачлык бөтенләй диярлек сизелмәгән—амбарларда, чокырларда әле былтыргы ашлык булган. Икенче елны ачлык сизелә башлаган. Өченче елны ачлык үзен бик нык сиздергән. Агачлар корыган, урманнарда киекләр, кош-корт калмаган. Терлек-туар кимегәннән кими барган. Дүртенче елда бөтен илдә чын-чынлап ачлык хөкүм сөргән. Акланда гына түгел, Кәмидә, Акайда, Килмәттә, тагын әллә кайларда ул елларда кешеләр яңгыр теләп, әледән-әле күккә караганнар, әледән-әле елгаларны, инешләрне күзәтеп торганнар һәм аллалар алдында үзләрен языклы санап, әле анда, әле монда корбан биргәннәр, келәү әйткәннәр.

Икмәкнең бәясе башта ике мәртәбә, аннан соң биш-алты, хәтта ун мәртәбә күтәрелгән. Ун мәртәбә күтәрелгәч, Карун икмәк сата башлаган. Бөтен Акланның алтын-көмеше, энҗе-мәрҗәне Карун сараена агылган. Аклан иленнән генә түгел, мака сарга ерак- ераклардан ач кәмәләр килгән.

Ачлык җиде елга сузылган. Җиде ел буена Карун икмәк саткан һәм менә шул елларда чын-чынлап баеп калган да инде ул. Тирә-яктан агылган байлыгы җир өстендәге, җир астындагы сарайларга сыймый башлагач, бу җир астын казып кереп, еракта, тирәндә, иркен итеп амбарлар салдырган һәм иген сатудан алган барлык алтын-көмешләрен, барлык затлы әйберләрен шул амбарларга, чүлмәкләргә тутырткан.

Дөрес, боларның барысы да имеш-мимеш кенә. Сабир ата белән Карунның сүз көрәштерүе дә имеш-мимеш. Ләкин монда шунысы хак—атаклы Сабир ата Карун заманында, атаклы Карун Сабир ата заманында яшәгән. Сабир ата чыннан да бер мәртәбә Түгәрәк таудагы изге сарайда, Карун янында булган. Акланда йөз елга бер мәртәбә корылык, корылыктан соң ачлык булуын да ул әйткән.

Сабир ата мака сар сараеннан әйләнеп кайта алгандырмы, юктырмы—беркем белми. Ни генә булмасын, Карлы тау келәүлегендәге, тау куышларындагы каберләрдә Сабир атаның сыны да, язулы ташы да юк. Ләкин ул вакытларда әле үлгән кешенең исемен язып, таш сынын кую йоласы да булмаган бугай. Сабир ата бары Акландагы, Карлы тау келәүлегендәге бик күпләрнең хәтерендә генә сакланып калган.

Кайберәүләр әле һаман мака сар Карунны комсыз булган, ач күз булган, катмыш-саран булган дип, яратмыйча сөйләсәләр дә, Карлы тау келәүлегендәге изгеләр аны бары яхшы яктан гына телгә алалар. Ни өчен дигәндә, мака сар Карун Карлы тау келәүлеге өчен күптин-күп изгелекләр эшләгән. Карунга кадәр келәүлекнең җире бик аз булган—мака сар келәүлекнең җирен арттырган, иркен тигез үзәнлекне бүлеп биргән. Аннан соң келәүлекне биек таш койма белән әйләндереп алган. Элегрәк, Карунга кадәр, келәүлекнең җире һәр яктан ачык булган чакта, изгеләрнең байлыгы күптер дип, Карлы тауны әледән-әле диңгез юлбасарлары талап китә торган булганнар. Элегрәк бит Акланның яр буйларында кәмәле, кораллы сакчылар йөреп тормаган. Теләсә каян килеп чыккан диңгез юлбасарлары, бернинди каршылыксыз ярга чыгып, ярга якын теләсә нинди авылны, торакны талый, яндыра алганнар. Келәүлекне биек койма белән әйләндереп алгач, мондагы кешеләр аллаларга зекер әйтеп, иркенләп, тынычлап яши башлаганнар. Тагын шул—мака сар Карун Карлы тау келәүлегенә ярашлы итеп төп капка баганасына юсык яздырган. Элегрәк келәүлеккә кайчагында хатын-кызлар да аяк баса алган

булса, моннан соң монда хатын-кызның аяк басуы тыелган. Шул ук вакытта келәүлеккә «азил» хокукы бирелгән. Дингездә һәлакәткә очрап исән калган кешеләр, качкын коллар, җинаятьчеләр тәүлекнең теләсә кайсы вакытында килеп, капка кага алганнар һәм аларны берсүзсез келәүлеккә кертергә тиеш булганнар. Капка ачып кергән һәркем монда изге санала башлаган.

Аннан соң, көне-төне яна торган нәфит утын да Карун заманында җайлап куйганнар. Очлы кыя башындагы түгәрәк көн өен дә, кыялардагы баскычларны да, тагын әллә нинди куышларны да шул ук заманнарда ясаганнар. Тау тарлыгы каршындагы буар җылан да әле яшь булган, бала гына булган. Ул шундагы таш-тау арасыннан шуышып чыккан да, болын уртасындагы яшь туйрага уралган. Кешеләр моны күреп алганнар һәм таяк тотып үтерергә килгәннәр. Шул чакны көпә-көндез күк күкрәгән, яшен яшьнәгән, кайдадыр якында гына тау башыннан ташлар ишелеп төшкән. Кешеләр куркып качыша башлаганнар. Имәнгә уралган җыланның изге ия булырга тиешлеген Сабир ата шундук чамалап алган һәм икенче көнне, таң атар-атмас торып, агач күбәтәгә баллы сөт салып, зекер әйтеп, буйсынган кыяфәттә, буар җылан янына киткән. Имән янына Сабир ата килгәч, күк тә күкрәмәгән, яшен дә яшьнәмәгән, шулай ук тау-ташлар да җимерелмәгән. Имәнгә уралып яткан җылан башын күтәреп, Сабир атаны каршы алган, «килдеңмени?» дигән кебек, җинелчә генә ысылдап алган һәм күбәтәдәге баллы сөтне эчкән дә, «рәхмәт» дигән сыман, тагын бер мәртәбә ысылдаган да шуышып шундагы ташлар арасына кереп киткән. Көн дә иртән ана баллы сөт бирү менә шуннан калган.

Мака сар Карун, байлыкка алданып, комсызлык юлына басса да, шулай да әле ул алланы берләгән һәм ничек тә изгеләр сүзеннән чыкмаска тырышкан. Аның заманында изге анабыз, изге атабызга багышлап корбан, салака бирүләр дә, келәүлекләрдә келәү әйтүләр дә, зекер әйтүләр дә тукталмаган. Аннан соң мака сар Карун, байлыгының уннан бер өлешен ярлыларга, ятимнәргә, гарипләргә һәм Аклandaгы келәүлекләргә, каравыл өйләренә, им өйләренә, ир өйләренә биреп барган. Ачлык елларында, икмәген кыйммәт бәягә сатса да, күптәнге тәртипне, юсыкны бозасы килмичә туралагы ачларга... бушлай икмәк тараткан.

Үзеннән соң килгән сарлар белән чагыштырганда, мака сар Карун, беләсегез килсә, алланың иң изге бәндәсе булган. Җир астына салынган амбарларындагы байлыгын да ул үзе өчен түгел, Аклан өчен, иле-көне өчен җыйган. Йөз елга бер килә торган ачлык кебек бөтен илгә килә торган кырап килүе ихтималын күз алдында тотып җыйган. Бит ул чакларда Аклан әле артык көчле булмаган, бай булмаган. Тирә-якта, дингезләрдә көнчел күршеләр, кыргыйлар, дингез юлбасарлары тыз-быз йөреп торганнар, таларга, яндырырга, ватарга-җимерергә җай чыгуын көтеп кенә торганнар.

Карагыз әнә бүгенгеләрнең эшенә, кыланышына. Ниләр генә эшләмиләр дә, ниләр генә кыланмыйлар алар! Алтын-көмеш сарайларда яшиләр, балда-майда йөзәләр. Аллаларны, изгеләрне оныттылар, ярлы-ябагайны кешегә дә санамыйлар. Бөтен ил, алар өчен бил бөгеп, ирекле баштан кол хәленә төште. Алар өчен—көн дә бәйрәм, көн дә туй. Көне-төне күнел ачалар да, чагыр эчеп уйнаш кылалар. Анысы гына җитмәгән, Түгәрәк таудагы салкын чишмә белән кайнар чишмәне, таш киртә белән әйләндереп алып, ил-көн күзеннән ябып куйдылар. Туралагы аксөякләр өенә көпшәләрдән кайнар суы да, салкын суы да килеп тора. Үзләре юынудан, атларын, хатыннарын, балаларын коендырудан калган суларын оятсызлар бакчаларга җибәрделәр. Шуны алар турыдан-туры чишмәләрдән килә дип аңлаталар. Чишмәләр киртәләп алынгач, ул суларның каян килгәнен үз күзләрен белән күрмәгәч, ничек ышанмак кирәк моңа?

Түгәрәк таудан чыга торган шифалы Салкын чишмә белән Кайнар чишмәдән башка тагын икенче бер чишмә дә булырга тиеш бит әле. Анысы—Изгеләр чишмәсе. Ту әниебез Дикә белән ту атабыз Минне кавыштырган

чишмә. Ту әниебез Дикәнең кабак савыт күтәреп суга йөргән чишмәсе. Ул кайдадыр шунда, Түгәрәк тау буенда, дингез ярына якын җирдә булган диләр. Ту атабыз Мин беренче мәртәбә ту әниебез Дикә белән очрашкан төшкә үз кулы белән сырлап-бизәп таштан куыш ясап куйган, куыш эченә, чишмә өстенә шулай ук үз кулы белән ясап ту әниебез Дикәнең таш сынын утыртып куйган. Гомер-гомергә Аклан кешеләре Изгеләр чишмәсенең суын эчкән. Салкын чишмә белән Кайнар чишмә генә шифалы булмаган, Изгеләр чишмәсе дә шифалы булган. Беркайчан монда кеше өзелеп тормаган. Аклан иленең, биләмәләренең барлык төбәкләреннән монда ту әниебез Дикә, ту атабыз Мин рухына багышлап корбан бирергә килгәннәр. Монда шулай ук авырулар, гарип-гораәбәләр дә килгән. Аксаклар таякка таянып килсәләр, үз аяклары белән кайтып китә торган булганнар. Изгеләр чишмәсеннән берике тамчы су эчү белән, яраланган, җәрәхәтләнгән төшне чылату белән, сукырлар күрә башлаган, саңгыраулар ишетә башлаган, бөтәү яралар күз алдында төзәлеп юкка чыккан. Килгән бер кеше чишмәгә көмеш тәңкәләр салып китә икән.

Хәзер боларның берсе дә юк. Ни өчен дигәндә чишмә юк. Изгеләр чишмәсе юк. Аннан да бигрәк, Изгеләр чишмәсенең кайдалыгын белүче дә юк. Алай гына да түгел, кайберәүләр хәтта ту анабыз Дикәне, ту атабыз Минне дә онытып бетергәннәр.

Менә шундый эшләр. Бөтен дөньяга атаклы Аклан йортында, илнең үзәгендә, турада, көпә-көндез дигәндәй, чишмә югалган. Әллә үлән басып киткән, әллә тау-таш җимерелеп, таш астында калган, әллә инде Җәпәй йоткан.

Чишмәнең онытылуына, югалуына үз вакытында пошынучы да булмаган ахрысы. Бит дөньяда башка төрле кайгылар, борчулар да булып тора. Аклан иленең төньягыннан бик зур яу килгән, сугыш каты булган. Каяндыр салкын яклардан, Буран иленнән кубып чыккан һәм Изге утраугa каршы корал күтәрергә батырчылык иткән ак тәнле, аксыл-саргылт чәчле, сусыл-зәңгәр күзле кыргыйларның берсен калдырмый турап дингезгә тутырганнар. Аклан ягыннан да үлүчеләр шактый күп булган. Күрәсең, яу белән мавыгып, кешеләр үзләренең изге аталарын-аналарын, йолаларын исләреннән чыгарып ташлаганнар.

Ни булса булган, чишмә югалган. Изгеләр чишмәсе. Ту анабыз Дикәнең сыны да, чишмәсе дә юкка чыккан.

Беркадәр вакыттан соң чишмәнең югалуына игътибар иткәннәр, эзләнә, төпчәнә башлаганнар, картрак, хәтерлерәк кешеләрдән сораштырып караганнар. Шуннан соң галимнәрдән сораганнар. Аклан илендә, изгеләр илендә Изге чишмәнең кайдалыгын әйтеп бирерлек бер генә кеше дә табылмаган. Нинди хурлык!

Аның Түгәрәк тау астында, дингез яры буенда булырга тиешлеген һәркем чамалаган, ләкин төгәл итеп әйткәндә—кайда, кайсы төбәктә—беркем белми икән. Кайбер кыюраклар, башсызраклар алтын койма белән уратып алынган һәм аркылысы-буе берәр чакырым чамасы булган Түгәрәк тау ягына да үтеп кергәннәр. Анда аларны, билгеле, шундук кулга алганнар. Ни генә булмасын, анда капкадан түгел, койма аша үтеп кергән беркемнең дә кире чыга алганы юк әле.

Бит алла тарафыннан утыртылган язулы баганада Аклан йортының ун биләмәгә бүленгән булуы, унның һәркайсы үзенчә яшәргә, унның берсе икенчесен колламаска, түбәнсетмәскә тиешлеге, тик шулай да олы кинәштә унның тугызы ага сүзенә, ягъни мака сар сүзенә колак салырга тиешлеге әйтелгән. Изге Атабыз исәпләгәнчә, Аклан патшалары гына түгел, җирдәге барлык илләр, барлык патшалар шулай олыны олы итеп, кечене кече итеп, үзара тату яшәргә тиешләр.

Анысы шулай. Һәркем үзенчә яшәргә тиеш. Мака сар Карун, турыдан-

туры Алла теләгенә каршы бара алмаганга күрә, күнелендәге хыялларын хәтта ялгыз чагында да кычкырып әйтергә курыкса да, эше-гамәле анын барыбер көфер булган. Иблис юлына кереп киткәч, Карун хәзер һич тә комсызлыгын тыя алмаган.

Шуннан сон күпләр мона кул селтәделәр. Сонгы елларда Изге чишмәне, Изге ананы, Изге атаны хәтта искә дә төшерми башладылар.

Ләкин көтмәгәндә, былтыргы яз Аклан илендә Мәсәви дигән бер исем ишетелә башлады. «Үлсәм үләрмен, Изге чишмәне барыбер табармын!» дип әйткән ди ул, имеш.

***

Сәрмия авылы өстендәге калкулыкларга якынайганнан якыная барган кызгылт кайнар кояш, уртадагы очлы тауга житеп, аскы ягы белән тау сыртына орынгач та, күк читеннән каралжым таплар сузылып чыкты. Көн яктысы кими төште, күз бәйләнә башлады. Шул ук мәлдә дип әйтерлек кичке корт-бөжәкләр жанланды. Жим эзләп ераккарак очкан бал кортлары, керәшәләр тизрәк үз ояларына кайтып китәргә ашыктылар.

Саилче урыныннан торды һәм яр астыннан авылга таба кузгалды. Бу мизгелдә ул пир ата Сабирны да, ана әйтәсе яналыкларын да, хәтта изгеләрдән дә изгерәк ту әниебез Дикәне дә исеннән чыгарып жибәрде. Анын өчен хәзер дөньяда бары бер генә төрле изгелек һәм бары бер генә ана кеше—жанлы, тере, яшь хатын гына торып калган иде. Менә хәзер килешенгән вакытта аны күрмәсә, анын белән очрашып үзенен тәкатьсез теләген үтәмәсә, дөнья кинәт жимерелер, таулар-ташлар баш-аяк килеп, елгалар, дингезләр ярларыннан чыгар сыман иде.

Саилче Мәсәви тиешле өй турысында яр өстенә менде, ачык калдырылган жил капкадан ындырга керде һәм ярым карангыда шәйләнгән жимеш агачлары, куе куаклар арасыннан ничегрәк узып китәргә белмичә, тукталыбрак калды. Шул чакны каранғы куаклардан аерылып, кемнендер якынаеп килгәне күренде.

—Әйдә... менә моннан,—диде Кәфия калтыраган-каушаган бер тавыш белән.

Яшь хатыннын кулы саилчегә кайнар, хәтта кирәгеннән артык кайнар тоелды. Ялгыш утлы кузга кагылып киткәндәге кебек, анын кинәт кенә кулын тартып аласы килде, ләкин тартып алмады—яшь хатыннын кулы, утлы куздай булса да, көйдермәде, яндырмады—йомшак, татлы һәм жылы май булып, бөтен тәненә таралды. Тәмам буынсыз калып, буйсынып ул хатын артыннан иярде.

Ят бусагадан атлап кергәндә саилче искәрмәстән анабыз Дикәне, Әбетине исенә төшерде, ярым пышылдап, ашыгып келәү әйтте. Кәфия келәүнен «илгә именлек, сарга—байлык» дигән сүзләрен генә ишетеп калды.

Таш өйнен эче иркен генә иде. Өй уртасында түшәмне, түбәне тоттырып шомарып беткән юан багана—караулы агач сузылып утыра. Баганадан читтәрәк яссы ташлар белән түгәрәкләп алынган учакта сүнәр-сүнмәс ут яна. Учактан төшкән кызгылт яктылыкта исә эстинә буенда ике якта ике ятак—сике калкып күренә. Сикенен берсендә ак мендәргә батып, аяк-кулларын як-якка ташлап, анадан тума ап-ак тәнле яшь бала йоклап ята.

—Улым йокыга китте... бигрәкләр дә акыллы!—диде Кәфия, улын мактап, көлештереп.

Саилче таягын, күн салагын ишек төбенә жайлап куйган арада хатын шыпырт кына каядыр чыгып китте. Үз-үзе белән булашып саилче анын шулай кинәт кенә юкка чыгуын искәрмичә калды. Ныклабрак караса, каршыда гына ачык калдырылган ишек барлыгын шәйләп алды. Күп тә

үтмәде, авыр гына агач табак күтәреп, ишектән Кәфия килеп чыкты. Бөтен өй эченә кыздырылган тәмле ит исе таралды. Табакны Кәфия учак янына идәнгә, ашаулык өстенә китереп куйды. Шуннан соң ул янадан икенче якка чыгып китте һәм аннан бора чүлмәге белән бер көмеш кәсә алып килде. Саилче төкерекләрен йотып, борынын тарткалап, каш астыннан гына хатынның һәр хәрәкәтен күзәтеп утырды. Анын шулай бер генә кәсә алып килүен күрде дә, түзмәде, сорап куйды:

—Үзен утырмыйсынмыни?—диде.

—Утырырмын,—диде Кәфия күндәм генә, ләкин үзе утырырга ашыкмады. Бер дә юктан улы янына барып әйләнде, анын өстенә ябып куйды. Шуннан сон нидер эшлисе эше бар кеше сыман, тышкы ишек ягына карап алды.

—Миннән шикләнмисендер ич, килен,—диде Мәсәви йомшак, ягымлы итеп.

—Шикләнүен шикләнмим,—диде хатын телгә килеп һәм егылып китә күрмим дигән сыман караулы агачка тотынган килеш, ипләп кенә идәнгә чүгәләде.—Бераз гына куркам бугай. Чит ир кеше белән утырып ашау-эчү язык булмасмы дим... Әбети анабыз ни әйтер дип тә уйлыйм. Жир куенына кергәч, мәнге утта янарга туры килсә, нишләрмен дип тә кайгырам.

—Юкка кайгырасын икән, килен,—диде саилче, майлы каз ботына үрелеп.— Әйтсәм әйтим—мин сина чит кеше дә түгел. Мин күптәнге алла бәндәсе. Алла бәндәсе ул, беләсен килсә, никахлы ире юк чагында теләсә нинди тиши янында куна ала. Бу безнен изге йолабыз.

—Ишеткәнем бар,—диде Кәфия.

—Шулай булгач?—диде саилче.—Бар әле икенче кәсә алып кил.

—Көмеш кәсәм... бер генә шул,—диде Кәфия, кызарынып..—Анысын да әле иремнән төсе итеп кенә саклыйм.

—Иреннен төсе итеп?!—диде саилче, анлап житмичә.—Ирем уракта кунатөнә эшли диден түгелме сон?

—Дигәнием,—диде Кәфия, теләр-теләмәс кенә.—Көмеш кәсә... беренче иремнән бүләге.

—Беренче иремнән?..—диде саилче, үзалдына сөйләнгән сыман.

Ул башка төпченеп тормады—ашавында булды. Анын инде мондый тәмле, майлы каз итен күптән ашаганы юк иде. Алар шулай беравык берни эндәшмичә, ашауларында булдылар.

—Курыкма да, кайгырма да син,—диде бераздан саилче, хатынның күнелен тәмам тынычландырмакчы булып.—Менә әле изгеләрнен изгесе пир ата Сабир янышнан кайтып киләм. Сабир мине үзенен яраны итеп алмакчы—шул турыда сүз булды.

Пир ата Сабир турында ишеткәч, Кәфия кинәт ашавыннан туктап калды.

—Сабир ата изгесен изге инде ул.—диде. Аны бит хатын-кызны яратмый икән диләр, чынмы шул?

—Чын,—диде саилче ашыгыбрак һәм ник әйткәненә үкенеп шундук телен тешләргә мәжбүр булды.

—Син дә... шундыймыни?!—диде Кәфия куллары майланып беткән, ашаудан башка берни белән кызыксынмый сыман тоелган саилченен йөзенә туры карап.

—Мин дә,?.. Минме? Хи-хи!..—диде Мәсәви көлеп ы-мы итеп. Мин—юк, андый түгел.

—Котымны алдын,—диде хатын үзе дә сизмәстән һәм жинел сулап.

Икенче көнне иртән, кояш чыгып дөнья янадан төнге йокыдан уянгач, беренче булып Мәсәви күзен ачты. Күзен ачу белән, гадәтенчә, ярамаган нәрсәне күрәсе килеп, яшертен генә Кәфия ягына карап алды. Әвәләнеп, борчылып беткән урын-жирдә таралып сылу тәнле яшь хатын ята. Озын

кара чәчләре тузгыган—бер толымы бер якка, икенче толымы икенче якка салынып төшкән. Янында, куенында кечкенә улы ята. Нәни аягын югары күтәреп, бала әнисенең юан боты өстенә салган, нәни кулы белән исә әнисенең тулып, бүлтәеп торган күкрәгенә үрелгән.

Менә шушы күренешне күрү белән, шундук саилченең күз алдына Сабир ата килде. Нишләп шул кадәр яратмый икән ул хатын-кызны?—дип уйлады Мәсәви үз алдына. Тау башында ятып аның беркайчан яшь, сылу тәнле кызлар күргәне дә булмагандыр. Шуна күрә менә ана үсмерләр-фәләннәр кирәк тә. Үсмер... ул да бар бит әле дөньяда. Онытыла да язган. Әмже бистәсе... Әмәт... Фалия... Сабир ата әйтә, ил-көн бозылды, бозыклыкка бирелде, ди. Изгелекне онытып бара, ди. Изге кеше нинди булырга тиеш икән соң? Аның кебекме? Барлык изгеләр дә бары бер-берсен генә яратсалар, балаларны кем табар да, кемнәр иген игәр, кемнәр көтү көтәр, кемнәр таш кисеп йортлар, сарайлар салыр.

Мәсәвинең күңеленә шундыйрак уйлар килде. Дөресрәге, элек тә үзенә тынгы бирми торган төрле уйларын-борчуларын ул янадан исенә төшерде. Ләкин бу мизгелдә, янында гына шундый якын да, аңлаешлы да, ләкин шул ук вакытта серле дә тоелган жан иясе... жан ияләре булган чакта, шушы тын, аулак өйдә, Актау ягындагы күңелсез корыган изгеләр турында озаклап баш ватасы да килмәде. Иплән кенә ул хатынның тәненә кагылды, дәрте уянган бармаклары белән аның хуш исле йомшак тиресеннән сыйпады. Хатын уянгандай итте, ярым йокылы бер хәрәкәт белән гәүдәсен якындагы ир ягына авыштыра төште, йөзе белән борылды һәм шул ук вакытта улын кочаклаган кулын саилчегә күчерде. Күзләрен ачмыйча һәм бер сүз әйтмичә ул капшанып кулын түбән шудырды.

—Каян килеп чыктың син?!—диде ул серле пышылдап, кайнар ирене белән иренең иренәнә үрелеп.—Син чыннан да изгедер. Күктән төштеңме, Актаудан төштеңме—минем өчен барыбер. Төннәр буе мин сине төшемдә күрдем, сагыштым, сагынудан нишләргә белмәдем.

Таң атып, көтү куылгач, бөтен авыл аякка баскач, һәм жиңелчә генә ашап-эчеп алгач, саилче юлга жыена башлады. Ашаганда-эчкәндә дә, юлчы үзенең барлы-юклы әйберләрен барлап азапланганда да Кәфия үпкәләгән сыман берни эндәшмәде. Мәсәви инде кузгалып китәм дигәндә генә, алар арасында кыскача гына сөйләшү булып алды.

—Китәсең дә мени?—диде хатын.

—Китәм,—диде Мәсәви саилче.

—Каргышыңны кире алмадың—диде Кәфия.

—Эх, онытканмын!—диде саилче.

Кулына алган таягын, иңбашындагы салагын ишек төбенә куйды да, тынып калган хатын янына килде, ике куллап аның беләкләреннән тотып алды һәм авыз эченнән келәү әйтеп, аның йөзенә тынын өрде.

—Улыма да шифалы тыныңны өр,—диде хатын таләп итеп.

Бала инде уянган иде, аяк кулларын бутап, үзалдына көлеп, «сөйләшеп» ята иде. Саилче балага да иелде, авыз эченнән генә ана да зекер әйтте һәм соңгы мәртәбә аның йөзенә таба шифалы тынын өрде.

—Китимме инде?—диде саилче, эшен бетергәч.

—Әллә китмисеңме?—диде Кәфия ялвару катыш таләп итеп.

—Ничек... китмисеңме?—диде Мәсәви, аптырап һәм ишек төбендә туктап, тоткарланып калды.

—Шулай. Ирем булырсың. Бергә-бергә торырбыз. Улыма ата, миңа таяныч булырсың.

—Ирең? Мин синең ирең булырмынмы?—диде саилче берни аңламыйча.— Урактагы ирең кайтып төшсә, ни диярсең?

—Юк минем ирем. Беркемем юк,—диде Кәфия, балта белән чапкан кебек, кистереп.—Моннан бер җыл элек… Актау ягында Бики бәк белән ауга баргач… арыслан ботарлаган аны. Без—Бики бәк каралары. Тагын бер җылдан миңа кияүгә чыгарга ярый. Кем алыр? Алырмы, Бики бәк үзенең сөяркәсе ясармы. Белмим. Көне-төне теләсә кайда, теләсә кем ишек төбендә кангырап йөргәнче, торыр урының булыр, тамагың тук булыр… Беләм, син изге… алла бәндәсе. Эшкә күнекмәгәнсең. Берни эшләмичә, тик кенә утырсаң да, янымда гына булсаң да, иркәләп, яратып кына торырмын. Теләсәң, якын-тирәгә йөрерсең, имләрсең, зекер әйтеп караларны туры юлга өндәрсең. Бики бәк белән сөйләшеп, келәүлек салдырырга була. Шунда изге эш эшләрсең.

Мәсәви, башын иеп, кулындагы таягын селкеткәләп, тын гына тыңлап торды. Кәфиянең соңгы сүзе Мәсәвинең күңеленә хуш килде.

—Менә монысы булыр кебек!—диде ул дәртләнеп.—Нишләп әле келәү йортлары кеше аягы басмаган биек кыя башларында гына булырга тиеш? Кешеләр күбесенчә түбәндә яши. Аларга изге сүз кирәкмимени?! Аларның да аллалар серен беләсе килмимени?!

—Алайса, китмисең—диде Кәфия, Мәсәвине кочаклап алып. Шулай тотып алып калмакчы булган кебек озак кына кайнар каты кочагында тотып торды, аның чәчләрен сыйпады, аркасыннан сөйде, битеннән, иреннәреннән үпте. «Карале, нинди дәртле, нинди үз сүзле хатын икән бу!« дип уйлады үз алдына саилче. Юл йөргәндә, анда-монда төн кунганда ул төрле хатын күрде, ләкин мондыйны әле күргәне юк иде бугай. Сәрмиядәге Дамия генә шундый ук дәртле иде ахрысы.

—Мин инде сине… сагындым да,—диде Кәфия пышылдап, саилчене үз артыннан ияртеп.

—Минем күрәсе-сөйләшәсе кешеләрем бар,—диде Мәсәви, хатынның теләгенә бик үк каршы килмичә.—Шуларны күргәч, сөйләшкәч, үз эшләремне җайлагач… берәр айдан килеп җитәрмен. Ризамы?

—Ярар, мин көтәрмен—диде Кәфия.—Алдасаң, каргышым төшәр. Мин каргасам, бик каты каргармын. Син изге булганны, мин дә… изге. Ту әниебез Дикәгә мин нәзер әйттем. Тик менә нәзеремне генә үти алмыйм. Үти алмасам, мин болай да им эйенә китәргә, үлгәнче шунда калырга тиешмен. Минем анда китәсем килми, ирле булып, иреклe булып яшисем, улымны үстерәсем, тагын уллар-кызлар табасым килә. Аңлашылмыймыни?!

—Барысы да аңлашыла!—диде Мәсәви саилче.—Мин сиңа сүз бирдем—бер айдан мин синең янында булырмын.

Олы ташлы юлга ул таныш җирдән—ындыр эченнән, яр буеннан барып чыкты. Юлга чыккач, артына борылып карады. Еракта, таш киртәнең ачык капкасы янында кул болгап Кәфия басып тора иде. Бу мизгелдә саилче янадан пир ата Сабирне исенә төшерде. «Хатын-кыз ул иблис токымыннан. Хатын-кыз ирләрне аздыру өчен генә яратылган»—дигән иде Сабир ата бервакыт хатын-кыз турында сүз чыккач. Чыннан да шулай икән. Китәргә кирәк моннан, качарга кирәк тизрәк. Ләкин—кайсы якка? Бу вакытта ул аны-моны уйламыйча, күпер уртасына килеп җиткән иде. Күңелендә шик тугач, ул кичәгечә урталыкта туктап калды. Беравык бер урында таптанып торды да, кырт кына артка борылды һәм житез-житез атлап алтын-көмеш сар сарайлары булган бәхетле турага—Аклан иленен башкаласы ягына юнәлде.

***

Җәйге җылы вакытларда Җәбир бакчада кунарга ярата иде. Әле җәй уртасы килеп җитмәсә дә көн коры һәм җылы. Бүген ул тышта кунарга уйлады. Карт алмагач төбенә чыгып яткач, Җәбир бик озак йокыга китә алмады. Аның әлләни йоклыйсы да килмәде. Төне буена ул уйланып, хыялланып

чыгарга да әзер иде. Төшәгән туп-туры чүлмәк өстенә җәйде. Күбрәк ул кесәсендәге яшел ташлы, алтын чылбырлы алтын тамга турында уйлады. Нишләтергә аны? Бик зур байлыкмы бу? Ул үзенең ниләр алачагын, ниләр эшләячәген уйлап хыялланды. Шул чакны аны авыр газаптан коткарырга теләгән сыман, күз алдына кер уучы җиңги килеп басты. Җиңги турында уйлау алтын тулы чүлмәк турында уйлау кебек үк татлы һәм мавыктыргыч иде. Озакламый җиңги турындагы уйлар да арыта башлады, күз кабаклары авырайды, аяк-куллар онытылды, бөтен тирә-якта, бөтен дөньяда тере, тынгысыз бер уй гына торып калды.

Ул инде онытылып та китә язган иде. Шул чакны кайдадыр якында ташка таш тиеп шакылдаган тавыш ишетелеп куйды. Әллә корыган ботак сындымы соң? Югарыдан берәрсе егылып төштеме югыйсә? Җәбир күзләрен ачты һәм бакчага чыгып ятканнан соң беренче мәртәбә күзен ачып күккә карады, тирә-якка колак салып тынларга тотынды. Төн булса да, күк төбе ничектер аерымачык булып, хәтта якты булып күренә иде, исәпсез-хисапсыз алтын комнары җемелдәшә, һава саф һәм салкынча. Якындагы каралты, куаклар, агачлар бөтенесе бер төсле булып, тигез яссылыкка төшерелгән сурәт кебек булып, кара булып күренә иде.

Күршеләр белән ике арадагы таш койма ягында тагын баягыча шакылдаган тавыш ишетелеп китте. Ләкин бу юлы ташка таш түгел, бәлки ташка агач тигән сыман булды. Җәбир, күзләрен зур ачып, башын калкыта төште һәм шул чакны койма өстенә нindидер карачкы килеп менгәне күренде. Койманың өстенә үк менеп җиткәч ул аска иелеп нәрсәдер тартып алды һәм тартып алган нәрсәсен иплəп кенә, капшанып кына бу якка төшерде. Ул, билгеле, баскыч иде. Карангыда, куаклар арасында аерым-ачык күренмәсә дә, Җәбир аны шундук шәйләп алды. Аннары ул шуны да белде: карангыда койма аша керүче бу карачкы, әлбәттә, җиңги кеше иде.

Йөрәге еш-еш типкән хәлдә, тынып-сагаеп ул көтә башлады. Менә карачкы бернинди тавыш-тын чыгармыйча, таш сукмактан алмагачка таба килә башлады. Җәбир күзләрен ярым йомык калдырып, йоклаганга сабышып, җиргә береккән кебек ятуында булды. Ул арада карачкы якынрак килде, күз алдын каплап, кап-кара булып, аның түшәге янына иелде, чүгәләде һәм кулын сузып аның битенә кагылды. Биткә кагылган кул ана бик салкын булып тоелды. Җәбир үзе дә сизмәстән »а!« дип кычкырып җибәрде.

—Курыкма, бу мин... җиңгән,—диде карачкы пышылдап, учы белән аның авызын томалап. Яшүсмернең иреннәре аның учының тиресенә тиде, ләкин ул аның учының чын кешенекеме, түгелме икәнен аңлый алмады—ул шундый салкын иде.

—Син... өрәкме?—диде ул бөтен тәне белән калтыранып.

—Өрәк түгел,—диде карачкы—Мин синең җиңгән... Галимә. Курыкма шул кадәр.

—Өрәк булмагач, ник кулың салкын?—диде Җәбир теше-тешкә тиеп.

Карачкы эндәшмичәрәк торды да:

—Курыксаң, әйдә безгә,—диде.—Абыең кизүдә. Мин дә куркам ялгыз өйдә бер үзем.

«Әйе шул, өрәк булса, курыкмас иде» дип уйлады Җәбир үз алдына. Өйдә аны тикшереп карарга була. Өрәк булса ул шундук юкка чыгачак.

Шундый фикергә килгәч, ул калтыравыннан туктагандай булды.

—Әйдә, алдан бар,—диде ул карачкыга.

Беренче әтәчләр кычкырганда ул яңадан үзенең алмагач төбендәге урынына чыгып ятты. Күпмедер вакыттан соң ул якында гына нindидер таныш тавышлар ишетеп уянып китте. Күзләрен ачыбрак караган иде, йомшак кына булып балкып торган иртәнге көн яктысында әнисен һәм әнисе янында

сукмакта басып торган әтисен күреп, шаккатты.

—Әтиең аягына басты, улым,—диде әнисе елмаеп.

—Менә, үз аягым белән килдем,—диде әтисе һәм үзенең чыннан да тазасау икәнен күрсәтергә теләгән сыман җиргә тибеп-тибеп алды.

Җәбир теләсә нинди кешенең үз аягы белән йөрергә тиешлеген бик яхшы белсә дә, шулай да ике-өч айдан артык инде урында яткан әтисенең ятакка береккән кебек ятып, йә утырып торуына күнегә башлаган иде. Хәзер исә аның чын-чынлап үз аягында басып торуы аңа чиктән тыш гаҗәеп хәл булып тоелды.

Ул сикереп урыныннан торды, әтисе янына килде һәм ышанып җитмәгән сыман әтисенең аякларын карарга тотынды.

—Чын, улым, чын,—диде әтисе көлемсерәп.—Әниең әйткән сөенечтән бастым аягыма. Син чүлмәк тапкансың икән. Каяле, күрсәт әле.

—Хәзер, әти,—диде Җәбир.

Тиз-тиз генә ул урын-җирен җыеп алды. Ястыгын, мендәрен, астагы камыш чыптаны, ябынчыкларын—бөтенесен бер төргәккә төреп, читкәрәк алып куйды һәм йөгереп кенә тимер көрәк алып килде. Кичәгенәк казып йомшартылган җир өсте ятак астында басылган һәм тыгызланган иде. Йомшак җир өстендә хәтта чыпта эзләре дә беленеп калган иде. Җәбир бер-ике көрәк балчык алып ташлады да, алтынлы чүлмәккә капланган тупас капкачны алды. Әтисе дә, әнисе дә якынрак килделәр. Чүлмәк эчендә кичәгечә алтын-көмешләр балкып-елмаеп ята иде. Әтисенең йөзе шундук яктырып китте. Әнисе инде, бер мәртәбә күргәч, ахрысы, бу юлы әлләни сөенеч белдермәде.

—Күрдем, күнелем булды. Ябып куй, улым,—диде әтисе күтәренкелек белән. Аннан соң улына ягымлы караш ташлады да, мактап әйтеп куйды:—Синең бәхетең бу, улым,—диде.—Син таптың. Болай булгач, баедык без. Моннан соң инде менә дигән иттереп яшәрбез, алла боерса.

Ул шулай диде дә, тиз-тиз атлап өйгә таба китеп барды. Аның артыннан Батима карчык атлады. Төреп куелган урын-җирен алып Җәбир дә алар артыннан иярде. Ләкин чүлмәкнең туфрак белән күмелми калуын исенә төшереп ул тиз генә алмагач янына килде, көрәк белән чүлмәкне күмде дә тирә-яктагы балчыкны тигезләп куйды.

Җәбир урын-җирен күтәреп өйгә, үзенең ишек төбендәге бүлмәсенә керде. Иртүк торып су салып казан астына ягып җибәргәннәр иде. Күршедә, юыну бүлмәсендә идәне, кырыйлары су үткәрми торган шома ташлар белән ныгытылган дүрткел чокыр бар иде. Изгеләр калкулыгыннан балчык көпшәләр буенча агып килә торган су ике төрле: берсе салкын, берсе җылы. Җылы су чишмәдән кайнар килеш чыга, ләкин монда килеп җиткәнче суына һәм җылымса гына булып кала. Шуңа күрә мунчада юынганда өстәмә су кайнатып салырга туры килә.

Батима карчык, Җәбирнең урын-җир күтәреп керүен күрде дә, улын казан янына чакырды.

—Әйдәле, икәүләп күтәреп алыйк,—диде ул учак өстендәге кайнар сулы җиз казанга күрсәтеп.

Алар, казан кылдавы аша үткәрелгән агачның ике ягыннан тотып, авыр, кайнар казанны учак өстеннән алдылар да юыну бүлмәсенә алып килделәр һәм чокырдагы суга капладылар.

—Әтиеннең аркасын ышкырсың,—диде әнисе Җәбиргә.

—Ышкырмын—диде Җәбир. Монарчы ул мондый эшләр белән булашмый иде. Су кайнату, су таманлау, арка ышку, юындыру—барысы да Фу-Фу белән Су-Си эше иде. Ул әтисенә булышуга каршы килмәде, шулай да өйдә колларның күренмәве аңа гаҗәбрәк тоелды.

—Тегеләр кая соң, күренмиләр?—диде ул.

—Мин аларга ирек бирдем!—диде кәмәче карт, күтәренкелек белән.—Кичәдән бирле алар—ирекле.

—Чыгып киттеләрмени?—диде Жәбир

—Үзем куалап чыгардым,—диде Батима.

—Өйдә үзебез генә, улым, курыкмыйча сөйләшергә була—диде әтисе.

Жәбирнең әтисе, бөтен гомерен дингездә үткәргәнгә тәнгә бик таза иде. Буйга ул артык зур түгел, ләкин күкрәккә кин, беләккә нык иде. Тик менә озак урын өстендә ятканга, ахрысы, тиресе йомшый төшкән, ит урынына май җыела башлаган иде. Анадан тума чишенеп ташлаган Жәбир әтисенең аркасына үзләнеп торган кара ләм үкәде. Башка җирләренә—кулларына, күкрәгенә, алгы ягына әтисе үзе үкәде.

Баштан-аяк ләмгә үкәнгәч, ул янадан коега керде. Аякларын, кулларын сузып беравык ләззәтләнеп ятты да, ышкына башлады. Су бераздан капкара булды. Жәбир мунчала белән әтисенең аркасын ышкыды. Тансыкка әтисе коеда шактый озак булашты. Сабынлы суда юынып арыгач, алар коеның бөкесен ачып, суны агызып җибәрделәр, шуннан соң җылымса су килә торган икенче бөкене ачтылар да, коендылар, тәмам чистарып калдылар.

Алар юынып чыгуга әнисе ашарга әзерләгән—табынга борчак боткасы, каймак һәм йөзем суы куелган иде. Кәмәче йөзем суы эчәргә ярата иде. Иң элек ул бор салынган чүлмәккә үрелде һәм көмеш кәсәләрне тутырып эчемлек салды. Ләкин эчәргә ашыкмады, кулына кәсәсен алу белән артына борылды да, учакка берничә тамчы бор сипте.

—Әбети, сина,—диде.

Башкалар да эчәр алдыннан берничә тамчы эчемлекне иң элек ут анага—Әбетигә бирделәр һәм бары шуннан соң гына кәсәләрне авызларына якын китерделәр.

—Нинди күнелле сезнең белән бергә табында, җылыда рәхәтләнеп утырырга!—диде кәмәче балаларча куаныч белән.

—Почмагыбыз түгәрәкләнде,—диде Жәбир дә олылар сымак акыллы булып.

—Түгәрәкләнмәде әле,—диде әнисе.—Кызыбыз юк. Аны барып алып кайтасы бар.

—Әтине күрсә шакката инде ул!—дип куйды Жәбир. Бор суы эчкәч, анын гел сөйләнәсе килә башлады.

—Шаккатарлык нәрсәләр күп булды, улым,—диде әтисе.—Мин әле һаман да ушымны җыя алмыйм. Нәрсә булганын анлап та житә алмам кебек.

—Ашагач та мин базарга китәм—сез өйдән чыгып йөрмәгез,—диде әни кеше боерган сыман итеп.

Түрә буенча, йола буенча, лелек хатыннары гаиләдә ирләр белән бертигез хокукта иде. Ләкин кайбер нәрсәләрдә алар хәтта ирләрдән дә өстенрәкләр. Монарчы да күп нәрсәне үзе хәл итәргә өйрәнгәнгә, Жәбирләр өендә әнисе гомумән барысыннан да өстенрәк, акыллырак санала һәм анын сүзе һичшиксез үтәлергә тиеш.

—Кая чыгыйк инде без өйдән,—дип куйды карты, бичәсе белән килешүен белдереп.

—Әллә мин синең белән барыйм микән соң, әни?—диде Жәбир.—Үзенә генә кыен булыр ич.

—Булмас. Өйгә чит кеше-ни кермәсен, капканы бикләп кенә утырыгыз,—диде әнисе.

Шулай сөйләнеп утырганда, бөтенләй көтмәгәндә тышкы ишек шыгырдаганы ишетелде һәм күп тә үтмәде, нинди-дер хатын-кыз тамак кырды һәм сузып:

—Өйдәләрмесез? Керергә ярыймы?—диде.

Өчесе дә ашауларыннан туктап, тынып калдылар һәм ишек ягына борылып

карадылар. Карасалар, ишектә ничектер бик сәер елмаеп киленнәре Галимә басып тора. Галимәне күрү белән барысы да тынсыз-өнсез калдылар. Җәбир авызын күптереп, йодрыкларын йомарлап, күзен түбән төшерде. Батима карчык, тамагына азык утырган сыман, »чәчәп» җибәрде, тамагын кыргалый башлады. Бары тик беркатлы диңгезче әти кеше генә чын күнелдән сөенеп утырган урыныннан кузгалды:

—Килен кергән ләбаса!—Әйдә, түрдән уз, нәрсә сорап торасың?—диде.

—Әйдә, әйдә, түрдән уз,—дигән булды әни кеше дә, тыелып кына.

Галимә керде һәм ашаучылар арасында табын янында чын таза-сау килеш аякларын сузып җибәреп, яшьләрчә шат күнел белән ашап утырган биатасын күреп, катты да калды. Нәрсә бу—кинәт аягына басканмы, әллә монарчы юри авыруга сабышып ятканмы?

—Бәрәч! Биатай да терелгән ләбаса!—диде ул беренче сүзе итеп.

—Бастым, килен, бастым,—диде кәмәче карт.—Куанычлы сүз ишетеп үзем дә сизми калдым.

Шул чакны Батиманың йөзе үзгәреп китте. Ачу белән ул картына бер усал күз карашы ташлады да:

—Бөтенләй үк йөрерлек түгел, шулай да менә торды әле,—диде.—Ас анага багышлап корбан биргән идек, шул килеште бугай.

—Килеште, килен, килеште,—диде карт, Батиманың ишарәсен аңлап.

—Мирзый сөенер инде, әти дә әти дип бик кайгыра иде,—дигән булды килен.

—Кеше-карага сөйләнмәгез әлегә,—диде Батима карчык кырыс кына.

—Нишләп сөйләник? Бездән сүз чыкмас,—диде килен.—Сөйләсән дә ни гаебе бар анын?

—Гаебе юк та, йөри башласын әле нығытып, әллә күз тияр,—диде биана, аңлатып.

—Күз тияргә—сабый бала түгел лә әткәй,—диде килен көлеп.

Ул шулай түргә дә узмыйча, йомышын да әйтмичә, ишек төбендә басып торды да торды. Сүзенә һәм тиз генә чыгып китмәвенә карап, анын болай гына, юри генә кергәнлеге сизелде. Биана түзмәде, беренче булып үзе сорады:

—Йомышың бар идеме әллә?—диде.

—Ни... ы—ы... Кәтмәнегезне биреп тормассыз микән дигән идем, диде килен көттереп.—Үзебезнекенең сабы сынган. Мирзыйга ничә әйттәм—һич вакыты юк.

—Үзенә кирәкмиме?—диде әнисе, Җәбиргә эндәшеп.

—Безнең икәү. Берсен алсын,—диде Җәбир.

—Бар, үзең карап бир!—диде әнисе ачу белән.

Җәбир ашаган җиреннән торып ишеккә юнәлде. Галимә дә аның артыннан кузгалды. Эш кораллары сөялгән җиргә килеп җиткәч, ул кәтмәннен берсен алды да, борылып җиңгәсенә бирде. Кәтмәнне биргәндә ул ничек тә анын күзенә карамаска тырышты. Галимә исә бер дә юктан көлеп куйган булды һәм ачу китергеч итеп үртәп, кызыктырып, матур ян-якларын уйнатып, алдан китеп барды.

Җиңгәсен Җәбир капкага кадәр озатып куйды. Ул аны капкадан кергәндер дип уйлаган иде. Ләкин капка эчтән бикле булып чыкты. Менә сиңа кирәк булса! Тагын койма аша кергән! Анын җиңгәсенә бирәр усал сүз әйтәсе килде, ләкин ул берни дә әйтә алмады. Аның караңгы чыраен күреп, Галимә Җәбирнен күзләренә тутырып карады да бик ягымлы итеп елмайды һәм ярым пышылдап:

—Иртәгә үзең кер,—диде.

Җәбир эндәшмәде. Ул янадан ашавын дәвам итмәкче булып, өйгә керде, табын янына килеп утырды. Әнисенең дә, әтисенең дә йөзләре бик сүрәнләнеп калган иде.

—Капканы бикләп куйган кебек идем—ачык калганмыни?—диде әнисе Җәбиргә карап.

—Ачык калган,—диде Җәбир теләр-теләмәс кенә.

—Син төнлә... яткан урыныннан торып беркая да бармадыңмы?—диде бераздан әнисе, төпченеп.

Ул, күрәсең нәрсәдер сизенгән иде. Ләкин Җәбир бер ялганлагач, икенче мәртәбә дә ялганламый булдыра алмады.

—Беркая бармадым,—диде ул.

Ләкин аның җавабы әнисен канәгатьләндермәде. Ул инде улының күз карашыннан ук барысын да сизенеп алган иде. Ашап туйгач, ул базарга барырга җыена башлады һәм ирләргә боерып: капканы минем арттан бикләп калыгыз. Сорамыйча беркемне кертмәгез,—диде.

Җәбир әнисен капкага кадәр озатты да, артыннан капканы терәтеп куйды һәм йөгереп әтисе янына керде. Аңа монда ниндидер эшләнәсе эше бар сыман тоелган иде, ләкин өйгә кергәч эшләнәсе эше бакчада булырга тиешлеге аңлашылды. Ул, әтисенә берни әйтмичә, бакчага чыгып китмәкче булды.

—Туктале, улым, сөйләшик,—диде әтисе.

Җәбир туктап калды. Әтисенең тавышы буенча, кыяфәте буенча ул ике арада бик тә җитди сүз буласын аңлап алды: җитди сүз, әлбәттә чүлмәк турында булачак иде.

—Улым, әниең югында икәү генә сөйләшик әле бер,—диде ата кеше.—Синең үз кайгың, минем үз кайгым дигәндәй. Безнең ныклап торып сөйләшкәнебез дә юк. Мин менә аякка бастым—мине изгелегеннән ташламаган изге иярләргә көч бирсен алла. Сөенечтән мин сабый бала кебек үзгәрдем. Ләкин сабый бала кебек булганга кадәр, мин инде өлкән яшькә җиткән кеше идем. Минем бөтен гомерем диңгездә, кәмәдә, кеше арасында үтте. Кеше арасында булгач, барысын да татырга туры килде. Син юлыккан алтын мине аякка бастырды. Ләкин ул минем башыма авыр кайгы да салды.

—Нинди кайгы, әти?—диде Җәбир түземсезлек белән.

Ул әтисенең алтынга каршы, табылган чүлмәккә каршы алдан ук үзендә кирелек, каршылык калка барганын да тойды.

—Алтынны кем дә ярата,—диде әтисе ашыкмыйча сүзләрен уйлап кына, җайлап кына.—Алтын сиңа да кирәк, миңа да кирәк. Алтының булса, башың югары була, өең иркен, табының мул була. Алтыны күп кеше җаны теләгәнне эшли ала. Бигрәк тә яшь чакта. Мин менә авырып урында ятканда күп нәрсә турында уйладым. Чынлыкта ник кирәк кешегә алтын? Аны ашап булмый, эчеп булмый, аннан яхшы корал да ясап булмый.

Җәбир әтисенең шундыйрак сүзләрен элек тә ишеткәләгән иде. Хәзер ул мыскыл белән көлеп җибәрмичә булдыра алмады.

—Әле генә үзең әйттең ич: алтының булса башың югары була, өең иркен, табының мул була,—диден!—диде ул әтисенең ялгышын тотып алып.

—Ашыкма, тыңлап тор,—диде әтисе.—Мин сиңа ике төрле нәрсә турында сөйлим. Алтынга ике төрле караш турында. Бүген, хәзер, безнең Атлантитада шулай: бөтен нәрсәнең тоткасы—алтын! Алтынга теләсә нәрсәне сатып алып була. Теләсә нәрсәне! Тик саулыкны гына, тормышны гына сатып алып булмый. Анысы Алла кулында. Менә нәрсәне әйтәм мин сиңа. Җанны безгә изге Атабыз, тормышны изге Анабыз бирә. Алтынны олуг атабыз күк биргән. Безнең тормышны ямьләр өчен, матурлар өчен биргән. Үзләрен Алла улы дип исәпләүчеләр алтынны күбрәк алып калганнар да, синең кебек, минем кебекләрне үзләренә буйсындырып тоту өчен, аны Аллага тиң нәрсәгә әйләндергәннәр. Менә нәрсә турында әйтмәкче булам мин сиңа!

—Беләм мин бу турыда, әти,—диде Җәбир дәртсез генә тыңларга теләмичәрәк.

Ата кеше кәефе кырылгандай тынып калды. Ул тиз генә сүзне ничек ялгап алып китәргә белмәгәндәй унайсызланып торды да:

—Белсәң, бик яхшы,—диде ул аннары бераз килешүчән тонда.

—Беләм шул!—диде Җәбир, тавышын күтәреп әтәчләнеп.—Алтынны ашарга да, эчәргә дә ярамый дип, бакчада яткан алтыннан баш тартырга киңәш итәсеңме әллә?

—Менә белмәдең!—диде әтисе ачуланмаска тырышып.—Алтын ул, улым, белеп, саклап тотканда гына—байлык. Алтын күреп әз генә акылыңны җуйдыңмы, ул шундук синең башыңа җитә. Менә нәрсә әйтмәкче булам мин сиңа!

—Артыгын түләмәскә, теләсә кемгә бирмәскә дисеңмени, әти?—диде Җәбир җинелчә елмаеп.

—Алай түгел,—диде әтисе.—Алай түгел. Синең кебек яшь чакта күп байлыкка юлыккач, бик тиз баш әйләнә, борын югары күтәрелә, уяулык югала. Кешедә комсызлык, кансызлык, явызлык баш күтәрә башлый. Менә шулардан сакланырга кирәк димәкче булам мин сиңа, улым.

—Киңәшеңне истә тотармын, әти,—диде Җәбир теләр-теләмәс кенә.—Шулай да син миңе чүлмәк эчендәге алтын әйберләргә карап сокланып кына утырырга күндермәкче буласың түгел микән?

—Юк, алай түгел,—диде әтисе.—Мин сиңа бары кайбер киңәшләр генә бирмәкче булам.

—Аңладым мин сине, әти,—диде Җәбир түземсезлек белән.—Миннән башка киңәшмичә берни дә эшләмә димәкче буласың син.

—Шулай дисәң дә ярый,—диде әтисе уйланып.—Күрше-күлән тирәсендә безгә әлегә бай булып күренергә ярамый.

—Анысын гына мин дә беләм!—диде Җәбир.

—Беләм дә беләм!—диде әтисе үртәлеп.—Тыңлап бетер әйткәнне!

—Нишләргә соң, әйтеп кара,—диде Җәбир карангы чырай белән.

Ул нәкъ менә әтисенең ниндидер киңәшеннән курка да иде. Бит ул юкка гына шулай читләтеп, уратып ерактан сүз башламагандыр?!

—Үзебезнең бакчада алтын тулы чүлмәк тапканны белсәләр...

—Беләм!—диде Җәбир үзсүзләнеп, әтисенең сүзен бүлдереп.

Улының бу кадәр кирелеген күреп, картның йөзе бозылды, мыек чылгытлары дерелдәп-калтырап куйды, шулай да ул улына кычкырудан үзүзен тыеп калды. Мәсьәлә үтә җитди, үтә четерекле иде.

—Белсәң беләсеңдер. Шулай да мин үз сүземне әйтеп бетерим инде—калганын үзең карарсың, башсыз малай түгелсең.

Әтисенең соңгы сүзләре Җәбирнең күңеленә хуш килде һәм аның йөзендәге кирелек кул белән алгандай юкка чыкты.

—Мин хәзер аякка бастым. Мин янадан диңгезгә чыга алам,—диде әтисе.—Галләмгә яисә берәрсенә көмәче булып яллана да чит илгә китәм. Кәмиткәме, каралар иленәме. Минем йөрмәгән җирем, күрмәгән илем юк. Көньякка да, төньякка да барырга була. Үзем белән сине дә алам. Менә шул—чит илдән баеп кайтабыз.

—Чит илдән алып кайткан алтында беркемнең эше юк—күршеләрнең дә, мака сарның да!—диде Җәбир, елмаеп, әтисенең фикерен дәвам итеп.

—Шулай!—диде әтисе.—Башта бурычка бераз тауар, акча алып торган буласың. Миңа ышанып тауар бирерлек кешеләр булырга тиеш. Бер-ике мәртәбә барып кайтсак, аннары үзебезгә көмә сатып алырбыз.

—Монысы—киләчәктә. Хәзер нишләргә соң?—диде Җәбир әтисе белән килешүен белдереп.

—Хәзер болай итик, улым,—диде ата кеше.—Син берни булмаган кебек бакчаны кәтмәнлә. Безгә аны барыбер казырга, әйбер утыртырга туры килә.

Мин менә шушы бүлмәдә, идән ташларын куптарып, баз казып куярмын әниен кайтуга.

—Чүлмәкне шунда күчерербезме?—диде Җәбир.

—Шунда,—диде әтисе.

«Түкми-чәчми шунда кертеп куярлар, тагын сакларлар инде гомер буе болай булгач»—дип уйлады яшь егет күңелсезләнеп.

—Сез мина бөтенләй берни дә бирмәссез микәнни, әти?—диде ул төшенке генә.

—Борчылма, алырсын,—диде әтисе ягымлы итеп.

Җәбир, сөйләшер сүзне беткәнгә санап, бакчага чыкты, кәтмәнен алып килде дә уйлана-уйлана, арык тирәсен казый башлады.

Яшел ташлы алтын тамганы нишләтергә соң? Кире чүлмәккә салып куяргамы? Юк, әлегә аны ачарга ярамый. Әтигә кертеп бирсән, ул әллә кире бирә, әллә юк.

Ул шулай уйлады-уйлады да, яшел тамганы үзендә калдырырга дигән карарга килде. Шул кадәр зур байлыкка тап булып, шул кечкенә таш, алтын кисәген үзендә алып калырга хакы бардыр ич анын?! Юк, аны барыбер әти-әнигә күрсәтмичә йөртеп булмаячак. Аларга әйтергә кирәк.

Ин ахырда ул шундый фикергә килде һәм эшен ташлап әтисе янына кереп китте. Ләкин ишек тоткасына тотындым дигәндә генә анын күнеленә икенче бер уй килде: нишләп, сорамыйча, каракларча алдын,—дип әйтсә әтисе? Хәзергә калсын үземдә генә, диде ул ниһаять ныклы бер карарга килеп һәм тынычланып, янадан кәтмәнләү эшенә тотынды.

Кичкә таба кара кәҗә житәкләп базардан әнисе кайтып керде. Әнисе белән сенлесе дә кайткан иде. Җәбир аларга үзе капка ачты һәм кара кәҗәне житәкләп үзе абзарга илтеп япты. Сенлесенен үзен генә туры китереп, ана беренче соравын бирде:

—Талия дә кайттымы? диде.

—Талия мака сар сараенда хәзер,—диде сенлесе күнелсез елмаеп.

Мондый көтелмәгән яналык ишетеп, Җәбирнен аяк буыннары хәлсезләнеп калды. Талия... сарайда! Талия юк. Талия ана язмаган. Менә ул ин зур кайгы дөньяда!

***

Яз быел да сонгармыйча вакытында килеп житте. Көннәр озая, төннәр кыскара башлады. Кышкы янгырлар, жил-давыллар тынып калды. Дингез тынычланды һәм күктә болытлар бөтенләй күренмәс булды. Ягымлы кояш, игелекле, бәрәкәтле кояш иртәдән башлап кичкә кадәр бәхетле лелекләр илен—мака сар яшәгән Изгеләр утравын жылы, шифалы нурларына коендырды.

Ел тәүлеге алышынып, көннәр жәйгә авышкач та, жирдә-суда, күктә бөтенесе—жанлы-жансыз хәрәкәткә килде. Быелтыр көздән яфракларын коеп куйган агачлар, куаклар, үләннәр яна бөре жибәрделәр. Яфракларын коймаган мәнге яшел агачлар тагын да яшәреп, матурланып калгандай булдылар. Тау буйларында, үзәннәрдә куаклар чәчәккә күмелде. Бакчаларда, юл буйларында ал, сары, ак, күрән төстәге купшы чәчәкләр күренә башлады. Камышлы күлләрдә, елга буйларында бала чыгарырга жыенган аккошларнын, кыр казларынын һәм торналарнын меңләгән, ун меңләгән башка кошларнын моңлы чыр-чуы, гүелдеге янгырап торды. Төннәрен ерак таулар-кыялар ягында бөтен тирә-якны дер селкетеп арысланнар үкергән, аюлар кычкырган һәм бүреләр улаган тавышлар ишетелеп торды. Иртәнге якта кеше аягы басмаган куе урманнардан балаларын ияртеп, бүрәнәдәй юан аяклары белән салмак атлап, кыргый филләр килеп чыкты. Алар бер-бер артлы тезелеп, тау елгалары ярына су эчәргә килделәр.

Жир уяну белән, агачлар, куаклар, җәнлекләр, бөҗәкләр генә түгел, кешеләр дә янадан җанланып киткәндәй булдылар. Урамнарда, йорт тирәләрендә балалар, үсмерләр тавышы ешрак ишетелә башлады, капка төпләрендә кояшта җылынып утыручы хәлсез картлар, корткалар күбәйде. Болыннарда, елга буйларында көяз кызлар, җегетләр күренде. Игенчеләр кырга чыгарга әзерләнә башладылар.

Ләкин, быелгы яз башка язлардан әлләни аерылмаса да һәм табигатьтәге бөтен җанлы-җансыз тиешенчә хәрәкәткә килсә дә, быел игенче язны теләр-теләмәс борчу һәм кайгы белән каршылады. Күпчелек игенче өчен иң зур кайгы шул булды: чәчәргә орлык юк иде. Былтыр көздән мака сар боерыгы белән бөтен биләмәләрдә игенчедән барлык бөртекле ашлыкны җыеп, очсыз бәягә сатып алдылар да, чокырларга, чүлмәкләргә тутырып, авызын томалап, тамгалап куйдылар. Былтыр көз мака сарның ашлыкны ни өчен шулай амбарларга җыйдыруын күп кеше бик үк анлап та житмәделәр. Кайберәүләр әйтте: илгә корылык килә икән—җирингә дә иген унмаса, халыкны ачтан саклап калу өчен җыялар икән диде. Икенче берәүләр әйтте: ачлык бездә булмый ул—ачлык башка илләрдә була—ашлыкны аларга сатып, зур табыш алу өчен җыялар, диделәр. Өченчеләре исә башкачарак фикер йөртте: мака сар Карун барлык игенчеләрне эшеннән аерып Кәмитне яуларга җибәрмәкче икән, шуңа әзерләнә икән, диделәр.

Көнәсә биләмәсенең башы Карман сакага бу хакта кайберәүләр сорау да биреп карадылар. Былтыр көз андый сораулардан бик җинел котылды: мака сарның боерыгы шундый—мин берни белмим, диде. Ләкин быел, язга чыгып, кыр эшләре якыная башлагач әле анда, әле монда игенчеләр чәчүлек орлыгы таптыра башладылар. Кырларыбызны чәчми калдырсак, Жир—Ана /Ас ана/ безгә рәнжер, таза баштан ач калырбыз—без ач булсак, бөтен ил ачыгыр, диделәр. Кайбер авылларда, калаларда ярсыган игенчеләр мака сар амбарларын ватырга тырышып та карадылар. Тавыш, ризасызлык көчәйде һәм игенчеләр былтыргы орлыкны йә бурычка бирергә, йә сатып бирергә таләп итә башладылар. Көнәсәдә генә түгел, башка биләмәләрдә дә хәлләр шундыйрак иде. Чәчүгә чыгу вакыты көннән-көн якынлашты, әммә Саркелдән, мака сардан амбарлардагы орлык хакында бернинди яңа боерык килмәде.

Карман сака, барлык эшләрен бер читкә куйды да, бүген менә җыенып мака сар каласына үзе китте. Нәрсә уйлый икән агасы Карун? Әллә быел игенчегә ашлык чәчмәскә дә ярый микән? Әллә монда яз килгәнен сизмичә-күрмичә калганнармы?

Үз каласыннан Карман сака бүген таң атканда кузгалып китте. Иртәнге якта диңгез тыныч иде, көндез дә тыныч һәм җилсез булачагы сизелеп тора. Шулай да көн яктыргач көчсез генә җил чыкты, каршы яктан исеп, җилкән киндерләрен каерды. Су өсте чайкала, дулкынлана башлады. Җилкәннәрне төшерергә туры килде. Яшь, таза ишкәкчеләр бар көчләренә иштеләр. Алар болай шактый тиз килделәр һәм бернинди хәвеф-хәтәргә юлыкмыйча, төштән соң Атлантита утравына якынлаштылар.

Утрауның очлы таулары караеп су өстеннән калкып чыккач та, кәмәче кәмәне бара торган юлына—унга, очлы таулар ягына турылады, чөнки алар сулга, көнбатышка таба баралар иде. Очлы таулар бик озак күренеп, маяк булып торды һәм барган саен зурайганнан-зурая, якынайганнан-якыная бардылар. Бер-ике сәгатьтән, ниһаять, утраудагы алтын, жиз, бакыр корылмаларга бәрелеп, утлы очкыннар булып, кичке кояш нурлары чагыла башлады. Чын кояш кәмәдәгеләргә сул якта—көнбатышта иде. Чын кояш, зурайганнан-зурая барып, кызарганнан-кызара барып һәм күкне, диңгезне куе кызыл-сары нурларга күмеп, жир астына төнге йокыга төшеп бара. Шул ук вакытта көнчыгыштагы утрауда, әйтерсең, аның игезәге булып, алтынга

күмелгән мака сар Карун Сәркеле балкып тора. Искиткеч күренеш иде бу.

Утрауга якынлаша барган саен, бу гажәеп күренеш көчәя, байый гына барды. Күренешләр төрләнде, төсләр үзгәрә барды. Өч ягында биек таулар калкып утырган утрауның көньягында, диңгез буенда киң, иркен тигезлек җәелеп ята. Менә шул тигезлеккә, диңгез ярына бер ун чакрым чамасы эчкәрәк кертеп Мака сар каласы салынган иде.

Атлантитага Карман сака һәрвакыт диярлек менә шушы вакытта—кояш баер алдыннан якынлаша һәм, очлы таулар күренү белән ул үзенең туган якларыннан күзен ала алмыйча, сокланып, хозурланып бара. Ерактa гүзәл корылмалар күренү белән соклану, хозурлану һәм горурлык тойгысы көчәйгәннән-көчәя.

Нинди матур, нинди бай һәм искитмәле аның туган каласы! Дөньяда илләр дә, калалар да, ныгытмалы тораклар да күп. Ләкин бер кайда, бер җирдә, бер халыкта мондый утрау да, мондый кала да, мондый коймалар да юк. Аркылысы егерме биш чакрым чамасы булган түгәрәк каланы өч кат таш койма әйләндереп алган. Уртада, үзәктә аркылысы бер чакырым түгәрәкне—Изге калкулыкны янә биек койма әйләндереп алган. Анда—үзәктә Мака сар. Изге калкулыкны тирә-яктан су божрасы уратып тора, су божрасынанан соң—җир божра, җир божрасыннан тагын су божрасы. Үзәкне, Изге калкулыкны аралашып өч су божрасы, өч җир божрасы саклый. Таш коймалар тышкы яктан бакыр белән, эчке яктан кургаш белән капланган. Изгеләр калкулыгындагы үзәктәге койма тышкы яктан җиз белән, эчке яктан бакыр белән капланган.

Күпме көч, күпме байлык киткән аларны төзүгә! Күпме мака сарлар, күпме галимнәр баш ватканнар үз калаларын барлык калалардан ныграк, матуррак итеп салу өчен! Һәм алар үз теләкләренә ирешкәннәр дә. Чөнки алар яшәешнең беркем белмәгән серенә төшенгәннәр. Алар һәрвакыт җиргә, суга һәм кояшка турылыклы булып калу турында гына уйлаганнар. Абаларга, Изге Атабызга, Анабызга багышлап вакытында корбан биргәннәр, йолаларны башкарганнар. Шуңа күрә дә аллалар изгеләр—мака сарлар яклы, лелекләр яклы булганнар. Менә шуңа күрә дә лелекләрне җирдә дә, суда да беркем җиңә алмый. Алай гына да түгел, аларга каршы беркем корал күтәрергә дә батырчылык итми. Мака сарлар, лелекләр—Кояшның иң сөекле уллары. Алардан изге беркем юк дөньяда.

Әйе, бөтен дөнья шулай дип уйлый. Ләкин мака сарның, сакаларның, лелекләрнең ни дәрәҗәдә изгелеген Карман үзе бик яхшы белә. Белә һәм уйлана. Хәер, бу турыда җаны булган һәркем уйлана. Уйлана һәм борчыла. Кайберәүләр каршы сүз әйтмәкче, баш калкытмакчы да булып карыйлар, ләкин күзгә күренмәгән көч—курку, куркытылу бик күпләрне телләрен тешләргә мәҗбүр итә. Иң яманы шул—балык башыннан чери. Дин онытыла, изге йолалар юкка чыга бара, бар нәрсәне байлык, алтын һәм бозыклык алыштыра бара.

Биек, озын коймалар белән әйләндереп алынган, ямь-яшел бакчаларга күмелеп утырган, күккә ашкан зур биналары булган һәм алтын-көмешләре, байлыгы белән балкып утырган шау-шулы калага якынлаша барган саен Карман саканың күңелен шундыйрак борчулы уйлар биләп алды. Ләкин дулкыннар өстеннән сикереп-сикереп тирбәнеп килгән зур кәмә Тамакка якынлашкач та, яр буендагы шакы-шокы тавышлары, кычкыру, сызгыру, җырлау аерымачык ишетелә башлагач та, борчулы уйлар үзеннән-үзе юкка чыкты. Аның күңеле бер дә юктан җилкенә башлады. Аның тизрәк менә шул шау-шулы тормышка кушылып китәсе килде. Бу калада, бу ыгы-зыгыда, бу таш йортлар, күперләр, коймалар, капкалар арасында теләсә кемне алдый торган, җилкендерә торган, үз эченә йота торган ниндидер сихри көч—теләсә

нинди изге абалардан да көчлерәк көч куып бара сыман иде.

Көнәсә биләмәсе Карман саканың Тамакка якынлашып килүен яр буендагылар ерактан ук күреп алдылар. Каршыга борыны, кырыйлары сарыга, калган өлеше кызылга буялган ике кәмә якынлашты. Карман сака Мака сар кешеләрен каршылау өчен, үз кәмәсенең борын өлешенә, тар сикегә чыгып басты. Карман сака Атлантитаның тугыз сакасы арасында иң яше, иң чибәре иде. Аңа әле нибары утыз бер яшь. Гәүдәгә ул оста сынчы ясаган бакыр сын кебек таза һәм калку буйлы. Башына ул ят кош каурыйлары кадап ясалган, затлы ташлар белән бизәлгән, алтын кыршаулы калпак кигән. Муенында гәрәбә муенса. Аның озын кара чәчләре тугыз үремгә үрелеп, аркасына салынып тора. Биленә ул алтын аеллы кызыл пута бәйләгән. Билдән түбәнге өлешен каплаган киеме аның буй-буй сары төшкән күк төстәге кыска итәктән гыйбарәт иде.

Аны каршыларга килгән кәмәләрдәге кәмәчеләр мака сарның туганын котлап кулларын күтәрделәр, чак-чак кына башларын иделәр. Карман сака аларга уң кулын күтәреп җавап бирде. Шуннан соң, аны-моны сорашып тормыйча, каршыга килүчеләр кире борылдылар. Кәмәләрнең берсе Карман сака кәмәсе алдына төште. Андагы койрыкчы сака кәмәсендәгеләргә аркан ташлады. Арканны борындагы ыргакка беркетеп куйдылар. Каршылаучы кәмәчеләрнең икенчесе шулай ук беренчесенең алдына чыкты да, ике арага тагын аркан ташладылар, һәм шул рәвешчә, ике кәмә бер-берсенә тагылып, сака кәмәсен тартып алып киттеләр.

Көне буена туктаусыз ишеп килгән кара ишкәкчеләр бик нык арыганнар иде. Кәмә үзеннән-үзе шуыша башлагач алар, иркен сулап, сөенечтән җиңелчә кычкырып җибәрделәр, ишкәкләрен тартып алдылар да, тирә-якка карап бара башладылар.

Дингездән кала үзәгенә—Саркелгә таба сузылган каналның киңлеге йөз адым, озынлыгы ун чакрым иде. Каланы уратып алган иң зур койма дингез белән канал кушылган төштә Тамакның ике ягында өзелеп кала иде. Ләкин койманың дәвамы рәвешендә, Тамак аша өсте ябулы бик зур, бик озын күпер салынган иде. Тамак янында—монда да, сулда да кораллы ирләре булган сакчы сугыш кәмәләре туктаган, күпердә һәм күпер янындагы ике яктагы таш манаралар башында шулай ук кораллы ирләр—күзәтчеләр йөреп тора иде.

Карман сака кәмәсен бернинди тоткарлыксыз Тамак авызыннан үткәреп җибәрделәр. Канал уртасындагы кәмәләр, каеклар, бер-берсенә тагылган горур һәм бизәкле кәмәләрне күреп алу белән, шундук читкә тайпылырга, яр буенарак сыенырга тырыштылар. Каршыга килүчеләр шулай ук тиз генә читкә каердылар. Үз кәмәсенең алгы ягына—борын өлешенә чыгып баскан һәм кулларын күкрәк турысында кушырып барган яшь, горур саканы котлап ярның әле уң ягыннан, әле сул ягыннан кычкырган авазлар ишетелде. Кайберәүләр, якын танышларын очраткан кебек, аңа кул болгадылар, ишкәкләрен югары күтәреп сәламләделәр. Изгеләр нәселеннән булган Карман саканы аның үз биләмәсендә генә түгел, Мака сар каласы Атлантитада да бик күпләр яраталар һәм якын күрәләр иде. Ни өчен дигәндә, ул монда, калада туган кеше. Аннары ул сакалар арасында иң яше һәм халык арасында сөйләнгән төрле имеш-мимешләргә караганда ул башка барлык сакалар арасында акыллырак һәм шәфкатьлерәк дип исәпләнелә иде.

Каналның ике як яры да тигез итеп киселгән таш койма белән ныгытылган. Койма өстендә, озын ботакларын су өстенә сузып төз кәүсәле пальмалар, иманнәр утыра. Агачлар арасында берәр, икешәр катлы таш өйләр күренеп калды. Өйләрнең бер төрлесе тоташ ак таштан, икенче төрлесе кызыл, сары яисә кара ташлардан салынган иде. Капкалар бизәлгән, капка канатларына

кояш бизәкләре төшерелгән. Каналның әле ун ягында, әле сул ягында ярга тарттырып бәйләп куелган буш кәмәләр, шулай ук әле яна килеп туктаган төрле каеклар күренеп калды. Кәмәләрнең кайберләренә агач, таш, кайберләренә шыплап өеп ашлык, кайберсенә чүлмәктер, савыт-сабадыр төялгән иде. Ара-тирә ат-сыер, сарык ише мал-туар төягән зур корсаклы авыр кәмәләр очрады. Яр өстендә балта, чүкеч тавышлары ишетелде, ниндидер кычкырган, балалар җылаган тавышлар ишетелеп калды.

Сака кәмәсен тартып баручылар шактый тиз алып бардылар. Кала үзәгенә таба якыная барган саен яр буйларындагы шакы-шокы килгән, тамак ярып кычкырган төрле тупас тавышлар кими башлагандай булды. Аның урынына яр буенда куе агачлар арасында утырган йортлар ешайды, биегәйде. Каланың бер ягыннан икенче ягына йөрүче ниндидер төрле төстәге, төрле кыяфәттәге каеклар күренде. Менә, ниһаять, канал тәкәнде һәм туп-туры беренче су божра эченә барып керде. Су божрага кергәнче алар каналның бу башына салынган киң күпер астыннан чыктылар. Ләкин күпернең урта бер җиреннән туры почмак буенча тармакланып, алга таба икенче бер күпер сузылды. Иң зур су божрасының киңлеге ярты чакрымнан артыграк иде. Канал аша салынган күпергә килеп терәлә торган икенче күпер менә шул ярты чакрымнан артык араны үтеп алдагы җир божра ягына барып чыга. Күпернең киңлеге илле адым. Бер-берсеннән тигез ара калдырып, ак ташлардан салынган баганалар ерактан ук матур булып, искиткеч булып күренә иде. Кәмәләр күпер астыннан, баганалар арасыннан бардылар. Як-якта каядыр ашыгучы төрле кәмәләр, каеклар күренеп калды. Ун якта, яр буенда зур гына сал килеп туктаган һәм кара тәнле коллар кичке кояшта аеруча кызгылт булып күренгән юан-юан нарат бүрәнәләр бушатып яталар.

Су божрасын аркылы чыккач, алар ярым караңгы куыш эченә килеп керделәр. Бу инде су божрасы бетеп, җир божра башлана дигән сүз. Беренче җир божраның киңлеге шулай ук ярты чакрымнан артыграк. Җир астыннан үткән су юлына яктылык төшсен өчен яктылык козыклары калдырылган. Көндез аннан кояш яктысы төшсә, төннәрен анда утлар яндырыла. Алар җир божра астыннан чыгып янадан күпер баганалары арасына килеп керделәр. Бу күпер икенче су божрасы аша салынган. Бу күпер тоташ кара ташлардан салынган. Кара күпер ак күпергә караганда кыскарак булды.

Икенче су божрасында агач-таш, ашлык-фәлән ташучы кәмәләр бөтенләй очрамады. Монысында тоташ кызылга буялган өр-яңа сугыш кәмәләре генә йөри ала иде. Ләкин алар төрле култыкларда, яшерен урыннарда саклана. Изгеләр калкулыгы дип тә, Саркел дип тә атала торган түгәрәк калкулыкны әйләндереп алган су божрасы башкаларына караганда таррак—ни бары ике йөз адым киңлегендә генә. Бу божра аша кызыл күпер салынган. Кызыл күпер астыннан, кызыл таш баганалар арасыннан узгач, алар тышкы яктан җиз белән капланган биек, түгәрәк койма каршына килеп туктадылар. Тартып килүче кәмәләргә ары бару тыела иде. Шунлыктан алар Карман сака кәмәсенә тагылган арканнарын ычкындырдылар да, икесе ике якка каерылып, кирегә борылдылар.

Изгеләр калкулыгы астына шулай ук ясалма су юлы керә. Ләкин бу су юлы җиз чылбырлардан теркәлгән челтәр белән бикләп куелган иде. Анда Мака сарның үз рөхсәтеннән башка бер кем дә керә алмый. Карман саканың кәмәсе җиз коймага артык якын килмичә, күпер баганаларының берсе янында туктап калды. Мака сарның сөңгечеләре аны күрделәр, таныдылар һәм ашыгыч рәвештә сарайга йомышчы җибәрделәр. Бу вакытта инде кояш баеп килә иде. Су өсләре карайган һәм ничектер тынып калган сыман күренде. Бары тик мәһабәт булып, кыя таудай калкып торган, туп-туры су өстеннән күккә таба үрләгән җиз коймадан гына кызгылт тонык яктылык чагылып

күренә иде. Якында гына шундый биектән шул кадәр күп жиздән төшкән кызгылт яктылыкны тою күнелле дә һәм шомлы да иде.

Көне буе кәмәдә килеп Карман сака шактый арыган, йончыган иде. Күпер баганасы янында туктап, көтеп торган арада ул ничектер тынычланып калып, тәне белән дә, күнеле белән дә ял иткәндәй булды. Аны хәтта сиздермичә генә йокы да баса башлагандай булды. Монда аңа бөтен нәрсә таныш һәм якын. Каршыдагы биек жиз койма да, таш баганалар, таш күпер һәм күпер өстендәге туктаусыз дөбердек тә, су өстеннән арлы-бирле шуып киткән кәмәләр дә, сөңгечеләр дә, тонык су өстеннән таралган рәхәт талгынлык та, барысы да таныш һәм якын иде. Аның бала чагы, үсмер чагы шушында—су өстендә, таш күпер араларында, биек коймалар янында үтте. Атлантитадагы Саркелгә кайтканда ул һәрвакыт шул бала чакларын, үсмер чакларын исенә төшерде һәм һәрвакыт аңа монсу да, күнелле дә һәм никтер оят та була.

Шул ук вакытта һәр кайтуында ул үзенең монда инде күпмедер дәрәҗәдә чит кеше икәнлеген дә, балачак һәм үсмер чак белән үзе арасында жиз, бакыр коймалардан да биегрәк булып нииндидер башка коймалар ятканын да тоймыйча булдыра алмады. Мондагы су өсте, мондагы һава, йортлар, коймалар, күперләр, әйтерсең, аның үзенә түгел, бала чакта, үсмер чакта торып калган, ләкин аңа бик тә таныш булган икенче кешегә якын, үз иде. Бүгенге, хәзерге Карман сака исә монда бары кунак кына, һәм бу чыннан да шулай иде. Карман саканың »туган жире» хәзер башка утрауда, башка калада, монда исә тулысынча аның иң өлкән агасы Карун хужа, Карун баш.

Биек ак ташка чукып язылган түрә буенча Кар баба нәселеннән булган тугыз саканың мака сар янына тәүлекнең теләсә кайсы вакытында керергә хакы бар. Мака сар үзенең йокы бүлмәсендә ятакта булган чагында гына аның янына беркем кертелми. Элегрәк сакалар Саркелгә кертелгәндә дә күпер астында туктап, сөңгечеләрнең рөхсәт алып килүен көтеп тормаганнар—туп-туры койма авызыннан эчкә үтеп киткәннәр. Менә шулай жиз койма авызындагы жиз чылбырга карап көтеп тору тәртибен Карун булдырды. Ата-бабалар ташка язып калдырган түрәдә Саркелгә ничек керү-кермәү турында бер сүз дә юк иде. Шуннан файдаланып Карун шулай сакаларның хокукларын чикләүдә хәйлә тапты. Түрәдәге һәр үзгәреш бары тик ага-энеләр тарафыннан расланырга тиеш булса да, Карунның тәкъдименә беркем ныклап торып каршы килә алмады, чөнки ул мондый чикләүнең кирәклеген нигезли алды. Имеш, ага ул аллага тиң кеше, имеш болай итсәң башка чит халыклар арасында аганың дәрәҗәсе бермә-бер артачак, аннан куркып, кан калтырап торачаклар. Карун ул гомумән шундый кечкенә яңалыклар, яңа гадәтләр, түрәләр уйлап табарга ярата. Ләкин ул уйлап тапкан гадәт-түрә аның үзенең хокукларын арттыруга, башкаларның—сакаларның, лелекләрнең яисә караларның хокукларын кысуга юнәлдерелгән була. Аның бөтен тырышлыгы, бөтен уй-хисе үз-үзен зурлауга, үз-үзен чиксез хужага әйләндерүгә хезмәт итә.

Көтеп тору Карман сакага озакка сузылгандай була башлады. Аның инде ашыйсы да килә башлагандай булды. Әкренләп анда ачу, үртәлү тойгысы кузгалды. Шул чакны, ниһаять, койманың гөмбәзле зур, биек авызыннан сөңгечеләр кәмәсе чыгып килгәне күренде. Тоташ кызылга буялган өч-дүрт кешелек кечерәк кәмә туп-туры күпергә, Карман сака янына якынлашты. Мака сар яныннан килгән сөңгече, кар курага менеп тормыйча, астан, су өстеннән генә мака сарның Саркелгә керергә рөхсәтен әйтте. Аннан соң өстәп куйды:

—Мака сар әйтте: ашыгыч йомышы булмаса, бүгенгә ял итсен, дип әйтеп әйтте,—диде.

Карман сака сөңгече алдында ярсып кычкырып жибәрүдән үзен чак-чак

кына тыеп калды. Ни өчен дигәндә, Саркелдә сөңгечеләр мака сарның иң ышанычлы кешеләре иде. Аларның бер өлеше аның белән бер йортта ук торалар, икенче өлеше барлык керү-чыгу юлларын—капкаларны, ишекләрне саклыйлар һәм Саркелдә мака сар турында кем нәрсә әйтә, хәтта кем ничек уйлый—барысын да ана житкереп кенә торалар. Шуна күрә хәтта сака булган кешеләр дә Карун турында алар алдында нинди дә булса сүз әйтүдән тыелып калырга мәжбүрләр иде. Ә бит мака сарның ана—Карман сакага «бүгенгә ял итсен» дип әйтергә бернинди хакы юк. Әле ул йокыга ятмаган, аның ятагында әлегә бернинди хатын-кыз юк. Шулай булгач, ул туп-туры керә алырга тиеш. Ул әнә аны чикли, аның юлына аркылы төшә, аның хокукын кыса. Ул шулай димәсә дә, Карман сака бүген үк аның янына керергә атлыгып тормый иде.

Сака шулай итеп үзен кыерсытылган итеп хис итте. Ләкин ул боларның барысын да эченә йотты һәм Карун боерыгын алып килгән сөңгечегә:

—Юлда бик йончыдым, иртәгә барырмын—шулай дип әйт,—диде.

Сөңгече кәмәсе коймага таба борылды. Сака кәмәсе дә әкрен генә кузгалып китте. Алар койма авызына якынаю белән, койма авызы янында кечерәк кәмә өстендә сакта торган сөңгечеләр югарыдагы, койма өстендәге кешеләргә өзек-өзек кычкырып боерыклар бирделәр. Кайдадыр өстә, биектә чыгырлар шыгырдады һәм жиз койма авызын каплап торган челтәрле чылбырлар пәрдәсе әкрен генә югары күтәрелә башлады. Сака кәмәсе су өстеннән шуышып барган шәпкә ярым караңгы жир авыз эченә барып керде.

Түгәрәк калкулык эченнән чыгып ясалган бу жир асты юлы иң үзәккә кадәр—мака сар сараена кадәр сузыла иде. Мака сар, дингезгә чыгасы килсә, үз сарае янындагы баскычтан түбән төшә дә, яр буена килә дә, су өстендә үз кәмәсенә утырып, шундук чыгып китә ала. Аның янына килүче сакалар да шушы жир астыннан сузылган су юлы белән генә килә алалар иде.

Ярты чакрымга сузылган бу жир асты су юлы мака сарның һәм шулай ук бөтен Атлантитаның яшерен амбары хезмәтен дә үти иде. Як-яклары, стеналары, астары, гөмбәзле түбәсе төрле ташлардан өелгән бу жир асты юлы шактый киң һәм биек иде. Бу юлдан өч рәт ишкәкчеләре булган кәмә бик иркен үтә ала, житмәсә як-якта әле кечерәк каекларга үтеп китәрлек урын да кала. Мондагы яшерен юлның үзенчәлеге шунда: як-якта монда туп-туры су өстенә төшә торган таш баскычлары, тигез басмалары һәм жир белән ныгытылган зур-зур ишекләре булган өстәмә икешәр катлы амбарлар бар. Амбарларның аскы катында бар жире дә буялган өр-яңа сугыш кәмәләре, өске катында дингезче өчен кирәк булган төрле нәрсә: агач-таш, бау-шу, буяу, балавыз, калак, ыргак, һәм, әлбәттә, сугыш кораллары—сөңгеләр, калканнар, ук-жәя кебек нәрсәләр саклана. Амбарның бер төрлесендә корал, бау-шу булса, икенче төрлесендә зур-зур чүлмәкләрдә, капчыкларда ашлык, жимеш, май, бор һәм башка төрле азык-төлек саклана. Жир асты юлына төшеп-менеп йөрү өчен йөз адым саен тирән ям казылган. Ямның як-ягы, гөмбәзле түбәсе шулай ук таш белән ныгытылган, жизгә төрелгән таш баганалар белән бизәлгән.

Карман саканың Саркелдә үзенеке исәпләнелгән аерым йорт-жире бар. Йорт-жирдә исә үзенең каралары, кайбер якын туганнары яши. Саркелгә килгән саен ул шунда туктала. Хәзер дә ул үз йортына якынрак урнашкан Карпе янында туктап калды.

Кәмә яр буена килеп туктау белән, борыннан да, койрыктан да ярга аркан ташладылар. Ярдагы кешеләр, тиз-тиз генә кыланып арканнарны таш баганаларга тарттырып бәйләп куйдылар. Ул арада кәмәдән ярга басма сузылды. Басмадан иң әлек саканың ун коралллы ире төште. Алардан беркадәр калышып Карман сака ярга үзе чыкты. Аның коралларын, авыр жиз

киемнәрен арттан өч яшь кара ир күтәреп барды. Алардан соң чыккан ирләр кулларына зур-зур чүлмәкләр, капчыклар күтәргәннәр иде. Иң ахырда дүрт таза ир аркылы таякларга утыртылган ниндидер бик авыр нәрсә күтәреп чыктылар. Ирләрнең икесе алдан, икесе арттан барды. Ташкурчакка ошаган авыр нәрсәнең өстенә киндер кисәге капланган. Бу Карман сака әнисенең бер батман авырлыгындагы алтын сыны иде. Сака аны үз каласындагы сынчылардан койдырды һәм ул аны Карунга бүләк итеп бирергә исәпли иде. Кыйммәтле бүләк алып килсәң мака сар Карун белән сөйләшүе җинелрәк була, юкса ул үзен кирәгеннән артык эре һәм һавалы тотачак. Анын мондый гадәтен белгән кешеләр беркайчан Саркелгә буш кул белән килмиләр, килгәндә һәрвакыт алтыннан ясалган бүләк алып килергә тырышалар.

Кин, тигез баскычлардан югары күтәрелделәр һәм ике ягында да биек агачлар үскән киң сукмак белән турыга бардылар да, аннары унга каердылар һәм бераздан зәңгәр капкасына кашкарый сүрәте кадакланган йорт каршына килеп җиттеләр. Капка төбендәге утыргычта калын иренле, көдрә чәчле кара утырып тора иде. Төркемләшеп килүче бик күп короллы кешеләрне, алар артында җилкәләренә ишкәкләрен күтәргән ишкәкчеләрне һәм бигрәк тә алдан килүче Карман саканы күрү белән, капка төбендәге кара шундук сикереп торды һәм кабаланып капка артындагыларга нидер кычкырды. Җиз кашкарыйлы зәңгәр капка шундук ачылып китте, ишек алдыннан карт кара сакчы килеп чыкты. Ашыгып ул сака каршысына килде, баш иде, саканың аягын үпте.

—Исән-имин кайтып җитүең белән котлыйм сине, сака,—диде кара сакчы карлыккан тавыш белән ялагайланып.—Йортың-җирең исән-сау. Барысы да үз урынында. Түрдән уз туган җиреңә.

Карман сака, рәхмәт әйткән сыман итеп, карт колның башыннан сыйпады һәм капка аша керешли генә, узып барышлый гына әйтеп куйды:

—Бар, әйт, җылы су таманласыннар, яхшы аш-су әзерләсеннәр. Арыдым, ачыктым,—диде.

Карман саканың дүрт яктан да таш койма белән уратып алынган йорт-җире шактый иркен иде. Монда аерым-аерым утырган берәр, икешәр катлы өйләр дә, терлек-туар тоту өчен абзар-куралар да, җимеш бакчалары, тегесен-монысын чәчү, утырту өчен буш җирләр дә, болай гына, матурлык өчен генә үстерелә торган төрле агачлар да, куаклар да бар иде. Җиз кашкарыйлы кин капкадан килеп керү белән турыга таш җәелгән кин урам сузыла. Урамны бер-ике җирдән таррак урамнар кисеп үтә. Анда-санда кешеләр күренде, үзара уйнап йөргән бала-чага тавышына катышып, сыер мөнгерәгән, сарык кычкырган тавышлар ишетелде. Изгеләр калкулыгындагы Саркелдәге бу коймаланган җир үзе бер авылны хәтерләтә.

Шушы кин, иркен кешәлекнең уртасында, үзәктә куе яфраклы матур агачлар артында тигез итеп киселгән, шомартылган ак ташлардан салынган ике катлы биек һәм зур йорт күренде. Бөтен авылда бу иң зур йорт. Заманында бу Карман сака әнисенең, мака сар Минәйнең дүртенче бичәсе Сәлимә йорты булган. Карман шул йортта туган. Сәлимә бикә исән чакта үзенең өлкән кызы Галиягә кияү алып, аларга шунда яна йорт салып биргән. Бикәнең икенче, өченче кызлары да үзләренә кияү алып, әниләренең авылында торып калганнар. Сәлимәнең Карманнан башка тагын ике улы булган. Аларның берсе Акайлар белән сугышта яуда үтерелгән, икенчесе—төпчеге үз өе белән аерым торып ята. Үзе яшәгән иң зур, иң бай борынгы йортны Сәлимә бикә өлкән улы Карманга калдырган. Ләкин Карман үлгәч, йорт анын балаларына түгел, ана нәселеннән булган өлкән ир балага калачак.

Хәзер исә бу авылда Карманның апасы Галия иң өлкәне һәм иң башы

исәпләнелә. Мондагы бөтен авылга, барлык кешегә ул баш һәм аның белән килешмичә монда берни эшләнми.

Саканың юлдашлары—алыплар, кәмәчеләр һәм ишкәкчеләр—йөзләп кеше барысы да диярлек ишегалга кереп тулдылар. Ишкәкчеләр ары китмәделәр—капкага якын җирдә, кергәч тә ун якта озын гына, тар гына таш йорт бар иде. Алар шунда калдылар. Кәмәчеләр сулга каердылар. Капкадан берничә адым читтә генә алар өчен дә йортлар бар. Утыз алып—Карман саканың ин ышанычлы сакчылары аның белән бергә киттеләр.

Карман сака ин элек үз өенә түгел, апасы Галия йортына юнәлде. Галиянең йорты Карман йортыннан кала бөтен »авылда» ин зурысы, ин күренеклесе иде. Ул да ике катлы, тик үзәктәге йортка караганда ул бераз гына тәбәнәгрәк һәм бераз гына кечерәк иде, ләкин шуна да карамастан, аның йорты җанлырак, баерак һәм матуррак сыман иде. Анда көне-төне шау-шулы тормыш, күнелле тормыш кайнаганы үзеннән-үзе ерактан ук күренеп тора. «Шулай булырга тиеш тә» дип уйлады Карман сака, үзенең ничектер боегыбрак утырган таудай ялгыз өе ягына күз төшереп алгач. Бит анда асраулардан, каралардан, хезмәткәрләрдән башка чынлыкта беркем тормый да.

Карман сака килүе турында бөтен авыл белеп өлгергән иде. Юл уртасыннан барганда әле уннан, әле сулдан таныш кешеләр килеп чыкты. Берәүләр килеп сака белән исәнләшергә, олы туганына карата хөрмәтен белдерергә ашыкты, икенче берәүләр, каралар—хурлар, кимнәр, үзләренең бик нык сөенгәнлекләрен белдереп, елмаеп, читтән генә, юл буеннан гына карап калдылар. Әрсезрәк үсмерләр, кыю малай-шалайлар, атаклы абзыйларының алдына ук чыктылар, аның кулын йә булмаса киемен үбәргә тырыштылар. Бер бала хәтта көлеп аның юлына аркылы төште һәм үзен күтәреп алуны таләп итә башлады. Юл читендәге асраулар шундук баланы тотып алмакчы булдылар. Ләкин Карман сака балаларны ярата иде. Ул ярым шәрә ике-өч яшьлек малайны апасының улы икәнлеген таныды, күтәреп алды да, аның белән сөйләнә-сөйләнә шул килеш апасының ишек төбенә килеп туктады.

Шул чакны, тышта күнелле шау-шу ишетеп, өйдән ашыгып апасы Галия килеп чыкты. Өстенә ул кыска җинле озын күлмәк кигән иде. Энесе Карманны күреп ул сөенеп кычкырып җибәрде һәм кулларын җәеп, ак шома мәрмәр баскычтан йөгереп төшкәндәй төште дә, шаулап, кычкырып сөйләнә-сөйләнә һәм шул рәвешчә үзенең бик нык куануын белдерергә тырышкан сыман, энесенең муеныннан кочып алды.

—Иртәдән бирле уң күз кабыгым кычыткан иде—сине күрергә булган икән!—диде ул.

Шулай шау-шу килеп сака белән исәнләшкәндә, ул аның куенындагы үз улын да күреп алды, бик нык гаҗәпләнгән булды, ачуланган булды, хәтта улын абыйсыннан тартып алмакчы да булды. Бала исә аның саен абыйсының таза тәнле, дингез исе сеңгән нык таза муенына сырыла барды. Галия улының кирелеген күреп шаулатып көлеп җибәрде, малайның йомшак җиренә чәпелдәтеп алган булды.

—Нишләп вакытсыз килдең?—диде Галия энесенә.—Сабан туй җитмәгән, мака сарның туган көненә әле иртә. Менә кунакка барырга дип җыенып ята идек әле.

Галия Карман сакадан ике-өч яшькә генә өлкәнрәк иде. Ул шулай шауларга ярата, килделе-китте дә сөйләнеп ташлый, турысын әйтәм дип кайчагында кешенең йөзен ертудан да тартынып тормый иде. Шуңа күрә Карман сака аның сорауларына әлләни игътибар да итмәде.

Шул чакны ишектән кырык яшьләр чамасындагы басынкы кыяфәтле бер ир кеше килеп чыкты. Бу Галиянең кияве, Карманга җизни кеше иде. Ул, Карманны ерактан ук күреп, исәнләшкән кебек аңа баш иде, туктап калгандай

булды, ләкин алай гына килешмәгәнлеген аңлап, аскарак төште, изге сака белән кул биреп исәнләште.

—Галия, кунакка бәлки бүген бармабыз олы кунак килгәч?—диде ул бикәсенә карап.

—Син бармасаң бармассың, мин барам!—диде Галия, каршы әйтергә урын калдырмыйча.—Ничек бармыйсың—сүз бирелгән. Алар көтәләр.

—Барыгыз, бар,—диде Карман сүзгә катышып.—Мин арыдым. Хәзер ашыйм-эчәм дә йокларга ятам.

—Юк, мин синең үзеңне генә калдыра алмыйм. Килешми,—диде җизни.—Син алайса үзең генә бар—диде ул бикәсенә карап.

—Теләсәң син дә бар безнең белән,—диде Галия.

—Арыдым. Иртәгә,—диде Карман сака, сүзне озакка сузасы килмичә.

Карман сака, апасы Галия белән күрешкәннән соң, артык тоткарланып тормыйча үз өенә китте. Өй алдында тигез итеп таш җәелгән һәм як-ягында яшел яфраклы куе куаклар үсеп утырган мәйданчыкта аны өй хезмәткәрләре, асраулар, хезмәтчеләр, эшчеләр каршылады. Алар бил бөгеп, баш иеп, олуг хуҗаның исән-имин диңгез аша кичеп, исән-имин үз өенә кайтып җитүе белән котладылар. Карман сака исәнләшкәндәй итеп, аларга кулын күтәреп, баш кагып җавап бирде дә, ашыгып биек баскычтан югары менде һәм беренче каттагы коену бүлмәсенә юнәлде.

Тышта инде күз бәйләнә башлаган, өй эчендә исә шактый караңгы иде. Ләкин үз өендә Карман сака күз йомып та үзенә кирәк булган теләсә кайсы бүлмәгә ялгышмыйча бара ала. Шуңлыктан ул ян-яктагы биек терәкләр арасыннан, төрле борылышлар аша, бүлмәләр, ишекләр аша, әле уңга, әле сулга борылып, өйнең аргы башындагы бүлмәгә таба баруында булды. Ул араларда хезмәтчеләр пыскыйларга ут яндырдылар һәм, бер-берсенә нидер кычкыргалап, сакадан алдарак барып җитәргә тырышкан сыман, бүлмәдән бүлмәгә ары-бире чабыша башладылар. Берсе шунда чыртлап янган пыскыен югары күтәреп, сака алдына килеп чыкты һәм сака адымнарына яраклашып, аның алдыннан бара башлады.

Ниһаять алар коену бүлмәсенә барып җиттеләр, җиз калайлар кагып бизәлгән авыр ишекне ачып эчкә керделәр. Өйнең ыгы-зыгылы, шау-шулы өлешеннән читкәрәк, аулаграк почмагына урнашкан коену бүлмәсе артык зур булмаса да, иркен иде. Килеп керү белән сакаының борынына бераз гына черек күкәй исен хәтерләткән ис катыш кайнар су исе килеп бәрелде. Бүлмәнең каршыдагы мөгеш өлешенә терәп ясалган зур гына түгәрәк коега җылы су тутырылган, ис һәм бу шуннан күтәрелә. Кое янында таш урындык, таш урындык янында—ятак. Урындыкта алтын савыт-саба, сөнге, кием-салым. Өстен сырлап бизәлгән ташлар тезелгән идәнгә камыш чыпта, камыш чыпта өстенә йомшак палас җәелгән. Өч якта, өч мөгештә таштан уеп, шомартып ясалган ак таш түмәрләрдә җиз пыскыйлар янып тора. Диварларда—диңгез күренешләре. Бер ягында зәңгәр су астында су үсемнәре, балыклар. Шунда ук сигезаяклар. Икенче ягында зәңгәр диңгез өсте. Еракта диңгез зәңгәр күк белән тоташкан. Әз генә җил исә һәм кызыл җилкәннәрен күтәреп, сары кәмәләр, аккошлар сыман тезелеп, каядыр еракка китеп баралар. Яр буенда, таш коймага сөялеп, яисә кулларын болгап аларны кызлар озатып кала. Ишеккә каршы яктагы диварда, коеның тар ягы терәлеп торган төштә, тау башыннан ташлар арасыннан ургылып агып яткан чишмә сурәтләнгән. Чишмәнең бер ягында зур, авыр яфракларын салындырып, пальмалар үсеп утыра, икенче ягында юан купшы имән үсә, алгырак якта ал чәчәкле, ак чәчәкле ләләләр күренә. Пальмалар артында алтын текмә. Кайнар чишмә суы туп-туры бүлмәдәге коега агып төшкән сыман итеп ясалган. Барысы да чынлыктагы кебек. Чишмә янындагы ташлар

да, ләләләр дә, куаклар да таудан алып шунда китереп утырткан кебек.

Барысы да таныш, барысы да якын монда. Моннан егерме, егерме биш ел элек ничек булган булса, барысы да шул көе. Күгәрченнәр, тутыйлар ясалган бизәкле түшәм дә, идән дә, диварлар да, мондагы дымлы һава да барысы да бала чактагы кебек. Шушында жылы суда тыпырчынып ятканда ул үзен юындыручы кара тәнле кимгә су чәчрәтә-чәчрәтә, еракка китеп баручы дингезчеләргә, бер-берсен куышып йөзгән балыкларга карап хыяллана торган иде. Еш кына анын да шул балыклар сыман су эчендә чумып йөрисе килә, йә булмаса кәмәнең иң югары басмасына менеп басып жил-давылга каршы, дошманнарга каршы яуга чыгасы килә иде.

Чишенеп, шәрә килеш калып коега кереп сузылып яткач та Карман саканың шул бала чак хыяллары исенә төште. Әйе, бүлмә дә, кое да, сурәтләр дә—барысы да шул ук. Коедагы су да шундый ук—жылы дисәң жылы түгел, кайнар дисәң кайнар түгел. Таман гына. Рәхәт. Тәнгә вак-вак куыклар килеп куна. Су өсте гел күбекләнеп, куыкланып тора. Барысы да шул ук. Тик менә уйлар, хыяллар гына хәзер башкачарак. Ана инде күп мәртәбә су үсемнәре арасында, балыклар арасында да йөзәргә туры килде, сигезаякларны да күрде ул һәм жилкәнле кәмәләргә утырып иксез-чиксез кинлекләргә дә күп чыкты. Ерак-ерак илләрне дә күп күрде, яуларда да булды. Дошманнарны да жинде. Шулай да, кайда гына булмасын, күнелендә шушы өйне, шушы бүлмәне, шушындагы матур әйберләрне юксынды һәм шушы коеда, кайнар-жылымса шушы суда шәрә килеш сузылып яту анын өчен иң зур хыял булып тоелды. Нәрсә кирәк соң бу ата баласына чынлыкта? Кая ашкына ул туктаусыз? Бүген иртән ул ашыгып йокыдан торды. Анын менә тизрәк монда, үз өенә килеп житәсе килде. Көне буе ул бары шул турыда гына уйлады. Килде. Менә хәзер кич булды. Төн кунасы бар. Иң күнелсезе—төн уздыру. Тизрәк таң аттырасы, тизрәк якты көнне күрәсе һәм ниндидер зур эш эшлисе, һәркемне таң калдырырлык берәр батырлык, изгелек эшлисе килә. Нинди генә батырлык эшли алыр икән ул иртәгә? Ә бит эшлисе иде бит ул батырлыкны!

Ул шулай уйланып, ләззәтләнеп ятты-ятты да, башын калкытты, һәм урындыктагы күбәтәгә үрелде. Анын шундый хәрәкәт ясавы булды, ишектән кара хезмәтче кол килеп керде. Биенең нәрсә эшләргә чамалавын ул бик яхшы белде. Күбәтәгә кара сабын салынган иде. Сабын дип аталган тау итәгеннән тирән чокырдан алына торган бу кара ләмне тәнгә үкәсән, ул тәндәге керне, майлы тапларны юып төшерә, арыганлыкны бетерә һәм тән тиресен йомшарта. Саркел аксөякләре сабын ләме белән бик теләп юыналар. Урта яшьтәге хатын-кызлар аны аеруча күп кулланалар.

Кол керү белән Карман сака кое читенә чыгып утырды. Нәкъ бала вакыттагы кебек кол анын аркасын, озын чәчләрен сабынлаганда ул түземсезләнеп хәтта аяклары белән коедагы суны чыпырдатып утырды. Ләкин ана алай озак чыпырдатырга туры килмәде. Биленә тикле бөтен аркасы сабынланугa ул коедан чыгып кое читенә басты. Кол иплэп кенә анын ботларын, балтырларын сабынлый башлады. Ул анын бары арка ягын гына үкәде. Алгы ягын ул үзе сабынлады һәм шул эшне бетергәч, янадан коега керде, беләкләрен, күкрәкләрен ышкып-ышкып юына башлады. Кол анын аркасын, чәчләрен юды, тарады.

Коедагы су кап-кара булды. Бөкене ачып, суны агызып жибәргәч кол көмеш комган белән су салып Карман саканы яхшылап коендырды да, чәчләрен үрде. Юынгач ул үзендә жинелчә арыганлык тоеп, бераз вакыт урында ятып тормакчы булды.

—Жизнигә әйтегез—кунакка китмәгән булса, минем янга килсен,—диде сака.

Ул шулай диде дә, аяклары арыслан аягы кебек итеп фил сөягеннән ясалган йомшак ятакка сузылып ятты, күзләрен йомды.

Карман сака үзенең коену бүлмәсендә юынганда аның алыплары күршедәге икенче бүлмәдә юындылар. Юынгач, тарангач һәм өр-яңа коры киемнәр киенеп алгач алар, шундагы озын сикеләргә утырып тордылар да, саканың ишектән чыгуын күреп, урыннарыннан кузгалдылар. Икенче катка алар арткы яктан мәрмәр баскычтан менделәр.

Менеп җиткәч, артык зур булмаган бүлмә аша үттеләр дә, ике якка ачыла торган зур ишектән киң, иркен һәм биек мәҗлес бүлмәсенә килеп керделәр. Бүлмәнең идәненә сырлы бизәкләр төшерелгән мәрмәр тактачыклар тезелгән, аның өстенә буй-буй бизәкле киң паласлар җәелгән. Ишектән кергәч тә диварларга якынрак төштә як-якта түшәмдәге кырлы матчаларны тоттырып, парлы терәкләр тезелеп киткән. Юан имәннән юнып ясап эшләнгән ул терәкләр тоташ кызылга, терәк өстендәге һәм астагы идәндә калку дүнгәләкләр куе сарыга буялган иде. Парлы терәкләр белән диварлар арасындагы тар аралыкларга таш сикеләр, төрле бизәкле һәм төрле кыяфәттәге зур-зур чүлмәкләр, диварлардагы куышларда—алтын-көмеш, җиз-таш сыннар, чүлмәкләрдә—гөлләр. Бүлмәнең урта бер җирендәрәк, парлы терәкләр янында аяклары арыслан аягы сыман итеп, агачтан кырып ясалган һәм алтын калай белән төрелгән, кырыйлары матур итеп бизәлгән, сырланган зур өстәл. Өстәлдә эреле-ваклы, төрле төстәге, төрле формадагы алтын-көмеш савытлар. Мөгешләрдәге таш багана башларында утлар янып тора. Шунлыктан күзнең явын алып бөтен җирдә алтын-көмеш, җиз һәм бизәкле чүлмәкләр ялтырый. Диварлар, түшәм бөтенесе матур итеп ал, кызыл, зәңгәр, сары төсләрне аралаштырып буялган. Түшәм астында, кашага буйлап кашкарый һәм ләлә чәчәкләре төшерелгән.

Карман сака, идәндәге йомшак паласка нык-нык басып, туры өстәлгә таба атлады. Ул арткы ишектән килеп кергәч, күп тә үтмәде мәҗлес бүлмәсенең түрдәге икенче ишегеннән җизнәсе килеп керде. Уртадагы өстәл янына алар икесе дә бер үк вакытта диярлек килеп җиттеләр. Ләкин бу өйдә төп хуҗа Карман сака булганга, җизни әдәп саклап, чак кына соңгарак калды.

Тәбәнәк өстәл белән парлы терәкләр арасына бай итеп җиһазланган ике артсыз урындык куелган. Берсе Карман саканың үзе өчен куелган, икенчесе җизни өчен иде.

—Түрдән уз, җизни,—диде Карман сака, өстәл янындагы урындыкка күрсәтеп.

Шуннан соң ул үзенең алыпларына борылды һәм күз карашы белән аларга да утырышырга кушты. Җизнәсе белән алар икесе йомшак урынга утырдылар, алыплар өстәл тирәсенә туп-туры идәнгә, калку йомшак урыннарга утырдылар. Алар утырышып бетү белән, аргы уң яктагы ишектән яңа пешкән кайнар ит күтәреп, нык беләкле, симез, таза ашчы килеп керде. Ике куллап тоткан сырлы-бизәкле алтын табагын ул туп-туры Карман сака алдына китереп куйды. Карман сака ашыкмаска тырышып һәм беркемгә карамыйча, авызындагы төкерекләрен йота-йота сөяк саплы җиз пычак белән ит бүләргә тотынды.

—Мака сар җырчы кызларын җибәргән, би,—диде ашчы, Саканың колагына иелеп.—Керсеннәрме?

—Җибәргәч, керми нишләсеннәр инде?—диде Карман сака туравыннан аерылмыйча.—Пешкән ашың җитәме соң?

—Җитмәсә, житкерербез,—диде ашчы аптырап тормыйча.—Башта ук билгеле булса, яхшырак буласы иде дә.

Карман сака алтын табактагы изелеп пешкән майлы куй итенең беренче

калҗасын кулына алды да, ятак аша үрелеп таш багана башындагы май янына—ут анасы Әбетигә корбанга бирде. Беренче кисәкне Әбетигә бирмичә ашый башлау дөрес түгел иде. Шуннан сон ул икенче кисәкне үзе капты да, өченчесен кунагы жизнәсенә сузды. Жизнәсеннән сон тиз-тиз генә берәм-берәм ит кисәкләрен алыпларына бирә торды. Алыпларның барысына да куй итеннән өлеш чыгаргач, аш-су шунын белән башланып китте. Моннан сон инде һәркем үзенең алдындагына үзе үрелде. Беренче изге кабымны ашагач, Карман сака ниһаять күршесе жизнәсенә күтәрелеп карады.

—Ул мина беләсенме,—ял итәсе килсә, ял итсен, иртәгә килер, дигән. Хәзер әнә жырчыларын жибәргән,—диде гаепләгән сыман итеп.

Жизни, билгеле, анын кем турында әйткәнен бик яхшы анлады. Ләкин, анласа да, яклау да белдермәде, каршы сүз дә әйтмәде. Ул мондагы кеше. Мака сарга, сарайга якынрак кеше һәм мондагы һәр төрле яналыкларны да, барлык гайбәтләрне һәм имеш-мимешләрне дә бик яхшы белеп тора. Ул көне-төне шулар арасында кайный һәм мака сарнын тормышын биш бармагы кебек белә. Мака сарнын бүген кәефе юк. Карман теләсә дә, теләмәсә дә ул аны кабул итә алмас иде. Ләкин бу турыда анын сакага әйтәсе килмәде. Анын шулай ук жырчы кызларны Карун исеменнән үзе чакырткан икәнлеген дә әйтеп торасы килмәде.

Күп тә үтмәде, кычкырып сөйләшә-сөйләшә, көлешә-көлешә жырчы кызлар керә башлады. Алар барысы да яшьләр, чибәрләр иде. Аларнын көдрәләткән, күпертелгән кара чәчләре ике яктан толым-толым булып аркаларына салынып тора. Кыска жинле, озын итәкле күлмәкләренен муен, күкрәк турысы ачык. Бит очларына, иреннәренә матур итеп кызыл буялган. Кайберсенен чәченә болай гына, әйтерсен ялгыш кына чәчәк кыстырып куелган, күбесе төрле ташлардан, алтыннан, көмештән тезелгән муенса таккан. Ак, сары жирлеккә аралаштырып аркылы буй-буй сызыклар төшерелгән кин күлмәк итәкләре аяк атлаган саен салмак кына дулкынланып бара.

Зал уртасына якынлашу белән, өстәл янындагы алыпларны күрү белән алар көлүдән, сөйләшүдән тыелып калдылар. Шул ук вакытта бер-берсенә карашып йә пырхылдап алдылар, йә тыелып кына нидер гайбәтләшеп алдылар.

Башларын югары тотып, күлмәк итәкләрен жилбердәтеп салмак, ышанычлы адымнар белән алар шулай алгарак уздылар да, ашаучыларга каршы яктагы озын сикеләргә утырыштылар. Үзләре белән алар гөслә, курай, кубыз ише уен кораллары алып килгәннәр иде. Өстәлгә, ашаучыларга каршы якта диварда идәннән бер колач югарылыктан башланып, түшәмгә кадәр сузылган кин ачыклык—тәрәзә бар иде. Көндез аннан бүлмәгә яктылык төшә, һава керә, кичен, менә шундый мәжлесләр вакытында шулай ук саф һава керә һәм өйдә янган пыскый төтеннәре, төрле аш-су исләре чыгып тора. Жырчылар әлеге тәрәзәнен ике ягына утырыштылар һәм кинәт кенә тынып калдылар да көтә башладылар.

Шул чакны кызу-кызу атлап ишектән өлкәнрәк яшьтәге бер хатын-кызнын килеп кергәне күренде. Бу жырчы-биюче кызларнын абыстасы... Фалия иде. Ул да кызлары кебек өстенә озын итәкле нәфис, юка тукымадан тегелгән күлмәк кигән. Тик анын күлмәге кызларныкына караганда бизәкләре белән аерылып тора. Күлмәкнен жиннәре кыска, түше ачык, хәтта кирәгеннән артык ачыграк сыман иде. Колакларына алтын алкалар, муенына кыйммәтле муенса таккан, иреннәренә, бит очларына шулай ук кызыл буяган. Кызларына караганда өлкәнрәк яшьтә булса да, ул әле чибәр һәм дәртле күренә.

Өстәлгә якынаю белән матур елмаеп һәм үзен бик иркен тотып ул сакага баш иде.

—Мака сар мине сина жибәрде, Карман сака,—диде.—Ашын тәмле булсын, йокын татлы булсын.

—Йокларга әле иртәрәк, Фалия,—диде Карман сака, көлемсерәп.—Жырлагыз, биегез—йокы качарлык булсын!

—Без жырласак йокың түгел, алыпларың да качышып бетәр!—диде Фалия шаяртып.

Карман сака алтын табактан итле генә бер кабырга алды да, өстәл аша үрелеп атаклы жырчыга сузды.

—Тавышыңны бозмас микән?—дигән булды ул, шулай ук җиңелчә шаяртып.

—Кәефемне бозмаса, миңа шул җиткән,—диде Фалия, итле сөякне алып һәм кычкырып көлде дә сөяген кимерә-кимерә, үзенең кызлары янына китеп барды.

Карман сакага аның көлүе бераз гына ясалма, тавышы да элекке кебек түгел, карлыккан сымаграк тоелды. Керфекләренә сөрмә тарткан, күз кабыклары тимер-күккә буялган һәм шунлыктан зур, серле күзле булып күренгән, чамасын белеп кенә төзәнә торган, чибәр, дәртле һәм кирәгеннән артык кыю, хәтта әрсезрәк булган бу абыстаны ул бик үк өнәп бетерми иде. Ул үзенең кемлеген һәм нindилеген яхшы белә һәм бәяне дә алдан үзе әйтә һәм аксөяк ирләр белән эш иткәндә, ничек тә күбрәк каерырга тырыша иде. Бу турыда Карман саканың башкалардан да ишеткәне булды һәм шулай ук үзенең дә... кармакка капканы бар иде. Билгеле, яшьрәк чагында. Моннан фәлән еллар элек. Хәер, ул вакытта Фалия дә яшьрәк, чибәррәк иде. Чибәррәк кенә түгел, ут кебек, жылан кебек иде!

Мака сар Карун Фалияне үзенә алып калганның беренче айларында чын-чынлап аңа гашыйк иде. Тора-бара ул аннан туйды.

Фалия исә мака сарның карасыннан бигрәк, җизнинең кименә әйләнде. Фалиянең чыннан да чибәр дә, булдыклы да булуын күреп, җизни аны жырчы, биюче кызлар башлыгы ясады. Ул хәзер еш кына мака сар исеменнән аны һәм кызларны үзе теләгән кешегә, үзе теләгән мәҗлескә алып бара. Әле дә ул, мака сарга әйтеп тормыйча, Фалияне Карман сака катына китертте. Мака сарга бүген биюче, жыручы кызлар кирәкми. Аннан соң, ул инде гомумән Фалия белән дә, башка биючеләр, жыручылар белән дә артык кызыксынмый иде. Ул элекке чибәр Фалияне онытып та бетергән иде бугай.

Жизнинең исә олуг каененесенә ничек тә бер яхшылык эшлисе килде. Карман сака боларның берсен дә белми. Чөнки аның былтыр көздән бирле Саркелдә булганы да, сарай гайбәтләрен ишеткәне дә юк.

Ачыккан алып ирләр, күзләрен дә күтәреп карамыйча, комсызланып ашаган-эчкән арада шаян чибәр кызлар әкрен генә жыр башлап җибәрделәр. Күмәк жыр тиз генә оешып китә алмады. Әле уңнан, әле сулдан берсе сузыбрак, икенчесе сузмыйчарак, берсе ачыграк, икенчесе тоныграк авазлар белән жырлаган тавышлар ишетелде. Шул ук вакытта, берсен-берсе узарга тырышкан сымак, җиз кыллы арфалар, көмеш кыллы гөсләләр чыңлап-гүләп алдылар. Чынлыкта бу әле жырлау-көйләү түгел, бу бары кылларны һәм тавыш җепселләрен сынап карау гына иде бугай.

Ниһаять, Фалия сака биргән итне ашап, артыннан бор суы эчеп куйды да, шундагы өстәл янынарак килеп сөлгегә кулын сөртте һәм тиз-тиз атлап янадан үзенең кызлары янына килде. Килешли ук ул көчле һәм ягымлы тавыш белән жыр сузып җибәрде. Аның тавышы барлык тавышларны күмеп китте. Башкалар аңа җайлашып, дәртләнебрәк жырларга тотындылар.

Мөгешләрдә, җиз савытларда утлар янган, терәкләр арасындагы, дивардагы ачыклыктан кичке талгын һава агылып торган иркен өй эчендә кызларның күмәк тавышы моңлы булып, сагышлы булып талгын гына агылып торды. Бер жырны бетергәч, алар икенче жыр башлап җибәрделәр. Монысы дәртлерәк, житезрәк көйле иде һәм алар монсын бирелебрәк башкардылар.

Ашаганда Карман сака жырчыларга бөтенләй диярлек игътибар итмәде. Тамагы туйгандай булгач ул ара-тирә аларның тавышларына колак салгалап алды, ара-тирә шулай ук күз ташлап та алды. Кызларның жыры, уены ана нишләптер тиз генә көйләнеп китә алмый сыман тоелды. Шул чакны ул, башын калкытып, Фалия ягына ымлады. Аның ымлавын, күз карашын кызлар шундук күреп алдылар, өстәлгә яңы беләнрәк торган Фалиягә нидер әйттеләр дә Фалия ялт кына өстәл ягына борылып карады һәм авызын зур ачып жырлавыннан туктамыйча сака янына килде.

—Син чакырдыңмы мине, сөеклем?—дип жырлады Фалия, кызыл читле ап-ак сөлге белән авыз читен сөртеп утырган Карман сакага иелеп.

Бу сүзләрне ул жыр көен бозмыйча, жыр сүзләре кебек итеп әйтте. Карман сакага каршы якта утырган яшь алып ашавыннан туктап, күзләрен зур ачып, сокланып Фалиягә карап тора иде. Аның шулай жырлап соравы аңа, күрәсең, бик кызык тоелды һәм ул тыела алмыйча көлеп жибәрде. Аның көлүен күреп Карман сака да елмаеп куйды. Барысы да күңелләнеп, елмаеша-көлешә башладылар. Фалия, кыюланып, күңеле күтәрелеп һәм шулай ук көлә-көлә нәфис кулы белән яшь алыпның дингез жиле кискән бакыр муеныннан кочып алды.

—Кызларыңның тавышы чыкмый,—диде Карман сака Фалиягә.—Чакыр монда, тамак ялгап алсыннар. Фалиягә шундый сүз генә кирәк тә иде. Тиз генә ул кызлары янына китеп барды, кулын күтәреп ул аларны табын янына чакырды. Кызлар чыр-чу килеп, көлешеп өстәл янына килделәр. Уен коралларын алар шунда утырган урыннарында калдырдылар, ләкин артсыз урындыкларны алырга туры килде. Кызлар, тартынып-нитеп тормыйча, кыю гына кыланып, кысылышып алыплар янына утырыштылар. Алыплар, аларга урын биреп, урыннарыннан кузгалдылар, өстәлдән читләшкәндәй иттеләр.

Кызларның барысы да диярлек утырышып беткәч, Фалия гадәтенчә кыю һәм әрсез кыланып, туп-туры Карман сака янына килеп утырмакчы булды. Ләкин Карман сака шул чакны башкалардан аерылыбрак калган, бер читтәрәк басып торган яшь кенә бер кызны күреп алды. Ул аңа чибәр һәм ягымлы тоелды. Мака сарның жыручы кызларын сака яхшы ук белә иде. Ләкин яшь кызны аның беренче күрүе иде.

—Син әнә Шөгәйгә бик ошадың,—диде ул Фалиягә, үзенең каршысындагы яшь алыпка күрсәтеп.

Фалия аңлап алды. Аның йөзе чак-чак кына үзгәреп китте, ләкин шулай да ул үзенең күңелсезләнүен күрсәтмәскә тырышты һәм унайсыз елмаеп, урындыгын Шөгәй янынарак күчерде. Карман сака исә оялган яшь кызны үзе янына чакырды.

Кыз тартынып кына аның янына килде, күрсәтелгән буш урынга утырды һәм ак нәфис кулларын күлмәк итәге аша йомрыланып калкып торган тезләренә куеп, башын иеп, тынып калды. Ул гына түгел, өстәл янындагылар барысы да тынып калдылар.

—Башыңны күтәребрәк утырсаң, син тагын да матурланып китәсең,—диде Карман сака, кызга елмаеп.

Аның шулай дип әйтүе булды, кыз ирексездән башын калкытты, елмаеп сакага карады, кызарынып китте һәм күрәсең үзенең уңайсызлануын яшерү өчен, кычкырып көлеп жибәрде. Көлгәндә аның ак, тигез тешләре матур булып елтырады һәм як-якка тырпаеп торган чәчләре селкенеп куйды. Аннан күрмәкче дигәндәй, башкалар да—кызлар да, алыплар да көләргә тотындылар. Бары Фалия генә үзенең тойгыларын яшерә алмады һәм бары аның гына кызылга буялган матур иреннәре йомык, нечкә кара кашлары кушылган килеш калды. Хәер, жизнидән башка аның йөзенә игътибар итүче дә булмады.

—Менә әйттемме!—диде Карман сака мактанган сыман, ләкин чынлыкта кызның чибәрлеген мактап.

Анның бу мактавына кызлар тагын көлешеп алдылар.

—Син минем кызларымны сүз белән генә сыйламакчы буласың ахрысы?—диде Фалия көлешү туктагач, Карман сакага карап, кыюланып.

—Шулай икән шул,—дигән булды Карман сака.—Кызлар, житешегез. Табында булганы—барысы да сезнеке!

—Безгә берни калмыймыни?!—диештеләр алыплар, көлешеп, шаяртып.

—Сезгәме? Сезгә табын да, кызлар да!—диде Карман сака.

Табын янындагылар янә гөр килеп көлешергә тотындылар.

Ул арада Карман сака үз алдындагы сырлап-бизәкләп ясалган озын аяклы алтын кәсәгә зур көмеш чүлмәктән бор суы агызды. Кызлар, үз алларындагы табакларга иелеп, ашый башладылар. Алыплар шулай ук ашауларын дәвам иттеләр. Үзенең кәсәсен тутыргач, сака жизнәсенә салды, аннары берәм-берәм башкаларның кәсәләренә кан төсендәге сыеклатылган бор-шәрәп койды. Башкалар ашаган арада шулай кәсәләрне тутырып чыккач, ул үз янындагы яшь, чибәр кызга иелгәндәй итте дә:

—Чибәрлегеннән күзем томаланып, сорарга да онытканмын—исемең кем синең?—диде. Кыз, уяу киек баласы кебек, ашавыннан туктап, тиз генә башын калкытты, әле һаман оялган, матур күз карашын сакага текәп:

—Талия,—диде.

—Нинди матур исем!—диде Карман сака чын күңелдән сокланып.—- Кем кызы?

—Кәмәчеләр бистәсеннән чүлмәкче Галләмнеке,—диде Талия.

—Галләм кызы!—диде Карман сака бераз гына гажәпләнү белән.—Атаклы Галләмнең шундый кызы бармыни?!

Ул моны үз алдына сөйләнгән сыман әйтте. Ләкин Талия, беркатлы буларак, анның һәр соравына жавап бирергә кирәк дип уйлап, үзе дә сизмәстән, «бар» диде. Тик шулай да бу мактану булып тоелмады. Карман сака уйланып калгандай булды. Ул хәтта Талиянең жавабын ишетмәде дә бугай. Чүлмәкче Галләмне Саркелдә белмәгән кеше юк иде. Чүлмәкче дип аталса да, аны бизәкче дип тә атарга була. Ул иң оста чүлмәкче дә, иң оста сурәтче дә. Үз чүлмәкләрен ул үзе бизи һәм анның төрле зурлыктагы, төрле рәвештәге чүлмәкләре бөтен Атлантитада иң яхшы, иң сыйфатлы исәпләнелә. Чит илләрдән килгән сатучылар анның кулы белән әвәләнгән, яндырылган һәм бизәлгән чүлмәкләрне аеруча яратып алалар. Аны шулай ук бик бай дип тә сөйлиләр. Ләкин шулай булса да ул әнә Саркелнең иң атаклы кешеләре яши торган Икенче божрада түгел, беренче божрада—кәмәчеләр бистәсендә яшәп ята.

—Чүлмәкче Галләм—данлы, атаклы,—диде Карман сака, үз алдына сөйләнгән сыман.—Шулай да нишләп әле булса ул кәмәчеләр бистәсендә яши соң? Мака сардан сораса, ул аны үзенә якынрак та күчерә алган булыр иде.

—Әтигә анда жайлы. Өйрәнгән жир, өйрәнгән урын,—диде Талия.

—Әниенә ничек?—диде Карман сака.

—Әнинең ничек тә күченәсе килә,—диде Талия—Мака сар ирек бирсә, ул бернигә карамый күченергә әзер.

—Күченергә... яңа урын, яңа йорт сатып алырга—шулайдыр ич?—диде сака.

—Шулай, диде Талия—әти тагын шуннан курка: йорт өчен бер түләргә, мака сарга тагын түләргә кирәк булачак, ди. Каян алырмын мин шул кадәр акчаны, ди.

—Ничек мака сарга түләргә? Йорт өчен түләгәч, житмимени?

—Мин белмим,—диде Талия.—Әти әйтә, мака сарга күп итеп алтын биререгә кирәк булачак, ди.

Карман сака тынып калды. Мака сар Карунның шулай төрле эш, йомыш өчен үз кешеләреннән—лелекләрдән дә алтын белән бирем алуы турында элегрәк тә ишеткәләгәне бар иде. Ләкин ул моңа ничектер ышанып җитми иде. Түрәдә әйтелгән: мака сар да, сакалар да үз кешеләренә яхшылык, изгелек эшләгән өчен бирем алмыйлар, диелгән. Мака сар белән сакалар арасында, Мака сар һәм сакалар белән лелекләр арасындагы һәртөрле алыш-биреш ике якның да килешүе буенча акчага эшләнелә, диелгән. Димәк болай булгач алтыннан күзе, акылы тонган мака сар үзе, вак-төяк сатучы, карак ялганчы кебек, бирем алучы булып чыга түгелме соң?! Моны болай калдырырга ярамый.

—Әниең өчен мин мака сардан сорасам, син нәрсә әйтерсең, Талия?—диде ул кызга иплә́п кенә.

—Әни бик сөенәчәк!—диде Талия, җанланып.—Ул мине шуның өчен мака сар сараена бирде дә.

—Җай чыгу белән берәрсенең колагына төшерерсең, дидеме?—диде сака.

—Шулай диде,—диде Талия беркатлылык белән.

Бор шәрәбе салынган зур корсаклы биек чүлмәк янда гына тора иде. Карман сака аш-су хуҗасы буларак, озын аяклы алтын кәсәләргә эчемлекне үзе салды. Барысының да кәсәсен тутыргач, ул иң элек, гадәтенчә, ут-анага өлеш чыгарды, үзе эчте, аннан соң башкалар да күтәрделәр. Ашагач-эчкәч, кызлар да, алыплар да шактый җанланып, кыюланып киттеләр. Баштагы тартыну, уңайсызлану кул белән алгандай юкка чыкты. Өстәл янында әле анда, әле монда тыелып кына көлгән, күршеләргә ишеттереп сөйләшкән өзек-өзек сүзләр ишетелеп китте.

Шулай күңелле генә гаплә́шеп утырганда, Фалия кинәт нидер исенә килеп, урыныннан сикереп торды, үзенең кызларына бер үткен күз карашы ташлап алды.

—Туарылдыгыз, болай булмый. Хәзер үк кузгалыгыз!—диде ул кызларны алыплардан читкә әйдәп. Фалиянең холкын яхшы белгән җырчы кызлар эчелеп бетмәгән эчемлекләре белән алтын кәсәләрен өстәлгә куйдылар, авыз читләрен сөрткәләп, озын күлмәк итәкләрен төзәткәләп, каршылыксыз урыннарыннан тордылар. Уен кораллары булганнар уен коралларын алдылар һәм теләр-теләмәс кенә үз урыннарына таба кузгалдылар.

Кызларның китеп баруын алыплар бик үк килештереп бетермәделәр.

—Утырыгыз әле!

—Шушында гына җырлагыз!—диган тавышлар ишетелде.

Фалиянең шулай тора салып кузгалып китүен Карман сака да аңлап җитә алмады. Хәер, ул аны аңлады да бугай, аңлаган нәрсәсенә ул ничектер игътибар итеп кенә җиткермәде ахрысы. Фалиянең, билгеле, ничек тә Талияне сакадан читкәрәк алып китәсе килде. Аныңча, сака янында, һичшиксез, ул утырырга тиеш иде. Ләкин аны читкә кактылар. Ничек итеп ул үзенең күз алдында аларның көлешеп-сөйләшеп утыруына юл куйсын!? Булмаганны! Изге сарайга башы керсә, аягы кермәгән, шулай да хәзердән үк сакалар тирәсенә елыша башлаган Талияне ул хәзер җаны-тәне белән дошман күрде.

—Болай күңеллерәк ич, кузгалмагыз,—диде Карман сака, үзенең алыпларын яклап. Фалия Карман сака сүзенә колак салмый булдыра алмады.

Бик тә ягымлы елмаеп ул сака янына кире килде, әлерәк кенә Талия утырган урындыкка утырды да, иркәләнеп һәм шул ук вакытта холыксыз бала-чага белән сөйләшкән сыман итеп:

—Син теләсән—кузгалмабыз,—диде.—Шулай да минем кызларыма күп эчәргә ярамый. Алар яхшы җырларга тиеш. Алыплар янында булганда алар яхшы җырлый алмыйлар.

—Ярар, жырлагыз,—диде сака Фалиянең ярым серле пышылдавына каршы килә алмыйча.

—Жырларбыз,—диде Фалия һәм кыюланып саканың сул як чигәсеннән үбеп алды, жинүче төс белән елмаеп, урыныннан сикереп торды һәм Карман сака аны-моны искәреп өлгергәнче, күлмәк итәкләрен жилфердәтеп, ислемай исләре таратып кызлары янына китеп барды.

—Мака сар белән дә... шулай микән бу Фалия?—диде Карман сака жизнәсенә, сул як чигәсен бармак битләре белән капшаштырып. Күрәсең, Фалиянең мондый кыланышларын күптән белгән жизнәсе, артык исе китмичә көлемсерәп тик утырды.

—Алай гына түгел—кайчагында аннан да яманрак кылана ул мака сар белән,—диде жизни.

—Ничек кылана?—диде Карман сака, аңламыйча.

—Була инде...—диде жизни ничектер турысын әйтергә теләмичә.

—Шулай да?—диде Карман сака, төпченеп.—Кеше алдында кыланамы, әллә үзләре генә калгачмы?

—Кеше алдында да, кеше артында да,—диде жизни, эчемлекле кәсәсенә тотынып.

—Элек яшьрәк чагында алай ук... оятсыз түгел иде бугай ул,—диде карман сака.

—Элек ул—болан кебек иде, хәзер—арыслан кебек,—диде жизни һәм көлемсерәп өстәп куйды.—Шома йонлы ана арыслан кебек...—диде.

—Мака сар күрәме соң анын шундый икәнлеген?—диде Карман сака аптырабрак.

—Син каладан ерактарак шул. Мондагы тормышны инде онытып бетергәнсен. Беләсең килсә, ул аны уч төбендә биетә!—диде жизни, тавышын әкренәйтә төшеп.

—Кем кемне уч төбендә биетә?!—диде Карман сака, эчүеннән туктап, шак катып.

—Шома йонлы ана арыслан карт ата арысланны,—диде жизни мыскыллы көлемсерәп.

Карман сака ышанмаганлыгын белдереп, коры гына көлеп куйды.

—Сез шуны күреп-белеп торасызмы?—диде ул.

—Күргәндә—күрмисен, белгәндә—белмисен,—диде жизни.—Син биш ел буе килми торган арада монда күп нәрсәләр булды. Син монда һаман элеккечә икән дип уйлый күрмә. Теге яшь кызны үз янына утыртып... ялгыштын син, кайныш.

—Нәрсә сөйлисен? Булмаганны!—диде Карман сака чак кына үртәлеп.—Фалиядән куркырга димисендер ич?

—Сина аннан куркуның кирәге юк. Шулай да Фалия кызыйны харап итәргә мөмкин.

—Бармак белән чиртеп кенә карасын!—диде кинәт Карман сака, үз алдына ярсып, кызарынып.

—Ул ана, бәлки, бармак белән дә чиртмәс, шулай да син аны үз янында утыртма.

—Кемне?

—Талияне,—диде жизни.

Карман сака кычкырып көлеп жибәрде.

—Әллә нинди куркакка әйләнеп беткәнсез сез монда... биек коймалар, алтын сарайлар эчендә ятып,—диде ул жинелчә шелтә белән. Шуннан соң ул кәсәсен кулына алды да, жизнәсен кыстап:—Әйдәле, эчик булмаса, жизни,—диде.

Ачык тәрәзә яныннан кызларның дәртле, жинел көйгә жырлаулары

ишетелә башлады. Барысының да тавышын күмеп Фалиянең көчле, хисле һәм моңлы тавышы ишетелеп торды. Шәп җырлый иде Фалия! Мондый тавышлы хатын-кыз алдында баш имәү, ана табынмау мөмкин түгел. Әлерәк кенә аны кыерсытуына, аны читкә тибәрүенә һәм аның турында яратмыйча сөйләвенә Карман сакага чак-чак кына унайсыз булып китте. Ул үзенең ялгышуын аңлагандай булды. Фалиянеке кебек тавыш өчен, моң һәм хис өчен ир булган ир кеше дөньяда эшләп булмастайны да эшли алырга тиеш.

Тәрәзәдән кергән җиләс, талгын һава кебек, Фалиянең тигез агышлы тавышы өй эчен тутырып талгын гына тирбәнде дә, кинәт тынып калды. Карман сака белән Җизни генә түгел, өстәл янындагы барлык яшь алыплар Фалиянең җырлавына сихерләнеп, тынып калганнар һәм барысы да җырчылар ягына борылганнар иде. Җыр туктау белән өй эчендә шактый вакыт тынлык сакланды. Кинәт барысы да берьюлы диярлек хәрәкәткә килде, барысы да шатланып эчке хисләрен белдереп шауларга, мактау сүзләре кычкырырга һәм кул чабарга тотындылар.

—Фалия! Яшә, Фалия!—дип кычкырдылар сихерләнгән яшь ирләр-алыплар.

—Менә, күрдеңме?!—диде Җизни, җиңүче төс белән елмаеп.

—Күрмәдем—ишеттем,—диде Карман сака, караңгы чырай белән.

Моннан өч йөз мең утыз биш ел элек тә хәзергечә, көндәгечә кояш чыкты. Таң атып, караңгы таралгач та таулар, урманнар, үзәннәр аерымачык булып күренә башлагач та, көнчыгыш якта—күк кырыенда иң элек үзеннән-үзе яктылык барлыкка килде. Таулар, урманнар, ялгыз агачлар һәм таш йортлар әле булса йокыдан арына алмагандай, тын гына оеп утырганда, үзәннәр өстендәге аксыл томан әле булса тарала алмый торганда һәм иксез-чиксез диңгез өсте кара кучкылланып, хәрәкәтсез җәелеп ятканда бары тик ерактагы тере нурның гына зурайганнан-зурая баруы үзе бер могҗиза иде.

Көмештәй якты нурга озакламый саргылт, кызгылт буяулар кушылды. Бер үк төсле соргылт, караңгы төсләр белән генә бизәлгән иртәнге манзара күз алдында үзгәрә башлады. Менә, ниһаять, диңгез сызыгы өстендә, ерактагы болыт шәүләләре арасыннан эрегән алтынсыман булып, балкып, сихри нурлар бөркелеп чыкты. Алтын нурлар искиткеч бер житезлек һәм кодрәт белән киң диңгез аша сузылды да, Изгеләр утравындагы Изге калкулыкка иң элек мака сарның таудай биек итеп салынган сарай түбәсенә—андагы алтын гөмбәзгә килеп бәрелде. Алтынга алтын тиеп, тирә якка тере, якты нур тамчылары чәчрәде. Күп тә үтмәде, Изге калкулыкның изгеләр яшәгән әле бер төшендә, әле икенче төшендә түбәләрдә, тәрәзәләрдә, биек коймаларда шатланып кояш нуры биеде.

Шулай итеп, Изгеләр атавында яңа көн туды. Яңа көн тууын белдереп, биек коймаларның әле бер төшендә, әле икенче төшендә җиз быргылар уйнады, бер-берсен узышып әтәчләр кычкырды, әрәмәдә төн кунган изге Бука үкерде һәм агач башларында, өй кыекларында күк күгәрченнәр гөрләште.

Яңа көн туу белән, Саркелдә һәм изгеләр каласының барлык бистәләрендә кешеләр йокылы күзләрен ачтылар, аякларына бастылар һәм иң беренче эшләре итеп, бөек Ланы күрергә ашыктылар. Көнчыгыш якта, диңгез астыннан калкып килүче тереклек иясенә күзләре төшү белән, изге абаны котлап, кулларын күтәрделәр, кычкырып, пышылдап йә булмаса ялынып-ялварып аңа үзләренең теләкләрен юлладылар.

Карман сака соң ятса да, Саркелдәге, каладагы башкалар кебек вакытында торды. Башкалар кебек иң элек көнчыгыш яктагы тәрәзәгә юнәлде. Тәрәзә аша якты кояш нурын күреп, көндәгечә кулларын күтәрде һәм теле чыгу белән өйрәнелгән дога сүзләрен пышылдады. Бүтән вакытта, бигрәк тә үзенә кыен, күңелсез булганда яисә берәр куркыныч янаганда ул әлеге сүзләрне, асыл мәгънәсенә төшәргә омтылып, ничек тә ихлас күңелдән әйтергә тырыша.

Бүген ул уйламыйча, борчылмыйча гына әйтте. Әйтергә кирәк булган өчен генә, әйтмичә калырга ярамаган өчен генә әйтте. Башка көннәрдәге кебек ул бүген кояшның югарыга күтәрелә баруына да, күктәге, дингездәге төсләрнең үзгәрә баруына да исе китеп, сокланып карап тормады. Күз карашын ул шундук тирә-якка, кала өстенә юнәлтте. Алтын түбәләр, алтын коймалар, изге сыннар, биек таш йортлар һәм шул таш йортлар арасындагы купшы куаклар, биек агачлар, серле куләгәләр, бер-берсе белән кисешкән тар урамнар, сукмаклар—барысы да аңа күптән таныш, ләкин шул ук вакытта бераз гына ят һәм тансык иде. Бала вакыты аның шушы өйдә, шушы түбәләр, куаклар, сукмаклар белән бергә үтте. Кайчандыр моннан күп еллар элек тә ул менә шулай, тәрәзә төбенә таянып, еракларга карап торды, иртәнге саф, салкынча һаваны сулады, әтәчләр, тавыклар тавышына, бука үкерүенә һәм сыерлар мөңгерәвенә колак салды. Кайчандыр, моннан күп еллар элек тә, менә шулай тулысынча йокыдан уянып җитмәгән килеш карап, тыңлап, сулап торганда берәрсенең куаклар арасында кыштыр-кыштыр китереп сукмак себергәне, йә булмаса берәрсенең иңбашына авыр чүлмәк күтәреп, каядыр китеп барганы күренде, еракта манара башларында сузып-сузып җиз быргы кычкыртканы ишетелеп торды. Аста куаклар, агачлар арасында кычкырып кемнәрдер сөйләште, югарыда, түбәдә, тәрәзә кашагаларында күгәрченнәр гөрләште.

Барысы да таныш, барысы да якын. Әйтерсең, дөнья да үзгәрмәгән, ел артыннан еллар үтеп, вакыт та үзгәрмәгән. Хәер, өстән караганда гына шулай бугай ул, үзгәрешне, яңалыкны күрергә-белергә теләмәгән өчен генә шулай бугай. Кояш чыгуы да, иртәнге тынлык, салкынлык та, алтын түбәләр юллар-сукмаклар да, билгеле, һаман да әүвәлгечә. Ләкин инде аның—Карман саканың хисләре-тойгылары һәм теләк-омтылышлары инде күптән әүвәлгечә түгел. Элек ул, малай чагында, менә шулай тәрәзәдән карап торганда да, бөек Лидан бигрәк янадан кире җылы урынга барып яту турында, рәхәтләнеп янадан бер йоклап алу турында хыяллана иде. Кайчагында аңа бу һич тә тормышка ашмастай хыял булып тоела торган иде. Аннан соң ул әнисе турында, әнисенең җылы куенына кереп, бөгәрләнеп янә дә йоклап алу турында уйлый иде.Үсә төшкәч, кәмәгә утырып, диңгез аша чыгып һичшиксез кояшның диңгез астыннан чыгып килгән чагын якыннанрак карау турында хыяллана иде. Ничек чыга ул? Каян чыга? Бит ул шундый җылы, кайнар—диңгез суы нишләп кайнамый икән дә, нишләп бу булып күккә күтәрелми икән? Бу турыда аның әнисеннән дә, башка өлкәннәрдән дә сорап караганы булды, ләкин беркем аңа тиешенчә аңлата алмады. Әллә аңлатырга теләмәделәр микән? Өлкәннәр бит алар күп нәрсәне балаларга әйтмәскә тырышалар. Ләкин аның беләсе килде, барысын да үз күзләре белән күрәсе килде.

Ул инде күрде, бик күп нәрсәне үз күзләре белән күрде. Дөньяның читенә, кояш чыккан төшкә үк барып җитә алмаса да шулай да җирнең, суның әллә нинди төбәкләренә барып чыкты. Менә ул янадан монда, туган каласында, дөньяда иң якын, иң изге җирдә. Ул җинеп кайтты, бик күп байлык, мал, кара алып кайтты. Агасы сөенәчәк, сөенми мөмкин түгел. Бүген дә, моннан соң да бөтен Атлантита иләндә ул—иң зур җинүче. Бүген аның иң бәхетле көне.

*Дәвамы киләсе саннарда*



Мансур
Шиһапов

# ДӨНЬЯ КЫРЫНДАГЫ ЮЛЛАРДА МИН...

## Ирексез

**Миңа әйтми генә—тудырдылар,
Көчләп биләделәр—биләүгә.
Моңа каршы акырып еласам да,
Гаҗәпләнмәде һич берәү дә...**

**Селкүләрне җенем сөймәсә дә,
Салып селкеделәр бишеккә.
Әрләп үстерделәр... Күрсәттеләр
Дөнья карап торган ишеккә.**

**«Укырга!»—дип фәрман яңгырады.
Укыттылар. Ансы ярыйсы...
Эх, шулкадәр килгән иде минем
Авылымда атлар карыйсы.**

**Ни дисәң дә, зәңгәр болыннарда
Син бәйсез бит! Җилләр иркендә.
Рәхәтләнеп атлар утлап йөри,
Хыялыңны сүтми беркем дә...**

**Әмма юкка! Тагын әмер булды:
«Белемеңне эстә калада!»
Нәрсә кала тумышыннан алып
Һаман гел хокуксыз балага?**

**Ачлы-туклы укыдым. Тик берсе дә
Җылы ярдәм кулы сузмады.
Аннан хезмәт... Гомерем буе язмыш
Фәрманнардан аерып тормады.**

Мансур ШИҺАПОВ (1940)—*шагыйрь; «Туй күлмәге», «Җырлыйсы җырларым бар иде», «Энекәш» һ.б. китаплар, күп популяр җырлар авторы. Казанда яши.*

Күрсәтмәләр биреп килде фирка,
Өстәл сукты түрә булганы....
Һәм бүген дә шулай! Сорау телә:
Мин үземә үзем хуҗамы?!

Табигатьтә бар тереклек азат,
Бәйсез хәтта анда үләне.
Адәм баласы да—табигатьтән,
Ник хокуксыз кеше дигәнең?!

...Дус җилләрем чакыра туган якка,
Колагымда атлар тавышы.
Ирекне бер татып карау өчен
Болыннарга кайтып барышым.

***

*(Тагын катнаш никах турында)*

Мәхәббәттә хәзер талымсызлык,
Тану кая арзан-бозыгын:
Уйнак күңелләрнең азгынлыгы
Сикереп чыга сөю сызыгын.

Гасырлардан милли йолаларын
Саклап килгән татар халкының
Йөзен көйдерә бүген ялган хисле
Катнаш никахларның ялкыны.

Рәшә төсле әкрен генә эри
Олы яратуның кыйммәте.
Төрле каннан туган кавемнәрнең
Юк чын горурлыгы, милләте.

Азмы бездә Әкрәм Ивановлар,
Хәбибуллин Егор, Борислар?
Ике дөнья арасында калган
Киләчәккә туган варислар...

Шунысы гаҗәп, сөюләрдә азган
Үзен тота шундый гөнаһсыз.
Ә артыннан «йөрәк җимеш»е килә:
Күбесе—телсез, денсез, имансыз...

## Бәлки

Кешелекле һәрбер гамәлләргә
Аяк чала кайбер мәгънәсез.
Юк, бу тормыш була алмас ахры
Мәгънәсез һәм мәнсез адәмсез.

Ә шулай да тормыш кысасында
Андый затлар алар сирәктер...
...Бәлки,
Кемнең кем икәнен белү өчен,
Шундый сиргә дә кирәктер?

## Тормыш җавап эзләтә

Кыйммәт тудырып килгән күңелебез
Тирәнрәк безнең диңгездән.
Анын тирәнлеге Илгә кирәк,
Ләкин...
Кирәклеген сорый кем бездән?

Йөрәкләрдә ирек давыллары
Көчле иде янар таулардан.
Үз вактында форсат ычкындыр да,
Табасың ди аны кайлардан?

Кан тамырың шартлап ярылганда,
Табиб ярдәм итә, ичмаса.
Илдә халык җаны сызлаганда,
Ачы сызлауларын кем баса?..

Бу тормышның салкын күкрәгендә
Шактый шундый сорау туа да;
Җавапларын табу өчен, бәлки,
Китә кеше теге дөньяга?!

♣



Гөлзадә
Бәйрәмова

# КӨЗЛӘРГӘ КЕРЕП БАРЫШ...

## Кыш—2006

*Бу заман сатылу заманы:*
*Сатыла һәм сата ханнары.*
*Шуңамы сыкрый Жир-Ана?*
*Декабрь яңгырга коена.*

Гаҗәпмени, иялэнелгән
Карына, буранына.
Чыгасы килми гыйнварның
Бурансыз урамына.

Каршы искән җилләрне дә
Тансыклый икән күңел.
Кабартылган кар бабайлар
Ул инде бабай түгел...

Борыннан «куык» чыгарып
Ясамагач аларны,
Кыш бабайның килеренә
Ышандыр балаларны!

Ясалма карлар китертә
Яңа заман байлары,
Кабул итәрме Җир-ана
Ясалма балаларны?!

## Таныш түгел берәүгә

Бу—ни соң, языкмы,
Күзеңә карасам?
Күңелең түрендә
Яктылык табалсам?
Җаныңның җылысын

Аз гына тоялсам...
Кайчакта өшимен,
Салкыннан күшегәм.
Кагылган-сугылган,
Бер дәрвиш кешедәй...

***

Кояшның да үз холкы:
«Чыгаргамы соң, юкмы?»
Уйлагач әллә ничә,
Көйләнде киресенчә.

Кемгә бүген—эссерәк,
Кемгәдер—җиләсерәк,
Кемгә кирәк—салкынча...
Түзимме азаккача?

Төшкә кадәр уйлангач,
Түбән карап моңайгач,
Җәлләде сабыйларны,
Гөнаһсыз наныйларны.

«Эт кояшы» исемен дә
Күтәрүе рәхәтме—
Гомер буе балкыткач
Алтынланган тәхетне!

Гөлзадә БӘЙРӘМОВА—*шагыйрә; «Әле кайчан гына» исемле китап авторы. Казанда яши.*

## Күбәләк

*Кулымда кипкән күбәләк—*
*Көндәлек дәфтәремнән...*
*И бу күңел! Ник ашкынган,*
*Шатлык, дип—хәсрәтенә?!.*

Җәй башында ак күбәләк—
Юраулары юш килсен,
Җәйләр матур уза, диләр,
Әгәр дә аны күрсәң...

Сарысы, имеш, сагышка
(Син күрмәмешкә салыш)...
Җәйләрдә сарыга сабышып,
Көзләргә кереп барыш...

## Кабатлану

Уйнадылар... рольләрне
Тагын бер кат яңартып.
Кул чапмады тамашачы,
Һәм калмады шаккатып.

***

Кайчак уйлыйм: нигә шулай,
Беркатлы син, и бәндәм!—
Язмышың бит билгеләнгән,
Йөри бары күләгәң.

## Үкенү

Бушандым. Ачылдым. Ышандым.
Дөньяга чәчелде серләрем.
Берәүләр—хөсетле көлделәр,
Гыйбрәтләр эзләде берләре
Ачынып сөйләгән сүзләрдән...

## Безнең әкият

Ул әкиятне, әйе, без тудырдык,
Үзебез дә ышандык дөреслегенә...
«Чит-ятларга керү тыела»,—дип,
Ник язмадык икән өслегенә?!

## Аңладым

Нигә акыл соңлап килә икән,
Күп нәрсәне соңлап аңладым.
«Бер мин генә ялгышмаган»,—диеп
Үз-үземне күпме алдадым.

Бәхәсләрдә һәрчак ярсый-ярсый,
Ачмак булдым йөзен ялганның.
Бөкерене кем соң турайталсын!
Еллар узгач кына аңладым.

Дусларнымы, әллә үз-үземне
Аңламыйча күпме «каралдым».
Каралтканнар агартмыйлар икән,
Еллар узгач кына аңладым.

## Ниләр диеп...

*«Начар төш күрсәгез*
*суга сөйләгез».*
Халыктан

Фал китабы. Төшләр юрыйм,
Төшләремдә кат-кат урыйм:
Инеш буе, калкулыклар,
Иксез-чиксез киң сулыклар...

Син киләсең миңа таба,
Сикерә-атлый түмгәкләргә,
Ә түмгәкләр бата-калка...—
Арада су җәйрәп ята.

Ә мин һаман чигәм артка,
Аякларым читкә тарта.

Кул сузымы ул аралар,
Ерагая никтер алар...

Сөйләргәме соң суларга,
Ниләр диеп, әй, юрарга?
Актарылды бөтен җаным,
Бу хисләнү нигә тагын!

Әллә минем күз яшеннән
Ул сулыклар яралганмы?
Тозлы суның тозлы җиле
Ачыттырды яраларны...

## Әни

Мин әнигә—бүген әни:
Кулларыма—авыру анам,
Хәлсезләнеп, башын салган.
Йә, Раббым, ничек яман:
Гомер биргән, яшәү биргән,
Сүнеп бара газиз Анам!

И Җир-Ана!
Мин бер балаң!
Инде мин дә ятим калам?!
(Гәрчә үзем—күптән ана.)
Әкияттәге үги кызлар,
үги уллар
Таныш миңа борынгыдан...

Бер киләчәк ул көн, беләм,
Юк кирәкми, бүген түгел,
Мин ялварам:
«Алып китмә, газиз Аллам!»

Күз алдымда—узган гомер:
Ни кылдым һәм ни кылалам—
Анам кадәр?
Бурычымны кайтарырлык
Бармы арам?
(Ни аяныч!
Соң минутта соңга калып уйланыла!)

Һәр ел саен туган көндә
Бер үк сорау кабатлана:
«Ничә яшең тула, балам?»
«Синекенең нәкъ яртысы:
Синең арттан, әни, барам...»

...Хәлсезләнеп, авыру анам
Кулларыма башын салган...

## Гаепләүчеләргә

Булсын. Тимә.
Ул—минем тормыш.
Анда бар төсләрнең,
Агы да, карасы да.
Сүтелеп киткән җиреннән,
Бар әле ямыйсы да!

Ул миңа шундый кадерле
Алыштыргысыз якын.

Анда самими яшьлегем,
Һәм беркатлы ярату.

Булсын! Тимә!
Гаепләмә!
Син бит хөкемдар түгел.
Җавабын үзем бирермен,
Вакыты җитәр беркөн.



Илдус
Диндаров

# КӨЗГЕ КҮКРӘҮ

## Хатирәләр

**Берәүләрнең, балык тәңкәседәй,**
**Медальләре түшкә эленгән—**
**Юбилейлар саен өстәделәр...**
**Хак-нахагын инде кем белгән?!.**

**Бер абзыйның фәкать бер медале—**
**«За отвагу» дигән медаль ул.**
**Һәм сугышның иң чын хатирәсе—**
**Сыңар аяк һәм дә сыңар кул...**

***

**Тәпи-тәпи китте тәти чагым,**
**Чаптырып ла качты балачак.**
**Яшен кебек яшьнәп үтте яшьлек.—**
**Фанилыктаниләр калачак?**

**Барсы уза. Тәкъдиребез шундый.**
**Мин тормышны болай күзаллыйм:**
**Бик тиз үтә гомер фасыллары...**
**Картлык исә... Юк, ул узалмый.**
**Күңел, юкса, һаман уктала...**
**Тик картлыкта барысы туктала...**

***

**Кара көзгә керде җиһан**
**Боегып, тәмам оеп.**
**Тынгы белмәс күңел генә**
**Җилкенә нидер тоеп.**

**Көтмәгәндә күк күкрәде**
**Кайдадыр тонык кына;**
**Яшене дә күренмәде,**
**Югалды тынып кына...**

Илдус ДИНДАРОВ (1949) — *журналист; шигырьләре һәм хикәяләре журналларда, көндәлек матбугатта басылып килә. Нурлатта яши.*

Кинэт уянган хислэр дэ
Нэрсэдер даулый шулай.
Гомер көзенэ кергэндэ
Бэхиллэшү шул бугай...

Алданып сөю кабынгач,
Килми лэ картаясы!
Бу көзге күкрэү—яшьлекнең
Булдымы кайтавазы?
Йэ булдымы—мэхэббэтнең
Саташып килгэн язы?!.

## Шомлы манзара

Шэжэрэсе нинди классикның!
Урманмыни нэсел агачы.
Бер тармакны башлый шагыйрь үзе,
Ботак саен—бала-чагасы.

Исемнэре гүзэл. Борынгылар!
Асылбикэ, Гали, Имамнар...
...Безнең чорга күтэрелгэн саен
Китте аннан—Зоя, Иваннар.

Ябалдашның корып кибүе бу,
Күперсэ дэ һаман як-якка!
Охшап бара агач—моңы бетеп,
Сандугачы качкан куакка...

Өскэ таба үскэн тармакларга
Нинди исемнэрне язарга?
... Бу—шэжэрэ-агач түгел инде,
Бу—сөрэйгэн шомлы манзара...

* * *

Төн тэрэзгэ зэңгэр пэрдэ элде:
Э бүлмэдэ бары икэү без.
Боек күзлэребез гел тэрэздэ,
Эйтерсең лэ нидер көтэбез.
Тын бүлмэдэ һаман икэү без.

Тэрэз төбендэге шау гөллэрне
Ай аралап керде, хислэнеп;
Сүрэн йөзебезне капшады да
Читкэ алды нурын, сискэнеп.
Искэртепме бэхиллэшер чакны,
Сэгать сукты кинэт: дан да дан!
Сөю китте... Инде ай да сүнде...
Бу—ялгызлык! Шуны аңладым..

## Кем ул—канатлы татар?

*Дөнья күләмендә танылган атаклы биюче, төрле кысымнарга түзә алмыйча КГБ тырнагыннан качып котылган, СССРны, Казан һәм Уфа шәһәрләрен, туганнарын сагына-сагына Франциядә, аннары Англиядә озак еллар яшәгән мәшһүр татарыбыз Рудольф Нуриев турында, аның сикәлтәле язмышы хакында без никадәр беләбез икән?*

*Һәрхәлдә, чама белән генә.*

*Рудольф Нуриевның тормыш һәм иҗат юлын җентекләп өйрәнгәннән соң Равил Вәлиев аның турында «Канатлы татар» дигән күләмле роман тәмамлады. Киләсе ел башында без романның журнал вариантын тәкъдим итәргә җыенабыз.*

*Ә хәзергә, әйдәгез, әсәрдән бер өзек белән таныша торыйк.*

...Мәртәбәле кунаклар Ак йортка килеп җиттеләр, барып керделәр АКШ президентының «оваль кабинет» дип аталган атаклы бүлмәсенә, син күр дә мин күр дигәндәй, утырдылар тирән эчле йомшак-затлы кәнәфиләргә!

Дөрес, бу минутларда Джон Кеннеди бүлмәдә үзе юк иде. Шунда ук Жаклин Кеннеди, ирен чакырып керергә дип, каядыр чыгып китте. Алар, балет сәхнәсе кебек киң-иркен һәм ат ятып аунарлык өстәлле зур бүлмәдә өчәү генә калдылар.

АКШ президентының затлы күн белән тышланган кәнәфие буш иде.

Шулчак шаккатыргыч бер хәл булып алды!

СССРдагы тышаулы язмышыннан бөтен тезген-дилбегәләрен өзеп кача алган татар биючесе Рудольф Нуриевның һич уйламаганда көтелмәгән адымнар ясау сәләте монарчы да күпләргә һәм күптәннән мәгълүм иде. Бу юлы да нәкъ шулай булды. Джон Кеннеди үз бүлмәсендә юклыктан файдаланып, нигә әле аның серле-ымсындыргыч һәм үтә дә биек кәнәфиенә утырып карамаска?! Бар җиһанны дер калтыратып торган АКШ президенты кәнәфие бит ул! Рудольф Нуриев кебек бер татарга мондый мөмкинлек тагын кайчан эләгәчәк? Ычкындырма сирәк очрый торган алтын мизгелне, егетем!

Һәм, дөрестән дә, тагын бер мизгелдән ул АКШ президенты кәнәфиендә утыра иде инде. Килеп утырган шәпкә, бу гаҗәеп хәлгә үзе дә ышанып бетәсе килмичә, башта әлеге кәнәфидә тегеләй дә болай әйләнгәләп карады. Шәп әйләнә президент кәнәфие! Аннары, телефон трубкаларын алып тормыйча гына, тегенди дә мондый затлы тугралар ясалган ул хәтәр аппаратларны куллары белән капшап-капшап куйды. Их, менә шушы кәнәфидән торып кына СССРда калган газиз анаң яки апаларыңа чылтырата алсаң икән ул! Юк, монысы инде—бөтенләй буй җитмәслек хыял!

Ул аңына килеп өлгергән арада менә ишектә Жаклин Кеннеди һәм аның ире үзе күренде. Аларны күргәч, май урлап ашаганда тотылган мәчедәй, Рудольф тирән эчле кәнәфигә сеңде. Ләкин тиктормас малайлар шуклыгы белән ясалган хатаны төзәтергә соң иде инде.

АКШ президенты кәнәфиендә—татар баласы!

## Җаһит Зарифоглу

(1940—1987)

*Төркиянең Каһраманмараш шәһәреннән булган Зарифоглу Истанбул университетының алман теле һәм әдәбияты факультетын тәмамлый. Күпмедер бер вакыт башлангыч мәктәп укытучысы һәм алман теле укытучысы булып мәктәпләрдә эшли. 1976 елдан башлап ТРТда (Төркия радио-телевидениесе) тәрҗемәче сәркәтип вазифасын башкара. Төрле гәҗит-журналларда эсселары басыла. Иптәшләре белән «Мавера» исемле журнал нәшер итә. «Заман» газетасында һәм «Мавера» журналында «Укучылар белән» исемле язмалары халык күңелендә бик зур яңгыраш таба. Шулай ук мәктәп ролен башкаручы әңгәмә почмаклары да оештыра.*

*1983 елда ТРТның Истанбул радиосында эшли башлый. Шунда радио уеннары яза. 1984 елда Төркия язучылар берлегенең балалар әдәбияты бүләге лауреаты була.*

*Зарифоглуның шигырьләре төрек әдәбиятында үзенчәлекле урын били. Әдип үзе заманча төрек шигъриятенең иң күренекле вәкилләреннән. Хикәя, көнлек (истәлек-хатирәләр), роман, эсселәр язу белән бергә, 1980 еллар башында балалар өчен дә яза башлый. Һәр яшьтәге кешеләргә атап язган балалар турындагы китаплары зур яңгыраш таба. Менә бу яктан да төрек балалар әдәбиятының классик әсәрләре арасында аның китаплары мөһим урын алып тора. «Йөрәк бабай белән падишаһ»—шуларның берсе. Зарифоглу коры үгет-нәсихәтсез тәрбияли, акыл сатмыйча гына искиткеч рәвештә белем бирә. Аның язганнары яшәешенә тәңгәл килә.*

*Балалар турында язган әсәрләрендә каһарманнарының күпчелеген хайваннар тәшкил итә, алар һәммәсе дә кеше кебек уйлый. Без аларны укыганда чыпчык, тукран, арыслан, төлке, карлыгачның кешеләр кебек сөйләшкәнен тиз генә аңлап алабыз. Бу язу стиле белән Зарифоглу төрек балалар әдәбиятында яңа сукмак яра.*

*1987 елның 7 июнендә фани дөньядан мәңгелек галәмгә күчеп киткән Җаһит Зарифоглу безгә иман һәм мәрхәмәт тулы олы йөрәгеннән ургылып чыккан әсәрләрен ядкәр итеп калдырды.*

# ЙӨРӘК БАБАЙ БЕЛӘН ПАДИШАҺ

Борын-борын заманда, күп тә түгел, аз да түгел, бары берничә гасыр элек бер авылда карт белән карчык яшәгән.

Авыл халкы әйтмешли, бу авыл «сәһил» җирдә урнашкан. Ягъни кыш көннәрендә өйләргә суык бураннар, салкыннар керми икән. Кышын яхшы гына булса да, җәен бу якларда яшәп булмый ди. Тын алгысыз, чиктән ашкан дымлы һавасында көч-хәл белән генә сулыш аласың. Ярар, болары калып торсын, тирә-якта һәрнәрсә саргаеп сула, терлекләргә ашарлык үлән дә калмый икән. Менә шунлыктан, тирә-як авыл халкы кышын авылга кайта, ә җәен авылларын ташлап җәйләүләргә чыгып китә икән.

Шушы авылда «Йөрәк Хәсән» исемле яшь егет яшәгән. Авылда шулай

эндәшкәннәрме, әллә армиядән алып кайтканмы? Билгесез. Еллар үтү белән, бу турыда кызыксынучы да булмаган.

Йөрәк Хәсән һәм аның яшь хатыны җәен җәйләүгә, кышын авылга кайтып яшәгәннәр һәм авылның нык тамырлы кешеләре булганнар.

Яшьләре егермегә, утызга, кырыкка, иллегә, алтмышка, житмешкә, ниһаять, сиксәнгә җиткән.

Гел бер төрле тормыш. Гел бер үк күченүләр. Ләкин күңелләрендә берниндн ялыгу, дөньяга карашларында берниндн үзгәреш булмаган. Бары яхшы күңелле булып калганнар. Йөрәк Хәсән Йөрәк Хәсән булып калган. Хатыны исә һәрвакыт яп-яшь килен кебек. Йөрәк Хәсәннең Гайшәсе... Бу вакытларда алар сиксәненче яшьләренең язына керәләр.

Җәйләүнең исе авылга тарала башлаган, бу елны җәйләүгә беренче тапкыр китәсе сабыйларның башлары да ул якка таба борылган.

Сарык, эт, кәҗә һәм дөяләрдә сизелерлек үзгәреш күзәтелә. Килен сөт тулы чиләген кулыннан төшереп җибәрә. Бала абынып егыла. Ата кычкыра. Ана борчыла.

Бер көнне иртә белән беренче төркем юлга чыга. Аларга баш булып авылның иң кешелекле, чын мөселманмы мөселман кешесе бара...

Йөрәк Хәсән белән хатыны Гайшә әби икенче төркемгә калалар. Гайшә әбинең тыны кысыла. Йә бу төркем белән, йә башка төркем белән кузгалырбыз дигәндә, бөтен авыл күченеп тә бетә. Йөрәк Хәсән белән хатыны Гайшә әби авылда гына кала.

Шул сәбәпле башта Йөрәк Хәсән, аннан Гайшә әби авырып китә. Язмышлары шулай булгач, күчәргә насыйп булмаган, димәк.

Бер көнне икесе дә сәламәтләнеп, аякка басканнар.

—Хатын, ни диярсең, иртәгә юлга чыгабызмы?—дип сораган Йөрәк Хәсән.

—Иркәем,—ди Гайшә әби—син ничек кушсаң, ничек кулай күрсәң, минем өчен иң яхшысы шул булыр.

—Солтаным, бу нинди сүз? Син ни теләсәң, минем теләгем дә шул булыр.

—Рәхмәт төшкере, иркәем әфәндем. Миндә нинди башка теләк булсын инде. Мин сиңа иярәм, син ни дисәң шул булыр.

Нинди генә эшкә бергә тотынырга уйласалар да, өйләнешкәнгә 65 ел вакыт булса да, бер-берсенең күңелен күрү өчен һәрвакыт шул рәвешле сөйләшеп, эшлисе эшләрен дә онытканнар. Менә бүген дә, җәйләүгә бару турында сөйләшүләре дә исләреннән чыккан. Бер-берсенә тәмле сүзләр сөйләп, иркәләнеп, назландылар. Икенче көнне:

—Сөекле хатыным, ни диярсең, көннәр шундый җылынды. Бөркүлек безне харап итәчәк бит, юлга чыгыйкмы әллә?

—Иркәем,—диде янә Гайшә әби—син нәрсә дисәң, шул булыр.

—Һымммм,—диде Йөрәк Хәсән.—Бүген әзерләнеп бетәрбез, иншалла. Иртәгә иртәнге намаздан соң юлга чыгарбыз.

—Бик яхшы булыр иде,—диде хатыны Гайшә.

Шулай итеп, бер бүлмәле өйләрендә тагын бер кич кундылар. Әйбәт кенә йокладылар. Йөрәк Хәсән уяну белән пышылдап кына:

—Хатын,—диде.

Әби шунда ук ишетеп, лә илаһә иллаллаһ, дип, яткан җиреннән торды. Тиз генә коедан су алып, аны комганга салды. Ләгән китерде. Хәсән бабай җиннәрен сызганды. Әби изге бер эш эшләгән сыман әкрен генә, Хәсән бабайның кулына комганнан су агызды. Аякларын юарга чират житкәч, Хәсән бабай комганны алып, аякларын үзе юды. Тураеп басуга, кулына сөлге тотып карчыгы килеп җитте. Йөрәк Хәсән ике кулын алга сузды. Әби исә, сөлгене җәеп, ана бирде. Йөрәк Хәсән сөлгене алып, хатынына изге теләк теләде:

—Хатын, Аллаһ синнән риза булсын! Тоткан әйберләренне алтын итсен! Хәерле итсен! Сиңа теге дөньяда яхшы гамәлләрне генә юлдаш әйләсен! Алсу битле җан юлдашым!

—Ярый әле дөньяда син бар, Аллаһ синнән дә риза булсын. Сина лаек була алмыйм, картайдым, көчсезләндем, гаеп итмә.

—Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла. Бу нинди сүз тагын, бүтән ишетмим, һы...

Берсе алда, берсе бер аршын артта.

Ике рәкагать сөннәт кылдылар.

Башларын иеп, бераз тын тордылар. Соныннан Хәсән бабай торып басты. Калын, егетләрчә мөбәрәк тавыш белән камәт төшерде. Ул имам булды. Гайшә әби—җәмәгать.

Алар укыган намааз!.. Тәннәре дә, рухлары да җиде кат күкләрдә, җәннәт бакчасы гөлестаннарында. Аларның йөрәк тибүләрен берәү күрә калса әйтер иде:

—Дөнья болар кулына тапшырылган, галәмнәр боларга бирелгән, ни кушсалар шул булыр, бул дисәләр булыр, җимерел дисәләр җимерелер.

Намаз беткәч, башларын иеп сүзсез генә тордылар. Кояш чыкканчы селкенмәделәр дә.

Һәм Гайшә әби ашны учакка куйды. Аннары, бисмилла әйтеп, болгата башлады. Аш пешә торган арада, Йөрәк Хәсән Аллаһка ялварып торды.

—Хакими мотлак, һичшөбһәсез, Син! Мал-мөлкәт синеке, мәгънә синеке. Мин гөнаһлыны кичер. Анам, атамны ярлыка. Гайшә хатынымны кичер. Хаким, һичшөбһәсез, Син! Мал-мөлкәт синеке, мәгънә дә синеке.

Утырып, бер савыттан аш ашадылар. Табакның төбен ипи белән яхшы гына сөннәтләделәр (сыпырып алдылар). Табын өстенә коелган ипи валчыкларын җыеп, бисмилла әйтеп авызларына каптылар.

Бер сәгать тә үтмәгәндер, әйберләрен җыеп та бетерделәр. Бер кат юка түшәк, кечкенә генә йон чатыр. Берничә азык-төлек капчыгында бераз он, әз генә талкан, тархана, ясмык, бер уч ногыт борчагы, бер уч дөге... Бер комган, бер кечкенә ләгән, берничә аш савыты, бер казан, берничә чокыр, бер бакрач...

Бар булган әйбер шулар. Әмма карасаң, шактый гына әйбер күренә. Таулар аша кем күтәреп барыр инде боларны? Һаа, туктагыз әле: бер кечкенә дөяләре дә барлыгын оныткнбыз?!

Бу әкият тә шул дөя аркасында килеп чыккан иде бит. Ниләр булган, ничек булган—сүзебез шул хакта.

Йөрәк бабай белән Гайшә әбинең бер ишәккәйләре булган. Ул аларга бик озак еллар хезмәт иткән. Шулай бер көн абзарга керсәләр—ишәк үлгән.

Йөрәк бабай белән хатыны бик кайгырганнар, әмма: Ходайның тәкъдире дип юанганнар. Йөк ташырга кирәк булганга, Ходай бирер әле, дигәннәр.

Тагын бер ишәк сатып алырга ниятләнгәннәр һәм Йөрәк бабай ат базарына ишәк алырга киткән, ләкин таба алмаган.

Ни күрсен, башын иеп кечкенә генә дөя басып тора икән, ана берәү дә борылып карамый икән.

Дөякәйнең хуҗасы исә, аны һәркөн ат базарына алып килеп, сата алмыйча, кире кайта икән. Әлбәттә, монда бер хикмәт бардыр, бер көнне сатып алучы табылыр әле дип, бер дә кайгырмыйча алдына ашарын куя икән.

Һи, әллә бу әкияттә бер начар кеше дә юкмы? Болай, булмас кебек күренә. Һәркем яхшы, һәркем канәгать, хәтта үлем килә калса да, ана буйсынып, ризалык белән каршы алачаклар. Ләкин тукта әле! Әлбәттә, нинди дер хикмәт булачак.

Ярар, Йөрәк бабайның дөяне күргәч күңеле җылынган. Хәтта йөрәге әрнегән. Аңа шуның өчен дә Йөрәк Хәсән дигәннәр бит. Шундый мәрхәмәтле, шундый сөйкемле була ул. Ярар, якынрак килеп, күзен дөядән алмыйча гына, сорап куйган:

—Бу сөйкемле, җанга якын дөякәйнең хакы күпме?

—Бер яхшы сүзгә бирәем сезгә,—дип җавап биргән хуҗасы.

—Бу нинди сүз?—дип әйтергә дә өлгермәгән, хуҗасы дөянең бавын Йөрәк бабайның кулына тоттырып китеп тә барган.

—Тукта, иптәш,—дип артыннан дәшеп Йөрәк бабай аны тиз генә куып җиткән дә, кулыннан эләктереп алган.—Кара әле, иптәш, ни эшләвең бу? Мин бит ничә сум гына дип сорадым. Нинди гаеп эшләдем, кулыма бавын тоттырып качасың?

—Бабай,—дигән,—әйттем ләбаса, хакын: бер сөю дә, бер яхшы сүз дип.

—Ярар,—дигән Йөрәк Хәсән.—Алла бирсә, рәнҗетмәбез аны, яхшы карарбыз. Тик әйт әле: бирәчәгем күпме, икенчедән, акчам җитәрлекме-юкмы?

—Җитәрлек, җитәрлек!

—Алайса, әйт, күпме?

—Бабай! Бер сөю белән бер яхшы сүз,—дигән сатучы янадан.

—Улым, күреп торасың, яшем шактый, тезләремнең җигәре дә юк, уйнап юанма минем белән.

—Нинди уйнап юану булсын. Алай бик түлисең килсә, ярар алайса. Ярар да. Һымм...

Хуҗа әйтергә дип уйлана икән. Ләкин берни әйтә алмый ди.

Йөрәк бабай да кызыксынып көтә. Ниһаять:

—Иң яхшысы: син моны миннән бүләк итеп кабул ит. Иншаллаһ, файдасын күрерсең,—дигән.

—Алай булмый. Минем акчам бар бит,—дигән Йөрәк бабай.

—Күпме акчаң бар?

—Менә!—дигән һәм бер бакыр акча чыгарып күрсәткән.

—Ооо!—дигән хуҗа.—Бу бик күп була бит. Сиңа бу акчага ике дөя бирерләр.

—Миннән көләсең инде син? Бу акчага кечкенә генә бер ишәк тиясен син дә яхшы беләсең. Хәтта тимәс тә әле..

—Алай! Димәк, шәһәрдә бәяләр бик арткан. Белми дә йөрим икән. Ярый алайса, бир бакыр акчаңны, ал дөяне.

Кул кысыша башлыйлар. Бер-берсенең кулларын тоткан килеш селкепме, селкиләр. Берсе, алдым, ди, берсе, бирдем, ди...

—Һәммәсе белсен, белмәгән калмасын! Һәркем шаһит булсын! Дөя өчен мин бер бакыр акча бирдем.

—Мин дә дөя өчен бер бакыр акча алдым.

Шул рәвешле, дөянең бавыннан тотып, Йөрәк бабай өенә юнәлгән. Хуҗа исә, бакыр акчаны кулында әвәли-әвәли, башка бер якка юл тоткан.

Әйберләрне дөягә төягән чакта, аны базардан ничек сатып алганын тагын бер мәртәбә исенә төшергән Йөрәк бабай. Дөя бик тә яшь, буе да тәбәнәк икән. Ләкин аяклары, муены, күкрәк итләре тулышып тора икән. Тамагы бик нык ачкан кеше аңа бер карап алса, авызыннан сулар килерлек.

Йөрәк бабай хатынына:

—Җанкисәгем, шушы дөя булмаса, бу ел җәйләүгә дә күченә алмас идек,—дигән.

—Әйе, шул. Аның хакын ничекләр генә түләп бетерербез икән?

Шулай итеп, капкаларын бикләп, өйләрен Аллага тапшырып, тауларга таба юл тотканнар.

Бара-бара кичкә таба җәйләүнең беренче тукталышына килеп җиткәннәр. Әгәр дә берәр каршылык килеп чыкмаса, икенче көнне башка тукталышка, өченче көнне җәйләүгә җитәчәкләр икән.

Йөрәк бабай белән хатыны дөягә төягән йөкне бушатып, тиз генә йон чатырны корганнар. Җиде урынга җиде казык кakkаннар. Чатырның җепләрен бәйләгәннәр.

Җилфер-җилфер җил исә икән.

Түбәндә, моннан еракта, бер шәһәрнең җем-җем янган утлары күзгә күренә.

Тау бөҗәкләренен исләре бер-берсенә шулкадәр кушылган ки, иснәгән кеше исерер, хуштан язар.

—Әй, Раббым,—диде Йөрәк бабай.—Тауларын үзгә, сәһилләрен үзгәчә. Кояшны чыгарасын, карангылыкны китерәсен. Күкне йолдызларын белән бизисен. Дөнья шул тауларнын авырлыгын күтәрә дә, бер бәндә бер гөнаһ эшләгәч, күкләр тетрәнә. Синен газабын үткәнче фәрештәләр куркуларыннан үләләр. Әй, бөек Раббым, Син яралткан меннәрчә бөҗәк хакы өчен, яралткан менләгән ис хакы өчен мине ярлыка, мине гамәлләремә карап бәяләмә, мен ел гомер бирсән, мен ел синнән башкасын уйламыйча гыйбадәт кылсам да, биргән бер бөртек күз нуры белән карап, галәмне күрүнен хакын, шөкерен үти алмам. Син мине кичермәсән, мин нишләрмен. Син беркемгә дә мохтаҗ түгел, әмма без һәрберебез Сина мохтаҗбыз. Синен ярдәменнән башка нәрсә эшләр идек?

Гайшә әби гел Йөрәк бабайнын артында утырып, анын сөйләгәннәрен йотылып тынлап, онытылып китә. Вакыт-вакыт тетрәнеп кайнар күз яшьләрен түгә.

Тора-бара икесен дә йокы үзенен иркен ястыкларына чакырып, атынчыгына утыртып атындырган. Икесе дә фәрештәләрнен канатлары астында, еракларга сузылган төшләренен атынчыкларында, учактагы ялкынны тукландырып яшәткән яна һава кебек, йокыга талганнар.

Тау һавасы салкынча да, җанлы да. Билгеле, бик тә арыган булалар.

Дөя чатырнын алдында гына тора. Ашказаны да яна ашаган үләннәр белән тулы. Җиргә яткан да, башын түбәндәге шәһәрнен җем-җем янып сүнгән утларына борган. Аннан бер хәбәр китерүчене, берәр кунакны көткән төсле керфек какмыйча тора. Тик бу күзләр гүя бер төш күрәләр шикелле. Юешләнеп ялтырыйлар.

Иртәгесен, тан атмас борын тордылар. Янә шундый ук җанлылык, шундый ук тизлек белән күз кабакларын ачтылар. Акыл тәндәге урынын алу белән, авыздан чыккан беренче сүз, башка килгән беренче җөмлә дә: әшһәдү ән лә иләһә илләллаһ вә әшһәдү әннә Мөхәммәдәр Расүллүллаһ...

Янә су, янә комган. Янә тәһарәт, янә намаз...

Яна урында өстәлгән дәрт белән бер мәртәбә кыйблага юнәлтелгән тирән дикъкать була аларда. Хәзер зиһен үзгәрәк. Караш җанлырак. Намаз тагын да иркен. Йөрәк бабай шулай, Аллаһу әкбәр, диюгә Гайшә әби җил бәргән сыман тирбәлеп китә.

Дөя инри. Барча бөҗәкләр берьюлы тыналар.

Шәһәрнен утлары... карала, әмма анын урынына башка бер яктылык төшә башлый.

Сәлам, сәлам, сәлам, сәлам, сәлам...(иминлек, тынычлык)

Унга... галәмнен теге башына кадәр һәм тарала.

Сәлам, сәлам, сәлам, сәлам, сәлам...

Тау башында кояш чыкканчы кешеләр ничек уянганнар икән?

Бер гади сәгать тә, шалтырауучы сәгать тә булмаган. Уятучы да, сакта торучы да юк.

Кояш ястүдән сон биш сәгатьтән, йә ун сәгатьтән чыга.

Кояшнын чыгуы ел фасылыннан ел фасылына үзгәрә. Ә үзгәрмәсә организм билгеле бер вакытта торырга иялэшкән дип әйтер идек. Ләкин бер фасыл кояш сәгать дүрттә, бер фасыл тугызынчы яртыда чыга.

Һәр иртәне, кояш чыгарга бер сәгать калгач, Йөрәк бабай күзләрен ача, Гайшә әби рәхәтләнеп йоклый икән. Иллә мәгәр Йөрәк бабай уятып савапка керәсе килә икән.

Әгәр шактый вакыт үтеп тә, кояш чыгарга бер чирек вакыт калгач, Йөрәк бабай һаман уянмаса, бу юлы күзләрен Гайшә әби ача да тиз генә:

—Ай, Аллам, бәй! Сонга калабыз. Озакламый кояш чыга,—дигәч, кабаланып торып, намазга басалар.

Озакламый намаз тәмам. Йөрәккә тагын бер ялтыравык атыла, караш юешләнә.

Шул рәвешле, Аллаһның боерыгы, бәндәнең теләге белән барган гыйбадәт, күз яше, ялвару, бөеклек, хикмәт һәм эре күз яшьләре белән чылатылган күңел почмаклары, утта кыздырылган бер тимер поднос шикелле кояш.

Жир авызын ачкан, кошлар ук кебек һавага атылган. Дөя торып, чирәмлектә йөри башлаган. Ул әйләнеп шәһәр ягына карый икән.

Тегендә, чатыр янында, бисмилла әйтеп аш ашыйлар. Гүя ашның да жаны бар. Гүя түксәң рәнжер, савытта калдырсаң үпкәләр сыман.

—Хатынкаем, әйберләрне иртәрәк төяп, таугa таба барыйкмы, әллә монда бер-ике көн юанып вакыт үткәрикме, ни әйтерсең?—дип сораган Йөрәк бабай.

—Син ничек теләсәң, шул булыр

—Синең фикерең ничек соң?

—Әйе, юлчының юлда булуы хәерле, диләрме?

—Шулай диләрме?

—Шулай диләр бугай.

—Диләрме икән?

—Диләр икән.

—Һыммм, алай булгач, тагын бер көнгә калыйк әле,—диде Йөрәк бабай. —Бу кичтә дә әнә шул шәһәрнең утларын карыйк әле. Мине ул утлар үзенә шулкадәр җәлеп иткәнен, уйландырганын белсәң иде...

Шәһәрнең кичен жемелдәп янган утлары карт кешене ни турында уйландыры икән? Ни турында сөйләгән Йөрәк бабай, нинди уйлану турында әйткән—безгә билгесез, анысы сер.

Тынлыйк әле бу сөйләшүнең ахыры ничек төгәлләнгәнен.

—Бераз йөреп, чишмә башын табыйкмы, җанашым? Юкса суыбыз җитәр дип монда калыйкмы?

—Ничек телисең. Теләсәң, мин барып бер карап килим. Син интекмә, сәфәр юлдашым, дөньядагы иптәшем.

—Ул нинди сүз тагын, ханым. Аллаһтан теге дөньяда икебезнең бергә булуын телим мин.

—Аһ, Аксакалым, анда сиңа ни кирәгем бар, яшем шактый, күрәсең. Пәйгамбәр Әфәндебезнең, «җәннәткә карт хатыннар кермәячәк» дигәнен беләсең.

—Бу сүзне ул кемгә әйткән?

—Карт бер хатынга.

—Хатын нишләгән?

—Борчылган.

—Соныннан Әфәндебез нәрсә әйткән?

—Борчылганын күргәч, өстәп куйган: «Чөнки анда ирләр яки хатын һәммәсе яшь-яшь булып керәчәк»,—дигән.

—Шулай булгач, Алла бирсә, син дә, мин дә җәннәткә кереп яшь-яшь булачакбыз, ә?

—Шулай да, хур кызлары була торып...

—Әллә син тегендә күчмәс борын хур кызларыннан көнләшә башладыңмы?

—Аһ, әфәндем! Ничек дип әйтим, көнләшмим дисәм, зур ялган булыр инде.

Йөрәк бабай кеткелдәп, көлде.

—Сиңа бер нәрсә әйтимме?—диде.

—Боер,—диде Гайшә әби.—Боер, эшлим.

—Хатынкаем! Мин дә сиңа әйтергә дип йөри идем: Күптән миннән бер әйбер дә сорамыйсың. Ни кушсаң шуны эшлим. Син куш, мин эшлим.

—Ай, әфәндем, бу нинди сүз, мин синең аягың астында җир булыйм. Боерык бир, үземне юлыңа корбан итим.

—Ай, күземнең нуры! Солтаным! Бу нинди сүз инде? Син мине кызартасың, оялтып бетерәсең.

—Мин синең әмереңне ишетергә телим.

Сүз янадан назга, нәзакәтле сүзләргә кайтып калган. Әмма соңыннан Йөрәк бабай шуны аңлаган ки: озак еллар инде хатыны үз гомерен тулысы белән иренә хезмәт итүгә багышлаган, әгәр берәр теләге була калса, аны бары Аллаһтан гына сораячак.

Ул теләгәнне Аллаһ әгәр Йөрәк бабайның күңеленә салса, булыр, салмаса булмас икән. Гайшә әби анысына да, монысына да риза.

—Бусы да нечкә бер эш,—диде эченнән генә Йөрәк бабай. Монда да бер үзенчәлек бар. Яши-яши безнең хатын бөек затка, әүлиягә әверелә. Һәм бусы да күз алдында була, мин генә сизмим, ахры.

Кулга кул тотынышып чирәмлектә, агачлар арасында йөри башлаганнар. Һәммә үсемлекнең хәлен белешеп, җиргә басарга курка-курка, чирәмне таптарга да кыймыйча, озак йөргәннәр һәм, якында бер чишмә табып, суларын янарткач, озак кына тирән уйга чумып йон чатырларына кайтканнар. Өйлә вакыты җиткән. Кояш өскә күтәрелгән. Күләгәләр ике катлы булып сузылган.

Кояш кичкә таба авыша башлаган. Менә шул мизгелдә Йөрәк бабай, хатыны Гайшә әби һәм дөякәй ераклардан тауга таба килүчеләрне күреп алганнар; бер төркем атлылар килә икән.

—Менә нинди шатлык!—дигән Йөрәк бабай хатынына.

—Менә нинди шатлык!—дигән Гайшә әби.—Шөкерләр булсын кунак җибәрүче Раббыбызга!

Үзләрен каршы алыр өчен ашыга-ашыга атлап килгән Йөрәк бабайга:

—Әссәламегаләйкум,—диде атлыларның беренчесе.

—Вәгаләйкүмәссәлам! Хуш килдегез, хуш килдегез!

Башкалары да бер яктан атларыннан төшеп, картны берәм-берәм сәламли башладылар.

—Әссәламегаләйкум!

—Вәгаләйкүмәссәлам!

—Әссәламегаләйкум!

—Вәгаләйкүмәссәлам!

—Әссәламегаләйкум!

—Вәгаләйкүмәссәлам!

—Әссәламегаләйкум!

—Вәгаләйкүмәссәлам, агайлар, бәйләр, хуш килдегез! Сөенечләр китердегез. Рәхим итегез бу якка, рәхим итегез!

Карт һәрберсен биек бер агачның салкынча, рәхәт күләгәсе астына алып килде. Чатыр да яннарында гына. Утырганнар. Хәл-әхвәл сорашканнар.

—Кайдан киләсез, кая барасыз болай?—дигән Йөрәк бабай. Төпченеп соравы түгел, ә болай, сүз кушар өчен генә, гадәттәгечә.

—Сәүдә эшенә чыккан идек, менә йөрибез шулай,—дигән башлыклары.

Йөрәк бабай гел бу башлык кешенең генә сөйләшүен, башкаларының әдәп саклап утыруларын күзәткән.

—Бу егетләрнең башы, башлыклары синме, улым?

Бу кеше елмаеп көлгән.

—Боларның һәрберсе минем кадерле иптәшләрем. Башлык дип белсәләр, башлыклары булырмын, әмма колыбыз дисәләр, ул вакыт аларның коллары булырмын.

Барысы бергә сискәнеп, кинәт күтәрелеп басканнар һәм кулларын йөрәкләре өстенә куеп:

—Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла,—дип пышылдаганнар...

—Улым, синә Ходай серле бер сүз әйттерде. Мин шуны аңладым, әмма теләсәң, син әйт.

—Ни аңладың, башта сине тыңлыйк әле. Зинһар, иң элек исемеңне әйт. Кем диләр сине?

—Минем исемем Хәсән.

—Бары тик Хәсән генәме?

—Хәсән дип дә әйтәләр, Йөрәк Хәсән дә, Йөрәк бабай дип тә...

—Йөрәк бабай, ә?

—Шулай, падишаһым.

—Башлыклары икәнемне кайдан белеп әйтәсең?

—Белмим, шулай телемә килде. Кайдан белим. Әмма карап торам да, син үзең дә, иптәшләрең дә падишаһ булырлык кешеләр. Телегез нәзакәтле, әдәбегез, холыкыгыз затлы, ә тәдбирегез бик нечкә...

—Нинди тәдбир ул, Йөрәк бабай?

—Бөтенегез дә чатырга аркагыз белән утырдыгыз, ягъни яшь кыз булса, ялгышып күз ташларбыз, гөнаһка керербез дип уйладыгыз. Их, моннан да нечкә тәдбир була аламы?

—Ничә яшьтә син, Йөрәк бабай?

—Сиксән, туксан булды бугай.

—Яшең сиксәндә-туксанда булса да, күзләрең, акылың, карашың әле дә бик үткен.

—Их, Аллаһының рөхсәте белән, шулайдыр...

Шулай дигәннән соң Йөрәк бабай, аларга салкынча су алып килергә дип торганда, борылып болай дигән:

—Тынычлап утырыгыз. Һәр як сезнең мөлкәтегез дип белегез. Һәм, өлкән бер яшьтәге хатыным бар, анагыз кебек булсын. Сезне дә үз балалары кебек күрер. Шуңа күрә тынычлап утырыгыз.

Алар иркенләп утырганнар.

—Сезгә суык әйрән китерим. Монда калыгыз, кунагыбыз булыгыз. Бергә ашарбыз. Без дә сезгә догада булырбыз, рәхмәт әйтербез.

—Ярар, бик әйбәт булыр,—дигән башлыклары.—Без болай да бик ачыккан идек инде. Тау һавасы аны тагын да арттырды. Чишмә суы эчкәч, тагын да ашыйсыбыз килде.

Йөрәк бабай рөхсәт сорап читкә китте. Чатырга керде.

—Хатын, килүчеләр бик тә ачыккан. Мескенкәйләр ачыкканнар, сусаганнар. Беренче булып сусауларын басыйм әле. Турсык белән суык су алып кайтуыбыз да ярап куйды. Хәзер үк илтим,—дип әйткән дә, җәһәт кенә касәне алып, турсыкны алып яннарына барган.

Зур касә белән тутырып бирүгә, башлык яртысын бер тында, яртысының яртысын тагын бер тында, калганын да бер тын алуга эчеп бетергән.

—Абау,—дигән Йөрәк бабай,—бигрәк янган икән эчегез. Шулай да, агайлар, бу кадәр күп эчеп карыныгызны туйдырмагыз.

Калганнарына да касә белән суык суны сузган. Күп йотып, иркен сулышлар алып, Бисмиллалар әйтеп, әлхәмдулиллаһ дия-дия, суны эчкәннәр. Йөрәк бабай рөхсәт сорап тагы киткән. Чатырга кергән.

—Җан юлдашым, болар бик кадерле кунакларга ошап торалар. Аллаһ безне кызганып, кунак итсеннәр дип боларны җибәргән. Әгәр болар килмәгән булса, шул юлга чыккан ике көннән бирле, «Әллә Аллаһ безне яхшылар дәфтәреннән төшердеме һәм онытттымы», дип эчемнән уйлый башлаган идем. Никадәр гөнаһлы бәндәләр икәнбез, ә? Аллаһны хәтерләп искә төшерү өчен йә сый-хөрмәт, йә бер бәла, йә булмаса, мосафир кунак тиеш булган. Аһ, ваһ безгә!

—Әфәнде, туктап тор әле, шуларны әйтергә дип кердеңме?

—Нәрсә әйтергә кергән идем әле?

—Аллаһ безне кызганды да, мосафирлар җибәрде, дигән идең. Дөресен әйткәндә, мин үзем дә шул турыда уйлый идем. Аллага шөкер, безгә кунаклар килде.

—Дөрес, дөрес,—диде Йөрәк бабай.—Хәзер нәрсә эшлисең, килгән кунакка нәрсә әзерлисең?

—Кулыбызда булганын алларына куярбыз.

—Нәрсәбез бар?.

—Бер казан талкан пылавы пешереп, күпме маебыз бар, барысын да салырмын. Аннан зур касәләрдә суык әйрән, кин савытта бик тәмле катык—кичә генә оеткан идем. Бераз икмәгебез дә бар. Вакыт булса, тагын ипи пешерермен.

—Яхшы,—диде Йөрәк бабай.—Бик яхшы. Вакытың табылыр.—Әмма үзе һаман нидер уйлый сыман.

—Яхшысын яхшы да…

—Бәем, әфәндем, нәрсә телисең, әйт.

—Менә шулай. Кунакның мондыен беркайда да табып булмас.

—Дөрес әйтәсең, дөрес…

—Һәрберсе падишаһка ошап тора. Валлаһи, болар бик кадерле кунаклар. Һәрберсен төрле ил падишаһлары дип уйлыйм. Аллаһ безне җәлләп боларны җибәрде.

—Ни хикмәттер, мин дә шулай дип уйлыйм.

—Шулай булгач, аларны болай гына сыйлау дөрес булырмы икән?

—Йә, ничек ничек сыйларга? Әйт, тагын нәрсә эшли алам, бәем әфәндем, бүтән ашый торган нәрсәбез юк!

—Ханым, Аллаһ безне кызганып җибәрде боларны, мең шөкер Ходайга. Ни әйтергә дә белмим, куенсынам да… Әйдә, кил, дөякәебезне чалып, боларны сыйлыйк. Ни диярсең, мәңгелек юлдашым, башымның тажы, солтаным?

—Аһ-ваһ!—диде Гайшә әби.—Ваһ минем кара язмышым. Ай, Аллаһым. Мин беттем, һәлак булдым. Аллаһ сиңа озын гомерләр бирсен, миннән алып сиңа бирсен. Ваһ, кара инде мине, моны ник баштарак уйламадым мин. Дөнья малы, дөнья хирысы минем күземне томалаган да, шуны да белмәгәнмен. Валлаһи, дөяне суеп ашатыйк бичараларны. Яхшы булыр, бик тә шәп булыр.

—Бераз курыккан идем риза булмассың дип.

—Алай булырга мөмкин түгел! Ләкин нәрсәдер борчый мине..

—Нәрсә ул?

—Дөякәй булмагач, үтәсе биек тауларны уйладым да… Аһ, нәрсә дип әйтим икән, картайдым, кулдан-аяктан калдым. Мин күпме генә әйбер күтәрсәм дә, нишлим, картайдым, аякларның җегәре бетте, йөкнең күбесен сиңа күтәрергә туры килер дип куркам. Ә син һичберсен миңа бирмәссең дә… Авыр йөкләр белән ни эшләрсең?

—Син бер дә борчылма—диде Йөрәк бабай.—Олуг Раббым бер җаен бирер. Ә хәзер вакыт барында ризыкларны әзерләп, алларына куйыйк.

Йөрәк бабай тиз генә дөякәй янына барган. Аңа яратып, мәрхәмәт белән шундый итеп караган да:

—Кил, дөякәй,—дип башыннан тоткан. Битеннән сыйпый сыйпый аны тиешле урынга алып киткән.

Агач төбендә утыручыларның берсе нидер әйтергә теләгән, һәрберсе башлыкларына карап нәрсә әйтер икән дип тынып калганнар. Ул кулы белән:

—Катнашмагыз,—дигән сыман ым каккан.

Дөячек күндәм генә Йөрәк бабай белән янәшә атлый икән. Йөрәк бабай:

—Дөякәй, бик тә иясләнгән идек сиңа. Әмма сиңа да, безгә дә бик зур бәхет ирешеп. Аллаһ безгә яхшы кунаклар җибәрде. Аларны кунак итү безнең бурычыбыз.

Дөякәй муенын иде, янбашы белән, килештек, дигән кебек, хуҗасының җилкәсенә төртте.

Йөрәк бабай дөякәйнең башын көньякка, Кәгъбәгә таба борды. Бисмилла әйтеп пычагын чыгарды. Дөякәйнең муенындагы төкләрен өреп, ике якка

ачты. Мәрхәмәтлек белән пычакны чалды. Бисмилаһ, Аллаһу әкбәр!

Карчыгы да шунда булып, дөякәй пычакны күрмәсен дип, куллары белән аның күзләрен каплап торды.

Дөячек Аллаһның аятенә туры килгән рәвештә, ян якка егылган.

Әйдәгез, без янадан мосафирларга кайтыйк. Кем икән болар? Төп-төгәл җиде кеше. Киемнәрен алыштырып халык арасына чыккан падишаһ һәм вәзирләре икән болар.

Бу падишаһ кичләрен утлары җемелдәп янган шәһәрдә яши, сарае да шунда имеш.

—Тирә-юньдәге авылларга, кырларга, тауларга, җәйләүләргә дә бер чыгып карыйк әле. Анда ниләр бар икән. Нинди яхшылыклар, нинди начарлыклар барганын белмәсәк, Ходай сорау алганда ни дип җавап бирербез,—дигәннәр һәм, шулай итеп, Йөрәк бабайның чатырын күреп алганнар.

Падишаһ, нинди генә падишаһ әле. Шундый падишаһ ки: дусларга да, хәтта дошманнарга да падишаһ. Ягъни дошманнар, кяферләр дә аның житәкчелеге астында исән-имин, рәхәттә генә яшәрләр.

Шундый падишаһ ки, гүзәл буй-сынлы, якты карашлы бер кеше.

Без Харун Рәшид дип әйтик, сез Фатих Солтан диегез, алар Солтан Сөләйман дисеннәр, мин дә Солтан Сәлим дим...

Нинди матур исемнәр.

Ә бит исемнәрне йөртүчеләр... Ул вакытларда малайларга, кызларга бик уйлап, үлчәп исемнәр биргәннәр.

Балаларына Күк, Кыя, Таш, Чәчәк фәлән дип беркайчан да дәшмәгәннәр.

Ә ничек? Иллә-мәгәр Пәйгамбәргә лаек булсыннар, алар кебек үк Исламга хезмәт итсеннәр, Пәйгамбәргә тугрылыклы булсыннар дип, бөекләрнең гүзәл исемнәрен эзләп табып кушканнар.

Менә падишаһның вәзирләре...

Һәрберсе—гөлестанда бер чәчәкле юл. Берсенең исеме, Сары Салтуклардан, Ибраһим улы Мөхәммәд. Бу—баш вәзир. Соңыннан, Хуҗазадәләрдән, Йоныс улы Габделкәрим. Башка вәзир, Чүлмәкчезадәләр дигәннәр, суфый гаиләдән Якуп улы Габделмәҗид. Тагын берсе исә, Корьән Кәримгә булган хөрмәт йөзеннән Аллаһ аны күтәргән, исеме Исхак улы Фәйзуллаһ. Тагын берәү, яше егерме биштән дә артык булмаганы, Гомәр улы Габдрахман. Аннан соңгысы исә шундый яшь, әле мыек та чыкмаган, коллыктан иреккә чыккан һәм алга таба Кол Морад исеме белән дан алачак, Мәсгут улы Морад.

Болар чатыр янында утырганда, анда Йөрәк бабай белән Гайшә әби дөяне чалу турында ишетелерлек итеп сөйләшүләрен, аһ-ваһ килүләрен оныталар.

Әлбәттә, моңа бераз картлык та сәбәптер...

Падишаһ да, вәзирләре дә аларның сөйләшкәннәрен ишеткәннәр. Әмма ләкин падишаһ вәзирләрен ахырга кадәр туктатып торган. Ягъни падишаһ:

—Туктагыз, нишлисез сез! Кыен хәлгә төшәрсез, мескенләнеп бетәрсез, дөякәйне чала күрмәгез дип әйтмәгән.

Ул әйтмәгәч, дөякәйне суйганнар. Алар да сабырлык белән көтеп күзәткәннәр.

Йөрәк бабай белән Гайшә әби сәгатьләр буе мәш килгән. Итне чистартып, иң яхшы кисәкләрен аерып куйганнар. Турыйлар, турыйлар. Кайсысын пешерергә, кайсысын шашлыкка дип куйганнар. Һәм шулай итеп, падишаһларны күздә тотып бер табын әзерләгәннәр. Өстенә кара борыч сибелгән ит шулпасында булгур пылавы парланып пешкән. Әйрән, катык, тегесен-монсын дигәндәй, тауның, болыннарның иң шифалы үләннәрен, һәр авыруга дәва булсын дип, итләр, катыклар янына куйганнар.

Падишаһ һәм янындагылар туйганчы, рәхәтләнеп ашаганнар.

Падишаһ эченнән генә:

—Тамак туйганчы туктарга кирәк, ди икән. Әмма, тагын берне, тагын

берне дип, гадәттән артыграк та ашап ташлаган. Бүтәннәр дә шулай ук.

Падишаһ дога укырга тотынган:

—Әлхәмдулиллаһ! Раббилгаләмин! Вәссәлату вәссәләму галә сәййединә Мөхәммәдин вә галә әлеһи вәсәһбиһи әҗмәгыйн. Әлхәмдулиллаһ, әттамәнә вә сәканә вә җәгаланә минәл мөслимин. Әттаминуллаһи тәгалә мин тәгамил җәннәһ вә мин шәрабүл кәүсәр вә зәүвиҗна мин хурилин. Вәлхәмдулиллаһи раббилгаләмин, бихөрмәтикә сирры сурәтил фатиха.

Догадан соң нәрсә булган диярсез. Әлбәттә, һәрберегез болай уйлагандыр: падишаһ мин фәлән фәлән; болар да фәлән фәләннәр дип үзләрен белгертеп, Йөрәк бабайны мактарлар.

Әмма ләкин алай булмаган шул. Иллә мәгәр падишаһ киемен алыштырып чыкса да, үтерсән дә, ассаң да үзен белгертмәс, танытмас.

Шундый бер гадәте булган аның.

Бу кин күңелле, юмарт, жаны саф падишаһ бу юлы да шулай эшләгән.

Ләкин китәр алдыннан картка әйткән:

—Әнә каршыда бер шәһәр, булганың бармы анда?

—Юк, һич язмыш ташламады ул якларга. Шулай да, җәйләүгә барышлый, монда туктап, берничә төн җемелдәп янган утларны күзәтәбез. Ул тирәләрне бик яратабыз.

—Анда пайтәхет бит, беләсеңме?

—Белмичә, әмма син янадан аңлат әле?

—Бер илнең, императорлыкның баш шәһәре пайтәхет дип йөртелә. Ягъни тәхете булган шәһәр.

—Ягъни падишаһыбыз анда утыруын әйтәсең, шулаймы, улым?

—Шулай, Йөрәк бабай. Анда падишаһ утыра. Нинди дип беләсең аны?

—Аны бик бөек, бик гадел, бик мәрхәмәтле дип беләм. Күңеле киң, беләге көчле булсын. Һәр намазымда аның һәм дөньясы, һәм дә ахирәте өчен дога кылам. Аллаһ аны сакласын, аның өчен мин бик борчылам.

—Нигә борчыласың, Йөрәк бабай?

—Борчылмыйча. Без йон чатыр белән, беткән казанның хисабын тегэ дөньяда ничек бирербез дип куркып торабыз. Әгәр аңа мал-мөлкәте турында сорау бирелсә, нәрсә дип әйтер, нәрсә сөйләр?.. Җинел генә җавапларын бирсен иде, Раббым! Менә бусы да аның сираты. Сират күпере.

Падишаһ дерелдәп куя. Йөрәк бабай моны күреп:

—Балам, һава салкынчаланды, суык булып киттеме?

—Әйе, баба... Ярар, байтак вакыт үтте, әле барасы юллар шактый, караңгыга калсак, юлбасарларның очравы бар.

—Мин үземне белгәннән бирле юлбасарлар бу тирәләрдә булмады. Падишаһыбыздан Аллаһ риза булсын. Аның дәүләтендә юлбасарлар барлыкка килсә, димәк, кыямәт кубачак.

—Шулай дисеңме?

—Әйе, шулай дим, әфәндем, солтаным, бәй улым. Әгәр бер илдә һәркем мул яшәгәннән соң һаман караклар була икән, әгәр бер илдә тулы гаделлек булып та, юлбасар барлыкка килсә, кыямәт галәмәтләредер, улым...

—Дөрес әйтәсең.

—Аллаһ падишаһыбыздан риза булсын. Ярар, балаларым, әйдәгез, юлыгызда соңга калмагыз. Дога кылыгыз. Үткәнегезне онытмагыз. Иншаллаһ, тагын килегез, янадан кунак булыгыз. Кыерсыткан-кимсеткән булсак, гафу итегез. Бәлкем, күңелегезне күреп бетерә алмагандыздыр, житешсезлекләребез дә булгандыр. Яшебез шактый. Кем белгән, кабат күрешергә насыйп булмас, шуңа бәхил булыгыз.

—Башта сез бәхил булыгыз, Йөрәк бабай. Анабыз да бәхил булсын. Исән-сау булыгыз.

—Әйдә, куаныч белән юлыгызда булыгыз. Якты күк йөзе кебек юлыгыз да якты булсын.

—Ә,—диде падишаһ, нәрсәнедер исенә төшереп.—Ул шәһәрдә олы мәчет бар. Ягъни үзәк мәчет дип атала. Падишаһ һәр җомгада ул мәчеткә килеп, намаз укып, вәгазь сөйли, нәсихәт бирә. Халыкны тынлый. Мохтаҗ булганнарга кулыннан килгәнчә ярдәм күрсәтә. Син дә бу җомгада шунда бар, ярыймы? Падишаһ янына кил, син дә берәр нәрсә сора. Ул сине кабул итәр, сараена алып китәр һәм сый-хөрмәт күрсәтер.

—Нәрсә әйтим, белмим шул,—диде Йөрәк бабай.

—Бер тапкыр булса да сынап кара.

—Нигә сынарга, улым. Син шулай дигәч, шулай булыр. Әйткән сүзләреңә ышанам. Мин башка бер нәрсә әйтмәкче идем.

—Нәрсә димәкче идең?

—Күпме мохтаҗлар була торып, падишаһны борчуыбыз дөрес булырмы?

Падишаһ тез чүгеп Йөрәк бабайның кулын үбеп, үзен фаш итәр кебек иде. Ләкин тыелып калды.

—Бабакай, үтенеп сорыйм, бер мәртәбә булса да барып кил һәм күреп кал, ерактан сөеп хөрмәтләгән падишаһың моңа лаекмы икән? Син дә үз бәянне әйт.

—Ярар, балам, барырмын. Бәлки яхшы да булыр, безнең дә ихтыяҗыбыз табылыр, кем белгән...

Йөрәк бабай шулай дигән һәм эчтән генә:

Минем җан юлдашыма бер дөя алырга бер бакыр акча бирер, бәлкем. Бик яхшы булыр иде, дип уйлап куйган.

Мосафирлар атларына атланганнар. Дөм караңгы булганчы шәһәргә кайтып җитәргә дип атларын куганнар.

Падишаһ күңеленнән уйлаган:

—Йөрәк бабай, Йөрәк бабай! Бер килеп күр. Безнең йөрәгебезне яулап алдың. Сине күргәч, үзем өчен оялдым. Синең тырнагыңа да тормыйм, әмма шәһәрне килеп күр, синдә безнең өчен тагын нинди акыллар, нинди хикмәтләр бар икәнен күрербез.

Йөрәк бабай чатырга кайтты. Аларны озатып, артларыннан бик озак карап калганнан соң, чатыр каршысына утырдылар.

Калган итләрнең беразын бер савытка куйдылар. Бераз икмәк, азрак катык белән әкрен генә ашадылар. Калган итләрне бергә җыештырып, бер капчыкка тутырдылар. Бер кисәкне дә әрәм-шәрәм итмәү чарасын күрделәр. Ярый әле монда көн салкынча. Өскә таба тагын да салкынча булачак. Боларны саклау ансат булачак. Әле пешерелмәгән бик күп ит тә бар бит. Болардан куырма ясап, кыздырып кәстрүлгә бастырып куярга кирәк.

Шулай итеп, бу урында тагын бер көн калачаклар. Аннары күз күрер.

—Хатынкаем, башымның таҗы, күземнең нуры, җан юлдашым, ни әйтерсең икән, ишетеп калыйм әле.

—Син сөйлә әле матур итеп, мин тыңлыйм.

—Әлһәмдулиллаһ, Аллаһ безгә кунаклар җибәрде, шөкерләр булсын, аларны сыйладык. Алларына да Ходай биргән ризыкларны куйдык.

—... Аллага шөкерләр булсын...

—Ханым, син эшнең ахырын ишетми калдың. Башлыклары булган ул буй-сынлы зат менә мина шулай-шулай диде. Нәрсә әйтәсең, бүген дүшәмбе булгач, берничә көн тагын бу тирәләрдә калып, җомгага анда төшимме икән? Юкса иртәгә итебезне кайнатып, куырмасын кәстрүлгә басып икендедән соң яки берсе көнгә юлга чыгыйкмы, ни диярсең?

—Син ничек уйлыйсың?

—Мин шулай уйлыйм: Ул мина шәһәргә төшәргә, падишаһны күрергә кушты. Мин дә юк дип әйтмәдем. Ярар, дидем. Бер барып кайтыйм әле дим.

—Яхшы, яхшы. Бер барып кайт.

—Ә падишаһны күргәч, янына барыймы соң?

—Син ничек хуп күрәсең инде?

—Шулай хуп күрәм мин: шәһәргә бер төшкәч, аны бер күргәч, янына барып сөйләшеп карасам дим. Болай дим диюен: әмма, ай-һай, ханым, моны уйлар өчен дә нихәтле көч кирәк. Белмим, белмим...

—Иркәем, сина бу олы затлар бу акылны биргән икән, әлбәттә, алар миннән яхшырак беләләрдер.

—Синнән генәме, миннән дә яхшырак белә алар.

—Миннән яхшы беләләр белүен, әмма синнән яхшы белүләренә килгәндә, син алардан яхшырак беләсең.

—Хатынкай, мина кайдан бу кадәр ышаныч?

—Хатын өчен иреннән дә яхшырак уйлаучы ир-ат булмый. Иң яхшысын ире генә уйлый ала.

—Их, син нинди ягымлы, нинди чытлык, нинди шаян кеше!

Йөрәк бабай шулай дип әйтеп бетермәде, аның янбашына яратып кына төртеп алгач, кеткелдәп көлде. Бер-берсен кочаклап, инде картайган янаклары беректе. Гайшә әби оялып күзләрен йомды. Аның шулай оялган вакытларында Йөрәк бабай һәрвакыттагыча:

—Яле, тагын әйт әле, тагын әйт,—диде.

—Ай, Ходаем, әфәндем! Нәрсә дип әйтим тагын...

—Әйдә әле, әйдә әле...

—И рәхмәт төшкере.

Икесе дә көлешеп, гөлчәчәк яфрагына кагылган төсле, бер-берсенен кытыршы йөзләренә кагылдылар.

—Белеп кайт әле, ниндиерәк кеше икән ул падишаһ? Сөйләгәннәре кебек гадел, буй-сынлы, ваемлы кеше микән? Шулаен шулайдыр да. Барыбер син дә бер күреп кайт әле.

—Яхшы. Ләкин тагын бер ни бар әле. Кунакларыбыз әйткәнчә, падишаһның үзеннән берәр нәрсә сорарга микән, юк микән?

—Билгеле инде, сора. Падишаһтан да сорамасаң?

—Әйе, димәк, падишаһ дисең, юлына да каршы чыкса, алдында басып торса, сорамыйча хәлең юк. Сорамасак нәрсә булыр икән?

—Нәрсә булырмы?

—Нәрсә була, сорамасак дөнья бетәрме?

Әби бер мәлгә туктап торды:

—Юк, бетмәс,—диде.—Сорамасаң да була. Ай, Ходаем, шуның өчен юлга чыгасың икән, сорарга кирәктер.

—Әллә барма диюеңме бу?

—Белмим инде. Син барам дисәң, ничек барма дип әйтим мин.

—Минем бер нәрсә дә ниятләнгәнем юк. Барырга да телим анысы, әмма үземне анда ничек тотармын, нәрсә эшләрмен, бер дә белмим.

—Иң яхшысы, карарсың, Мөхәммәд өммәте ничек эшләсә, син дә шулай эшләрсең.

—Ягъни... әәәә, әйе. Аңладым. Алланың рәхмәте яусын, һай мең яшә, хатынкай! Янакларыңда гөлчәчәкләр атсын. Күңелең шат, теге дөньяда урының җәннәттә булсын. Мине зур мөшкелдән коткардың, күңелемне тынычландырдың. Чыннан да, нәрсәгә монда үземне бимазалап йөрим. Хәзер ни генә уйласам да файдасыз. Анда баргач, билгеле булыр әле.

Аннары үзалдына мыгырданып:

—Мөхәммәт өммәте нәрсәдә иттифак итсә, мин дә шулай эшләрмен.

—Шулай шул,—диде карчыгы.

—Нәрсә шулай икән?

—Нәрсә дип әйттем ки?

—Кычкырып уйландың да.

—Әә, әйе...

—Әйдә, йокла инде. Күрмисеңме, башың авырайган, чәчләрең иңәлеп,

син кайчан безне мендәргә саласын инде,—дип сорыйлар.

Менә шулай сүз сүзгә ялганып, авызлар арыгач, Гайшә әби иркәе бераз йокласын, ял итсен диеп аңа гел болай дия иде:

—Күрмисеңме, башың авырайган, чәчләрең инәлеп сорыйлар. Син кайчан безне мендәргә саласың инде,—диләр.

Ул шулай дип әйтүгә, Йөрәк бабай белән бергә башын мендәргә куялар иде.

Бу юлы да бергәләшеп башларын мендәргә куйдылар. Һәм балдан татлы итеп йоклый башладылар.

Җомга көн.

Иртәнге намазын кылгач, авызына бер валчык ризык капмаган килеш, Йөрәк бабай юлга чыгарга әзерләнде.

Шәһәр кулыңны сузсаң тотып алырлык ераклыкта күренә, әмма Йөрәк бабай болай әкрен барса, җомга намазына чак-чак өлгерәчәк иде.

Саубуллашалар.

—Бәхил бул. Барып та кайтмау, кайтып та күрешә алмау бар. Артымнан изге теләкләр теләп тор.

—Аллаһ юлларны имин кылсын. Аюдан, бүредән сакласын сине.

Елгалар, таулар аша Йөрәк бабай шәһәргә килеп житкән. Олы мәчетне дә тапкан. Карый, анда халык шактый күп. Моның кадәр халыкны гомерендә беренче мәртәбә күрүе иде аның.

Караса, кешеләрнең барысы бер якка агылалар, кайнашалар. Башын борып караса, бераз алдарак падишаһ хәзрәтләре. Кайсы аның белән сөйләшергә тели, кайсы үтенеч житкерә.

Йөрәк бабай шулай карап тынып калган. Аның болай бер урында кыймылдамыйча торганын күреп, падишаһ аңа якынлашырга теләсә дә, халык падишаһны сырып алгач, аның янына бара алмаган.

Халык күбәеп, дәррәү ябырылгач, иминлек сакчылары бер кемне рәнжетмичә генә, иплән кенә падишаһка юл ярганнар.

Йөрәк бабай урынында шул рәвешле көтеп калган.

—Моның кадәр халыктан соң чират житмәс, дигән. Һәм падишаһны карап калырга, йөзен-күзен хәтеренә сендерергә теләгән.

Кайткач Гайшә әбигә сөйләп күрсәтәсе бар бит әле. Тагын үзенчә уйлана:

—Мохтаж кешеләр никадәр күп икән! Боларның барысы да һәрхәлдә бөтенләй фәкыйрьләр, хәсрәтле кешеләрдер. Аллага шөкер, бар нәрсәбез дә бар, Ходай безгә һәрнәрсәне мул итеп биргән. Юкса, билгеле, мин дә монда килеп, бу капкада ярдәм теләнер идем.

Шулай дигән дә, падишаһның күзләре бик ерактан аңа карамасынмы? Шулкадәр оялган, һәм тиз генә башын түбән игән.—Ярар, дигән, бер тапкыр күзгә күз дә караштык бит. Монысы да бик житкән. Аллаһым, мең шөкер, безгә мондый гүзәл, мондый гадел падишаһ биргәнсең. Күңелем бик тыныч, ярый әле күреп калдым. Хәзер тагын күзгә-күз килгәнче, моннан әкрен генә китеп, күздән югалыйм әле. Күрәсен күрдек, тиешлесен эшләдек, шунысы безгә бик житкән.

Ул башын шулай иеп торганда, тавышлардан, этеш-төртештән ниндидер хәл булганын аңлап алды. Тавышлар бераз басылгач, эченнән генә:

Нәрсә булды икән, дип әйтергә өлгермәгән, башын күтәрүгә, караса падишаһ каршысында басып тора түгелме?

—Ай, Аллам,—дип әйтеп куйган үзен тота алмыйча.

Падишаһ житди, калын тавыш белән:

—Синең нинди теләгең бар?—дип сораган.

—Саулыгыңны телим. Һичбер үтенечем юк.

—Әйдә, бабай, сөйлә әле. Ишетеп калыйк әле, нинди йомышың, нинди хажәтең бар?

—Минем бер нинди йомышым да, хажәтем дә юк. Мин килдем...

—Берәр нәрсә сорарга килдеңме?

—Бер нәрсә дә сорамаска дип килдем.

—Бу ни дигән сүз?

—Карасам, монда чын мохтаҗлар гына. Минем берәр теләгәнем булса, аны да боларга бир, дияр идем.

—Синен исемен ничек, бабай?

—Минем исемем Хәсән.

—Бары тик Хәсән генәме?

—Хәсән дә дип әйтәләр, Йөрәк Хәсән дә, Йөрәк бабай дип тә...

—Йөрәк бабай, ә?

—Шулай, дәүләтлем.

Падишаһ таудагы сөйләшүнең бермә-бер кабатланганын күреп сөенгән һәм көлеп тә җибәргән. Бабай да хәлне анлап алгандыр дип уйлаган. Ләкин караса: Йөрәк бабай сафлардан да саф күнелле... падишаһны таный алмаган.

Ул каян белсен падишаһның киемен алыштырып халык арасында йөргәнен. Мондый эш, падишаһ өчен, дәүләт өчен үлчәм булса да, Йөрәк бабайның акылына сыймый. Ул моның ише нәрсәләрне хәйлә-алдау дип белә.

Шул сәбәпле, падишаһны теге килгән кунакларга охшатып торса да, барыбер анлый алмаган.

Аның мондый булуы падишаһны тагы да сөендергән.

—Алай булгач,—диде эчтән генә, намаздан соң сарайга алып кайтырмын, вәзирләрне дә чакырып үземне ачыклап, берничә янчык алтын да биреп җибәрермен. Безне кунак иткән дөя өчен теләсә өч йөз дөя алсын.—Шулай уйлаганнан соң:

—Әйдә, Йөрәк бабай, әйт әле, нәрсә телисен, шуны бирәм.

—Саулык-сәламәтлегегезне телим. Сезнең саулыгыгыз булсын, минеке булмаса да бик мөһим түгел, Мөхәммәд өммәтенә иң элек Аллаһ, Пәйгамбәр, аннары Сез кирәк.

—Син шулай да берәр нәрсә сора.

—Сорамыйча булмыймыни?

—Юк, булмый.

Падишаһ таудагы сөйләшүне Йөрәк бабайның исенә төшерүен һәм бер дөялек акча соравын тели иде. Әмма ләкин Йөрәк бабайның исенә төшми икән.

Уйлаган да уйлаган. Аның шулай уйлавына халык бераз сәерсенеп тә караган.

—Исемә бер нәрсә дә килми, падишаһым. Хаҗәтем булса сорар идем.

—Хаҗәтен булмагач, нишләп монда басып тордын?

—Башта да әйттем, Падишаһым: йөзегезне күрергә теләдем, Аллага шөкер, күреп морадыма җиттем.

—Монда буласыбызны кайдан белден?

Йөрәк бабай теге көндә булган хәлне сөйләп биргән дә, «Ул зат мина падишаһка бар, аны күр» дип әйтте,—дигән.

—Тагын нәрсә әйтте?

—Падишаһ сине кабул итәр, сараена алып барып сыйлар. Һәм анда сине бүләкләр,—диде.

—Алай булгач, мин дә сине сарайга алып барып, сый-хөрмәт күрсәтим. Аның сүзе һавада эленеп калмасын.

—Юуук... Сез нәрсә, падишаһым! Мин бит бары тик аның сүзләрен җиткерер өчен сөйләдем. Вакытыгызны минем өчен әрәм итмәгез.

—Нинди әрәм итү булсын. Безгә синнән файда гына булыр. Әйдә, хәзер намаз укырга керик. Хәзер азан әйтәләр. Минем янымда гына бул, еракка китмә, яме?

Шулай итеп, эчкә кереп киткән падишаһ. Йөрәк бабай да аның артыннан барган.

Гөрләп азан яңгыраган.

Намаз, аннары җомга хөтбәсе дигәндә хозур белән укылган җомга намазы... Тәсбих тартудан соң, дога кылырга чират житкән. Падишаһ белән бергә барлык халык кулларын күтәреп Аллаһтан сорый башлаган.

Беравык Йөрәк бабай, падишаһның догасын колак салып тыңлагач, аның шулай ялваруын ишеткән:

—И, Раббым! Син бер кемгә мохтаҗ булмаучы, чын байлык иясе, бәндәләренә мул итеп бирүче кәримнәрдән дә кәримсең. Безгә бик шәфкатьле, рәхимсең. Олыларның олысы Син. Миңа ризык бирче, саулык-сихәт бирче Син!

Бу сүзләрне ишеткәч, Йөрәк бабай үзалдына:

—Моның да кулында бернәрсә юк икән. Ә мин аннан сорарга дип килдем. Күр әле, ул үзе дә бүтән бер падишаһтан сорый. Мин исә аның белән сараена барырга ризалаштым. Мин дөрес эшләмәдем. Тиз генә моннан чыгып, чатырга кайтыйм әле. Юл буенча агачлар, чәчәкләр, һава белән серләшеп, барлык хәҗәтемне Аллаһыма сөйләп бирим, бары тик Аннан гына сорыйм. Минем янда шушы игелекле, юмарт падишаһ булса да, аннан сорамыйм. Әгәр сорасам, әдәпсезлек булыр Раббыма. Ә ул миннән мондый нәрсәне яратмас.

Йөрәк бабай кабаланып мәчеттән чыккан.

Падишаһ дога кылганда, Йөрәк бабайның башын сузып тыңлаганын чамалады һәм аның ашыга-ашыга торып чыгып киткәнен дә күреп калды. Бер дә дәшмәде. Ул Йөрәк бабайның изге кеше икәнен белде. Шуңа күрә аның ни өчен торып китүен аңлады.

Бу юлы догасын үкенүләр белән тутырып, күзләреннән яшьләр агызып, Аллаһка яп-яңа бер рух белән ялвара башлады һәм эченнән генә:

—Менә нинди икән син, менә нинди икән син, Йөрәк бабай!—дип кабатлап торды.

Гайшә әби караңгы төшәр-төшмәс, калын агач таягын җилкәсенә күтәреп каршы чыккан. Йөрәк бабайны күргәч, сөенә-сөенә килде.

—Әссәламегаләйкүм, гүзәл хатыным, җан юлдашым.

—Вәгаләйкүмәссәлам, әфәндем, солтаным. Хуш килдең, сафалар китердең. Җаныма хозур бирдең, шатлыклар алып кайттың.

—Ничек хәл-әхвәлләрең? Яхшымы? Бөтенесе дә әйбәт, иншалла?

—Яхшы, Аллаһыма шөкерләр булсын. Сине күргәч, бөтенләй яхшырып китте, күңелем шатлык белән тулды. Мондый олы бәхет өчен Аллаһка рәхмәтемне ничек кенә житкерә алырмын икән.

Йөрәк бабай белән Гайшә әби чатыр янына кадәр бергәләп атладылар. Йөрәк бабай көне буе авызына валчык ризык та капмаган иде. Хатыны:

—Ачмы син?—дип сорагач.

—Әйе. Иртән чыккан килеш торам.

—Һай,—диде хатыны.—Һай, минем иркәем, әфәндем!

Тиз арада нәрсәләрдер әзерләп китерде. Бу ризыклар Йөрәк бабайга җәннәт тәгамнәре булып тоелды.

—Миңа болар җәннәт ризыклары кебек булды. Синең кулың аша килгәч, Аллаһ биргән ризыклар шулкадәр тәмле була ки...

Бергә ашадылар, эчтеләр. Намазларын кылдылар. Догаларын укыдылар.

Йөзләре белән кыйблага борылып, ун кулларын битләре астына куеп, җәннәт йокылары кебек йокыга талдылар.

Иртәгесе көн әйберләрен җыйдылар. Һәм аларның җиңелен, авырын бүлеп аркаларына күтәрделәр.

Әкренләп юлга чыктылар. Һәм Гайшә әби кичә сөйләмәгәннәрен иркенләп юлда сөйләшеп бардылар. Йөрәк бабай башыннан үткәннәрен сөйләде, Гайшә әби тыңлады да әйтте:

—Бик дөрес эшләгәнсең. Мин сиңа әйткән идем бит, син алардан яхшырак беләсең дип.

—Син моны күз алдында тотып әйткән иденме?

—Юк, ул кадәр үк түгел. Әмма менә шулай дидем.

Әле юлның дүрттән берен дә үтә алмадылар. Икесе дә арып, алҗап йөкләрен җиргә бушаттылар. Бер-ике сәгать урыннарында сулышлары кабып кыймылдамыйча утырдылар. Тик намаз кылу өчен хәл кереп җанланып кузгалдылар.

—Хатынкай,—диде Йөрәк бабай.—Алда тагын юл бар барын, ләкин адым атларлык хәлебез калмады бит. Бу тирәне бик яхшы белеп бетермибез. Тирә-юньдә су бар микән. Шунда туктыйкмы әллә дим.

—Яхшы булыр, бик тә яхшы булыр,—диде хатыны.

Караштыра торгач, чатыр корыр өчен бер җирне ошаттылар.

Бераз ял иткәннән соң, чатыр өчен казык кагарга һәм чатырның җепләрен бәйләргә тотындылар. Соңгы казыкка чират җиткәч, кагып кына булмый бит казыкны. Җепнең сузыласы җире билгеле. Ни бер карыш тегендә, ни бер карыш монда кагып булмый казыкны.

—Хатынкай,—диде карты.—Шул кәйләне бир әле, монда бер таш чыкты, Алланың хикмәтедер инде, ватып урынына казыкны кагыйм әле.

Йөрәк бабай ташны урыныннан алыр өчен берничә мәртәбә кәйлә белән суккач, алтын тулы казан, кыйммәтле ташлар чыкты.

Бу хәлне күргәч, аптырап калдылар. Казанны бөтенләй чыгарып, капкачын ачуга, бик күп хәзинәне күреп шаккатып тынып калдылар.

Кояш баерга тора иде. Йөрәк бабай ашыгып әзерләнде. Агач таягын кулына тотты да:

—Гүзәл хатыным,—диде.—Бары тик Аллаһтан гына сорасаң, Ул мул итеп бирә. Ләкин бу кадәрле йөк һәм моның хәтле байлык була торганда йоклап төн үткәрсәк, белеп тор: башыбыз бәлада. Йоклап уянмавыбыз бар. Аннары Аллаһ бездән: «Шуның хәтле байлыкны нишләттегез?» дип сораса ни дип җавап бирербез. Шуңа күрә хәзер үк шәһәргә төшәм. Гарип-горәбаларны җыеп китерәм. Һәрберсенә өләшеп чыгам.

Һәм шулай итеп, Гайшә әбинең догалары белән, Йөрәк бабай юлга кузгалды.

Гайшә әби намазлыкка утырды. Аның йөрәге бу авыр җаваплылык алдында дерелдәп тора иде.

Гайшә әби иртәгәсен Йөрәк бабай өлкәнең иң фәкыйрьләреннән оешкан зур халык төркеме белән күренгәнче урыныннан тормады. Аларны күрүгә, шөкерләр әйтә-әйтә торып басты. Сөенә-сөенә туры Йөрәк бабайга таба йөгерде.

Караса, ул кечкенә бер дөякәй сатып алган икән. Җиленнәре сөт белән тулы дөякәй. Йөрәк бабай юлда аңа атланырга кыймаган. Бавыннан тотып алып кайткан һәм «Ничек сөенер инде!» дип самими елмаю белән Гайшә әбигә карап тора иде..

Төрекчәдән<br>**Фатих КУТЛУ**<br>*тәрҗемәсе*

*Журналыбызда яшьләр иҗаты белән даими таныштырып барабыз. Сезнең игътибарга Казан дәүләт университетында укучы ике яшь шагыйрәнең яңа шигырьләрен тәкъдим итәбез.*



Алинә
Куропаткина

# ҖАН—КҮК КЫЗЫ БУЛГАНГА

***

*Бүген төштә мин җинаять кылам,*
*Хисләремне җирдән юк итәм.*
Г. Кашапов-Үзиле

Мин төн буе елап чыктым…
Җинаять кылдым бүген:
Сөюемне үтердем мин—
Мәңгегә җиргә күмдем.
Җиргә күмдем: ул—гөнаһлы,
Адаштырды хисемне…
Күкләр җиргә аткан җанны—
Хисемне җир күпсенде.
Имеш, күкләрчә сөям мин—
Илаһи Сөю миндә.
Җирдә бу хисләр ярамый,
Артык саф күңелем дә…
Күкләр Җиргә атты—бәлки,
Тапларыннан пакьләргә?
Ә Җир, ахры, теләгәндер
Шул тапларын сакларга?..
Җиргә каты егылганмын—
Күкләр кызы булганга.
Шуннан бирле, һушсыз килеш,
Саф күңелем җыр яза:
Күкләр кызы булганга!..

***

Елмаюын, йөз чалымын
Мин аның төштә күрәм.
Иреннәрем тетри һаман
Соң кабат үбүеннән…
Мин һаман төштә күрәм.

…Ник күзләре нуры качкан—
Моң югалткан шигырьдәй?!
Иреннәре дә чит, салкын…—
Үпкәнме ят иреннәр?!

***

Күзләрем аның күз нурын
Эзләп Кояшка бага.
Сизми дә: аның җырларын
Көйләп, җаным моңлана.

Кайда ул?— дип сорамагыз,
Күкләрдән эзләп йөрү…
Йөрәктә—җыр… Мөмкинме соң
Сөю хисен үтерү?!



Резеда
Гобәева

# ТАМЧЫДАГЫ КОЯШ НУРЫ БУЛЫП...

***

**Айдан нурлар алып яшәсәм дә,
Мин җир кызы...
Бары якты хыялларда гына—
Таң йолдызы!..**

***

**Мәхәббәт ялганга төренгән—
Күрәшү диярсең син аны...
Мәхәббәт бәхетсез була, дип
Алдалап кара син дөньяны...**

***

**Ярату гади буламы?
Ярату көчле була!
Мәхәббәттә югала бел—
Дөньяга үчле булма...**

***

**Бәхет! Бәхет!—
Ирешелмәгән хыял чаткысы.
Һаман алда—үтелмәгән кебек
Көннәремнең иң-иң яктысы.**

***

**Мин болытта тамчы булып яшим—
Язгы яңгыр— менә явачак...
Ләйсән яңгыр—синең иренеңә
Шатлык яше булып тамачак...
Тамчыдагы кояш нуры булып,
Күзләреңдә уелып калачак...**

***

**Еллар үтә...
Хәтер яши,
Хәтер үлми—мәңгелек!
Тарихларга кереп калсын—
Тормышка бер ямь бирик!**

# КИНАЯЛЕ СҮЗ УЙНАТУ

*Шигырь язуга килгәндә,*
*Һәр кеше аңа ия.*
*Шагыйрьлек?! Анысы башка—*
*Анысы—аномалия!*

М. Әгъләм.

*Кызык ул: юк тәкә башын*
*Юк казанда булу!*
*Һәркемгә дә тәтемәгән*
*Яшь аралаш көлү!*

Р. Фәйзуллин.

Шагыйрьләрнең сүз уйнатучылар булуы һәркемгә дә мәгълүм. Поэтик осталык, гади генә итеп әйткәндә, сүз уйнату булып чыга да. Сүз уйнату төшенчәсе лингвистикада «контекст эчендәге берәр сүзнең яки тәгъбирнең бер үк вакытта ике мәгънәдә анлашылуына нигезләнгән шаярту алымы» буларак билгеләнелә. Шулай да сүз уйнатуга шагыйрьләр шаяртып карамаганнар дип уйларга нигез бар. Һ. Такташның «шигырьдә матур сузләр уйнатудан мәгънәгә күчү дәвере килде» дигән фикере яши. Дөрес, 20-30 еллар әдәбиятында башкача әйтергә дә ярамагандыр. «Сүз уйнату» төшенчәсен М. Кәрим шагыйрь Р. Хариска карата кулланган иде («Акыл да чөя, сүз дә уйната»). Шагыйрьнең үзенең дә шундый юллары бар: «Этем дә юк, атым да юк... Сүз уйнатам, басып торып, дөньяның кыл уртасында».

Шулай да шигырьгә сүз уйнату гына җитми. «Шигырь поэтик булсын өчен шомалык һәм янгырашлылык кына аз, шулай ук бердәнбер хис кенә дә җитми. Теләсә нинди поэзиянең асыл эчтәлеген тәшкил итүче фикер кирәк»,—дигән В. Белинский. Шигырьдә аваз, ритм, сүз, мәгънә—бербөтен, аерылгысыз. Әлеге фикерне М. Әгъләм шигырьләре нигезендә расларга тырышып карыйк. Шагыйрьнен соңгы елларда язылган шигырьләрен уку барышында мин аларда күпләп омоним сүз формасыннан файдалануга тап булдым. Дөрес, әлеге күренеш әдәбиятта күптәннән килә (әдәбиятта—«каламбур»). Омоним турында сүз чыгуга, әдәбияттан аз-маз хәбәрдар булган кеше XIX гасыр шагыйре Г. Кандалыйның «Сәхипҗамал» поэмасыннан традицион мисалны китерергә ашыга:

*Бу нидән булды чи генә?*
*Эшем дә йитте чигенә,*
*Сәхибем кире чигенә,*
*Исем китәрде җанкай ла!*

Тагын да килеп, мәшһүр Тукайның «уй да мин» һәм «бал авыз», «алдарга оста бикә»ләрен санап үтеп булыр иде. Телдәге омоним чаралар шигырьгә юмор хисе өстәү өчен менә дигән корал инде.

Татар телендә бер үк төсле әйтелсә дә, мәгънәләре бер-берсеннән ерак булган, болар өстенә тагын әле алар арасында бернинди уртаклык билгеләре дә табылмый торган сүзләр очрый. Андый сүзләрнең кайберләре тарихи яктан бер тамырга барып тоташырга да мөмкин. Шулай да аларның күбесе фонетик яки морфологик үзгәреш нәтиҗәсендә генә аваздаш булып кала бирә. Тел фәнендә әлеге сүзләр «омоним» термины белән йөртеләләр. Омоним үзе өч төргә бүленеп карала: саф омоним, омоформа һәм омофон.

Шулай итеп, Кандалый, «чигенә» дигән омонимны дүртьюллыкта өч төрле

мәгънәдә күрсәтүгә ирешеп, лирик геройның шәхси кичерешен генә тасвирласа, татарның «коеп куйган шагыйре» М. Әгъләм «Ыңгыраша гына» дип исемләнгән шигырендә әлеге сүзгә иҗтимагый яңгыраш та өсти:

*Сүзләренә күрә акыл чыга—*
*Иманепләр китәр им генә.*
*Эчләрендә ята: халык җанын,*
*Халык канын, малын им генә.*
*Ыңгыраша халык,*
*Чигенә—*
*Ул җитәчәк соңгы чигенә.*

Әлеге шигырьдә капма-каршы мәгънәне аңлата торган тагын бер омоним бар: «иманепләр китәр им» һәм «халык канын, малын иму». Шагыйрь тагын шуна игътибар итә: җанны, канны талау процессы гаҗәп оста башкарыла. Әлеге фикер шигырьнең баштагы ике юлында урын алган. Шулай итеп, әлеге сәяси эчтәлекле шигырьгә дүрт төрле мәгънә салынуын сизеп була. Беренчедән, матур сүзләр белән акыл сату; икенчедән, нинди юллар белән булса да әйтелгәнне эшкә ашыру процессы; өченчедән, алданганны аңлап, чара күрергә омтылыш; дүртенчедән, «җину»гә ышаныч күренмәвен шигырьнең исеменә чыгару. Ә бит бары бер строфалык шигырь! Әмма никадәр тирән фикер! Сокланырга гына кала. Шигырьдәге һәрбер сүзгә күптөрле мәгънә салынуы сизелеп тора. Бер үк вакытта шагыйрь сайлаган һәр сүз аны алыштырырдай башка сүз табып булмаячагына ышандыра да.

*Бер сүз эзләп, телемнән*
*Күпме сүзем коелды.*
*Уен түгел, чын бит бу,*
*Ташлыймын бу уенны,—*

дисә дә, М. Әгъләмнең икенче бер шигыре дә «ыңгырашу» турында, ләкин аңысы «Ыңгырашмый кара» дип атала.

*Дөнья йөген ничек аппарырга?*
*Син этмә дә, имеш, тартма да...*
*Шундый хәлдә катгый таләп тора:*
*Син эчмә дә икән, тартма да—*
*Мәш киләбез шулай бөҗәкләр кук*
*Империя дигән тартмада...*
*...Иң очсызы—Кеше... Эч кенә!*
*Сулык-сулык кылә эч кенә.*

Аңлаган кешегә гаҗизлек хисен моннан да үтемлерәк итеп әйтеп булмас кебек. Шигырьдән безгә илдә дөрес яшәү мөмкин түгеллегенә тәмам инанган «очсыз» Кеше карап тора. Аның, тартмадагы бөҗәк кебек бәргәләнә торгач, кайгысын эчеп басудан башка әмәле калмый. Шәхес фаҗигасен шагыйрь шулай бирә. Шигырьгә кешене сискәндереп җибәрергә сәләтле, үзгә, кинәйтелгән метафора килеп кергәч («империя дигән тартма»), шагыйрьнең кешене бөҗәк белән чагыштыруына аптырыйсы да калмый.

Сүзебезне XIX гасыр шагыйре Кандалыйдан башлаган идек. Шигырьгә «бөҗәк» төшенчәсе килеп кергәч, яңадан ул чорга әйләнеп кайтасы килә. XIX гасырның олы шагыйре Әбелмәних Каргалый да «Сәхрадан кайткач» исемле пейзаж лирикасына карый торган бер шигырендә бака, чикерткә, чебен кебек бөҗәкләрдән поэтик мәгънә таба. Шул чорның икенче бер Гомәр Мөхәммәт углы дигән шагыйре, гуманистик традицияләре булган татар әдәбиятында гали кешене «мәкәс» (чебен) дип атап, мәсхәрәләү объектына әверелдерә. Ә яңа гасыр шагыйре М. Әгъләм,

бөҗәкне «тартмага ябып», бөтенләй чыгар юлын калдырмый. Шулай итеп, шагыйрь билгеле бер социаль катлам вәкилләренең тормышын сәнгатьчә тасвирлауда кабатланмас поэтик бизәк табуга ирешә.

Шагыйрьнең нибары сигезьюллык шигырендә татар теленең лексик байлыгы һәм сүзнең көчәрелмә мәгънәсе әйтеләсе фикерне җиткерүдә ифрат оста файдаланылган. Ә «тартма» һәм «эч кенә» сүзләре шигырьнең нигезен тәшкил итә. Әлеге шигырь сурәтләү чараларына искиткеч бай. Монда метафора, чагыштыру, эпитет кебек троплар, «дөнья йөге» сүзенең көчәрелмә мәгънәсе, риторик сорау һәм өндәү, әйтеп бетермәү кебек поэтик синтаксис чаралары да бар. Шигырьнең ритмик нигезен омоформаларга корылган башлангыч һәм юл ахыры рифмалары тәэмин итә. Риторик «җавап» та бар шигырьдә, ул аның исеменә үк чыгарылган.

Шулай да «империя дигән тартма»да М. Әгъләм берүзе генә түгел. Башка шагыйрьләрне дә борчып торган сорау бу. Мәсәлән, 1993 елның сентябрендә Р. Фәйзуллин болай язган иде:

*Империя коллыгында*
*Гел күнеккәч искегә,*
*«Демократия»сеннән дә*
*Юылмаган ис килә.*

«Ынгырашып» язылган шигырьләр М. Әгъләм иҗатында тагын да күзәтелә. Шигырьдән шигырьгә көчә торгач, аларда ирониянең сарказмга үк әйләнүе сизелә башлый. «Мин дөньяга багам»да ул «Ынгырашып турая тез / Иңгә төшкән йөктән», дип яза. Мондый шигырьләрне укый торгач, алдагы якын һәм ерак киләчәккә өмет тә калмаган кебек. Дөрестән дә, шагыйрьнең бер шигыре «Алгы киләчәк» дип атала.

*Түрәләргә инде өмет бетте,*
*Ничек кенә булыр киләчәк.*
*«Кәләпүше кирәк!»—дисә Мәскәү,*
*Болар*
*Башың кисеп алып киләчәк.*

Күренеп тора, «сәясәттә, урта гасырлардагы кебек үк, хаклык һәрчак көчлеләр ягында» дигән фикерне шагыйрь омоним чара һәм метонимия кебек троп аша бик үтемле ирония белән белдерүгә ирешкән. Чын шагыйрь башкача булдыра да алмый торгандыр. Р. Фәйзуллин әйткәнчә: «Кем ишетсен Галәмгә дип төбәп, җиң эченә әйткән хаклыкны». Ә М. Әгъләмнең тагын да усалрак фикере болай яңгырый:

*Коллыктан яманрак ул*
*Бездәге мөстәкыйльлек.*

Хәер, инде хәтта рәсми даирәләрдә дә «мөстәкыйльлек» сүзен искә алучылар сирәк калып бара бугай. Күптән билгеле гыйбарә: безнең илдә шагыйрь шагыйрь генә булып кала алмый. Ул тарихчы, җәмәгатьче, дипломат кебек фикер йөртергә дә тиеш булып чыга. Шагыйрьнең «Иләк ягы да бар» шигыре шуңа ишарә:

*Болгар читеге ул безнең өчен*
*Эшкәртелгән гади күн генә...*
*...Дәүләтеңне югалткансың икән,*
*Башкаеңны иеп күн генә.*
*...Акчаның шул иләк ягы да бар:*
*Төшеп тормый һаман күн генә.*

Бу юлы инде шагыйрь телнең лексик чаралары белән генә чикләнмичә, фразеологик берәмлекләрне дә эшкә җиккән. Шагыйрьнең 1996 елның август аенда язылган бер шигыре «Дәүләт теле» дип атала. Бу шигырендә шагыйрь дәүләт

сәясәтенең тел өлкәсенә караган мәсьәләләрен күтәреп чыга. Башкалар кебек ул туган телне парламентларга да «менгерми», «кухня теле» дип тә кимсетми, әмма планканы иң югарыдан «ала», акча бирәмлеге итә:

*Мохтаҗлыларга ярдәмле,*
*Яманга гыйбрәтле ул—*
*Бары акчага сугылган*
*Тел генә дәүләтле ул.*

Ә менә 1999 елның декабрендә язылган «Җинеллекне күтәрүләре авыр» исемле шигырьне һич тә сәясәттән башка карап булмыйдыр. Әлеге алты строфалык шигырь үзе үк Татарстан тарихының билгеле бер чорын сәнгатьчә тасвирлау булып тора.

*Без китәбез генә, диган идек,*
*Дөрес юлга җүнәлеп кенә;*
*Шалт!—авызлык кысты,*
*Торганнар бит*
*Вакытлыча җибәреп кенә.*

Чын шагыйрь һәр чорда да алдан күрүчәнлек сәләтенә ия була. Ләкин әлеге экстрасенска хас сыйфатны бу шигырьдән табуы кыен. Күрәсең, бу очракта җавап кирәкмидер дә дигән фикергә киләсең. Шигырьдә ул болай яңгырый:

*Җиңдек, дидек,*
*Килде җиңеллек!*
*Без авырлык көттек,*
*Һәм күрәсең,*
*Җиңеллеккә килеп җигелдек.*
*Җиңелдек!*

Шагыйрь бу очракта сәясәт һәм икътисад өлкәләренә карый торган карарларны тормышка ашыру (мәсәлән, «базарга йомшак керү») процессын ирония аша бик үткен итеп укучыга җиткерүгә ирешкән.

Дәүләт сәясәте турында язганда шагыйрьләр түрә-чиновник төшенчәләренә дә битараф кала алмыйлар. XIX гасырның тагын бер Һибәтулла Салихов исемле суфый шагыйре замана хакимнәрен еланга охшатып сурәтләгән. Шагыйрь хакимнәрнең, юк хатаны бар итеп, ришвәткә сатылып, зур җинаятьләрне күрмәмешкә салышулары турындагы фикерләрен шул рәвешле шигырь юлларына салып җиткергән. Суфыйчыл һәм мәгърифәтчел шагыйрь буларак, Һ. Салихов дидактик максатны алгы планга чыгара. «Начарлык кешегә кунган чебен» кебек сурәтләү чараларыннан файдалана.

Заманча яза торган татар шагыйрьләрен хәзер дә әдәбияттагы традицияләргә хилафлык итүдә гаепләп булмый. Менә М. Галиев та әлеге әдәби детальне шигыренә «тарихи черки» итеп кертеп җибәрә. Тагын да килеп, мисал өчен шагыйрь З. Мансуровның, түрә-чиновник һәм бөҗәк арасында параллель үткәреп, сурәт тудыруын гына искә төшерик. Аның кинаясе болай яңгырый:

*Эш җаваплы, ат канатлы—*
*туктаталмас берни дә.*
*Кайчак тотып тора икән*
*күзгә кергән черки дә.*

Билгеле, XIX гасырның үгет-нәсихәтчелек шигърияте белән М. Әгъләмнең кинаяле шигырьләре арасында уртаклык зур була алмый. Шагыйрьнең «аномалияле» шигырьләре белән танышу барышында күңелгә «бу шигырьләрнең көче нәрсәдә?» дигән сорау килә. Билгеле, беренчедән заманчалык көчле. Ул хәтта

«Заманасын җәлләп» шигырендә болай дип белдерә:

*Кешелек тә кешелектән чыккан,*
*Ни хәл итим—авыр замана.*
*Бу туклыктан*
*Йә ачлыктан микән?—*
*Ходай ярдәм бирсен аңа да.*

Икенчедән, шагыйрь әлеге өч ритмик буынлы 10-9 лы традицион үлчәмгә корылган шигырьдә төп фикер аңлата торган ике сүзне яңа юлга чыгарып, драматизмны көчәйтүгә ирешкән. Соңгы строфадагы өч омоним рифма («күбенә») әлеге тәэсирне арттырып та җибәрүгә сәләтле. М. Әгъләм хәлле түрәләрне чеметеп кенә калмый, бәлки үз теләкләрен дә әйтә. Шундый шигырьләрнең берсе «Изге теләк» дип атала.

*Шатланыплар күпме көл генә,*
*Һәммәбездән кала көл генә!*
*Байлыгыңны чәчеп көлч(е) әле—*
*Һәр хәерче булсын көлчәле.*
*...Шул заманны алып килчәле...*

Монысын инде шагыйрьнең «яңа татарлар»га мөрәҗәгате дип кабул итик. Күп тә өмет итми шагыйрь, һәр «хәерче»гә көлдә әче камырдан пешерелгән берәр кабартма булса да җитә. Шагыйрь төрлечә языла торган, ләкин әйтелештә берберсенә бик якын булган, паронимнар дип аталган тел чарасыннан файдаланган (көлчәле—көлче әле—килчәле).

М. Әгъләмнең соңгы еллар иҗатында лирик геройның тормышка бер дә ышанычы калмаганлыгын күрсәткән шигырьләре дә әледән-әле очрап тора.

*Мин дөньяга бары тамак ябып*
*Су эчәргә килдем,—*

дип белдерә ул. Ләкин кичеккәнлеген аңлый. Бәлки, барысына да искечә яшәү гаепледер, бәлки үзгәрергә кирәктер. Моңа да җавабы әзер шагыйрьнең:

*Яхшы эшнең бугазына басып,*
*Ямьсезлекне матурлыкка төреп,*
*Үзгәрергә, әнә керештеләр,—*

ди шагыйрь, әйтеләсе фикерне иронияләштереп. Шагыйрь иҗатында аерым кешеләрнең шәхси фаҗигасенә игътибар иткәннәре дә очрый. Шундый «аномалияле» шигырьләрнең берсе, «Димәк, беткән» исемлесе, суицид турында. Әлеге шигырь:

*Аягүрә ныклы торганда да,*
*Кеше кирәк барып егылырдай.*
*Рәхмәт илә дога кылганда да*
*Һәркем киләчәген уйлый бугай,—*

дип башланып китә. Кеше бүген белән канатланып алса да, кабатлана алмый, дип раслый шагыйрь. Яңача булдыра алмау, искене кабатларга теләмәү фәлсәфәсе кешене үзе теләп бу дөньядан ваз кичүгә китерә.

*Ышандыра күрмә, син беркемне:*
*Үзем төштем диеп, асылына.*
*Нигә икән көннәрдән бер көнне*
*Тиктомалдан кеше асылына.*

Шигырьдә суицидның сәбәбе дә ачылган. Шагыйрь «аның өчен дөньялыкта барып егылырдай кеше беткән» нәтиҗәсен чыгара. Әлеге дүрт строфалык шигырьнең баштагы ике юлы һәм соңгы ике юлы бер-берсенә шарт һәм нәтиҗә вазыйфасын үтәве белән дә кызыклы килеп чыккан.

Поэзия, илаһи матурлыкка тартылып, кешегә ләззәт хисе бирергә тиешле сәнгать төреннән санала. Беренче карашка әлеге шигырь поэзиягә куелган гомумталәпләргә җавап бирми! Ләкин М. Әгъләмнең уңышы шунда: ул шигырьдә яшәү фәлсәфәсенең асылын ачып бирүгә ирешкән. Гомумән алганда, Яңа гасыр поэзиясендә «антишигырь» дип аталган шигырьләр дә күренеп ала. Бу очракта иң уңышлы мисал итеп Р. Фәйзуллинның «Җан көеге», Г. Моратның «Урам кызы», «Сәрхуш хатын», М. Мирзаның «Эштән чыккан татар кызына» шигырьләрен билгеләп үтү дөрес булыр. Әлеге күренеш тә татар әдәбиятына бүген генә килеп кермәгән. Г. Тукайны искә төшерү дә җитә.

Ләкин сүз башыбыз М. Әгъләм иде бит. Ә менә «Көтүчеләр» шигырендә шагыйрьнең биографик моментлары да урын алган. «Иҗатымның чишмә башы— балачакта» дип исемләнгән бер әңгәмәсендә шагыйрь: «Көтү көттем мин, дүрт җәй рәттән... Мәктәп укытучылары көтүне бирдертмәделәр миңа. Чөнки алда сигезенче сыйныф—сынау тотасы ел! ... Ярар, алар тыя дип, теләгемнән кире кайтмадым... Дуңгыз көтәргә ялландым...»—дип искә ала. Эпиграф итеп С. Хәкимнең омонимлы шигырь юлларын алган әсәр болай башлана:

*Мин көтүче идем,*
*Көтү көттем.*
*Рәхәт котә-котә*
*Дөнья көттем—*
*Үз иңемдә тарттым мин аны,*
*Чыбыркыдай озын дөньяны.*

Шигырьдән аңлашылган төп фикерне болай дияргә булыр иде: балачакта көтүче булган, хәзерге көндә дөнья көтүче шагыйрь көтү кайткан кебек милләтенең үз-үзенә кайтачагын өмет итеп көтә бирә. «Көтү» төшенчәсе шагыйрьнең берничә шигырендә символик образга ук әйләнә. Бу символ «рәхәт котә-котә» дөнья көткән кешенең горурлыгын да, бала чакның матур хатирәләрен дә сыйдыра. Әлеге фикерне алда телгә алынган шигырьләрдән тыш тагын «Тик булсын», «Булмый кичәгечә» әсәрләреннән табарга була.

Кызыклы факт: татар әдәбиятында Г. Ибраһимовның «Көтүчеләр»еннән соң М. Әгъләмнең «көтүчеләр»енә бөтенләй башка символик мәгънә салынган. Г. Ибраһимовта «көтү көтү» җанны-тәнне баскан авырлыкны аңлатса, М. Әгъләмдә, киресенчә, романтик иркенлек мәгънәсен бирә. Ә менә өченче төрле «көтүче»не М. Галиевтән табарга була. Аның хәтта фәлсәфи фикер тулы «Мин көтүче булам, диган идем» шигыре дә бар. Ә менә «Хозурлык» шигырендә ул «гаярь чыбыркылы» көтүчегә мәдхия укыса, «урман-кырларга мәҗүсидәй гашыйк була белүче» көтүчеләрнең бүген бетеп баруын, хәзер һәммә кешенең чираты житкәч, чыбыркысыз көтүчегә әйләнүен сагыну хисе тулы «Көтүче» шигырендә сурәтли.

Дөрес, М. Галиевнең шигырьләрендә омоним формасы аша сүз уйнату сизелми. Ә менә М. Әгъләмдә, дөрестән дә, әлеге алым шактый еш очрый. «Сөен» шигырендә ул «дөнья—затлы кием—ботактагы тиен» төшенчәләре арасында параллель уздыра да булганына сөенеп яшәргә чакыра. Әгәр сөенә белмәсән, «кирәген бер тиен!» дип, татарлыкны сакларга өнди.

Омонимнар кулланып язылган шигырьләрнең барысы да сәяси тематикага карый дип раслау дөрес булмас иде. Шагыйрьнең ике строфалык бер шигыре «Шулай кыясың» дип исемләнә.

*Үз-үземне юатам да инде,*
*Үз-үземне кайчан кисәм дә.*
*Мәйданнарда эзләп табасың бит,*

*Нинди генә кием кисәм дә,*
*Кыяр-кыймас кына йөргән кебек*
*Баш җитмәстәй эшкә кыясың—*
*Мәйданнардан эзләп табасың да*
*Сүз эндәшеп җанны кыясың—*
*Кайчак—үзән,*
*Кайчак—кыясың...*

Әгәр «кыясың» омонимына игътибар итсәк, беренче бу төшенчәнең «кыю» тамырыннан килүе аңлашылса, икенче очракта фразеологик берәмлек аша «бимазалау» мәгънәсен аңлата. Өченче очракта, әлеге лирик геройны «җәфалаучы» затны кыя кебек горур итеп күрсәтә. Ә менә шигырь исеменә чыгарылган дүртенче мәгънәне аңлатса, М. Әгъләм үзе генә аңлата алыр кебек иде. Шигырьнең ритмик бөтенлеген бу юлы да шагыйрьгә хас булган һәм башлангыч, һәм юл ахыры рифмалары саклап тора.

Гомумән, шагыйрьнең иҗатында омоним формасы белән сүз уйнату шактый еш очрый. Бу күренеш, әлбәттә, үзе үк махсус һәм күләмле тикшеренү сорый.

М. Әгъләм һәрвакыт хаклыкны күзгә карап әйтә белде. Шагыйрь фикер-хисләрен «астан өскә карап» әйтә, шуңа аның шигырьләре халык күңеленә тиз юл таба. «Ыңгыраша гына» шигырендә дә ул авырая барган тормыш шартларына бәйле рәвештә гади халык һәм пенсионерларның хөкүмәт биргән «ташламаларга» мөнәсәбәтен күрсәтә. Дөрестән дә, шигырьнең соңгы юллары шагыйрьнең перспективалы фикер йөртүенә мисал булып тора. (Шигырь матбугатта 2004 елда дөнья күрде). Пенсионерларның митингларга «ташламалар» таләп итеп чыгуы «чигенү»нең соңгы чиккә җитүен аңлата лабаса. Ә лирик геройның үзенә килгәндә, «Лүзиягә соңгы шигырь»ендә ул:

*Мин үземнең кем икәнне беләм,*
*Беркемнән дә көтмим ташлама,—*

дип белдерсә дә, Лүзиягә «бу дөньяны ташлама»,—дип ялвара. Шуңа да карамастан, шәхес М. Әгъләмдә нинди генә авырлык килсә дә, миллилегеннән һәм шагыйрьлегеннән ваз кичми. «Шигырь йокламаган» дип исемләнгән бер әсәрендә ул «Миндә татар үлгән? Әллә инде йоклый?» дип сорый да:

*Шигырь бит шулай,*
*Кайчак бетә чама—*
*Елак булып чыга,*
*Табып кара чара!—*

дип үз-үзенә сорау бирә. Билгеле «елак шигырь»ләр язуда М. Әгъләм ялгыз түгел. Менә М. Мирзаны укып карыйк:

*Еламсык шигырьләр яза,*
*Тагын сыктый, димәгез...*
*Яралы җаным сулкылдый,*
*Ялгыш та бер тимәгез!*

М. Әгъләмнең шигырьгә Х. Туфан кебек сакчыл каравы күпләргә мәгълүм. Иҗатташларының язмышына да битараф түгел шагыйрь, һәм тагын аның позициясе—рәнҗетелгәннәр ягында. «Иҗат» шигырендә менә ничек яза ул:

*Иҗат белән кемнәр канатланып,*
*Кошлар булып күктә очмаган?*
*Азмы алар??? Очу хыялыннан*
*Мәхрүм калып гомер очлаган.*

Т. Галиуллин әйткәнчә: «поэзиянең үзәгендә бүгенге көн борчулары ятарга тиеш». Р. Харис та бит: «Шагыйрьләр, заманнарын сүгеп шагыйрь булган. Заман барган юлга / Алар гына читтән карый алган» дип яза. Шулай итеп, без дә М. Әгъләмнең «заманча» шигырьләренә бер караш ташладык. Дөрестән дә, шагыйрьнең әсәрендәге һәр сүзе, аны алыштырырлык сүз юклыгын күрсәтеп тора, шул ук вакытта шагыйрь сайлап алган нәкъ менә шул сүз бөтен әсәрнең эчтәлеге таләп иткән уй-фикерне биреп тә бетерә.

М. Әгъләм шигырьләрен укыганда, М. Вәли-Барҗылы фикерләре искә төшә: «Шигырь шагыйрьләр өчен генә түгел, ә үзләренең хис-кичерешләрен шигырьдә табарга теләгән меңнәр һәм миллионнар өчен дә языла. Аны әнә шул миллион йөрәкләргә бәйләгән җепләр никадәр күбрәк булса, шигырьнең гомере дә шунын хәтле озынрак». Сүз дә юк, хак әйтелгән фикерләр...

**Фәридә ХӘСӘНОВА,**
филология фәннәре кандидаты

---

## *Алхәбәр*

### Зәки Зәйнуллин

*Әлеге өзек Зәки Зәйнуллинның Кави Нәҗми турындагы романыннан алынды. Бу яңа әсәрне киләсе елгы саннарыбыздан укый аласыз.*

«Фадеев Кавины урман эченә сузылган сукмактан алып кереп китте. Дәшми генә биш минутлар чамасы барды да, тукталды. Кави да туктады. Аның йөрәген, башынниндидер билгесез шом, тынычсызлык били башлаган иде. Ничәмә-ничә еллар инде белеп, ул Фадеевның шулай борчылу хәлендә икәнен беренче мәртәбә күрә иде. Туктагач, түзмәде, сорыйсы итте:

—Кәефегез юк кебек, Александр Александрович? Берәр начар нәрсә бармы әллә?

—Бар шул, Кави. Сезнең өчен бик тә начар вакыйга булуы мөмкин.

—Кем ул «сезнең өчен» дигәнегез?

—Сез, татарлар өчен.

Кавиның йөрәген, башын утыз тугызынчы елны НКВД подвалыннан алып чыккан курку, шом били башлады. Колаклары чыңларга тотынды. Фадеев аның кулбашыннан сул кулы белән тотты:

—Тыныч кына тыңларга тырыш инде син мине. Бу көрәшү безнең соңгысы булуы да бик мөмкин».

# ТАТАРНЫ ҮЗ ИТКӘН НЕМЕЦ

Карл Федорович Фукс 1776 елда Германиянең Һерборн шәһәрендә профессор гаиләсендә туган. 1798 елда ул Марбург университетында медицина һәм хирургия буенча докторлык диссертациясе яклый. Аннары Россиягә килеп, Санкт-Петербургта хәрби полк табибы булып эшли башлый.

1805 елдан алып гомеренең соңына кадәр аның язмышы Казаныбыз белән бәйле. Яңа ачылган университетта хезмәтен ул табигать фәннәре тарихы һәм ботаника кафедрасы профессоры буларак башлап җибәрә. Студентларга үз фәненә кызыксыну уятырлык лекцияләр укый; табигатькә чыгу, үсемлек төрләре, һәртөрле бөҗәк, күбәләкләр җыю Фуксның укыту программасына кертелгән була. Бу хакта аның укучысы, танылган язучы С. Т. Аксаковның кызыклы язмасы бар.

1819 елда Карл Фукска патология, терапия һәм клиника кафедрасы тапшырыла, ә инде алдагы елда аңа анатомия, физиология һәм суд медицинасы буенча лекцияләр уку йөкләнә.



Карл Фукс Идел буе төбәгендә иң танылган табиб була. «К. Ф. Фуксның табиб буларак, кеше сөючәнлеге үзе бер үрнәк. Мохтаҗлыкта яшәгән авыруларны караганда ул акчалата ярдәм итә, ризыктан да калдырмый, аптека даруларын да табып бирә торган була. Үзем шаһит булганым бар: минутларны санап, яраткан табибын көтеп яткан авырулар, ул килеп кергәч бөтен хасталарын онытып, йөзләре нурланып китә торган иде»,—дип яза замандашы Н. А. Скандовский.

Фукс гарәп, татар телләрен өйрәнә, иске кульязмалар, татарның борынгы тәңкәләрен халыктан җыя.

Профессор Френ исәпләгән тасвирламада Фукс туплаган дүрт йөз туксан биш тәңкә искә алына, шуларның 410ы—Җучи династиясенә, калганнары Иран белән Туранга карый. Сирәк, бик сирәк, кайсылары бөтенләй очрамый торган бу тәңкәләрнең 392се көмеш, 103е бакыр була. Фуксның Алтын Урда дәверенә караган тәңкәләр тупланмасы аерым бер әһәмияткә ия. Чөнки сугылган акчаларда Батудан башлап Олуг Мөхәммәдкә кадәрге кыпчак-татар чыңгызыйларының тәхет көчеше эзлекле бер рәттә тулысынча диярлек чагылыш таба. Кызганыч, Фуксның университетка тапшырылган, дөньяда тиңе булмаган бу коллекциясе Шәрык разряды белән бергә 1850 елда Санкт-Петербургка күчерелә (татарның хәтерен бетерергә тырышуда тагын бер адым!).

Фукс тырышлыгы белән университетның ботаника бакчасы булдырыла. Төп бина урнашкан ишегалдында, хәзерге обсерватория һәм Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханә урынында 1806 елда бу бакчага нигез салына. Берничә ел үтүгә, ботаника бакчасында сигез йөз төрдән артык үсемлек туплана. Орлык һәм үсентеләр Ригадан алып Якутскига кадәрге арадан—бөтен Россия өлкәләреннән кайтарыла. Европа илләреннән, Англиядән, Бразилиядән махсус орлыклар сатып алу оештырыла.

Карл Фуксның үз йорты да музей кебек була. Андагы борынгы кульязмалар, сирәк китаплар, кош-корт карачкылары, күбәләкләр коллекциясе, картина галереясы, борынгы әйберләр тупланмасы күргән бер кешене шаккатыра.

Казан журналисты Н. Я. Агафоновның "Казанские вести"дә 1891 елда ба-

сылган мондый бер язмасында болай диелә: «Фукс яшәгән йорт ихатасында үзгә бер күренешкә тап буласың. Анда аю балалары титаклый, койма аша тәва, фазан, торна, попугай кебек кошларны күрергә мөмкин; су җибәрелгән чокырда ташбакалар, кәлтәләр йөзә; ихатаның бер почмагында дөя, болан, кыргый ат тора. Һәркөнне урам малайлары җыелышып килә, койманы сырып алып, эчтәге дөньяны рәхәтләнеп тамаша кылалар. Өлкәннәр моны хәзер дә хәтерләп сөйлиләр әле».

1844 елда Карл Фукс гомеренең данга күмелгән иң югары кимәлендә була. Төбәкнең фәнни тикшеренүчесе, белгече булуы белән ул бигрәк тә горурлана. "Казан татарлары: статистик һәм этнографик җәһәттән" дигән китабы чыгуаның бу өлкәдә олы хезмәт куюын һәм татарларның тормыш-көнкүрешен өйрәнүгә беренче булып юл сабуын раслый.

Европа галимнәре, шул исәптән, төрле милләт исеме астында Россиягә үтеп кергән яһүдләр дә, гадәттә, бүтән бер халыкны сурәтләгәндә вәкарь биеклектән торып, үзе аңламаганнан мыскыллы көлебрәк, ваемсыз тасвирларга күнеккән. Карл Фукс бөтенләй башка. Немец кешесенә җиде ят кавемнең бөтен хикмәтләрен аңлау җиңел булмаса да, кайберләрен аңлап җиткермәсә дә, ул аңларга омтыла, Казан татарларының эчендә кайнап, күңел хасиятенә үтеп кереп, яратып яза, халкыбызның холык-табигатен, шул чордагы яшәү рәвешен, дини йолаларын, бәйрәмнәрен тарихи хәтер көзгесендә җанлы, тере мисалларда чагылдырып кала.

Галим Н. И. Воробьев бу хакта болай дип яза: «Казан татарларының яшәү рәвешен үтемле итеп яза белүе өстенә, Фукс көндәлек тормышта да бу халыкка карата гаҗәеп яхшы мөнәсәбәттә була, Европа галимнәре арасыннан аңа кадәр дә, аннан соң да татар халкының сөеклесенә әверелеп танылган бүтән берәү дә булмый».

Күпкырлы галим буларак, Карл Фукс Казан төбәге белән һәрьяклап кызыксына. Менә бер мисал.

1842 елның 24 августында коточкыч янгын чыгып, Казанның 70 кварталы, 1500гә якын йорты янып көл була. Шул янгынга кадәрле Фукс губернатор Мусин-Пушкиннан шәһәр архивына кереп Иван Грозный чорына һәм тагын да борынгырак заманнарга караган, тарих өчен кыйммәтле документларның күчермәсен алырга рөхсәт сорый. «Ул дәвердә губернатор булып надан кеше утыра иде. Французча сөйләшкән булса да, гамьсез-битараф, уенда эш түгел, ә карт сугу һәм хатын-кызлар иде. Ул мине бик тупас кабул итте, минем үтенечемә «әйе» дә, «юк» та димәде. Шуннан соң күп тә үтмәде, янгын чыкты; дәүләт учреждениеләре белән бергә әлеге кыйммәтләр дә, түрәләрнең оятына каршы, янып юкка чыкты. Чөнки ут өермәсе дәүләт учреждениеләренә пожарның өченче көнендә генә килеп җитте. Губерна идарәсе бинасын ут чолгаган иде инде, мин анда кереп грамоталарны коткарырга омтылыш ясаган идем, әмма ялкын шулкадәр көчле иде, миңа ул ниятемнән кайтырга туры килде. Кирмәнгә керү юлына да урамнарны чолгап алган ут ялкыны аша якын килү мөмкин түгел иде.».

Шулай итеп, татар тарихының тагын бер өлеше чын мәгънәсендә җан атып йөргән Карл Фуксның күз алдында янып юкка чыга.

Көл ителгән университет обсерваториясе бинасыннан ялкын телләре китапханә бинасына таба үрли. Анда—40 000 том бибәһа басмалар. Китапларны студентлар Арча кырына күтәреп ташыйлар.

Дәһшәтле ут ташкыны Болак аша аргы якка сикерә. Ялкын телләре үз өенә таба якынлаша башлагач, Карл Фукс коллекцияләр салынган сандыкларын коткарырга керешә. Бар да исән кала, әмма гадәттән тыш дулкынлану, көч килү Фуксның сәламәтлегенә суга. Бөек табиб параличны уздырып җибәрсә дә, тулысынча савыгып җитә алмый.

1846 елның 24 апрелендә Карл Фукс дөнья куя. Мәрхүм белән хушлашырга бөтен шәһәр халкы агылып килә. Профессор Н. А. Скандовский бу хакта болай дип яза: «Төрле дәрәҗәдәге гражданнарның, төрле дин мәзһәбендәгеләрнең, олысы-кечесенең табут тирәсендә туплануы—күмү мәрасименә болай гына кызыксынып җыелуы түгел иде. Бөтенесе дә халыкның күз карасы кебек кешесен соңгы тапкыр күреп калырга тели, мәрхүмнең саваплы эшләре өчен һәммәсе күңеленнән рәхмәтен белдерә, дога кылып, җан шәрифен якты дөньяларга иңдерсен иде дип Ходайдан сорый иде. Әйе, Карл Федорович Фукс җәмәга-

тенә һәм бердәнбер кызына аз мөлкәт калдырды; әмма ул сирәк була торган хәзинә—кешелек дусларына үзе хакында асыл сәхифә калдырды. Бу истәлекне алар, һичшиксез, киләчәк буыннарга тапшырырлар.".

Танылган галим, табиб, табигать фәннәре белгече, төбәк тарихын өйрәнүче, нумизмат, журналист, олы йөрәкле кеше—Карл Фукс истәлегенә 1896 елда шәһәр Думасы аның өе урнашкан Поперечно-Тихвинск урамына Фукс исемен бирергә, Казансуның текә яры турына бакча ясап, аңа Фукс бакчасы дип исем кушарга дигән карар чыгара. Бу карар җиренә җиткереп гамәлгә ашырыла.

1996 елда Казаныбызда Карл Фукска үз исемендәге бакчада һәйкәл куелды.

Онытылырга дучар ителгән язма мирасыбызны барлап халыкка кайтару буенча олуг миссия башлап җибәргән академигыбыз Миркасыйм Госманов җитәкчелегендә Татар телен һәм мәдәниятен саклау һәм үстерү фонды («Җыен») Карл Федорович Фуксның үз хезмәтләрен һәм аңа багышланган язмаларны туплап 2005 елны саллы китап бастырып чыгарган иде инде. Хәзер менә шул китапның татарчага тәрҗемәсе әзерләнә. Әлеге җыентыкка керәсе «Казан татарлары...»н беркадәр кыскартып журналда бирсәк, укучылар өчен кызыклы булыр дип уйлыйбыз. Ике гасыр элеккеге чор бит ул... Бу дәвер эчендә илләр ава, дәүләтләр җимерелә, халыкларның телләре бетә, исемнәре үзгәрә, яңа утраулар калка, шәһәрләрне җир йөзеннән себереп түккән цунамилар уза. Гасыр арты гасыр... Казан татарлары элек нинди булган, ни рәвешле гомер сөргәннәр—бүгенгебез белән чагыштырып карыйк әле. Хәерле сәгатьтә!

**Марсель ГАЛИЕВ**

Карл
Фукс

# КАЗАН ТАТАРЛАРЫ*: СТАТИСТИК ҺӘМ ЭТНОГРАФИК ҖӘҺӘТТӘН

Казан татарлары, буйсындырылганнан соң өч йөз ел үтсә дә, күзәтүчән этнографның олуг игътибарын җәлеп итәрлек дәрәҗәдә күп кенә үзенчәлекле якларын, милли сыйфатларын саклап калганнар. Алар руслардан һәм башка кавемнәрдән аерымланыбрак, кайчандыр ата-бабаларына хас булган өстенлек сыйфатларын тоеп яшиләр.

Үзләренең чыгышы, әхлакый сыйфатлары, дине, яшәү рәвеше белән горурлана белү тойгысы аларның үзгә бер холык-табигатен билгеле дә инде.

Татарларның гореф-гадәте хакында бәян итүдән элек кайбер саннарга тукталмакчы булам.

Ир-ат һәм хатын-кызларны бергә исәпләгәндә Казанда яшәүче татарлар саны 6 мен 500гә җитә. Күпләп яшәгән урыннары—шәһәрнең көньягында, Иделгә таба урнашкан Иске һәм Яңа бистәдә 786 йорт-кура, сигез мәчет һәм шулкадәр үк мәдрәсә, кунак йорты һәм магистрат йорты бар.

Шушы халык санына кәрә:
1нче гильдия купецлар—5 гаилә;
2нче гильдия купецлар—3 гаилә;
3нче гильдия купецлар—68 гаилә.
Әлеге 76 гаилә эчендә:
Ирләр—376;
Хатын-кызлар—375.

*Марсель Галиев тәрҗемәсе. Тәрҗемә кыскартып басыла.

Жәмгысе купецлар катлавыннан 751 кеше.
Мещаннар—722 гаилә;
Ирләр—1.736,
Хатын-кызлар—1.934
Жәмгысе—мещаннар катлавыннан 3.670 кеше.
Шушы 4.421 кешедән торган сәүдәгәр һәм мещаннар ике татар бистәсендә утрак көн итүчеләрнең төп санын тәшкил итә.

Әмма якын тирәдәге авыллардан 700ләп кешенең ел саен вакытлыча килеп, рус һәм татарларның тире иләү, сабын кайнату заводларына эшкә урнашуы аркасында татарлар саны арта тора. Шулай ук Казан губернасының төрле өязләреннән килгән, Казан мещаннары санына теркәлгән 850ләп сәүдәгәрне дә монда өстәргә мөмкин. Хәзер мин Казанда нигез корып яшәүче татарларның яшен яшькә аерып, таблицага бүлеп чыгам.

| | Ир-атлар | Хатын-кызлар | Жәмгысе |
|---|---|---|---|
| 5 яшькәчә | 385 | 330 | 715 |
| 5 тән 10 яшькә чаклы | 267 | 241 | 508 |
| - 10—15 - | 234 | 237 | 471 |
| - 15—20 - | 177 | 241 | 418 |
| - 20—25 - | 186 | 226 | 412 |
| - 25—30 - | 181 | 219 | 400 |
| - 30—35 - | 120 | 141 | 261 |
| - 35—40 - | 120 | 145 | 265 |
| - 40—45 - | 102 | 131 | 233 |
| - 45—50 - | 73 | 106 | 179 |
| - 50—55 - | 70 | 91 | 161 |
| - 55—60 - | 69 | 90 | 159 |
| - 60—65 - | 47 | 52 | 99 |
| - 65—70 - | 43 | 27 | 70 |
| - 70—75 - | 23 | 17 | 40 |
| - 75—80 - | 11 | 9 | 20 |
| - 80—85 - | 4 | 1 | 5 |
| - 85—90 - | - | 3 | 3 |
| - 90—95 - | - | - | - |
| - 95—100 - | - | 2 | 2 |

Жәмгысе—2.112—2.309—4.421.

Соңгы 40 ел эчендә Казан татарлары сан ягыннан шактый кимеде, дигән фаразлар бар. Моның сәбәбе күп хатын алу нәтиҗәсендә дигән фикер дә йөри; әмма мин, үз күзәтүләремнән чыгып, бу фикер белән тамырдан килешмим. Татарларның бик азы гына ике яисә аннан да күбрәк хатынга өйләнә. Бу өлкәдә мин менә нәрсәләр ачыкладым: Казанда татар ирләренең җәмгысе 55е ике хатын белән тора, фәкать алтысы—3әр, нибары 2се—4әр хатынга өйләнгән. Нәтиҗәдә: 63 ир-атка 136 хатын туры килә.

Әлеге 63 никахлының кайберләре бөтенләй баласыз, мәсәлән, 44 яшьлек бер татарны мисалга китерә алам: өлкән хатынына 38 яшь, кечесенә—14, икесенең дә балалары юк; 62 яшьтәге бер ир шулай ук ике хатын белән яши, беренчесенә 41, икенчесенә 28 яшь—икесе дә баласызлар; өченче ирга 41 яшь, 30 яшьлек беренче хатыныннан да, 17 яшьлек икенче хатыныннан да баласы юк; дүртенче ирга 26 яшь, үз яшьтәшләре булган ике хатыны шулай ук, бала китермәгән.

Мондыйлар арасында ишле гаиләләр дә очрый. 48 яшьлек бер татарны беләм, өч хатынга—7 малай, 2 кыз; 45 яшьлеге—3 хатынга 4 кыз, 67 яшьлегенең—4 хатынга 5 улы, дүртенче ирнең 2 хатынга—7 ул, 2 кызы бар.

Гомумән алганда, бер хатын белән генә яшәүче татарлар үрчемлерәк, гәрчә бу

яктан руслардан калышсалар да...

Күп хатынлы гаилә тотучыларның иң нәселлесе, мөгаен, Казанның элеккеге ахуны Саттар Сәгыйтовтыр. Ул дүрт хатынга өйләнә, берсе Бохарадан, калганнары– Казан татар кызлары. Үзе мондагы мещан; мәрхүм булганнан соң тол калган өлкән хатыны 3нче гильдия купец катлавына языла. Ахунның балалары: Хәдичә (24 яшь), Зөһрә (22 яшь), Мәфтуха (20 яшь), уллары: Габделкаһар (20 яшь), Хәсәнҗан (18 яшь), Хөсәен (12 яшь), Фәхретдин (11 яшь), Сәгетдин (11 яшь), Садыйк (9 яшь), Габделнасыйр (7 яшь), Йосыф (4 яшь).

Шушы мисаллардан чыгып кына да, күп хатынлылыкның халык саны артуга мөһим йогынты ясамавын аңларга була.

Мин үзем халык саны кимүгә икенче бик җитди сәбәпләрнең берсе булып татарларның рус трактирларына тартылуы, анда Европа зиннәтләренә кызыгып эчкечелеккә бирелүеннән дип саныйм. Бу мавыгу аларда соңгы егерме елда бик тә көчәйде. Күп кенә татар сәүдәгәрләре һәм мещаннары көн дә диярлек трактирларга сугылып, шактый акчаларын калдырып чыгалар. Килеп кергән унайга каты аракыга хуш исле үләннәр кушып төнәтелгән бәлзәмне 2-3 рюмка соратып алдыралар; аннары чөгә балыгыннан үтә тәмле пешерелгән солянка китертеп, аңа мул итеп куәтле сыра серкәсе салалар; болардан соң инде иң яраткан эчемлекләре сыра килә. Гадәттә бер татар бер утыруда 5-6 шешә, тазараклары хәтта 12 шешәне бушатып куя. Эчү мәрәкәсендә үзләренең яраткан җырларын сузалар, орган музыкасын яратып тыңлыйлар. Сәламәт татар руска караганда өчләтә артык эчә һәм ашый дияргә мөмкин. Әмма аларның мәҗлесендә ызгыш-сугышлар русларныкына караганда сирәк кабынып китә. Кабына икән, тиз генә сүндерәм, тынычландырам димә. Тәкәбберлекләре ярсулы ызгышканда да үзен сиздерә.

Алар татлы ризыкны гадәттән тыш яраталар: җәйге көн иде, күзәтеп торам, бер татар трактирның ачык тәрәзәсеннән туңдырма сатучыны чакырып китерде дә, комсызланып, стакан арты стакан туңдырма ашый башлады, ахырда сатучының берәү дә калмады.

Кайчакларда алар трактирга үрдәк түшкәсе яисә сыер ите кыстырып килеп солянка пешертәләр, чөнки алар рус чалган мал итен ашамыйлар; кайсылары ашны кире дә какмас иде, руслар дуңгыз итен салып пешергәндер дип куркалар шул. Кәрван сарайда (Гостиный двор) сату итүче бай татар сәүдәгәрләре дә, бистәдәге өйләре ерак булганлыктан, төшкелеккә рус трактирына керәләр...

Татарларның сан ягыннан ни өчен артмавына тагын бер сәбәп турында әйтмичә кала алмыйм. Хатынлыкка артык яшь кыз баланы сайлау, хөкүмәт тарафыннан катгый тыелган булуга карамастан, бигрәк тә байлар арасында күп таралган. Өлгереп җитмәгән мондый хатын-кызларның чырайлары көлсу, сырхау була. Андыйлар йә бөтенләй бала таба алмыйлар, йә тиз арада үлемгә дучар ителгән, зәгыйфь, җитлекмәгән бала китерәләр.

Күп татарлар, рекрутлыкка алынмасын дип, үз улларын төрле өязләргә, хәтта бүтән губерналарга теркәтәләр. Шулай итеп, Казан татарларының саны елдан-ел кими бара. Трактирларда акчасын туздырып яисә шәһәрдә сату эшендә бөлеп, күп кенә Казан татарлары купец яки мещан кавеменнән төшеп кала, сәүдәгәр-крестьянга әверелеп, төрле өязләргә юл йөри башлый. Инде килеп, шуны да искәртергә кирәк, татарлар төрле эш урыннарына сайланудан шул кадәр куркалар ки, хәтта башлык дәрәҗәсенә яисә Ратуша әгъзалыгына сайлануны да хуп күрмиләр. Шундый мисаллар да бар: кайберәүләре сайланудан куркып бүтән губерна шәһәрләренә күчеп китәләр.

Татар бистәсенең урамнары шәһәрнең гомум планы буенча төзелсә дә, анда фонарьлар юк, юллар түшәлмәгән, шунлыктан, бигрәк тә көзге айларда ерып чыкмас саз була.

Күп йортлар агачтан, икешәр катлы, таштан, шәп итеп төзелгән өйләр дә хәтсез күренә. Йортларны монда рус осталары сала, мәчет төзелешендә дә аларны күрергә мөмкин. Киресенчә дә була: мин рус авылында татар ирләренең бура бурауларын еш күрдем.

Ызбаның аскы каты амбар хезмәтен үти яисә вакытлыча файдалануга биреп

торыла, өске катта исә хужалар үзләре яши. Элегрәк татарларның шәһәрдәге йортлары авылдагыча төзелә иде: йорт үзе, галәттәгечә, ишегалды уртасында, әйләнә тирәсен амбар-коймалар уратып ала. Хәзерге көндә дә әле мондый йортларның берничәсе сакланып калган.

Татарларда сәер бер гадәт бар: мәчет-мәдрәсәләре җәмгыять тарафыннан төзелми, төзәтелми, ә аерым бер бай карамагында була. Кайбер җәмәгать биналарының әйбәт сыйфатта тотылмавының сәбәбе шуннандыр дип уйлыйм.

Гадәти мешан йортларының эче мондыйрак тәртиптә: ак бүлмәгә үтәсе ишектән уң кулда зур мич тора; аңа аш пешерә торган казан беркетелгән. Мич уентыгында җиз комганнар. Берсе—ирнеке, икенчесе—хатынныкы. Йола буенча алар икесе бер комганнан файдаланырга тиеш түгел. Юыну өчен мич аралыгындагы почмакка зур җиз таз куелган, бит-кулны, аякны сөртергә аерым-аерым ике сөлге эленгән.

Арырак, уң кулда—стенага терәлгән киң сәкедә чаршау аша кабартып куелган мендәр-ястыклар күренә. Чаршау эленмәгән очракта, ястык-юрганнарны бөтереп, стена буена өеп куялар. Ишеккә туры уң якта йоннан тукылган чәчәкле-чуклы эскәтер җәелгән өстәл тора. Өстәлгә кечкенә терәтмә көзге куелган. Сулдарак, почмакка таба, савыт-саба, фарфор чынаяклар тезелгән тагын бер өстәл. Стена буенда гади агач урындыклар, самавыр һәрчак мич кырыенда булыр. Өстәлләр арасында стенага якын куелган, бик матур бизәкле җиз калай белән тышланган, өстенә келәм җәелгән ике сандык өй эчен күркәмләтеп тора. Каршы диварда көзге, идәндә гали генә келәм, тәрәзә төбе саен кына, хуш исле рәйхан гөлләре. Зур мичтән уң якта чаршау белән бүленгән урын бар. Гадәттә хуҗа ир кунаклар белән мәҗлес корып утырганда, хатыны табынны карый һәм бер арада шушы пәрдә артына кереп ялгызы гына тамагына капкалап ала. Өялды түрендә мичсез генә бер бүлмә булыр. Анда тун, толып ише һәртөрле кием-салымнар, кирәк-яраклар эленгән. Җәйге эсседә хуҗалар йокы урынын да монда күчерәләр.

Бай татар купецларының йорты тышкы яктан рус дворян-купец йортыннан әллә ни аерылып тормый. Өй эчен күп вакыт рус малярларыннан бизәтәләр: чәчәкле урман аланы, елга күренеше яисә җилкәнле кораб йөзгән диңгез манзарасы ясаталар; ләкин бер йортта да син адәми зат, кош-корт, җәнлек сурәте күрмәссен. Бу—катгый тыелган. Зур бүлмәләрдә европалагыча эшләнгән диван- урындыклар. Өстәлләр һәрчак бизәкле эскәтер белән капланган булыр. Стена буенда берничә зур көзге. Көзге кую аларда әле күптән түгел генә гадәткә керде. Хәзер инде һәрбер сәүдәгәр, өенең мөһим бер күркәмлеге итеп, көзге куюга аерым игътибар бирә. Идән затлы фарсы келәмнәре белән капланган. Почмакларда кызыл агачтан эшләнгән комод-шкафлар. Рус купецларындагы кебек монда син шкафларда көмеш заты күрмәссен, татарларда көмеш калаклар куллану тыелган; аның каравы, яхшы сыйфатлы фарфор, җете бизәкле кытай фарфорыннан эшләнгән чынаяк, савыт-сабаны бигрәк тә яратып кулланалар. Байлар өендә дә татарның иң кирәкле әшьясы—зур җиз таз, комган, бизәкләп чигелгән ике сөлге, болардан да өстә хуҗа ирнең мәчеткә намазга барганда кия торган ак чалмасы эленеп тора. Сәүдәгәр өенең һәрберсендә диярлек читлек бар, читлек эчендә мисыр күгәрчене, хатынынны калдырып китмә, дип гөрелдәп утырадыр сыман. Түшәмгә бәллүр люстралар асылган, стеналарда—май лампалары. Бөтен тәрәзә төпләре, бигрәк тә урам якка караганнары чүлмәккә утыртылган лимон, инҗир куагы, яран, бохар кынасы, хуш исле рәйхан гөлләре белән бизәлгән. Өстәлләрнең берсенә Казан басмасындагы Коръән, тышлыгы бик матур бизәлгән кыйммәтле дини китаплар куелган. Стена сәгате, төрле җиргә кул сәгатьләре эленгән. Монда син хатын-кызны күрмәссен: алар арткы бүлмәләрдә, ирләргә анда керергә ярамый. Кунаклар җыелган табынны ир-егетләр карый.

Табиб буларак, берничә мәртәбә мина хатын-кызлар ягына керергә туры килде. Хуҗа ир мине әллә ничә буш бүлмә аша үткәреп, йокы бүлмәсенә хәтле озатты да, өлкән яшьтәге ханымны чакыртып, мине авыру янына озатырга кушты, үзе кермәде. Йокы бүлмәсендә купшы келәм җәелгән киң сәке, бихисап мендәрләр күзгә ташлана. Стенада һәрьяклап хатын-кыз күлмәкләре, бик кыйммәтле туннар эленгән. Урындыклар юк, алар урынына искиткеч матур итеп каймалап эшләнгән, өстенә

келәм җәелгән зур-зур сандыклар куелган иде. Минем авыру ханым затлы пәрдә артында ястыкта ята иде. Мин, белгән кадәр татарчалап, пульсын тикшереп карарга рөхсәт бирүен үтенгәч, пәрдә астыннан кул сузылды. Алтын беләзекләрдән, һолланд тәңкәләреннән торган кулдан кан тибеше урынын табу мөмкин түгел иде, бик озак үтенә торгач, бу зиннәтләрне салып куярга көчкә ризалаштырдым үзен.

Иң мөһиме—авыру ханымның телен караган арада матур инсәсен күреп калу теләге котырткан иде дә, янәшәмдә торган карчык моңа теше-тырнагы белән каршы килде.

Бай Казан татарларының көндәлек ризыгы түбәндәгечә: таннан торып чәй эчәләр, эченә сыер ите турап салынган, пәрәмәч дип аталган кечкенә пирожки ашыйлар. Төшке ашка: 1) катык катылган, сыер итеннән ясалган пилмән (казан бөкмәсе), яки таралып пешкән сарачин бодаена[1] йөзем кушылган пылау; 2) түгәрәк бәлеш (ит, борай), моңа ияртеп тозлы кыяр бирелә; 3) кыздырылган каз яисә үрдәк ите, бәрәнге белән; 4) пешкән сыер ите, керән яисә тозлаган кәбестә белән; 5) башта парда тотылып, аннары суытылган өрек 6) чәй, бавырсак дип аталган, урман чикләвеге зурлыгындагы баллы кечкенә пирожкилар белән. Кичке сәгать алтыда тагын сөт өсте салып бавырсак белән чәй эчәләр. Кичке ашка пилмән яисә токмач ашы бирелә.

Мещаннарның һәм бай булмаган татарларның ризыгы мондыйрак: иртән ак күмәч белән чәй эчәләр; төшкелеккә токмачлы аш яисә пилмән ашыйлар. Татар крестьяннары иртән тоз салып суда кайнатылган арыш оны (боламык йә талкан); төшкелеккә—умач (сарык мае кушып уылган кечкенә камыр кисәкләре), җәйге көннәрдә саран гына майда пешкән карабодай боткасы, аңа катык яисә каймак кушыла; кичләрен тагын шул ук боламык. Бәйрәмнәрдә исә сарык ите дә эләгә. Җыен бәйрәмендә, туйларда инде елкы ите табынга килә.

Татар сәүдәгәрләренең киенү рәвеше аерым игътибарга лаек, чөнки алар бүтән бер халыкка да охшамаганча киенәләр. Ирләрнең ситсыданмы, бәзләнме, кытай ефәгеннәнме тегелгән ак яки кызыл күлмәге тезенә кадәр төшеп тора. Ыштан балаклары киң. Оеклары киҗе мамыктан. Оек урынына сафьян күннән эшләнгән сары яки кызыл читек киючеләре дә бар. Башмаклары (кәлүш) кара яки яшел төстә. Күлмәк өстеннән камзул: парча яки ефәктән, җиңсез. Аның өстеннән җилле,, озын итәкле, әдрәс эчле ефәк казаки киелә. Аннары инде зәңгәр сукнодан яки киҗе-мамыктан тегелгән чикмән киеп, билен ефәк билбау белән буып, култык астына ефәк кульяулык та кыстырып куйгач, башка түбәтәй генә киясе кала. Гади түбәтәй биш сум булса, алтын белән тәкыялап чигелгәне 60 тәңкә тора. Салкында нинди дә булса мех белән каймаланган бүрек кияләр. Байларныкы—кондыз мехы белән каймаланганы 400 сумга төшә.

Һәр шимбәдә татарлар сакал-мыек төзәтәләр, ике атна саен чәч кырдыралар. Җомга көнне иртән үз мунчаларына барсалар, шимбәдә исә күпләре русларның сәүдә мунчасына йөри. Хатыннары һәр 40 көн үткән саен, нәни эскәк белән коралланып, култык астындагы һәм җан җирендәге төкне йолкып, аны күкерт кисәгенә ябыштыралар. Бу—нәзберек урыннарда тән тиресе катыланмасын дип эшләнә торган, шактый четрекле һәм авыртулы операцияне җиңеләйтү өчен алар бритва кулланмыйлар. Татарлар тәнгә йон үсү кебек табигый бизәкләр булганда Аллаһыга гыйбадәт кылу ярамый дип саныйлар.

Мулдан яшәүче сәүдәгәр өендәге хатын-кыз киеме:

1) Укалы, чачаклы ефәк калфак, хакы 50 сум. Никахлы хатыннар яулыгы ефәк яки парчадан эшләнә, очлы түбәсе уң якка ятып тора. 2) Көмеш кашлы, чөлдерле алтынланган алканың якынча бәясе 35 сум. 3) Муенса (каптырма); чага—алтынланган көмештән, асылташлардан, бигрәк тә фирүзә белән бизәлә, сурәте тән ягына каратып куелган алтынланган тәңкәләр тезелә, хакы 60 сум. 4) Күлмәк—ситсыдан, киҗе-мамыктан (китайка) яки ефәктән, чуар төстә, итәге үкчәгә кадәр төшеп тора, өч рәт бөрмәләнгән балитәкле, яка һәм түш тирәсенә ука тасмалар тегелә—хакы 80 сум, әгәр инде парчадан тегелсә—350 тәңкә тора. 5) Ыштан—комачтан булса, 9 аршын, ситсыдан 6 аршын, чуар ефәктән киң итеп эшләнгәне 5 аршын. Байларныкы 15 тәңкә тора; урта хәлле хатын-кызларныкы—4 тәңкә, авылнықы-

[1] Сарачин бодае – борай булырга тиеш (М. Галиев искәрмәсе).

ларның бетле бәздән тегелгәне 25 тиен. 6) Читек—сәхтиян күннән, ефәк жөй белән бизәкләнгән, кызыл, сары, яшел төстә, 9 тәнкә тора, алтын белән чигелгәне 18дән 30 сумга кадәр бәяләнә. Оек урынына балтырны юка сөлге белән урыйлар. 7) Кызыл сәхиян күннән, алтын жеп белән тегелгән туфли бәясе—7дән 10 сумга кадәр. 8) Хатын-кыз түшен каплап торган, ука белән бизәп, парчадан эшләнгән күкрәкчә—10 тәнкә тора. 9) Ефәктән ука белән каймалап тегелгән, тезгә чаклы төшеп торган, уң якта кульяулык тыгу өчен кесәсе булган (татар хатын-кызы кульяулыкны беркайчан да кулына тотып тормый) камзул 80 сумнан 400 сумга чаклы бәяләнә. 10) Шактый озын жиңле, озын итәкле, укалап парча яисә ефәктән тегелгән жилән байлар өчен 2000 тәнкәгә житә. Хәзер инде жилән модадан чыгып килә; аның урынын озын жиңле камзул биләп бара; байларның парчадан, ярлыларныкы китайка яисә киже мамыктан, эче төлке яисә куян тиресеннән астарлап тегелә. 11) Алтын чәчәкле, арканы ябып торган фата (куш жаулык) калфак өстенә беркетеп куела, байларныкы 120дән 300 сумга кадәр житә. 12) Мәржән беләзек—алтынланган көмештән ясала, гарәп язуы белән, ахак, фирүзә ташлар тезеп бизәкләнә, һолланд тәнкәләре яисә берничә кызыл мәржән жеп яки энже бөртекләре куела, хакы 3000 сум. 13) Йөзек—байбичәләрнең бармагы саен, алтынланган көмештән коела, фирүзә, аметист, энже кашлылары була. Шундый ун йөзек (ике кулга) 500 сум тора. 14) Бер толым итеп, көмеш тәнкәләр тезеп эшләнгән, чынлап торсын өчен очына зуррак тәнкәләр куелган чулпы. 15) Энже, асылташ, алтын тәнкә белән бизәлгән хәситә (бөти) сул иннән култык астына төшереп бәйләнә, уң ягындагы кечкенә кесәсенә бик вак язылган нәни генә Коръән тыгылган була; ләкин күп вакыт Коръән урынына агач кисәге куялар. Сәбәбе шул: татар хатын-кызлары күп итеп чәй эчәргә яраталар, тышка чыгарга туры килә, шуның өчен изге китапны өйдә калдырмыйча булмый. Хәситә 3000 сум тора. 16) Бөркәнчек—постаудан яки кижә мамыктан тегелә, кулны жиң эченә тыгып тормыйча, баштан бөркәнеп кенә кияләр.



*Казандагы Беренче гимназия.*

Моннан утыз еллар элек шундый баш киеме бар иде: башлы шикәргә охшаган, ефәк белән тышланган, рус тәнкәләре, энже, мәржән белән бизәлгән, конус кебек очлаеп менә дә очы түгәрәк алтын сәдәф белән тәмамлана. Мондый баш киеменең авырлыгы 20 кадаклар булгандыр. Хәзер инде ул модадан чыкты.

Катлы-катлы киенгән бай татар хатын-кызы үрдәк сыман бик мәзәк итеп атлап йөри. Шундый сорау туа: мондый да купшы киенеп кемгә күренә ала ул? Бердәнбер иренә, яисә сеңелләре, дус хатын-кызлары белән генә аралашуы мөмкин, чөнки татар хатын-кызына хәтта иң якын ир кардәшенә дә битен ачу ярамый. Ни үкенеч татар хатын-кызы өчен!

Кичке бишләрдә хатын-кызлар компаниясенә кунакка барырга жыенган татар хатын-кызы менә ничек әзерләнә: башта тулаем юынып чыга да чиста күлмәк киеп, бизәнергә утыра. Битенә иннек-кершән ягына, кыйгач каш-керфекләренә сөрмә тарта; аннары тешләренә кара яга, фарсы хнасына төелгән ачуташ кушылган порошокка манылган чүпрәкне тырнак турларына бәйләп чыга. Шулай итеп, берничә сәгать эчендә тырнаклары кызгылт-сары төскә керә. Әнә шундый бизәнү мәрәкәсеннән соң, күкрәк турына тәнгә берничә тамчы роза мае да сөрткәч, бәйрәм

күлмәге киелә. Шуннан соң ул, ат җиктереп, билгеләнгән җиргә кунакка килә. Иң беренче итеп мулла, мәэзин хатыны, аннары, дәрәҗәсенә карап, сәүдәгәр хатыннары, иң актыктан инде мещанкалар белән исәнләшеп чыга. Баш ию, үбешүләрсез генә, ике кулны берьюлы сузып-кысышып, бер-берсенә хөрмәтен белдерәләр. Шушындый мәрәкә вакытында ялгышып куйса, әйтик, иң беренче мулланыкы белән түгел, сәүдәгәр хатыны белән күрешсә, ул чакта инде мулла хатыны күрешергә сузылмый, ике кулын өскә күтәрә, учларын күрсәтеп, үпкәләвен белдерә.

Гомумән алганда ир-атлары минә дигән гәүдәле. Озынча йөзле, үткен карашлы, кара яисә зур соры күзле, кабарынкы сыртлы, озынча шәрык борынлы, калын иренлеләр, кара сакал-мыеклары пөхтә төзәтелгән, ирен тирәләре тигезләп кырылган, такыр итеп кыркылган баш түбәсенә түбәтәй чәпәп куелган, озын колаклары тырпаеп тора. Калын муен, киң җилкә, текә күкрәк. Гадәттән тыш төз, озын гәүдәлеләр, сынны горур тотып йөриләр. Тәннәре ак, йонсыз. Күбесе калын бәдәнле, корсагы беленеп торганнары да бар. Мәчеттә мин аларның олпат картларына сокланып карап тора идем. Борынгы Италиянең мәшһүр рәссамнары иске һәм яңа Тәүраттагы тарихи вакыйгаларны чагылдырганда бу могътәбәр картларны һичшиксез файдаланырлар иде.

Татар хатын-кызлары арасында артык матурларын күрмәдем шикелле. Андыйларын бик астында тоталардыр, шуңа күрә мин үзем өченче кимәлгә керткән, вак мещаннарның хатыннары, кызлары турында гына сөйли алам. Юантык гәүдәле, уртача буйлылар. Ирләре кебек үк гәүдәне төз тоталар, әмма атлап йөрүләре ташкаулчим. Алаңгыр киемнәре комачаулый, күрәсең. Тиз картаялар, 27 яшьлек хатынга 40 яшьне уйламыйча да бирергә мөмкин. Сәбәбе: бик иртә кияүгә чыгалар. Иннек-кершәнне артык мул кулланып, бит тиресен бозып бетерәләр, алар яңак сөякләре чыгып торганга, киң йөзлеләр, чагыштырып карасаң, тар чырайлы ирләре чибәррәк күренә. Хатын-кызларның тәннәре, мин күргән кадәресе, саргылт төстә, пергаментка охшаган, купшакланып тора, калын мамык юрган ябынып ятудан, артык җылы кием киюдәндер инде—вак бетчә белән капланган була.

Татарлар—горур, шөһрәт сөючән, кунакчыл, акчага хирыс, чиста, үз дәрәҗәсенә карап укымышлы, хорафатларга аз ышанучан, мактанчык, үзара тату, эзләнүчән, беркадәр юмакай, күп нәрсәдә чама белгән, сәүдәгәрлек өчен туган эшчән халык.

Шактый еллар буена төрле өязләрдә йөргәндә яисә махсус татар авылларына барып чыкканда миңа аларның гореф-гадәтен, әхлагын, гаилә тормышын якыннан күзәтергә туры килде. Һәр халыкның да яхшы һәм начар ягы була. Шул исәптән татарларның да. Ике гасыр дәвамында буйсындырылып, руслар арасына сибелгәч тә, гел үзайры яшәгән кебек, гореф-гадәтен, йолаларын, горурлыгын саклап кала алган гаҗәеп халык бу.

Иң матур сыйфаты—кунакчыллык: таныш татар кешесе авылда сине кунакка чакыра икән, белеп тор, икенче көнне хастага әвереләсең... Татарның әвәлге төп сые—чәй. Син аны дүрт касәдән дә ким эчеп туктый алмыйсың (ярлыракларда бал белән). Өстәлгә бик куе итеп туглыган каймак куела. Кура җиләге кагы, кайнар табадан гына төшкән коймак. Боларның һәммәсен кабып карарга тиешсең. Әмма моның белән генә бетми икән. Бөтенләй таныш булмаган тагын ике-өч татар сине кунакка алырга дип көтеп тора. Кире кага алмыйсың. Үпкәләячәкләр. Өйләренә керденме, кыстый-кыстый баллы камыр ризыклары белән сине тагын өчәр чынаяктан да ким чәй эчертмичә җибәрмиләр.

Мин бу чәй җәзасын берничә мәртәбә кичердем; ашказанымда егерме биш чынаяк чәй мөлдерәтеп өемә кайтып авам да икенче көнне дару кабарга тотынам.

Күрше татар авылында мин берничә тапкыр гаиләм белән кунак булдым. Анда инде татарларның кунакчыллыгы бөтен балкышы белән ачылды; безнең хөрмәткә бөтен авыл бәйрәмчә киенгән, зур яулык бөркәнгән хатын-кызлар басу капкасы төбенә җыелган. Кунакка аласы ирләр чирек чакрым каршы чыгып көтеп торалар иде.

Менә башлана инде хәзер чәй табыннары. Кимендә унбиш ызбада булырга кирәк. Безне көткән өйләрнең идәне ялт итеп юылган, киң эскәмияләргә юрган түшәлгән, вак мендәрләр салынган; стенада матур хатын-кыз күлмәкләре, ирләрнең киҗе камзуллары, чигүле сөлгеләр эленгән. Өстәлгә бизәкле ашъяулыклар җәелгән. Гадәттә җиткелекле яшәгән татар гаиләсендә самавыр була. Әмма бу авыл ярлырак

иде, мулла самавыры безнен белән бергә өйдән-өйгә сәяхәт итте...

Татар авылында өй борынча кунак булуыбыз мулла өендә тәмамланды. Мондагы сый-хөрмәт инде Казандагы татарларныкына охшаш: кура җиләге кагына йөзем, өрек-курәгә, кара җимеш, пестә чикләвеге өстәлә. Мулла шәкертләрен тәкъдим итеп, үзенең галимлеген күрсәтеп калырга тели. Икенче бүлмәдә абыстай кыз-кыркыннан Коръән сурәләрен җырлата; һәрберсенен кулында дәфтәр, күрсәткеч таягы; борын аша җырланган сузынкы көйләре күнелгә бер дә ятышлы түгел.

Татарларнын кунакчыллыгы бик тә күркәм. Бер сәяхәт вакытында сиртмәле арбабызнын кайсыдыр төше ватылды, ят бер авылга көчкә барып життек. Экипажны төзәттергән арада мин, кызым белән икәү, эсседән качып бер ихатага кердек тә, йорт куләгәсенә сыендык... Хуҗа күреп алып, безнең янга килде, кем икәнебезне, каян килүебезне сорашып та тормыйча, өенә дәшеп алып, чәй эчертте. Июль аенда бит бу, төш вакыты үтеп, сәгать икеләр тулган чак.

Муллаларга да гадел бәя бирергә кирәк. Алар Шәрык мәгърифәтен шәһәрләрдә генә түгел, ин ярлы авылларга кадәр таратып, бу өлкәдә шактый уңышка ирешәләр. Һәр мулла үз өендә мәдрәсә тота, бик арзан гына түләү хакына малай-кызларга гарәп телен укыта, Коръәнне ятлата, шәригать кануннарын өйрәтә. Шәрык мәгърифәтенең сала һәм калаларга тигез таралуын һәр татар авылына килеп кергәч үз күзең белән күреп ышанасың. Кечкенә, инә барган иске йортлар арасында берничә матур өй балкып утыра; аларга кермичә китә алмыйсың. Керсәң, сине ак бәз күлмәк өстеннән Бохара камзулы кигән хуҗа каршы ала; бик пөхтә тегелгән ситсы күлмәк кигән хуҗабикә яулык чите белән йөзен каплап йөри. Көмеш беләзекләре, фирүзә кашлы йөзекләре күренеп-күренеп ала. Өй эче бик чиста; самавыр, чынаяк-тәлинкәләр—шкаф уентыгында, кыршыла башлаган фарсы келәме җәелгән кин сәкедә төрелгән юрганнар, ястык-мендәрләр өелеп тора. Рус мужигының яшәү рәвеше белән чагыштырсаң, бу татар ире бай яши дип уйларга да мөмкин. Юк, бу җир кешесе үз күршесеннән әлләни алга китмәгән. Ләкин анын тормыш алып баруы гадәти крестьянныкыннан үзгәрәк инде. Ул һәркөнне, гаиләсе белән түгәрәкләнеп, дини китаплар укый, кичкырын чалмасын киеп мәчеткә юнәлә, анда инде өлкән яшькә житкән татарлар арасында мулла эре кыяфәт белән акыл өләшә. Мулла анын белән ике куллап күрешә, агайлар аңа хәзрәт кырыеннан олылап урын бирәләр. Монда ул караңгы төшкәнче утырып, мул табын зарыгып көткән өенә кайтып китә. Аның уллары һәм кызлары белем алганнар, Коръәннең эчтәлеген дә мулладан ким белмиләр. Уллары өйгә бик сирәк кайтып керә; ел әйләнәсендә ярминкәләргә үз атлары белән йөк ташыйлар, аннары шәһәрдән чыккан татар купецларына яллананалар, лавкаларында тауар ташып, кап бәйләп, сату эшенә өйрәнеп, прикащик булып алалар да, әкеренләп, капитал туплап, үзләре дә купецлыкка чыгалар. Кызларын исә, зур калым бәрабәренә, Казанның бай татар егетләренә кияүгә бирәләр. Мондый татарлар арасында хәйран баеп киткәннәре, авылда мәһабәт таш йортлар салдырганнары да бар. Болар инде Шәрыкча зиннәткә күмелеп яшиләр. Казан купецларыннан күреп, хатыннарын алтын, фирүзә, энҗе кебек асылташлар белән бизиләр. Җир эшеннән китеп, мажиклыктан чыгасы килү авыллдагы һәр татар иренең аерылгысыз теләге. Әгәр анын җыя килгән ике-өч йөз тәнкәсе бар икән, ул инде ярлырак туганлашларыннан аерылыбрак тора; тазарак өй буратырга керешә, самавыр юнәтә, хатынына бизәнү әйберләре ала, мәчеткә ешрак йөри башлый.

Татарлар гадәттән тыш баллы һәм майлы ризык яраталар. Гадәттән тыш диюем шуннан, гаилә башлыгы еллык ашлыкны җыеп алганнан соң, шуның яртысын сатып, ит ала, шуның аркасында үзе икмәккә кытлык кичерә...

Гомумән алганда, татарларның көнкүреше мина бик ошый. Хатын-кызлар үзара тату, тыныч көн итәләр, зур гаиләдә аларның саны унга кадәр житә, кайсыбер иренең өч хатыны була. Шәрык кануннары боларга әнә шундый күндәмлек, сабырлык сыйфатлары сеңдергән.


Татарларга пакьлек, пөхтәлек хас. Ызбалары чиста, елга берничә мәртәбә мичне дәртләнеп акшарлап чыгалар, хәтта аварга торган иске йортта да бу шулай. Хатын-кызлар ихата-кураны бик чиста, тәртиптә тоталар. Ипи пешерергә осталар. Алардагы кебек куе, тәмле каймак, кайнатылган сөт өсте бүтән беркайда да юк. Пакьлек-

чисталыклары сыер сауганда да күренеп тора; алъяпкыч бәйләп, сыер жиленен жылы су белән юып, йомшатып алалар, сөтле чиләк өстен чиста сөлге белән каплап куялар.

Күп кенә хуҗалыкта кышын сыер саумыйлар. Көздән үк запаска әзерләп куелган каймакны, зур кисмәктә сакланган кайнатылган сөтне кышын җылытып табынга куялар. Авылда татарларнын гадәти ризыгы умач, пилмән, каймак салынган борчак боткасы. Үзләре үстергән кәбестәне яратып ашыйлар, таза хәлле гаиләнен берсендә дә итсез ризык күрмәссен.

Татар хатын-кызлары кул эшенә осталар: тукыган ашъяулык, чиккән яулык, сөлге кебек әйберләре бик матур була. Йортка чит кеше яисә кунак киләсе икән, әнә шул чиккән-тукыган әйберләре стена буйлап бауга эленә, өстәлләргә бизәкле ашъяулыклар җәелә.

Эшчән татарларнын бакчасында бәрәнге, суган, чөгендер, кишер-кәбестә кебек яшелчәләр мул үстерелеп, кышка сакларга куела.


*Университет күренеше. Болак ягыннан төшерелгән фото.*

Татарлар рус мужиклары кебек үк кышны авылда үткәрәләр. Артык икмәге, печәне бар икән, Казанга сатарга алып киләләр. Әгәр инде якын тирәдә шәраб яисә селте заводы бар икән, татарлар монда мәш килә; утын кисәргә ялланалар, әвен һәм мич көле җыялар. Күп кенә татарлар Казаннан иннек-кершән, сабын кебек вак-төяк әйберләр юнәтеп, шуны авыллар буеча сатып йөриләр. Татарлар, минемчә, иген игүгә караганда сату эшенә маһиррак. Авылда яшәүче татарларнын яхшы сыйфатлары белән беррәттән яман яклары турында да искәртеп үтәргә кирәк. Әйткәнемчә, Шәрыкнын акыллылардан да акыллы пәйгамбәре үзенен катгый кануннары белән йөрәкләренә үтеп кереп, аларны йомшаграк холыклы, нәфис хисле итә алмаган. Шәрык халыклары кебек үк татарларга да каты бәгырьлелек, тупаслык, мәрхәмәтсезлек, кырыслык хас. Гауга чыгып, сугыша башласалар, бер-берсен тешләре белән өзгәләп ташларга житәләр. Эчкерле, үч алучан булсалар да, сәдака бирергә, бәла-каза килгәндә ярдәм итәргә һәрвакыт әзерләр.

Болар Мөхәммәд пәйгамбәрнен хәмер эчмәскә дигән боерыгын беркайчан да сакламыйлар шикелле. Авылда руслар кебек үк исергәнче шәраб эчәргә яраталар, шуна күрә эчкечелектән килеп чыккан әдәпсез күренешләр, килешсез кыланышлар аларга да ят түгел. Мулла исә хәмергә якын да килми, әгәр анын шәраб яисә сыра эчкәнен фаш итәләр икән, шунда ук урыныннан төшерәләр...

Авылда дини бәйрәмнәр шәһәрдәге кебек үтә. Ураза тоту катгый саклана, көнен гел эштә үткәргән авыл кешесе өчен бу бик авыр. Бигрәк тә июль, август айларында, иртәнге сәгать өчтән алып кичке уннарга кадәр кырда, көнозын эссе кояш астында кибегеп бил бөккән мескен татар иренәнә бер тамчы су да тидерә алмый...

И, хатын-кызлар! Анабыз Һәвадан башлап, бүгенге мәгърифәтле чорга кадәр шулай: без, тупас ирләр кавеменә буйсынучан бит сез. Тыштан караганда, югары катлау әдәбе сезгә безнен белән идарә итү өстенлеге биргән кебек тоелса да, жентекләп уйласан, сез бит күп мөнәсәбәтләрдә безгә карусыз буйсынасыз. Ләкин без мөселманнар кебек тупас, аяусыз буйсындыручылар түгел; без бит сезгә яшәүдән

һәртөрле ләззәт алу мөмкинлеген бирәбез; йортыбызның хуҗабикәләре буларак, сез безгә иптәш тә, беренче кинәшчебез дә. И төксе Шәрыкның бәхетсез хатын-кызлары!.. Мөхәммәд үзенең кануннары белән рәхимсезлек күрсәтеп, аларны мәңге буйсынучан иткән. Менә шундый җәбер астында изелеп яши безнең татар хатын-кызлары. Татар ире никадәр баерак, сәүдә эшендә никадәр танылганрак булса, хатынын шунын кадәр яшеребрәк тота; йокы бүлмәсендә генә йөзен ача җанашы; чөнки анын чыраен йортта яшәүче каената да, иренең ир туганнары—олысы-кечесе дә күрергә тиеш түгел. Бай хатын-кызнын тормышы эчпошыргыч бертөрлелектә уза. Алар кул эше белән дә шөгыльләнмиләр: йорттагы хуҗалык эшләрен ире карый, каенана, карчык-корчыклар мәш килә. Ә яшь хатын бизәнү һәм ашказаны ягын гына кайгырта. Бай татар хатын-кызы иртән торуга бизәнергә керешә, алтын җепләрдән тукылган күлмәген киеп куя, битенә калын итеп иннек-кершән ягына, аякларын бөкләп, диванда алебастр курчак шикелле утыра. Каршында самавыр гөжли. Үзе агызып чәй ясый да битенә сыланган кершәне тир белән агып беткәнче чынаяк арты чынаяк бушата тора. Аннары тагын буяна-төзәтенә дә иртәнге ашка чыга. Бераздан инде берәр ахирәте килсә, өстәлгә тагын самавыр менеп кунаклый. Кунак белән тагын, иртәнге кебек, җиде чынаяк яисә аннан да күбрәк чәй эчелә. Тагын тир белән биттәге акшар юылып бетә; төшкелеккә ире каршында балкып торсын өчен янадан буянырга кирәк. Төшлектә майлы ит ризыгы ашаганнан сон, ашказанын эшләтү өчен дип чәй эчү татарларда зарури гадәт. Менә шулай чәйләп алып, истирәхәт кылганнан сон, татар хатыны яна күлмәген киеп, кунакка барырга җыена; дагалы пар ат җигелгән, бизәкле көймәле арбада ниятләгән җиренә барып җиткәнче борынын да чыгармыйча бөркәнеп утыра. Байбичә һава сулаудан да мәхрүм. Өй каршындагы бәләкәй бакчага, ир туганнарынын күзенә чалынудан куркып, җилән бөркәнеп кенә чыга ала. Урамнан үтеп баручыларга күренмим дип ул хәтта тәрәзәдән карарга да кыймый. Урам буш чакта бәлки бер мизгелгә генә дөньяга күз салыр да иде, ләкин куе булып үскән гөлләр тәрәзәне томалый, саф һава урынына рәйхан гөленең үткен каты исен иснәргә генә кала.

Менә шулай үтә Казаннын югары кимәлдәге байбичәләр тормышы. Әмма алар мондый тормыштан канәгать. Европа хатын-кызларынын яшәү рәвешенә гаҗәпсенеп, үзләрен бик бәхетле саныйлар. Алар уенча, Европа хатын-кызлары берничек тә оҗмахка керә алмаячаклар, шуна күрә үзләренен мөселман өммәтеннән икәнлекләренә шөкрана итеп, Аллаһыга гыйбадәт кылалар.

Казаннын икенче дәрәҗәдәге хатын-кызлары алай ук байлардан түгел, бай булган очракта да бик тәкәбберләнми. Мондыйлар инде бай, мәртәбәле татар ире үтеп барган мизгелне санамаганда, урамнан үткән-сүткәнгә игътибар итмичә, саф һава сулап, тәрәзә каршында утыра бирәләр. Болар өй эшен дә башкаралар, бәлеш, пилмән пешерәләр. Ат, сыер абзарынын чисталыгын карарга ишегалдына чыгалар. Ихатада каенатадан кала, ир-ат туганнарыннан йөзен яшермичә йөриләр. Кунакка исә бөркәнчек астыннан борынын, сынар күзен күрсәтеп, җәяү баралар.

Өченче дәрәҗәдәге хатын-кызлар үзләрен тагын да иреклерәк хис итә. Кер юу, сыер саву кебек хуҗалык эшләре болар кулында. Шәһәргә кирәк-яракка чыкканда, каршыга татар ире очрамаса, йөзен ярым ачык килеш калдырып йөриләр, кул эшен дә башкаралар; арада менә диген тегүчеләр бар, алтын җеп белән каләпүш-түбәтәй чигеп, аны энҗе, асылташлар белән бизәклиләр; чигүле читек-кәвешләре бишәр йөз сум тора.

Мин бүлеп чыккан шушындый өч дәрәҗәдәге хатын-кызларны язгы Сабан бәйрәмендә ачык күрергә була.

Беренче дәрәҗәдәгеләр бу бәйрәмгә беркайчан да катнашмыйлар. Икенче кимәлдәгеләр ыспай пар ат җигелгән, сбруйлары җиз тәнкәләр белән бизәлгән, җете төсләргә буялган көймәле арбада киләләр. Үзләренен киемнәре дә балкып тора: алтындыр, энҗе-мәрҗәннәр; иннек-кершән ягылган йөзләре маска кебек, кызганыч, бу зиннәтләр бар да бөркәнчек астында. Арбалар бәйрәм мәйданыннан арырак, агач күләгәсенә туктатыла; менә шушыннан инде татар хатын-кызлары авыр бизәнү әйберләреннән сыгылып, бөркәнчек астыннан сынар күзен генә елтыратып, тирләп-пешеп утыралар.

Өченче кимәлдәгеләр арбага басып, Сабан мәйданын тамаша кылалар. Җәяүлеләре үргә яисә берәр танышының арбасы кузласына басып, бөркәнчек аша күзәтәләр. Әмма берни дә күрә алмыйлар, чөнки бәйрәм шаукымы болардан шактый ерак, арада—атлы арбалар, кешеләр кайнаша.

Бу өч дәрәҗәдәгеләрнең дә бәйрәм итүләре бер төрлерәк: туй, Рамазан, Корбан бәйрәме. Берничә көн буена мәҗлесләргә йөриләр, иң затлы күлмәкләрен кияләр, иннек-кершән ягыналар, тешкә кара ягалар, каш-керфекләрен каралталар, тырнак буыйлар. Йөзләп хатын-кыз җыелган мәҗлесләр берничә көнгә сузыла. Монда нинди күнел ачу көтә инде боларны? Ике чиләк сыешлы самавыр кайнап тора, чәй табыны өч сәгать буена бара, яңа кунак өстәлгән саен самавыр яңартыла, баштарак туйганчы эчеп хушланганнар алдына да яңа чәй китерелә. Аннары төрле җимешләр (Бохара, Кяхта, Эрбеттән китерелгән) салынган тәлинкәләр алга куела. Аннары—кичке аш. Байлар өендә бу шаккаткыч, чөнки иллеләп төрдә аш-су әзерләнә. Шунысы гаҗәп: хатын-кызлар барысын да рәттән авыз итеп утыралар. Миңа бер туй мәҗлесендә булырга туры килде, боларның ашау дәртенә исем китеп, күзәтеп утырдым. Кичке ахшам намазыннан соң башланган мәҗлес иртәнгә кадәр (кичке биштән таң беленгәнче) фәкать ашказанын канәгатьләндерүгә тотыла. Бөтен хозурлыклары ашау-эчү, кием-салым хакында зарыктыргыч гәп куертудан гыйбарәт.

Мин санап чыккан өч дәрәҗәдәге хатын-кызлар да мәҗлестә бергә утыралар. Байлар ярлыларны да кунакка дәшә, үзләре дә аларга бик теләп баралар. Яшәү рәвеше авылча, крестьянча булган, ялланган хезмәтче хатын-кызлар гына болар рәтенә керә алмый.

Минем карашымча, авылда яшәүче хатын-кызлар күпкә бәхетлерәк. Рус хатыннары кебек үзләрен иркен тоталар, өй-курада, кырда батырып эшлиләр; җәен кырда, урманда, кышларын исә бәйләм бәйләү, чигү-тегү, язын туку эшендә; кул кушырып утырырга вакытлары юк. Бөркәнчек ябынып йөрмиләр, җомга көннәрне генә иннек-кершән ягыналар. Шунлыктан авыл хатын-кызлары шәһәрнекеннән матуррак күренә. Ләкин авыл байбичәләре дә казанлылардан күрмәкче, киенеп-ясанып, бер эшсез өйдә кагаеп утыралар.

Авыл хатын-кызларының да ирләрдән аерым бәйрәм итүе шәһәрдәгечә, әмма күңеллерәк; кайчакта җыр да сузалар, туйларда биеп тә алалар.

Шәрыкның дәһшәтле канун чыгаручысы мөслимәләргә храмга кереп гыйбадәт кылуны тыйган. Ләкин моңа карап аларның диндарлыгы һич тә ким түгел. Байга, ярлыга карамый авылда яшәгәннәре дә укый-яза белә һәм аларның төп рәхәтлеге Коръән сурәләрен моңлы итеп уку. Һәрбер татар хатын-кызы кырыс дин сабакларын гаҗәеп төгәллек белән тырышып башкара. Мәчетләрдә көнгә биш тапкыр намаз кылынган вакытта татар хатын-кызы кайда гына булмасын, кунакта чәйләп утырамы, кырда яисә урмандамы, бернигә дә карамыйча, бөтен шөгылен ташлап, уңайлы тыныч урын табып намазга баса. Бу халәттә инде аңа берни дә комачау итми, игътибарын читкә юнәлтә алмый. Ничек уйлыйсыз, шушындый да каты тәртип-йолаларга буйсынып, бик артында яшәгән хатын-кызлар янына мәхәббәт кошы очып кереп сөю-гашрәт кузгата аламы? Әйе, мәхәббәт кошы калын диварлар аша да үтеп керә, теңкәгә тигән бөркәнчекләрен тартып ачып, йөзләрен балкыта ала икән шул.

Байбичәләр арасында иренә хыянәт итүчеләр буладыр дип мин элек башыма да китерә алмый идем. Сөйләүләренә караганда, ирендә прикащик булып эшләгән яшь егетләргә күз атулар булгалый икән шул. Моңа гаҗәпләнәсе юк, чөнки житмешкә житкән бай ирләр дә уналты яшьлек кызга өйләнүне мәртәбә саныйлар, ә үзләрен яшь-җилкенчәк прикащиклар урап алган. Татар ханымнарының ишек ярыгыннан, чаршау артыннан бөркәнчек читеннән сыңар күзен елтыратып булса да, чибәр егетләрне аера белүе безнең бал-кичәләрдәге Европа дамаларыныкыннан бер дә ким түгел. Мин алда әйтеп үткән өченче дәрәҗәдәге хатын-кызлар өчен мәхәббәт бик мөһим яссылыкта тора. Монда инде йөрәк хисе белән язылган, ике арада йөрүче хат, шигырь, җырлар китә...

*Ахыры киләсе санда.*

Адлер
Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***ҺУ КОШЫ*** – Оҗмах кошы. Әгәр "һу" сүзен "Аллаһу" мәгънәсендә аңласак, Алла кошы, Аллаһка бирелгән кеше булып чыга.

***ЦИФР*** *г.* – Сыйфр; санны белдерә торган тамга; сан. Ләкин бу сүзнең башлангыч мәгънәсе-буш, ноль (нуль). *//Ләкин җыен ярлыдан бер бай чыкмаганга, цифрларның мәҗмугәсеннән цифрлар гына чыкканга, Хәлимгә бу "чәйдәш" лектән файда чыкмады.* Г.Исхакый.
Тагын кара: ***СЫЙФР.***

***ЧАБАВЫЛ ЯСАУ*** *тар.* – Баскынчылык итү, көтмәгәндә атлы яу булып килү.

***"ЧАБАТАЛЫ МОРЗА"*** – Чукынудан баш тарткан өчен биләмәсе тартып алынган һәм бөлгән татар морзасы. Мәс., Исмәгыйль Рәми Яушев Нәүширван "чабаталы морза" (бөлгән дворян) гаиләсендә туып үсә" дип яза. Бөлгән мирзаларга итсез аш белән киченергә туры килә башлый... "Шундый табын өстенә кереп, ашарга утырган кеше гаҗәпләнеп: "Бу нинди аш?"-дип сорый калса, моңа каршы шаянрак хуҗалар, сер бирәсе килмичә, киная белән: "Әйдә, җитеш, бу "Корды би ашы" (ягъни "корды би"-бөлгән, корыган бәк, морзалар ашы) дип" җавап биргәннәр имеш. (Нәкый Исәнбәттән.)

***ЧАВЫШ*** *тар.* – Борынгы Болгар, Казан дәүләтләрендә кече офицер. Бу сүз, мәсәлән, Каюм Насыйрида очрый. Туйда тәртип саклаучыны да *чавыш* дигәннәр.

***ЧАГАРАК*** *тар.* – Күчмә киез тирмәнең түбә тәрәзәсе урынында киез япкыч белән ачылмалы-ябылмалы түгәрәк тишек, төннек. Атаманың *чыңрак, чаңгырак* вариантлары да булган.

***ЧАГЫР*** – Кузнецк якларында (Пенза өлкәсе) ике япьле агачның башына үткен тимер, күбесенчә сука тимере, беркетеп ясалган корал. Кабер казу өчен кулланылган. Ульян өлкәсе Хвалын якларында аны *чалгыр* дигәннәр.

***ЧАДРА*** *ф.* – Мөселман хатын-кызлары өйдән чыкканда күзләрен генә калдырып баштанаяк ябына торган бөркәнчек. Төрекчә-*чаршаф* (чаршау). Гадәттә ак, зәңгәр яки сирәк кенә кара төстә була.

***ЧАК*** – Вакыт; мизгел. Р.Әхмәтьянов "чак" сүзенең гомум төрки телдә "ике сәгатьлек период, тәүлекнең уникедән бер өлеше" булуын күрсәтеп уза. Ягъни борынгы төркиләр тәүлекне унике өлешкә бүлеп исәпләгәннәр, ә аны 24 сәгатькә бүлү, күрәсең, Ислам белән бергә килгәндер. Элекке бүленештә һәр *чак*-ның үз исеме булып, алар унике еллык хайван календарендагы еллар исеме белән аталганнар. Мәс., *барыс чагы* – исәп буенча өченче чак, ягъни иртәнге 4-6 сәгатьләр була. Төн уртасы *дуңгыз* белән *тычкан*

*Дәвамы. Сүзлек 2004 елның 1нче саныннан басылып килә.*

*чаклары* арасына, ә көн үзәге *елан* белән *елкы чаклары* арасына туры килгән.

Шулай итеп, татарча *сакчы / чакчы* сүзе рус телендәге *часовойга*, *"человек, стоящий на часах"* төшенчәсенә тәңгәл икән.

Тагын кара: ***КЫЙБЛАНАМӘ.***

***ЧАКМА***— Чакматашка бәреп чаткы (очкын) чыгара торган корыч кисәге; чакмалы мылтыкта капсюльгә бәрә торган металл очлык. // *Чакма савыты* — чакматаш, чакма, чакма мамыгы (филтәсе, ку) салып йөртә торган калай савыт. Мондый нәрсәләр соңгы тапкыр 1941-45 еллардагы сугыш вакытында кабат таралыш алган иде. *Чакма чагу.*

***ЧАКМАТАШ*** — Бер-берсенә яки корыч кисәге белән бәргәндә очкын чыгара торган каты минерал, русча — *кремень*. Тарихка кадәрге дәверләрдә төрле кискеч һәм кыргыч кораллар, ук-сөңге очлары ясау өчен кулланылган.

***ЧАКРЫМ*** — Кеше тавышын ишетеп була торган ара, рустагы верстага якын, ягъни 1,06 км. Казакъларда — кышкырым. // *"Чакрым бер микъдар мөсафәт ки, адәм кычкырса ишетелерлек булыр, аны бер чакрым диярләр. Ягъни чакыргач ишетмәле микъдар; кадим заманда татарларның каладан калага тавыш ишетерлек мөсафәт саен бер кеше куелмыш иде. Телефон мәнзәләндә — әгәр бер вакыйга булса, тавыштан тавышка хәбәр биреп, дирхаль икенче шәһәргә хәбәрне җиткерерләр иде"*. К.Насыйри.

Бездәге чакрым өч аршынлы 500 сажинга тигез булган һәм Татарстанда метрик система кертелгәнче (1927 елга кадәр) гамәлдә йөргән. Соңгы вакытларда километр диясе урынга чакрым сүзе куллану еш күзәтелә, ләкин бөтендөнья өчен уртак булган метрик системадан тайпылуны хуплап булмый.

***ЧАЛБАР*** — Фарсы телендәге *шалвар* сүзеннән. Рус телендәге *шаровары* сүзе исә, *штаны* сүзе кебек үк, төрки телләрдән кергән. Татар теле диалектында *сирвалә*-хатын-кыз чалбары. Борынгы төрки телдә чалбар сүзе мәгънәсендәге *өм* сүзе актив булган.

***ЧАЛМА*** *төрк.* — **1.** Мөселман руханиларының баш киеме, түбәтәй яки фәс өстенә ак (кайчакта яшел) төстәге озынча җиңел тукыманы берничә кат чалып (чорнап, урап, сарып) киелә. Кайбер шигыйларда зәңгәр чалма урау да билгеле. Бөек имам Әбү Хәнифә ибн Сабит кара чалма сарып йөргән. Тарихи яктан караганда, чалма Муса вә Һарун пәйгамбәрләр заманыннан бирле яһүдләрдә кулланылган. Яһүдләр моны һиндүләрдән алган булсалар кирәк (Р.Фәхреддин). Ләкин шулай да гарәпләрдә чалма гомуми кием булып китмәгән.

Электә Мөхәммәд Пәйгамбәр ак чалма урап йөргәнгә, ул мөселман киеменең мәҗбүри өлеше булып исәпләнгән. Ләкин Пәйгамбәрнең кара чалма киеп йөргәнлеге дә ривайәт ителә. Ул гадәттә чалмасыннан җилкәсенә койрык төшергән, чалманы бүрек белән дә, бүрексез дә кия торган булган. Мөселманнар чалманы гыйбадәт вакытында, мәчеткә барганда, каберләрне зиярәт кылганда урарга тиеш булганнар.

Чалма турында иң билгеле хәдистә: "Чалма мөслимнәрнең затлылыгын һәм гарәпләрнең куәтен гәүдәләндерә,"-диелә.

Тукыманың озынлыгына, төсенә һәм урау ысулына карап, бер мең чамасы чалма төре була. Әдәбиятта "Бохараи шәрифчә итеп чалынган зур чалма" дигән гыйбарә очрый.

Чалманың очы (койрыгы) *тилсан* дип атала.

Чалма чалуны ике кул белән эшлиләр.

Хәзерге вакытта имамнар да чалманы мәчеттә гыйбадәт кылганда гына кияләр. Мөфти хәзрәт Тәлгать Таҗетдин башына чалма урап, муенына галстук тагып йөри, ләкин аңа иярүчеләр бик күренми шикелле.

Сәйф Сараи чалма мәгънәсендә *тәхфифә* сүзен дә куллана (кыскарак, җиңелрәк чалма?). Аңарда ук *мисри касабә* (Мисыр чалмасы) сүзе очрый. Борынгы төрки телдә чалма мәгънәсендәге *сулук/сувлук* сүзе дә йөргән. // *Сулук сару.*

Фарсыча: *сәллә* һәм *дәстар*, гарәпчә: *гамамә*. "Дәстар" сүзе, татар теленә кереп, *"тастар"* (шарфка охшашлы баш яулыгы) сүзен барлыкка китергән. Борынгы әрмән-

кыпчак язмаларында очрый торган *дулбан* сүзе фарсыча "дулбәнд"тан ("зур чалма") килә (*дул*—түгәрәк, *бәнд*—бәй, бәйләвеч, урама). Бу сүз татар теле диалектында *дулман* рәвешендә сакланган (Р.Әхмәтьянов). Рус телендәге *тюльпан* һәм *тюрбан* сүзләре асылда шушы сүздән чыкканнар икән.

**2.**Электә татар теле диалектларында "пароходны дебаркадерга беркетә торган аркан" (Р.Әхмәтьянов). Монда русча "чалить", "причал" сүзләре белән генетик бәйләнеш ачыла.

***ЧАЛПЫ САЛУ***—Ырымлауның бер төре. Зәхмәт кагылган дип уйланылган кешенең авырткан җирен берәр әйбер белән ырымлап, шул әйберне, ырым язылган язуны җиргә куму ("Татар теленең диалектологик сүзлеге"ннән, 1993). Бу ырымны *чалпы тәгәрәтү* дип тә атаганнар.

***ЧАНА***—Р.Әхмәтьянов бу сүзнең охшашларын якут, тува һ.б. телләрдә күрсәтеп, аның "яңак" мәгънәсендә булуын ачыклый. Галим фикеренчә, "чана табаны яңак сөягенә охшатылган". Гильом де Рубрук "Көнчыгыш илләренә сәяхәт" дигән китабында урянкат (монгол) кабиләсе кешеләренең кыш көне аякларына шомартылган сөяк бәйләп, каты кар һәм боз өстендә гадәттән тыш тиз хәрәкәт итә алулары, кош һәм җәнлек аулап йөрүләре турында яза. Бу сөякләрнең чыннан да, әйтик, ат башының аскы казналыгы булуы бик мөмкин, ягъни Р.Әхмәтьянов фикере тулысы белән раслана. Хәзерге тимераякларның ерак бабасы булган бу җайланмадан инде "чана"га һәм "чаңгы"га ерак калмый. Рәшидетдиннән исә урман урянкатларының кыш көне кар өстендә аякларына киеп йөри торган такталарны "чанэ" дип атаганлыкларын беләбез. Бу такталарның алгы башына каеш тезгеннәр беркетелгән, чаңгычының кулында этелеп-этелеп китү өчен махсус таягы булган.

***ЧАҢ***—**1.**Зур кыңгырау, гарәпчә—*накус*, русча—*колокол*. Себер татарларында-*муңкылтак* яки *каңгыртак*. Христианлыкның башлангыч чорында әле грекларда һәм көнчыгыш христианнарында (несторианнарда) чаңнар булмаган, аның урынына тимер яки агач тактага агач чүкеч белән суга торган булганнар (греклар бу тактаны *семанттрон* дип атаганнар). //*Чаң каләсе*—чаң манарасы, колокольня. **2**.Бер-берсенә бәреп (кагып) чыңлау тавышы чыгара торган җиз "табалардан" гыйбарәт музыка коралы—*кимвал*.

***ЧАҢЫРАК*** *тар.*—Җәйләүдәге күчмә киез өйләрнең түбә алкасы.

***ЧАПАР*** *тар.*—Чыбыктан үргән зур калкан, күчерелмә читән, ур (окоп) калканы. Мәс., IX гасырда хәзәр гаскәре яуда үзе белән озын казыклар, юан бау һәм чапарлар төяп йөрткән. Дошманга якын гына җирдә төнгелеккә туктап лагерь корганда сугышчылар җиргә казыклар кадап, бау сузганнар һәм шуларга чапарларны сөяп куя торган булганнар. Мондый чапарларны Аксак Тимер гаскәре дә кулланган. Чыганакларда татар гаскәре кулланган читән-калканнарны *үрмә* дип атау очрый.

***ЧАПРАЗ, ЧӘПРАЗ*** *ф.*—Фарсыча *чәп-у-раст* (уңлы-суллы, уң һәм сул) сүзеннән. Борынгы сугыш киемнәрен, хатын-кыз киемен һ.б.ны төймәләү урынына шнурлап кую алымы.

***ЧАР ЯКЬ*** *ф.*—Чирек, дүрттән бер өлеш (ягъни татарча *чирек* сүзе русча *четверть*тән алынмаган, бәлки тамыры белән фарсы теленә барып тоташа). Электә шушы ук мәгънәдәге *робыг (робгъ)* сүзе дә кулланылган.

***ЧАРДУГАН***—Кабер өстенә корылган тимер яки агач рәшәткә, киртә, электә бурап та эшләгәннәр. Пенза якларында аны *чардак* дип тә атыйлар икән. Себердә—*чатырык* яки *өй*. Анда: "Чатырыкны бер буяп куя да шуның белән бетә, икенче кат буясаң, тагын сөаль бирәләр ди, җавап бирәсе була",-дигән сүз язып алынган.

***ЧАРЙАР, ЧАРИЙАР***—Фарсыча "Чәһар йар" сүзеннән—"дүрт яран "мәгънәсендә. Мөхәммәд Пәйгамбәрнең дүрт сәхабәсе—*Әбү Бәкер, Гомәр, Госман* һәм *Гали* хәзрәтләр турында әйтелә.

***ЧАРЛАК/ЧАРДАК*** *ф.* — Хәзерге мәгънәсе түшәм өстендә, нәкъ түбә астында урнашкан бина—чорма. Рус теленә төрки телдән "чердак" рәвешендә кергән. Фарсы телендә *чар* (чәһәр) — дүрт, *так* — дугайлы арка (гөмбәз), лапас, ягъни дүрт баганалы лапас, чатыр. Төрек телендә — "дүрт баганалы ачык сәйрханә (беседка), лапас", Кырым татарларында — "балкон", караимнарда — "өске өй". Чорма сүзенә килгәндә, Р.Әхмәтьянов аның беренчел мәгънәсе "чарлак тәрәзәсе" булып, ул күгәрчен очырту өчен кулланылган, исеме дә "чорма/очорма" шуннан килә дип исәпли.

***ЧАРЫК*** — Тула куныччлы, күн аслы йомшак аяк киеме. "Диване лөгатет-төрк" сүзлегенә караганда, мондый аяк киеме борынгы төркиләрдә үк булган һәм *излик* дип тә аталган: *Йадаг аты — чарык* — җәяүленең аты-чарык. *Излик болса, эр улдымас, ичлик болса, ат йагрымас* — чарык булса, ир аягы кырылмас, эчлек (эчерге киез) булса, ат сырты кырылмас (суелмас).

***ЧАТАГА*** *бор.* — Аткан вакытта мылтык көпшәсен терәтеп кую өчен чатлы таяк.

***ЧАТЫР*** — Шәрык халыкларында патша хакимлегенең төп символларыннан берсе — аның өстендә тотып йөртелә торган бизәкле зонт. Атама санскрит теленнән алынган. Ибн Баттута солтан чатырының тоткасы алтыннан ясалып, ефәге энҗе белән чигелгән булуы турында яза. Гомумән, чатырның бизәлеше хуҗасының дәрәҗәсенә карап йөргән.

***ЧӘЙ*** — Чәй үсемлеге беренче тапкыр Кытай чыганакларында моннан 4700 еллар элек үк телгә алынган. Имештер, бер кытай руханиы, гыйбадәт вакытында йоклап китүенә ачуы килеп, үзенең күз кабакларын кисеп ташлаган, һәм шулардан чәй куагы үсеп чыккан.

Кытайда чәйне, культура буларак, 350 нче елларда үстерә башлаганнар, 805-810 елларда ул Япониягә, аннары Кореяга үтеп кергән. IX гасыр урталарында гарәпләр әле чәй эчүне белмәгәннәр, ләкин кытай чәе инде мәгълүм булган. Урта гасырларда монголларда сәүдә алмашы вакытында чәй "гомуми эквивалент" (кыйммәт үлчәме) сыйфатында йөргән (акча берәмлеге кебек). Мәс., 30 данә сары чәй 1 данә калын чәйгә, ә 2 данә калын чәй 1 данә юка чәйгә бәрабәр булган һ.б.

"Чәй" төшенчәсе русча чыганакларда 1665 елдан бирле очрый дияргә мөмкин. Төркиләргә исә ул алдарак мәгълүм булган (татарча атамага охшаш яңгырашлы сүз төрек, үзбәк, әзәрбайҗан, фарсы, монгол, бурят телләрендә билгеле). Р.Әхмәтьянов XV гасырдан башлап татар сәүдәгәрләре чәйне Рәсәйгә дә китергәннәр һәм рус телендәге "чай" татар теле аркылы кергән дип исәпли. Дөрес, рус галимнәре "чай" сүзе турыдан-туры кытай теленең үзеннән алынган дигән фикергә авыша башладылар шикелле. Якынча шул ук вакытларда чәй Көнбатыш Европада да таралыш ала һәм чак кына үзгәрәк яңгырашлы сүз белән атала.

1824-26 елларда Ява һәм Суматрада, 1824-25 елларда — Вьетнамда, 1833 елда — Һиндстанда, 1842 елда Цейлонда чәй үстерә башлыйлар. Россиядә беренче чәй куагын 1817 елда Кырымдагы Никита ботаника бакчасында тәҗрибә тәртибендә үстереп карыйлар, ә культура буларак ул Грузиядә 1833 елда игелә башлый. 1896 елда беренче чәй куагы Әзәрбайҗанда да утыртыла.

Узган гасырларда татарда чәй эчүне бидгать эш дип санаучылар да булган, бу хакта шактый бәхәс-низаглар да чыккалаган. Мәс., Утыз Имәни үзенең бер поэмасында чәй эчү белән мавыгуны нәфсегә бирелеп, Шәригатьтән тайпылу дип бәяли. Ләкин шул ук вакытта аның чәй-каймакка дан җырлаган шигыре дә бар:

*Гуяки кәүсәрне татыр*
*Чәйне бер эчкән кеше,*
*Нәкъ матур кызлар йөзенә*
*Охшый ал гөлдәй төсе.*

Бу тасвирдан куе итеп ясалган каймаклы яки сөтле чәй күз алдына килә. Мондый чәйне Урта Азиядә дә бик яратканнар, ул анда *ширлы чой* һәм *ок чой* дип атала. Сүз уңаеннан сөтле чәйне инглизләрнең дә яратып эчкәнлеген әйтеп китик. Эсседә бернинди

тәмләткеч кушылмаган *буш чәй* эчүне артык күргәннәр. Халык бөртек чәйне *чын чәй* дип санаган, такта чәйне чүп белән чагыштырганнар.

Тукаебыз да:

*Бу дөнья һич тигез түгел,*
*Адәмнәр дә игез булмый,*
*Кеме эчкән чынаяк чәй,*
*Кеме өчне, кеме бишне,*
*Кеме бер самовар эчеп туймый,*
*Ходай тигез яратмаган...,—*

дип шаярткан.

Халыкта чәйне күп эчеп мавыгучыларны *чәйхурлар* дип атап йөрткәннәр (Казан арты керәшеннәрендә *чәй кипене* дигән сүз булган). Казан өязе Иске Кенәр авылыннан Салих мулла бер утырганда, алтмышар чынаяк чәй эчкән имеш. Көннәрдән бер көнне авыл баена кунаклар килгән, ди. Кунакларына кызык күрсәтмәкче булып, бу бай Салих мулланы чәйгә чакырган. Ике чиләк сыешлы зур самоварны чыгарып табынга куйганнар. Әмма мулла да төшеп калганнардан түгел, мәсьәләгә тиз төшенгән. Бер чынаяк эчкән дә чынаягын каплаган.

– Хәзрәт бу ни эшегез, сезне алтмыш чынаяк чәй эчә дип сөйлиләр ич,– дигән моңа хужа.

– Рас әйтәләр, менә сезгә килер алдыннан гына илле тугызны өйдә эчкән идем,– дип җавап биргән тапкыр мулла (Исмәгыйль Рәмиевтән).

Халык арасында чәйне хурлап чыгарылган такмазалар да юк түгел. Мәс., С.Г.Рыбаковның "Музыка и песни уральских мусульман" дигән китабында (СПб, 1897) түбәндәге җыр урнаштырылган:

*Бу заманда фетнә өчен*
*Чыкты чәй дигән үлән.*
*Чәйне долгка ала-ала,*
*Рәзэрит булып түлән...*

Электә татар авылларында чәй һәм аш-су өчен тотыла торган суны чишмәдән алып кайтканнар. Ул суны халык "чәй суы" дип йөрткән.

Билгеле булганча, чәйдә кофеин, эфир майлары, теин матдәсе бар, ә алар тонусны, кәефне күтәрәләр, нәтиҗәдә кешенең акыл һәм физик эш сәләте арта. Бу вакытта кан басымы да күтәрелә. Дөрес, анысы вакытлыча гына була, соңыннан басым хәтта баштагысыннан да түбәнрәк төшә.

Шунысы да мәгълүм: озак вакытлар чәй белән мавыгу бөер өсте бизләренең зәгыйфьләнүенә китерә, ә аларның эшчәнлеген торгызу еш кына мөмкин дә булмый.

Шуңа күрә кайбер табиблар гади чишмә суын эчү гадәтенә яңадан кайтырга кирәк дип саныйлар.

Кайбер табиблар исә безнең бакчаларыбызда чүп үлән дип, йолкып атыла торган кырлыган (кипрей, иван-чай) кайнатып эчәргә киңәш итәләр. Бу – күпьеллык үлән, буе 60-150 см. Яшь үсентеләрен, алсу чәчәкләрен, яфракларын һәм тамырын салат ясау, ашка салу өчен дә кулланырга мөмкин. Аның яфракларыннан кайнаткан чәй йокысызлыктан ярдәм итә, баш авыртканны баса, тынычландыра, ялкынсынуга каршы чара булып исәпләнә, температураны төшерә, эчәк эшчәнлеген нормага сала, чәч тамырларын ныгыта. Кырлыган чәен ашказаны һәм эчәк җәрәхәте булганда, бавыр һәм бөерләргә таш утырганда эчәргә киңәш итәләр. Кырлыган чәендә кофеин булмый, алкалоидлар исә безнең организмга җитәрлек кадәр генә, ә матдәләр алмашын боза торган пурин кислоталары анда бөтенләй юк.

Су, чәй, каһвә кебекләрне аяк үзендә булган хәлдә эчмәскә тиешлеге хакында хәдис бар.

**ЧӘРЕХ** *ф.* – **1.**Чарык; тәгәрмәч, көпчәк, коршау; чыгыр. // *Чәрхе фәләк* – язмыш чарыгы, язмыш чыгыры. // *Дидем: "И чәрхи фәләк, нәттем саңа, Нә кинә кылыб, нә йаздым мән саңа."*–И фәләк чыгыры, дидем, аңа, Ни кинә кылыб, ни яздым сиңа. Мөхәммәдьяр. **2.**Хәйлә.

*Дәвамы киләсе саннарда*

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Биектау

Биектау тимер юл станциясе Казаннан 27 чакрым ераклыкта урнашкан. Биектау авылы район үзәге Биектау тимер юл станциясеннән 2, Казаннан 25 чакрым ераклыкта урнашкан.

Биектау районы 1965 елның 12 гыйнварында оешкан. Үзәге—Биектау тимер юл станциясе. 1993 елның 1 гыйнварына районның мәйданы—1700 км2, халкы—50,3 мең кеше булган. 1992 елның 1 гыйнварына барлык халыкның 46,1 проценты ир-ат, 53,9 проценты хатын-кыз. 1989 елның 12 гыйнварына барлык халыкның 56,4 проценты татарлар, 41,4 проценты руслар, 0,8 проценты чуашлар. Районда 27 авыл советы, 135 торак пункт булган. Район җирләренең 17 проценты урман белән капланган.

Район җирләре аша Казан—Екатеринбург тимер юлы һәм Казан—Малмыж—Киров автомобиль юлы үтеп китә.

1993 елга районда басуларның мәйданы 92,4 мең гектар, печәнлекләр—1,3 мең гектар, көтүлекләр 23,1 мең гектар булган. Игенчеләр бодай, арыш, солы, бәрәнге, яшелчә үстерәләр. Терлекчелектә мөгезле эре терлек, җәнлек асрау тармаклары алга киткән.

Сәнагатьчелек өлкәсеннән Биектау районы җирендә түбәндәгеләрне күрсәтеп була: Казан авторемонтлау заводы, сөт заводы (Биектау авылы), Коркачык сәнагатөзү комбинаты, спирт заводы (Усад, Алат авыллары), Коркачык икмәк кабул итү предприятиесе, Ары урман хуҗалыгы.

Камай авылы янында Иске Казан шәһәрлеге бар. Өбрә авылында Салих Сәйдәшев музее, «Каменка» туберкулез диспансеры эшли.

***

Биектау исемле авыл Балык Бистәсе районында да бар. Ул район үзәге Балык Бистәсе авылыннан 47 чакрым, тимер юл станциясе Арчадан—74, Бөрсет пристаненнән 28 чакрым ераклыкта урнашкан.

Авыл атамасы тарихи-статистик, географик-статистик хезмәтләрдә, теркәү кенәгәләрендә, татар халкының авыз иҗаты әсәрләрендә һәм башка борынгы чыганакларда еш искә алына.

XVIII йөздә (Д. А. Корсаков) авылның Балдоза (Балгуза), Шомбыт суы янына утырган Көчек Чаллысы дип аталганлыгы һәм анда 151 йомышлы татар яшәгәнлеге мәгълүм. А. Артемьев китабында (1866) Шомбыт суы янына утырган бу авыл Кучуковы Челны (Балгузина) дип күрсәтелгән. Андагы 73 хуҗалыкта 472 ир-ат һәм 497 хатын-кыз исәпләнгән, авылда бер мәчет эшләгән. 1898 елда чыккан хезмәттә авыл Көчек Чаллысы (Кучуково Челны) рәвешле бирелгән. К. П. Берстель хезмәтендә (1908) дә авыл Көчек Чаллысы (Кучуково Челны) дип телгә алына һәм анда 1629 татар яшәгәнлеге мәгълүм.

Күренекле галимә Нажия Борһанова мәгълүматларына күрә, Биектау авылы халкы июньнең соңгы декадасында күршедәге Тәбәрде Чаллысы, Котлы Бөкәш Чаллысы, Бирдебәк Чаллысы, Казакъ Чаллысы, Бикчурай Чаллысы, Таулар авыллары белән Чаллы җыены үткәргән.

Олылар хәтерендә авылның Көчек (атама алыштырылган) атамасы барлыкка килү турында түбәндәге истәлек сакланып калган.

---

*Дәвамы. Башы журналның 2006 елгы 6 санында.*

Имеш, бер бабайның өч улы булган. Аның иң кече улы шушы җиргә килеп урнашкан. Гаилә корып җибәргән, тора-бара авыл зурайган һәм авылга Көчек дип исем биргәннәр. Соныннан ул Көчеккә әйләнгән. Мондый фараз халык этимологиясенә нигезләнгән.

Авылның хәзерге исеме—Биектау. Бу атаманы 1937—1938 елларда Хатыйп исемле мәктәп директоры тәкъдиме белән куйганнар һәм тарихи Көчек Чаллысы атамасы рәсми кулланыштан төшеп калган. Көчек атамасы алган авыл Әгерҗе районында да бар.

«Көчек»—этноним, ягъни кавем-кабилә исеме. Билгеле булганча, этнонимнар тора-бара кеше исемнәренә әверелә́ләр (янарак этнонимнар кеше исемнәреннән дә барлыкка килә), сонынннанрак топонимнар һәм гидронимнар булып ныгып калалар. Югарыда сүз алып барылган «көчек» сүзе дә нәкъ шундый үсеш юлы үткән һәм Көчек Чаллысы атамасы рәвешендә сакланган. Бу тирәдә Чаллылар күп, бабалар аларны бер-берсеннән аеру өчен Көчек Чаллысы, ягъни көчек кабиләләре төзегән Чаллы дип аерып күрсәткәннәр. Менә шушы этнонимны йөрткән кавем-кабиләләр безнең якларга да килеп чыкканнар, аларның бер өлеше Кече Жузга кергән казакъларны, ә икенче өлеше татар халкын формалаштыруда катнашкан.

Башкортстандагы Кара Көчек авылы да шушы ук ояга керә.

Биектау мәктәбе директоры Хатыйп әфәнде халыкка акылга муафыйк киңәш бирмәгән һәм нәтиҗәдә авыл берниндн мәгънә аңлатмый торган Биектау атамасы алып калган. Тарихтан хәбәрдар булмыйча, топонимия законнарын аңламыйча, авыл кадәр авыл, шәһәр кадәр шәһәр исемнәрен алмаштырырга ябышу—тарихыбызга, тамырларыбызга балта чабу белән бер.

Авыл атамасының икенче берәмлеге—«чаллы» турында галимнәр арасында күп төрле фикерләр яши.

Г. Саттаров, атамалары составына чаллы сүзе кергән географик берәмлекләрне болгар бабалар телендә төбе, тирә-юне ташлы булган су чыганакларын атау өчен кулланылган чал «таш», чаллы «ташлы» сүзе белән бәйли. Әзәрбәйҗан галиме Г. А. Гейбуллаев чал, чолларны төрки кавем-кабилә атамалары дип дәлилли. Г. А. Гейбуллаев фикеренә таянып, Н. Борһанова да составында чал сүзе булган атамаларны төрки чал, чол, чул этнонимнарына нисбәтән карый.

Күренекле татар галиме Һ. Йосыпов күптән инде атамалар составындагы чал берәмлеген этнонимга мөнәсәбәтле дип язып чыккан иде. Шушы җәһәттән аның «Казан татарлары этногенезын тикшерү өлкәсендә болгар-татар кабер ташларының һәм топонимнарының чыганак буларак кулланылуы» мәкаләсеннән бер өзек китерәбез: «Күп сандагы Чаллы топонимы, күрәсең, этнонимик характерда булган һәм аны елъязмаларда очраган челмат» компоненты белән бер ояда карарга кирәк. Г. М. Хисаметдинов аны этник яктан катнаш яки катлаулы (ягъни берничә төрле кавем-кабиләләр катнашкан) этноним дип фараз итә. Чуаш топонимисты Г. Е. Корнилов чал берәмлеген чуаш телендә таш мәгънәсен белдерә торган чул белән тәңгәлләп тикшерә. Ул Татарстандагы һәм Чуваш республикасындагы Чаллы исемен йөртә торган күп санлы авылларны, гәрчә алар янында бер генә таш булмаса да, Ташлы авыллар дип әйтмәкче. Бер өлкәдә, бер республикада, хәтта Урал һәм Кавказда да без бу кадәр күп Ташлы авылларны очрата алмыйбыз. Аңлатма дөреслектән ерак тора». Бу урында рус галиме Н. И. Надеждин сүзләрен китерү урынлы булыр: «Кайбер сүзләрнең, күренешләрнең мәгънәсен ачу өчен китап өеме өстендә утыруга караганда барып күрү хәерлерәк». Галим бик дөрес әйткән. Чаллы елгалары янында, төбендә, Чаллы авылларының тирә-юнендә таш булмаганнары да күп. Чаллыны таш белән бәйләү урынсыз.

Чал компоненты этнонимик характерда дип әйтелгән фикер белән тулысынча килешәбез һәм Көчек Чаллысы атамасы ике этноним (көчек + чал) кушылмасыннан ясалган дип уйлыйбыз.

Һәр авылның үз тарихы, үзенең яшәеш һәм үсеш юлы була. Биектау авылының үз тарихы бар.

Авыл халкы арыш, бодай, тары, карабодай, солы, ясмык иккән, терлек үрчеткән, яшелчәлек бөтенләй булмаган.

Революция еллары Биектау авылына нык тәэсир итә. 1918—1921 елларда авылның 150 улы Кызыл Армия сафларына алына, алар кулларына корал тотып илдә совет

хакимияте урнаштыру өчен көрәшәләр.

1941 елда авыл ир-егетләре Ватан сугышына китә, бөтен эш хатын-кыз һәм бала-чагалар җилкәсендә кала. Авыл халкы фронтка икмәк, акча, киемнәр, азык-төлек белән ярдәм итә.

Ул елларда үзләренең тырыш хезмәтләре белән тракторчылар Марзия Шакирова (8 бала анасы) һәм Хуҗагарипова Мәрьям (5 бала анасы) апалар халыкның аеруча тирән ихтирамын казаналар, алар көнлек нормаларын һәрвакыт арттырып үтиләр, күп яшьләрне трактор йөртергә өйрәтәләр.

Авыл егете Зәки Шәймәрдәнев сугыш кырында батырлык күрсәтә, авылга ул Советлар Союзы Герое булып кайта. Авыл халкы сугышта катнашучыларны онытмый, аларга тирән ихтирам күрсәтә. Сугыш корбаннарына авылда һәйкәл-обелиск куелган, анда 161 кешенең исеме алтын хәрефләр белән язылган.

Обелиск янына халык күп килә. Мәктәп укучылары Ватан сугышы корбаннарының сугышчан юлларын өйрәнәләр, аларның якты исемнәрен торгызалар, мәктәптә хәрби дан почмагы—музей оештырганнар.

Авылдан сугышка 302 ир-ат алына, шуларның 162 се һәлак була, 140 кеше исән килеш, ләкин күбесе авыр яралар алып кайталар.

Авыл бик матур уйсу җирдә урнашкан. Аны өч яктан урман чолгаган, тирә-юнендә таулар да бар. Авылны нәкъ урталай бүлеп Шомбыт суы ага, элекке вакытларда аны Ачы суы дип тә йөрткәннәр. Суның бик күп кушылдыклары бар һәм аларны халык һәрберсен үзенчә атый: Арышлар суы, Йортлар өсте елгасы, Сулы Керкәле елгасы, Пәриле нарат елгасы, Печән юлы елгасы, Көрәшчеләр елгасы, Казаклар елгасы, Иске зират елгасы, Илбак елгасы, Биккол әрчүе елгасы, Үти чабындысы елгасы, Пимәр суы, Чүп елгасы, Сусыз Керкәле елгасы һ. б.

Пәриле нарат елгасы бик тирән һәм ике яктан агачлар белән капланган. Тау башында нарат агачы үсеп утырган. Ул агачны күп тапкырлар яшен суккан һәм хәзер аның янган кәүсәсе генә тора. Бу нарат тирәләре адаштыра дип сөйлиләр. Шуңа мөнәсәбәтле рәвештә елга да Пәриле нарат елгасы дип аталган.

Давыллы елга тирәләре дә юлчыларны адаштыра торган урын, имеш. Әгәр төнлә шул турыдан үтсәң, төрле хәлләргә тап буласың икән. Бу елга ике авыл уртасына урнашкан.

Һәрбер авыл үзенең чишмәләре белән горурлана. Аларны авыл кешеләре карап, чистартып торалар. Авылга якын чишмәләр: Пимәр чишмәсе, Җамали чишмәсе һәм Сатлыган чишмәсе. Авыл басуындагылар: Бурсык чишмәсе, Баллы чишмә, Илбак чишмәсе, Йортлар өсте чишмәсе, Ташчишмә, Керкәле чишмәсе һ. б.

Күлләрдән Каенлы күлне, Мунчала күлен атап күрсәтергә мөмкин.

Авыл янындарак кына Бәхтияр тавы урнашкан. Халык аның турында болай сөйли. Имеш, Пугачев кузгалышы вакытында Бәхтияр Канкаев үзе авылга килеп, шушы тауга менеп кешеләрне үзе артыннан барырга чакырган. Моннан тыш тагын басуда Алып бабай чабата каккан тау, Пәри нарат тавы, Хәлим тавы бар.

Авыл урамнары: Бәхтияр очы, Завод урамы, Пимәр урамы, Чутай урамы, Килмешәкләр урамы. Килмешәкләр урамындагы йортларны колхоз төзегән һәм анда читтән килгән кешеләр яши. Шуның өчен урам халык телендә Килмешәкләр исеме алган.

Биектау—Балык Бистәсе районындагы иң зур авылларның берсе. Хәзерге вакытта анда 400 ләп хуҗалык бар. Авыл хәзер тагын да зурая. Шәһәрләрдә яшәп яткан яшь гаиләләр авылга кайтып урнашалар, яңа йортлар салалар.

Авылда урта мәктәп эшли, мәдәният йорты, мәчет, китапханә, шифаханә, балалар бакчасы, кибет бар. Тарих музеен халык кадерләп саклый. Халык үзәкләштерелгән газ яга. Су кертелгән, юлларга асфальт түшәлгән.

Авылда күбәүләрнең кушаматы бар: бүре, куян, аю, төлке, сулагай, дрән, чыпчык, кукай, кетер, төбе, шипай, тәпи, япон, мөәзин, пин, чараш, орлык, батман, кәптә, козмый, чыпчык, чүмеч, тояк, гөнә, әтәч, бәрән, пан, пәс, җемү, җимеш, таракан, таз, морзакай, борчак, кулик, тырнак, көтек, баклан, мора, канат, кетер, сандугач, карәҗау, таяк, җен, пәлә, пышкый, бака, сыер һ. б. Кайбер кушаматларның мәгънәсе онытылган да инде.

## Бибай Чаллысы авылы

Бибай Чаллысы Әлки районында, район үзәге Базарлы Матак авылыннан 16 чакрым ераклыкта урнашкан.

Бибай Чаллысы атамасы тарихи чыганакларда һәм фольклорда шактый искә алына. Д. А. Корсаков бастырып чыгарган тарихи белешмәдән (XVIII йөз) күренгәнчә, Бибай Чаллысы авылында 62 татар һәм 2 керәшен татары яшәгән. А. Артемьев редакциясендә басылып чыккан белешмәдән (1866) аңлашылганча, Бибай Чаллысы авылы Чаллы суы ярына утырган һәм андагы 70 хуҗалыкта 239 ир-ат һәм 245 хатын-кыз яшәгән, мәчет эшләгән. 1898 елда басылып чыккан белешмәдән билгеле булганча, Бибай Чаллысы авылында татарлар гомер кичергән. К. П. Берстель (1908) мәгълүматларына караганда, авылда 610 татар кешесе көн иткән.

Элек авыл урнашасы урын тоташ урман булган. Өлкән буын сөйләвенә караганда, авылны Бикбау исемле кеше нигезләгән. Бикбау артыннан бу җиргә башка кешеләр дә килеп урнашканнар. Алар аучылык белән шөгыльләнгәннәр һәм шуның белән тамак туйдырганнар. Әкренләп өйләр күбәйгән, авыл шактый зурайган. Бикбау исемен кыскартып, авылны Бибай дип йөртә башлаганнар.

Авыл халкы балаларын мулланың өенә биреп дин сабагы укыткан. Мәчетне Шамкай кушаматлы бер кеше салдырган. Мәчет манарасы 1933 елны кисеп төшерелгән. Аннан соң аның бер ягын мәктәп, икенче ягын клуб иткәннәр.

Авылның тирә-ягында урманнар үсә. Авыл яныннан Актай һәм Чаллы сулары ага. Чишмәләр һәм күлләр, нигездә, кеше исемнәре белән аталган. Бер күлгә Кәрим исеме бирелгән. Кышкы салкын һәм буранлы көннәрнең берсендә тракторчы белән Кәрим исемле кеше трактор чанасына калай төяп авылга кайтырга чыгалар. Авылга кайтып җитәрәк, алар буранда адашалар. Адашкан урыннарында әйләнеп йөргәндә Кәрим абзый чана астында калып үлә. Ул үлгән тау астында җәй көнне кечкенә генә күл барлыкка килә. Бу күлгә Кәрим бабай күле дип исем бирәләр. Авылда тагын Хөсәен күле, Хәллә күле һәм Дубрау күле бар. Күлләрне алар үзләренең бакча артына казыталар һәм халык күлләрне аларның исемнәре белән атый. Авылда Каюм чишмәсе, Барик чишмәсе һәм Госман чишмәсе бар. Алар барысы да бу кешеләрнең үзләре тарафыннан казылганнар. Элек ул чишмәләрдән халык эчәргә су алган. Урман ягында Сафиулла сызасы бар. Сафиулла исемле бер бай кеше шунда төпләнеп яшәгән. Аның шунда көтүлеге дә булган. Урман аланнары да шактый күп: Поп аланы, Сары алан һ. б.

Иске Чаллы белән Бибай Чаллысы арасында күпер бар. Аны халык Көмешле күпер дип йөртә. Авыл янында Җиләклек, Трифон урыны, Өч елга дип атала торган печәнлек җирләр бар.

Авылда өч зират бар. Беренче борынгы Керәшен зираты. Бу зиратка чукындырылган кешеләр күмелгән. Авыл уртасында иске зират һәм хәзерге зират урнашкан.

Авылда күп кеше музыка коралларында уйнаган, хәзер дә уйнаучылар бар. Элек скрипкада уйнаучылар да булган. Скрипканы Каюм исемле кеше ясаган.

Авыл халкы йортларын бик матур итеп, кәрнизләрен, тәрәзә яңакларын, рәшәткәләрне бизәкләп эшләгәннәр. Йортлар матур һәм яңа. Халык ашамаса ашамас, әмма каралты-кураны ямьле итеп, нур агып тора торган итеп төзәр, аны карап, төзекләндереп торыр.

Бибай Чаллысы авылы халкы төрле яктан сәләтле. Кешеләр бер-берсеннән мөнәҗәтләр, бәетләр язып алганнар һәм кич утырганда аларны бер-берсенә сөйләгәннәр, укыганнар.

Хәзер авылда барысы 47 йорт. Башлангыч мәктәп, клуб, медпункт бар. Авыл халкы үзәкләштерелгән газ яга, юлларга асфальт түшәлгән.

Авылда 1997 елның 18 нче июлендә мәчет ачу тантанасы булган.

Һәр авылдагы кебек Бибай Чаллысы халкы да бер-берсенә шактый үзенчәлекле кушаматлар таккан. Алар арасында әтәч, сарык, чулчин, мәче, капчык, куян, тавык, төтен, сөт, әпчек, шайтан, чегән, тоз, бәһый, кәшки, кусыпе, леке, кердеш, аю, бәбәй, песәй кебекләре бар.

## Җәке авыллары

Олы Җәке авылы Зеленодол районында, район үзәге Зеленодол шәһәреннән 40, Казаннан 42 чакрым ераклыкта урнашкан.

Олы Җәке авылы шактый борынгы заманда оешкан. Ул Казан ханлыгы чорында да булган.

Питиал суы ярына утырган бу авыл Д. А. Корсаков җыентыгында (XVIII йөз) искә алына. Анда 138 ясаклы татар яшәгән. Йомышлы Җәке исеме белән бирелгән авылда—14 йомышлы татар, Кече Җәкедә—2 керәшен, 9 йомышлы татар булган. А. Артемьев хезмәтендә (1866) күрсәтелгәнчә, Олы Җәкедәге 92 хуҗалыкта 356 ир-ат һәм 389 хатын-кыз яшәгән, авылда бер мәчет эшләгән. Кече Җәкедә 5 йорт булып, анда 22 ир-ат һәм 30 хатын-кыз гомер иткән, Н. Н. Вечеслав Олы һәм Кече Җәке авыллары турында мондый мәгълүмат бирә. Олы Җәкедәге 119 хуҗалыкта 436 ир-ат һәм 443 хатын-кыз исәпләнгән, авылда бер агач мәчет, мәдрәсә, бер кибет булган. 1898 елгы китапта Олы Җәке һәм Кече Җәке авылларында татарлар яши дип искәртелә. К. П. Берстель белешмәсе мәгълүматларына караганда, Олы Җәкедә 990 татар кешесе яшәгән.

Авылның тирә-юнена нисбәтле атамаларны саный башласаң, аларның хисабы илледән артып китә. Бу атамаларның һәркайсы урынлы, мәгънәле (әлбәттә, серлеләре һәм бик үк аңлашылып бетмәгәннәре дә бар), янгырашы аһәңле һәм, бербөтен буларак, барлык татар авылларына хас система тәшкил итәләр.

Суфия чишмәсе тау өстендәге бер чокырдан агып утыра. Беренче булып бу чишмәне Суфия исемле хатын таба һәм аның хөрмәтенә кизләүне шулай атыйлар.

Изгеләр чишмәсе. Бу урында изге кешеләрнең мәетләре күмелгән, каберлекләр рәшәткә белән уратып алынган, ә аның кырыеннан чишмә ага.

Тукран елгасы буенда каеннар үсеп утыра (авыл халкы аны посадка дип атый). Ел саен анда тукран тукылдаган тавыш ишетелгәч, елгага Тукран дип исем биргәннәр.

Бакыр елга. Бу елганың суы һәрвакыт болганчык сарырак төстә булган.

Озонбы елгасының ни өчен алай аталганын белүче юк. Озын болын сүзе белән бәйләп аңлатырга да тырышалар.

Әби дәүәни улагы. Бу урында аеруча күп булып үгиана яфраклары үсә. Авылда усал үги ананы әби дәүәни дип атыйлар.

Питиалка күле авыл уртасында тирән генә күл булган. Аңа биш авылның суы аккан. Хәзер бу күл кибеп беткән, яз көне генә күл икәнлеген белгертеп ала.

Каратмән күле. Күл буенда киң яфраклы, карасу әрекмәннәр үсеп утырган. Ә атаманың төбендә нугай татарларының карабәк (би) исеме алган төркеме һәм «төмән» («мең») сүзе ята. Якында гына Каратмән авылы да бар.

Таллык күлен икенче төрле Таллык буе дип тә атыйлар. Чөнки күлнең бөтен ягын тал агачлары әйләндереп алган.

Әпәли урманы. Бу урманда ялгыз гына бер сакау яки әпә кеше (телсез) яшәгән.

Пәхри урманы. Авылда Фәхретдин исемле бай кеше яшәгән. Урман аның исеме белән аталган, чөнки ул аның җирендә булган.

Соловьевка урманы. Җәке авылы янында руслар яши. Урман бик матур һәм анда һәрвакыт кошлар сайрый. Руслар бу урманга сайрар кош—сандугач (соловей) исемен биргәннәр. Урман Соловьев фамилияле кеше җирендә урнашкан булганга да шулай аталырга мөмкин, әлбәттә.

Тукый йорты урманы. Бу атама кеше кушаматыннан ясалган. Шушы йортта торучы кеше мунчаладан намаз укый торган палас тукыган һәм шуны сатып көн күргән.

Кече Җәке урманы. Олы Җәке авылының кайбер гаиләләре икенче урынга күченеп китәләр һәм урман буенда кечкенә генә авыл—Кече Җәке барлыкка килә.

Гаптиева рощасы. Бу атаманың килеп чыгышы күбәүләрнең хәтерендә. Колхозлашу чоры башлангач, районнан авылга колхоз төзелешен ныгыту өчен комсомолка кыз Гаптиева җибәрелә. Бервакыт чәчү өчен әзерләнгән бодайны урлыйлар. Гаптиева каракларның эзенә төшә. Бодай кулак амбарында була. Авыл байлары Гаптиевага күп мәртәбә үлем белән яныйлар. Беркөнне Гаптиеваның районнан җыелыштан кайтып килгәнен сагалап торалар һәм аны үтерәләр. Шушы

фажигадан соң куаклыкны «Гаптиева рощасы» дип йөртә башлыйлар. Халык хәтерендә «Гаптиева бәете» әле дә саклана.

Мәһирауза урманында шул исемдәге дивана кыз адашып үлә.

Иван чокыры кызыл балчыклы булган. Яңгыр яуса бу чокырдан чыгу бик авыр булган. Иван исемле кеше шунда батып үлгән.

Бәкәли чокыры. Бу кечкенә генә бокалга охшаган чокыр, исеме шуннан килә диләр.

Тухтәнгир чокыры. Авыл халкы Тухтәнгирне мари исеме дип уйлый. Бу ярлы мари кешесе шушы чокырга утын алып кайтырга йөри торган була.

Акбалчык чокыры авылдан якын гына урында тау башында. Авылның хатын-кызлары мич агартыр өчен шушы чокырдан ак балчык алып кайтканнар.

Өч шомырт чокыры буенда рәттән өч шомырт агачы үсеп утырганга шулай аталган.

Аерым Исхак чокыры. Колхозлашу елларында Исхак исемле кеше авылдан аерылып, шул чокыр буена күчеп китә. Колхозга кермичә читтә яшәгәне өчен чокырга аның исемен биргәннәр.

Хамаша чокыры. Мөхәммәтша исемле бай кеше жирендә урнашкан бу чокырны, Мөхәммәтша исемен кыскартып, Хамаша чокыры дип атаганнар.

Кашлак чокыры. Кашлак—«тау бите» дигән сүз. Биек тау битеннән якын гына урнашкан чокырны шулай дип атыйлар.

Көтүче чокыры. Авылда гомере буе көтү көтеп яшәгән бер кеше була. Ул чокыр буенда алачыксыман өйдә торган һәм шунда картаеп үлгән.

Ялгыз имән чокыры. Бу чокыр янында бер имән агачы ялгыз гына үсеп утырган.

Бүре чокыры. Авыл янындагы бу чокырда бүреләр яшәгән. Бүреләрне кырып бетергәннәр, ләкин шул бүреләрне аткан өчен үкенәләр, чөнки авыл янындагы урманнар хайваннарга, жәнлекләргә бик ярлыланган.

Таулардан сәеррәк исемлеләрен күрсәтик.

Кишәнгер тавы. Бу тау итәгендә жир жиләге күп булган. Тау янына барган һәр кеше жир жиләгеннән авыз итми калмаган.

Ахшамак тавы. Имеш, бу тау исеме «акчам юк» дип сөйләшергә ярата торган кешенең кушаматыннан алынган. Бу фараз «халык этимологиясенә» корылган, әлбәттә.

Экспедиция дәфтәремә болыннардан Карамалы болыны (ул Кишәнгер тавы өстендә), Урта күпер болыны (Питиал күле аша өч күпер салынган: Олы күпер, Урта күпер һәм Кече күпер. Күл буендагы болынны Урта күпер болыны дип йөриләр) һәм Озын болын теркәлгән.

Жәке авылы түбәнлеккә утырган. Жәйләрен һәм бигрәк тә яз-көз көннәрен авылда үтеп булмаслык пычрак була. Авылны икегә күпер бүлеп тора. Күпернең сул ягын Түбән як, ә уң ягын Югары як дип йөртәләр. Югары як, әлбәттә, корырак булган. Марсель Әхмәтжанов мәгълүматына күрә, Олы Жәке авылының бер очы хәзер дә Чураби урамы булып йөри.

Авылда урта мәктәп, балалар бакчасы, мәдәният йорты, китапханә, медпункт, мәчет, кибет эшли. Халык үзәкләштерелгән газ яга, юллар асфальтланган.

•••

Атамаларында «жәке» берәмлеге булган авыллар Мамадыш районында да бар. Түбән Жәке авылы район үзәге Мамадыш шәһәреннән 26 чакрымда, Кукмара тимер юл станциясеннән—65, Казаннан 131 чакрым ераклыкта, Казан-Чаллы трассасы янында урнашкан.

Югары Жәке һәм Түбән Жәке авыллары тарихи чыганакларда шактый еш телгә алына.

Түбән Жәке авылы зиратында соңгы болгар—Алтын Урда чорына мөнәсәбәтле кабер ташлары һәм Түбән Жәке зиратының көнчыгыш өлешендә, Омар суының уң ярында шул ук чорга нисбәтле авыл хәрабәсе билгеләнгән. Д. А. Корсаков белешмәсендә Югары Жәке, Түбән Жәке авыллары теркәлгән. Югары Жәкедә—63, Түбән Жәкедә 65 ясаклы татар яшәгән. Ике авыл да Омар суы буенда утыра дип

күрсәтелгән. 1859 ел мәгълүматларын туплаган тарихи белешмәдә билгеләнгәнчә, Жәке суы ярына утырган Түбән Жәкенең 68 хуҗалыгында 289 ир-ат һәм 387 хатын-кыз гомер кичергән, мәчет эшләгән. Югары Жәке авылының 48 йортында ислам дине тота торган 190 ир-ат һәм 203 хатын-кыз яшәгән, мәчет эшләгән. Түбән Жәке авылы «Аграрный вопрос и крестьянское движение в Татарии XIX века» (М. -Л., 1936, 318—319) дип аталган тарихи чыганакта телгә алына. Андагы халык мәдрәсәдә рус теле укытуга бердәм рәвештә каршы чыккан.

И. А. Износков белешмәсендә ике авыл да Жәке суы ярына урнашкан дип күрсәтелә. Югары Жәкедә 221 ир-ат һәм 231 хатын-кыз, Түбән Жәкедә 322 ир-ат һәм 308 хатын-кыз яшәгән. 1898 елда басылып чыккан белешмәдә ике авылда да татарлар көн күрүе турында әйтелә. К. П. Берстель белешмәсендә күрсәтелгәнчә, Түбән Жәке авылында—1020, Югары Жәкедә 792 татар кешесе яшәгән.

Н. Борһанова мәгълүматларына караганда, Югары Жәке авылы халкы күршедәге Урта Кирмән, Кече Кирмән (Кирмәнбаш), Арташ, Нурма, Алан авыллары белән бергәләшеп Кирмән җыены үткәргән. Бу җыен июнь уртасында бәйрәм ителгән. Түбән Жәке авылы халкы Уразбакты авылы белән берләшеп июнь ахырында Имән базары исемендәге җыен үткәргәннәр.

Хәзерге Мамадыш районындагы Түбән Жәке һәм Югары Жәке авыллары революциягә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязенә кергән. Авыллар яныннан шактый күренекле Омар елгасы агып үтә.

Түбән Жәке авылы табигатьнең гаҗәеп матур урынына утырган. Биек жирдән караганда ул аеруча ямьле булып күренә. Көмештәй чиста сулы Керәнче елгасы Инешкә кушыла. Авыл читендә ак таштан салынган фермалар тезелеп киткән. Арырак, басулар артында, офыкка сузылган урман. Авыл елга-суларга, чишмә-кизләүләргә бик бай. Кая карама берсеннән-берсе тәмле сулы чишмәләр чыга. Аларның исемнәре генә дә ни тора: Куян, Кызыл яр, Кушай, Серьги (тегерманче рус Сергей хөрмәтенә шулай аталган), Мәүлет, Ташкисәр, Тау арты, Айман, Кама башы, Сулы-сусыз чишмә һ. б. Изгеләр чишмәсе дип йөртелгән чишмә авылда икәү. Берсенең суы салкынча, икенчесенеке—җылымса. Шул чишмәләрнең берсе баш һәм күз авыруларына файдалы, икенчесе йөрәк авыруларын сихәтләндерә. Шуңа күрә җәйнең матур көннәрендә чишмәләр буенда аларның шифалы суларын эчеп, юынып, тазарырга өмет баглап килүчеләрне еш күрергә мөмкин. Изгеләр чишмәләреннән өстәрәк кечкенәрәк зират та бар. Ул да изгеләр зираты дип атала. Авыл халкы ул зиратны һәм чишмәләрне зурлап изге исеме биргән. Бер-берсе белән рәттән урнашкан һәм жирдән саркып чыгучы көмештәй саф сулы бу чишмә-кизләүләрне карап, чистартып торалар.

Елга-чокыр, тау битләре, урманнары төрле-төрле җиләкләргә, агач җимешләренә бик бай. Җәй, көз айларында авыл халкы табигать хәзинәсеннән шактый нигъмәт хәстәрли.

Олылар сөйләвенә караганда, элек авыл урынында мәһабәт һәм төп-төз нарат урманнары булган. Урын үзенең матурлыгы һәм тынычлыгы белән кызыктырган.

Дәүләтшин Мөхәммәтхан һәм Вәлиев Гали абыйлар сөйләвенә караганда, авылга иң элек килеп урнашкан кешеләр тау куышлыкларында яшәгән булсалар кирәк. Тау битләренә урнашкан 5—6 лап куыш була. Һәр куышның авызын каплый торган капчыкларына кадәр сакланган вакытларны да хәтерли Мөхәммәтхан абый. Вакытлар узу белән ул куышлар җимерелеп бетә.

Куышта торучыларны халык төрлечә фаразлый. Иван Грозный патшалык иткән вакытта үзләренең динен сатмас өчен чукындырудан качып килгән татарлар булмаганмы болар дип тә уйлыйлар.

Түбән Жәке авылы ничек барлыкка килгән?

Югарыда исемнәре аталган өлкәннәр белән бер рәттән укытучы Хисмәтуллин Нурулла, Гафифә апа һәм башкалар авыл оешуны болайрак сөйлиләр.

Югары Жәке һәм Түбән Жәке авыллары башыннан Лашман юлы узган. Бу юлдан күп сандагы атлар белән имән һәм нарат агачларын бөтен буе белән Казандагы Аракчинога (Адмиралтейство бистәсенә) тарттыра торган булганнар. Бу—Петр I патшалык иткән чор була. Ул агачлар кораблар ясау өчен киткән.

Түбән Жәке белән Югары Жәке авыллары арасында «Злом» борыны дигән урында агач тарттыручы атлы колонна туктап хәл ала торган була. Атларны да ашатканнар, эчерткәннәр. Ул урында атлар өчен аерым абзарлар, лапаслар төзелгән булган.

Югарыда әйтелгәнчә, Казаннан 40 чакрым ераклыкта, Зеленодол районында Олы Жәке дигән татар авылы бар. Агач тарттыруда шул авыл кешеләре дә катнашкан була. Туктап ял иткән вакытта алар әйләнә-тирәгә күз салалар, тикшерәләр һәм бу урын яшәү өчен әйбәт җир булырга ошый дигән нәтиҗәгә киләләр. Урманга бай, чишмә-сулары күп, табигать җимешләре һәм нигъмәтләре дә чамасыз унган урын кемне кызыктырмас?

Авылларына кайтып сөйләшәләр, кинәшәләр һәм хәзерге ике авылга күчеп тә киләләр. Лашман юлының югары ягына утырганнары авылны Югары Жәке, ә түбән ягына утырганнары Түбән Жәке дип атаганнар. Һәр татар авылының зур тарихы бар. Жәке исемен йөрткән авылларның да тарихы зур һәм борынгы. Аның үткәне киләчәктә тагын да җентекләп өйрәнелер.

1930 елларда авылда клуб булмый. Шул елларда Себергә җибәрелгән Гәрәй байның алты почмаклы йортын кызыл почмак итеп оештыралар. Зуррак бүлмә клуб урынына файдаланыла. Бу кызыл почмакта беренче ачылган елларны китап бик аз була. Өстәлләргә газета-журналлар тезелә, кечкенә брошюралар куела. Шунда ук домино, шашка, шахмат уеннары да оештырыла. Клубта һәм кызыл почмакта аңлату һәм оештыру эшләрен бер кеше башкарган. Авылда культура тармагында беренчеләрдән булып Тәкәнеш районыннан (ул елларны аерым район саналган) килгән Хәмидуллин дигән кеше эшләгән.

1938 елларда избач (изба-читальня сүзеннән, ягъни китапханәче) һәм партячейка секретаре вазифаларын да Фәсхиев Хөҗжәт башкара. Сугыш елларында авыл халкы арасында мәдәни-агарту эшләрен Миннур ага алып бара.

1947 елның язынннан Шиһапов Исмәгыйль культура-агарту эшләренә җитәкчелеккә тәкъдим ителә. Бер үк вакытта ул клуб мөдире һәм уку йорты мөдире вазифаларын да башкарган. Клубта драмтүгәрәк оештырыла, уку йортына матур әдәбият сөючеләр тартыла. Иске мәчетне (арт урамда була) олы урамга күчереп салалар. Аның зуррак өлеше уку йорты, кечерәк бүлмәсе колхоз идарәсе итеп оештырыла. Уку йортында китаплар бер шкафка сыеп беткән. Барлыгы 370 ләп китап була.

Революциягә кадәр авылда 250 дән артык хуҗалык булган. Авыл ике мәхәлләдән торган, ике мәчет эшләгән, мәдрәсә булган. Беренче мәхәлләдә Һадиев Нәҗип, икенчесендә Шәрәфи мулла имамлык эшләрен башкаралар.

1912 елда авылда көчле янгын чыгып 193 хуҗалык һәм 1 мәчет янып бетә. Янгын Ульданов Каюм бабайлардан чыга.

1918 елда Сөнгатуллин Вафа абый һәм мулла малае Сәүбән белән үз өендә (мәктәп итеп) балалар укыта башлый.

1920 елда Түбән Жәкедә 4 сыйныфлы мәктәп ачыла. Авылда укый-яза белмәүче кешеләр күп була. Аларны педагогия училищесы әзерләп чыгарган укытучылар укытканнар. Дүрт классны тәмамлаган укучылар Урта Кирмәнгә барып укыганнар. Түбән Жәкедә җидееллык мәктәп 1966 елда ачыла. Иске мәктәп янында үсеп утыручы мәһабәт каеннар 1929 елда утыртылган. Гомерләрен балалар укытуга багышлаган олпат укытучылар һәр татар авылында очрый. Андый шәхесләр Жәкедә дә бар. Нурулла абый Хисмәтуллин 1933 елдан алып 1975 елга кадәр гомерен балалар укытуга багышлаган. Түбән Жәкегә килгәнче бер ел Арташта, бер ел Югары Жәкедә укыткан.

Авыл матур гына яшәвен дәвам итә. Анда хәзер урта мәктәп, мәдәният йорты, медпункт, китапханә, балалар бакчасы эшли. Юллар асфальтланган, халык газ яга.

# ...БИЗДЕРГӘН ДӘ ТЕЛ

**Журнал 7нче санда Адлер Тимергалинның «Татарга нигә кагыйдә?» дигән мәкаләсен басып бик дөрес эшләгән, зур гыйлемгә ия әдибебез исә тел-орфография мәсьәләсен бик тә, бик тә вакытлы кузгаткан.**

Заманалар үзгәреп, матбугат, сүз ирege алдык дип түш киереп йөри башлагач, телебезгә дә караш үзгәреп китте. Татар телендә яңа газеталар арта барган саен ана карата талымсызлык та арта барды. Аларның һәркайсы үзенчә сукалый, термин-атамаларны үз «күңеленә» хуш килгәнчә яза башлады.

Совет власте вакытында терминнар комиссиясе эшләп килде.

Язып кара ул елларда хәзерге кебек бер үк сүзне ике-өч төрле итеп!

Тагын күпме вакыт «түгәрәк өстәл артында сөйләшү», «уныш астына ашлама кертелде», «одеял эченә кереп ятты» дип язарбыз икән? Болары еллар буена газета-журнал битләрендә кабатланып килә торган сүзтезмәләр булса, инде тәрҗемә аша кергән колакка ятышсыз атамаларны тавык та чүпләп бетерә торган түгел. Телевизордан яки радиодан тапшыру алып баручы «Безнең тапшыруыбыз ахырына якынлашып килә», ди. Урысчасы: «Наша передача подходит к концу». Шуны саф татарча итеп «Тапшыруыбыз тәмамланып килә», дип әйтеп булмыймыни?

Рус телендә «освоил» дигән, еш кулланыла торган сүз бар. Шуннан: «Төзү-монтаж эшләрендә 520 миллион сум үзләштерелде.» Шулкадәр акча үзләштергәч, бу төзелештә гел караклар гына эшли микәнни соң?

2005 елның июлендә Алабугада нефть, энергетика тармакларын үстерү хакында җыелып киңәшү булды. Кайбер газеталарда «Алабуга шәһәрендә саммит үткәрелде» дип хәбәр иттеләр. Нәрсә соң ул саммит? 2002 елда чыккан «Краткий словарь политического языка» дигән сүзлеккә багам: «Саммит— встреча глав государств, совещание на высшем уровне». Бу очракта «киңәшмә» нигә ярамаган?

Менә тагын тешне сындыра торган бер ят сүз телебезгә үз аягы белән килеп керде: «миллинеум». Казанның меңьеллыгын бәйрәм иткән көннәрдә ул бик тә «модный»га әйләнде. Татар телендә чыга торган газета-журналларны укучылар гына түгел, русларның да күбесе әле моның мәгънәсенә һаман төшенә алмый. Мин үзем аны бер сүзлектән эзләп таптым. Үзебездә бар сүз икән бит, «меңьеллык» икән!

Рус теленнән кергән сүзләрне саф татарча итәбез дип мәгънәви төгәлсезлекләр дә җибәрелә. Халык телендә күп еллар буе «повар» булып йөргән сүз бер селтәнүдә «пешекче»гә әйләнде дә куйды. Повар ничек пешекче булсын инде, «пешекче» сүзенең тамырында «пешекләү» ята бит. «Поселок» «бистә» икән. Ә «слобода» нәрсә? «Больница» сүзен дә миңа төрләндереп бетердек: сырхауханә, хастаханә, ятакханә, шифаханә... «Льгота»—«ташлама» икән. Ләкин «скидка»да—«ташлама» бит.

«Сотовый телефон»ны «күзәнәкле телефон» дип тә, «кәрәзле телефон» дип тә язалар. Татар сүзен рус сүзеннән ясыйм дисәң, шулай анысы—кәрәзле телефон. Ләкин аның кәрәзгә ни катнашы бар? Ник шуны гади генә итеп, үзебезчә әйтмибез: «чыбыксыз телефон», «кесә телефоны».

Гомер-гомергә тәрҗемә телгә, бигрәк тә аерым терминнарның әйтелешенә бәйле фикер каршылыклары булып торды. Мин үзем эшләгән «Ватаным Татарстан» газетасында бастырып чыгару өчен партия съездында М. Горбачев

ясаган докладтагы «гласность» сүзен төгәл тәржемә итә алмыйча интеккән комиссия әгъзаларынын кызып-кызып бәхәсләшкәннәрен хәтерлим. Барыбер унышлы тәржемәсе табылмады ул чакта. Съезд документларына «ачыклык» дип керде. Тик берничә елдан сон гына кемнендер башына килеп, «хәбәрдарлык» дип алырга тәкъдим итте һәм телебездә шулай урнашты да ул.

Туган телебезнен сафлыгын саклау, телдәге чатаклыклар, язылыштагы ике төрлелек турында вакытлы матбугат әледән-әле үзенен сүзен әйтә тора. Шул хакта телчеләрнен, язучылар һәм журналистларнын борчылып язган мәкаләләре чыгып килә. Тик менә шуннан сон нәрсә эшләнде һәм эшләнә?

А. Тимергалин хаклы: «Һаман саен сүздә генә калу килешми, күмәкләшеп, оешып, әртилебез белән тотынып, бу юлы эшне «үле ноктасыннан» кузгатып җибәрик...» Шулай булмаса, стенага борчак атудан файда юк.

**Мөнир АБДУЛЛИН**

---

# ТЕЛ БАЙЛЫГЫН КАЛӘМ САКЛАР...

Ни хикмәттер, орфографиягә, сүзләрнен дөрес язылышына элегрәк игътибар көчлерәк иде сыман. Ул гынамы, үткен күзле кайбер «мыжык» укучылар газета-журналлардагы имла хаталарын эләү белән генә чикләнеп калмыйча, тыныш билгеләрен куюдагы ялгышларны да чүпләп чыгарга иренмиләр иде. Үзе үк эшли торган газетадан хөсетләнеп пунктуация хаталарын эзләүче берәүгә шундыйрак такмак чыгарганыбыз да истә әле... Сибгат Хәкимнен мәгълүм шигырендәге ритмик үлчәмгә ияреп, ул хезмәттәшебез болай дип тиргәнә-сукрана, янәсе:

*Нервы бетә, каһәр, газетадан*
*Эзли-эзли сынар бер хата;*
*Башка берни дә кирәкми,*
*Эзләп тапсам,*
*Хәбәр салсам,*
*«Югары»га шул хакта!*

Хәзер исә андый үҗәтләрнен пгул рәвешле «казынулары» артык булмас иде бәлки: артта «очлы күзләр» барлыгын истән чыгармыйча «ташка» бастырганда орфография, пунктуация мәсьәләләренә җаваплырак карыйсын бит ул.

Бер үк сүзне төрлечә язу очракларынын иге-чиге юк. Тукай китапларында тәкрар итү бар, ә без тәкърарлап язабыз. Мәхмүт Галәүнен «Мөһаҗирләр» романы бар, шунын «моһаҗир» формасында язылышы да еш очрый. Кайсы дөрес? Тагын: фатиха—фатыйха, вазифа—вазыйфа, имла—имля, тугъры—тугры, фидакарьлек—фидакярлек, шәрык—шәрекъ, казах—казакъ, әбәд—әбәт, челпәрәмә—чәлпәрәмә. Ә кеше исемнәре белән нинди буталыш китте? Әйтик, Тәлгат та бар, Тәлгать тә. Салих—Сәлих, Вазыйх—Вазыйхларны кем ничек тели, шулай яза. «Дәрдмәнд» дигән бөек шагыйребез дә «Дәрдеменд» дигәне дә бар. Тагын бер сүз барысыннан да уздырган, анысы өч рәвештә языла икән бит: ядкарь, ядкәр, ядкяр.

«Тузга язылган онытылмый», дигән борынгылар. Ягъни ишетелгән онытылса да, элегрәк «тузга язган», хәзер исә «ташка басылган» хәтердән җуелмый, күзләр аша күнелгә нык сенеп кала. Тел байлыгын сак тоту, бу хәзинәдән дөрес файдалану өчен кулларыбызда «үткен каләм» бар лабаса!..

**Илдус ДИНДАРОВ**

## «Һәм»нән «хам» ясамыйк!

Хөрмәтле «Казан утлары» хезмәткәрләре!

Сезгә журналны күп еллар алдырып, яратып укучыгыз яза. Адлер Тимергалинның 7нче санда басылган, «Татарга нигә кагыйдә?» дигән мәкаләсен зур канәгатьлек белән укыдым. Бик тә житешкән мәсьәлә, ягъни тулышкан шеш бу. Татар телен куллану, әйтелеш һәм язылыш мәсьәләсен һәрьяклап тикшереп, тиешле карарлар кабул итәргә вакыттыр.

Миңа ел да Казанда булырга, «Колшәриф» мәчетендә, әлхәмделиллаһ, җомга намазларын укырга туры килә. Татарча радио тапшыруларын яратып тыңлыйм, сөйләшүләргә игътибар итәм. Ошаганы күп, язып тормыйм, рәнжеткәне Казан радиосында «һ» авазын «х» белән алмаштырулары. Ничек инде «арыш хәм бодай», «Казан шәхәре» (моңлы шәхәр, нурлы шәхәр?), «әти хәм (хам?) әни» була ала?! Тапшыруларны алып баручылар, артистлар—профессионаллар, үз эшләрен камил башкарсын өчен акча алучы кешеләр ләбаса! Аннан, алар тапшыруларны дәвам итсеннәр инде, иттермәсеннәр (кемнәндер!).

Барысын да язып тормыйм, минем сүзне дәвам итүчеләр һәм үстерүчеләр, шәт, булыр әле.

**Мәхмүт САБИРОВ,**
*хезмәт ветераны,*
*медицина фәннәре кандидаты.*
*Уфа*

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кульязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)

# ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛУ БАШЛАНДЫ

Хөрмәтле укучыларыбыз!

2008 елның беренче яртысы өчен вакытлы матбугатка язылу башланды. «Казан утлары»ның индексы—**73210**, Татарстанда ярты елга язылу бәясе **168 сум**.

Журналга язылуны җиңеләйтү максатыннан быел да абонемент үрнәген тәкъдим итәбез. Шушы квитанцияне кисеп алып, анда үзегезнең тулы адресыгыз, исем-фамилиягез һәм язылырга теләгән айларны күрсәтеп, үзегез яшәгән җирдәге элемтә бүлегенә тапшырырга кирәк.

Казанлылар журналга «Горпечать» киоскларында языла алалар. Бу очракта журналны да шуннан барып аласы була. Фатирыгызда почта әрҗәсе бик үк ышанычлы булмаса, сезгә моннан да кулай ысул юк.

«Казан утлары»на язылырга онытмагыз!

Ф.СП-1

Управление почтовой связи
"Татарстан Почтасы"

**АБОНЕМЕНТ на** ~~газету~~ журнал **73210**
(индекс издания)

***Казан утлары***
(наименование издания)

Количество комплектов:

на **2008** год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ____________ ____________
(почтовый индекс) (адрес)

Кому ____________
(фамилия, имя, отчество)

---

**ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА**

| ПВ | место | литер |
|---|---|---|
| | | |

на ~~газету~~ журнал **73210**
(индекс издания)

***Казан утлары***
(наименование издания)

| Стоимость | подписки | ______ руб. ______ коп. | Количество комплектов |
|---|---|---|---|
| | переадресовки | ______ руб. ______ коп. | |

на **2008** год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ____________ ____________
(почтовый индекс) (адрес)

Кому ____________
(фамилия, имя, отчество)



**—Газетагызның исеме гел үзгәреп торган: «Эш», “Кызыл Татарстан», “Совет Татарстаны», “Социалистик Татарстан». 1992 елдан алып—«Ватаным Татарстан». Кемнәрнедер хәзер бу исем куркытадыр да. “Ватаным Россия» дигән газета чыгарыр заманнар килмәсме?**

***Миңназыйм СӘФӘРОВ, «Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррире:***

—Исем алыштыру безнең кандадыр инде. Күрәсең, шул рәвешле начар үткәнебездән, яман гамәлләребездән котылмакчы булабыздыр. Ләкин үзеңнән качып булмый шул. Булганны җимерүгә корылган кыйбласызлыгыбыз бу безнең. Беренче кабат чит илгә баруымда шаккаткан идем: итальяннар бер генә һәйкәлне дә җимермәгәннәр. Искесе янәшәсендә янасына да урын табып була икән бит. Миңа калса, исем алыштырып азапланганчы кыйбланнан тайпылмыйча яшәвең мең кабат хәерлерәк. Татарның Рәмиевләре чыгарган «Вакыт»ны дәвам иткән булсак, татар матбугаты бүгенге хәлгә үк калмаган булыр иде дип уйлап куям. Шуңа да моннан 15 ел элек үзгәртелгән исемебез мәңгелек булсын иде дигән теләктә калам. Ә инде «Ватаным Татарстан» дигән исемнең тора-бара мәскәүләрнең ачуын китермәсме дигәнгә килсәк, авызыбызга су кабып торсак, шикләнмәскә була—исемегездән сепаратизм исе килә дип әйтүчеләр табылачак. Ирек бирелгән заманнарда гына түгел, ирек бик нык кысылган чорда да без—журналистлар дөресен сөйләүдән туктамаска тиеш. Чөнки халыкны бары тик фикер генә бергә туплый һәм юкка чыгудан саклап тора. Кыйбласызлык бүген тагын татарны укудан читләштерде. Фикерле, житди, уйландыра торган укудан читләштерде. Ләкин бу вакытлы гына күренеш. Тамагы туйса да, кеше дигәнең барыбер «Мин бу дөньяга нәрсә өчен яратылган соң?» дигән сорауга җавап эзләмичә булдыра алмый. Хайвани инстинктлар белән озак яшәп булмый. Нәкъ менә шуның өчен дә безгә—житди матбугатта эшләүче журналистларга төшенкелеккә бирелергә яки башка күпчелек артыннан «җинеләергә» яки «саргаерга» ярамый. Вакыт дигәнең бик тиз узучан ул. Инде «җинеләйгәннәр» дә сәясәт турында язмыйча булмаганлыгын аңлап килә бугай. Көн саен тирләп-пешеп ярышка әзерләнгән йөгерешче генә җиңүгә ирешә ала бит. Тагын ирекле заманнар килер дә халык безне кырылып укый башлар дип хыяллану акылсызлык булыр иде. Моннан да ireклерәк заман бүтән булмастыр дип эшләргә кирәк. Көн саен үзеңдәге куркуны һәм фикер ялкаулыгын җинсәң генә иртәгесе көнең ышанычлы буладыр ул.

Ә планнар зурдан. Алла боерса, атнасына бер тапкыр чыга торган дүрт кушымталы «ВТ-Әллүки» санын татарлар яшәгән барлык төбәкләргә дә таратырга исәбебез. Күбесенчә анализга, уйландыра торган язмаларга корылган бу газетаны үзен татар санаган һәркем укырга тиеш. Бу эштән Татарстан хөкүмәте белән Президентыбыз да читтә калмас дигән өмет бар. Ни генә дисәк тә, уртак бер эш башкарабыз бит бүген. Россия хөкүмәте регионнарда яшәүче гражданнарын «Российская газета»га яздыру өчен миллиардлар тапканда татар өчен дә тырышып карарга ярардыр бит.

Вакыйф
Нуриев

# СОҢГЫ ЙӨРЕШ

Ул көнне Сеже балалары да, Мөрәленекеләр дә әче таңнан торып чыктылар. Автобус тукталышында түгәрәкләнделәр. Болар—Арчага район беренчелегенә үткәреләчәк шахмат ярышына баручылар.

Авыл әле уянып кына килә. Морҗалардан чыккан горур төтен баганалары төн юрганын күтәргәннән-күтәрә бара. Яктыра. Тынлык. Лампочкалы багана төбендә әвәрә килгән урам этләре дә, төнге аудан биһуш булып кайтып килгән җирән мәче дә, аяк астындагы карның тансык шыгырдавы да бу тынлыкны боза алмый. Илаһи, серле, мәгънәле тынлык.

Таң ата.

Ак җиһанның пакь таңы!

Авыл гүя кар дингезендәге бер утрау. Бераз арырак китеп аны әйләндереп алган урман гүя шул дингезнең ярлары.

Мондый иртәләрдә юлга чыкканда күңел кыршауларын ычкындырасы, хисләрне уртаклашасы, кабынасы, яшисе килә.

Малайларның, кызларның очкынлы күзләре өлкән яшьтәге бер агайга төбәлгән. Абзыйның рәвеш-кыяфәт шәп: мәһабәт гәүдә, төз буй-сын, элеккеге мәшһүр артист, рәссам, язучылар йөрткән, пачти зәһәр дип әйтерлек, карау һәм тәрбия күреп торган чал мыек. Аскысы эчкәрәк баткан, өскесе алгарак чыгып уйнап торган көчле иреннәр. Һәр сүзен уйлап, ашыкмыйча, иплэп-җайлап, сеңдереп әйтә. Балалар аны суламыйча тыңлый.

—Синең кәефләр ничек соң, Илнур?—дип сорап куя ул бер малайның җилкәсенә кулын салып.

—Әйбәт!

Остазның бу шәкертенә игътибарны күбрәк бирүенең хикмәте бар. Илнур—бик хисле малай. Юкка-барга да борчыла, яна, көя. Җиңелүне күңеленә бик авыр ала. Үзбәк абыйны иң куркытканы— малайның йөрәге шәптән түгел. Әйе, балалар тренерының тормышы ярышлардан гына тормый. Ана һәр шәкертнең сәламәтлеген дә, йөрәген дә кайгыртасы...

Абзый белән якыннанрак таныштырыйм әле үзегезне. Гомере буена туган авылы мәктәбендә балалар укыткан, сигез дистәне тутырып килүче Үзбәк Кәрим улы Яхин ул. Бүген шахмат ярышына баручы команданың остазы, тренеры. Инде күптән пенсиядә булса да, егерме елдан артык түгәрәк җитәкчесе буларак ул балаларны да шахмат уйнарга өйрәтә. Үзе дә дөньякүләм танылган шахматчы Рәшит Нәҗметдиновның шәкерте бит ул, уенның бөтен кагыйдәләрен үзләштергән бер дигән шахматчы. Хәер, шахматчы гынамы соң?! Ходай Тәгалә акыл-сәләт өләшкәндә капчыкны тутырып биргән Үзбәк агага. Ул—бер дигән рәссам. Аның кулындагы кыл-каләмнән гаҗәеп

картиналар туа. Казанда үткәрелгән күргәзмәдә дә катнашып, Татарстан Мәдәният министрлыгының дипломнарына лаек булды. Бактың исә, аның бу сәләте балачактан ук килә икән. Без Үзбәк аганың бертуган сеңлесе, язучы Гөлчәчәк ханым Галиева, аның ире, техник фәннәр докторы Әхмәт ага Галиев белән Яхинның «Яшь ленинчы» гасетасында басылган рәсемнәрен карап утырдык. Узган гасырның 30нчы елларында басылып чыккан бу рәсемнәрне кечкенә рәссам, көнен-елын күрсәтеп, альбом битләренә ябыштырып барган. Беренче биттә—Сталин рәсеме. Шушы дәһшәтле елларда «халыклар атасы»н ясатырга әтисе ничек риза булгандыр. Болай да имам-хатип Бәдретдин углы буларак һаман тырнак астыннан кер эзләргә торалар. Кәрим ага үзе дә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлаган шәхес бит. Өстәвенә ике ел Казанның Күл буе мәдрәсәсендә мөгаллим. Рәсемнең берәр кыегы булса, башың белән җавап бирергә тиешсең бит. Улының сәләтенә нык ышанган, күрәсең.

Еллар узу белән бераз саргая төшкән рәсемнәргә карыйсың да, уйлап куясың, балалар кайчан да балалар шул. Ул чорда да алар—үзләре ачлы-туклы булганнардыр инде—чана-чаңгы шуганнар, урманнарга барганнар, су кергәннәр, табигатьнең матурлыгы белән хозурланганнар. Рәсемнәр шулкадәр осталык белән ясалган ки, аларда бернинди артык сызык юк, һәрнәрсә үз урынында.

Бу альбом—үзе бер тарих. Анда Ү.Яхинның «Яшь ленинчы»да басылган мәкаләләре дә, редакциядән килгән хатлар да урын алган. Үзбәк ага хәбәрче буларак та каләменә гомере буена тугры калды. Район, республика газеталарында матур-матур мәкаләләре басылып тора.

Үзбәк Кәрим улы нинди эшкә тотынса да булдыра. Мандолина, думбра кылларына да бик оста чиртә, кулы агач эшенә дә ябыша. Ул—бер дигән бакчачы, умартачы. Ходай биргән сәләтен гомере буена балалар белән уртаклашты. Мин үзем дә Укытучым, Остазым дәресләрен сагынып искә алам. Безнең күңелләр аның ярдәмендә сәнгать дигән бөек тылсымлы дөньяга орынды, Репин, Левитан, Шишкин, Урманче, Якупов, Фәттаховлар белән сөйләште.

Аның әтисе Кәрим Яхин да—үз заманында акыллы, зирәк мөгаллим, алай гына түгел, чын мәгънәсендә мәгърифәтче. Бөтен гомерен авылдашларына, шул исәптән балаларга гыйлем, тәрбия бирүгә багышлый. Шушы юлда сәламәтлеген җуя. Салкын көздә Казаннан авылга, мәктәпкә китаплар, күргәзмә әсбаплар алып кайтканда авырый башлый. Мөгаллимнең тәне яна, күз аллары караңгылана, хәле китә. Курса стансысында поездлан төшә. Авылга тагын җиде чакрым җәяүләп кайтасы. Авыру кешегә бу араны үтү җиңелме?! Йөге дә бар бит әле. Аптырагач, берәүләрдән бала арбасы алып тора. Китапларны, күргәзмә әсбапларны шуңа салып алып кайта. Кайтуга егыла. Бүтән тормый. Кәрим ага, үпкәсенә салкын тидереп үлем түшәгенә яткан булып чыга. Ни кызганыч, үзенең фидакарь хезмәте өчен Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнүен дә ишетергә өлгермичә гүр иясе була.

...Тукта әле, сүзем балаларның Арчага шахмат ярышына барулары турында иде бит әле. Тукталышта сөйләшеп торганда Үзбәк ага да, балалар да ара-тирә юлга карап ала. Автобус күренмиме? Килә генә күрсен иде инде. Югыйсә эш харап. Харап булмыйни, елның елында чемпион булган команда ярышта күренмәсен әле?! Автобус аркасында килә алмаганнар дип уйламаслар. «Беткәннәр болар,шуна күрә ярышка килергә дә курыктылар. Хәчтерүшләр»,— дип әйтәчәкләр. Белмәсләр алар, Үзбәк аганың 30-35 градус салкында күрше Мөрәле авылына үзе барып, клубның ачкычын үзе эзләп табып, үзе ачып, шахматчы балалар белән күнегүләр уздырып йөрүен.

Бер уйласаң автобусның килми калуы да ихтимал бит. Юлда ни булмас?

Өлкән шахматчы шунысын да уйлап куя.

Тормыш үзе дә—нәкъ шахмат уены бит ул. Йөрешләрдән, жинүжинелүләрдән гыйбарәт. Бу хакта Үзбәк ага балаларга гел искәртеп тора. Менә бүген автобус килмәде ди. Сина каршы йөреш булды ди бу. Ә син аңа нинди «ход» белән җавап бирәсең. «Запас вариант» бармы? Бар! Ул вакытта 5 чакрымны җәяүләп булса да, стансага, поездга китәргә туры килә.

Үзе ул тормышта акыллы, мәгънәле йөрешләр генә ясарга тырышты. Хатыны Әлфия ханым белән бергә берсеннән-берсе чибәр, берсеннән-берсе унган биш бала тәрбияләп үстерделәр. Икенче улы Айдар да әтисе юлыннан китте. Казан сынлы сәнгать училищесын тәмамлап, бер дигән рәссам булды.

Каян килә мондый сәләт? Үзбәк аганың Камилә әбисеннән түгел микән. Ул картиналар да ясаган, көмештән, тимердән менә дигән сәнгать әсәрләре койган, агач эшенә дә кулы ябышкан. Бу сәләт Үзбәк аганың сеңлесе Гөлчәчәк апаның улы Булатта да ярылып ята.

Хәлбуки, язмышның ачы сынаулары, рәхимсез йөрешләре Үзбәк ага тормышында да булды. Армия, сугыш, имгәнгән умыртка сөяге аркасында бер селкенмичә еллар буена гипста яту, аның картиналары куелган күргәзмә бинасында янгын чыгу, күпме хезмәтнең көлгә әверелүе... Боларга каршы Үзбәк Яхин бер генә йөреш белән җавап бирде—сабырлык. Фәкать сабырлык! Тормыштагы йөрешләр тактадагы фигураны шудыру гына түгел шул. Алар рәхимсез булырга, бәгыреңә тиярга, хәтта йөрәгеңә ук булып кадалырга мөмкин.

Шулай уйланып торганда тау итә :ннән ут көлтәсе сузылды. Ул унгасулга, аска-өскә тибрәлә-чайкала алга бара.

Тренерның да, балаларның да эченә җылы йөгерде.

Килә!

Автобус килә!!

Юлның сикертмәләрендә, чокыр-чакырларда чайкала-чайкала автобус килеп тә җитте. Ишекнең «пошт» итеп ачылуы булды, халык ни арада автобус эченә агып кереп тулды. Ыгы-зыгы әлләни озакка бармады, пассажирлар кайсы кая урнашып бетте. Сумкалар, капчык-копчыклар, пакет-макетларның байтагы тез өстенә менеп кунаклады, байтагы идәнгә утыргыч астына посты.

Китәсе юл үргә каршы булганлыктан, машина авырлык белән, көчәнеп кузгалды. Аның артыннан авылның саф һавасына зәңгәр-кучкыл, тыгыз төтен бөркелеп калды. Бераз көчәнгәч, автобус хут алды, отыры бер көйгә генә чаба башлады.

Үзбәк ага тәрәзә буена утырды. Рәссамның исәбе күңеленең капкаларын табигатькә ачып куеп, кышкы таңның матурлыгын, җанга хозур күренешләрне карап-күзәтеп бару иде.

Хәзер инде борчыласы юк. Автобус килде, балалар утырды-урнашты. Илнур да үзенә җайлы гына урын эләктергән. Җан тыныч. Табигатьнең кабатланмас манзарасын күңел полотносына яз да бар. Әмма тренерга һәм шахматчы балаларга каршы йөреш автобусның үзендә көтеп торган икән. Кайбер йөрешләр йөрәккә ук булып кадалырга мөмкин, дигән идек. Менә шундый укларның берсе бүген автобуста атылды.

Бераздан кондукторның көр тавышы яңгырады:

—Тәк, балалар, билет алабыз.

Үзбәк ага сискәнеп китте, әсәренеп куйды:

—Бу балалар Арчага ярышка бара. Шахматчылар болар. Ярышларга, олимпиадаларга баручы укучылар юл өчен түләми. Хакимиятнең карары бар.

—Тәк, алайса справкагызны күрсәтегез. Менә бу балалар ярышка бара дигән справкагызны.

Үзбәк ага кесәләрен актара башлады. Тукта, кайда соң әле ул справка?

Юк. Бер кесәдә дә юк. Бар иде бит, алган иде бит ул аны. Справка да, башка документлар да өйдә онытылып калган. Кичтән барысын да әзерләп куйган иде югыйсә. Ветеран каушады. Төне бик борчулы булды шул анын. Остаз тан атканчы керфек какмады. Тәрәзәдән тәрәзәгә йөрде. Көн бозылмасмы? Буран чыкмасмы? Балалар уяна алырмы? Күрше авылныкылар җыенып килеп җитә алырмы? Автобуска сонга калмаслармы? Район чемпионы исемен быел да саклап калып булырмы?

—Справка өйдә калган бит, черт побери...

—Башыгыз калмаганмы?

—Баш та калган. Паспортта фоторәсемдәге баш минем баш бит инде ул,—Үзбәк ага киеренкелекне бераз гына булса да юмор белән йомшартмакчы булды.

—Тәк, справкагыз юк икән, юл хакын түлисез!

—Юк, сез бу балаларның ярышка баруына ышанасыздыр бит инде. Шахмат ярышына бара алар. Югыйсә таң тишегеннән торып чыкмаслар иде.

—Знать не знаю. Түлисез, бетте-китте.

Үзбәк аганың башында уйлар өермә булып кайный башлады. «Син—фронтовик. Иленне яклап сугышка киткән кеше. Син—укытучы. Хакыйкатьне яклап яшәгән кеше. Син—рәссам. Матурлыкны яклап тезләнгән кеше. Бүген биш-алты бөртек баланы яклый алмыйсың. Күр әле бу кондукторны да. Бигрәк үҗәт. Акча, акча, дип дәһшәт чәчә, йөрәккә басып тора».

—Документлар дип, справка дип кире өйгә кайтып булмый бит инде хәзер. Аңлагыз инде мине.

—Аңламыйм да, аңларга теләмим дә. Ә син, абзый, үзең дә билет алмадың бит әле.

—Мин—фронтовик.

—Каян белим мин синең фронтовик икәнеңне. Маңгаеңа язылмаган.

«Нишләп язылмасын. Язылган шул. Мангаена кыеклап тарап төшерелгән чәчләр арасында сугыш агарткан чәчләр юкмыни! Маңгаендагы җыерчыклар арасында сугыш сызганнары юкмыни!!» Үзбәк ага уйларыннан бүленергә, җанына тынычлык табарга теләп тәрәзәгә күз салды. Автобус тизлекне тагын да арттырды бугай. Юл буендагы ак бәс сарган агач-куаклар, электр баганалары выжт та выжт артка атылып калалар. Алар белән бергә ак кар астындагы курпы арасыннан баш сузган, шушы ак иртә күренешенә ятып бетмәгән әрсез әрем, котсыз шайтан таяклары да сикереп кала.

Кондукторның бөереннән чыккан тавышы рәссамны бу күренештән аерылырга мәҗбүр итте.

—Билет аласызмы сез, юкмы? Югыйсә хәзер автобусны туктатабыз, үзегезне төшереп калдырабыз. Башта үзенә ал, абзый!

Үзбәк аганың йөрәге кысылып куйды. «Балаларны түгел, әллә үзеңне дә яклый алмыйсың инде син, ветеран»,—дип эндәште аңа күңеле. Шахмат тактасындагы бөтен фигуралар дәррәү һөҗүмгә ташланган кебек тоелды. Ул отылган пешка хәлендә.

—Билет ал!

Үзбәк ага дәшмәде.

—Билет!!

Кондуктор талпан кебек кадалды.

Киеренкелек тагын күпме дәвам иткән булыр иде икән, ярый әле, автобустагы авылдашлар дәррәү күтәрелеп чыкты:

—Сугыш ветераны бит ул, ник бәйләнәсез аңа.

—Гомере буена балалар укытты. Гадел, намуслы кеше.

—Ярышка баралар алар. Авыл данын, мәктәп данын якларга. Тимәгез аларга!

Шушы сүзләрне ишеткәч, кондуктор, ниһаять, тынычлангандай булды. Әмма ветеранның йөрәгенә кан сава башлаган иде инде. Отыры анын тыны кысыла, һава житми башлады. «Автобусны туктатып, ишекне ачтырырга мәллә. Бераз һава керер иде», дип тә уйлаган иде. Күреп тора бит, кешеләр ашыга. Кайсысы эшкә, кайсысы укуга. Машинаны туктаттырмады. Уңайсызланды. Сабыр гына түзеп утырды.

Арчага көч-хәл белән килеп житте ул.

Стансыдан район үзәгенә менәр өчен тагын автобуска утырасы. Монысыннан да гайрәте чигеп, жаны бизеп калган Үзбәк абый һәм балалар утырамы сон?! Жәяүләп менәргә булдылар. Житмәсә жиле дә каршы. Авыру йөрәккә тауга каршы, жилгә каршы бару жинел дисезме?! Күпне күргән, байтак фажигаләрнен шаһите булган текә Арча тавы бит әле ул.

Тын һаман кысыла. Күкрәк—таш. Маңгайга салкын тир бәреп тора.

Ничек кенә булса да, Үзбәк ага балаларны ярышка вакытында, исән-имин китереп житкерде.

Ә үзе...

Йөрәк!..

Шул вакыт бер малай анын өстенә капланды. Ул идәндә чалкан яткан Үзбәк аганың күкрәгенә баса, аның авызына кайнар сулышын өрә башлады. Малай шулкадәр тырыша ки, анын маңгаеннан шабыр тир ага.

Остазына жан өрергә маташучы бу малай... Илнур иде.

Йөрәк!..

И син, йөрәк! Өзгәләнгән йөрәк!! Телем-телем йөрәк!!!

Балаларның күз алдында...

Барысы да таштай катып калды.

Шул арада Үзбәк аганың Арчада яшәүче улы Айдар да килеп житте. Ул да үзенең шәкертләре белән бүгенге ярышта катнашасы икән бит.

Ярышырга, көч сынашырга дип ашкынулы-ярсулы йөрәк, жилкенгән күнел белән кил дә жан биреп яткан газиз әткәнә тап бул инде.

Хәзер укучыларда ярыш кайгысымы?!

Шулай да шахмат тактасы янына утырырга үзләрендә көч таптылар. Алай гына да түгел, Үзбәк абыйлары үзләренә рәнжеп китмәсен, аның рухы—ул шушында ярыш үткәрелә торган залдадыр—сөенсен өчен жиңәргә, ничек кенә булса да жиңәргә сүз бирделәр.

Нәтиҗәдә Сеже мәктәбе укучылары—тагын район чемпионнары!

Ни кызганыч, бу шатлыкны уртаклашырга яннарында Укытучы, Остаз юк шул инде.

Юк шул...



## Габдулла Тукай

(1886—1913)

Габдулла Тукай—татар әдәбияты күгендә иң якты йолдызларның берсе. Аның исеме һәм язмышы татар халкының үткәне, бүгенгесе, киләчәге белән мәңгегә бәйләнгән.

Булачак шагыйрь 1886 елның 27 апрелендә хәзерге Арча районы Кушлавыч авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Туып биш ае да үтәр-үтмәстән, әтисе Мөхәммәтгариф үлеп китә. Бер-ике елдан соң әнисе Мәмдүдә дә дөньядан китеп бара. Шулай итеп, бәләкәй Апуш кечкенәдән тома ятим кала.

Казанның Печән базары... Аннары Җаек (Уральск) шәһәре... 1905 ел революциясе китергән матбугат иреге нәтиҗәсендә, Уральскида Камил Мотыйгый тарафыннан «Фикер» газетасы, «Әлгасрелҗәдит» басмасы, соңрак «Уклар» дигән сатирик журнал чыга башлый. Инде каләмен чарлаган Тукайга актив иҗат эшчәнлеге өчен киң мәйдан ачыла.

1907 елның көзендә Тукай Казанга кайта. Аның «Яңа кисекбаш» кебек сатирик поэмасы һәм башка күренекле әсәрләре нәкъ менә Казан чорында языла.

Ятимлектә үткән балачак еллары, Казанның карангы һәм салкын номерлары, мохтаҗлык—болар бар да шагыйрьнең сәламәтлеген нык какшата. 1913 елның 2 нче (искечә) апрелендә аның йөрәге тибүдән туктый.

Тукайның рәсемдәге бюсты Арча үзәк мәйданына куелган.



## Фатих Хөсни

(1908—1996)

Татар прозасының күренекле вәкиле Фатих Хөсни (Фатих Хөснетдинов) 1908 елның 3 февралендә хәзерге Теләче районы Олы Мәтәскә авылында крестьян гаиләсендә туган. Авыл мәдрәсәсендә, аннары инде совет мәктәбендә белем алганнан соң, 1924 елда Казанга килә. «Безнең юл» (хәзерге «Казан утлары»)ның 1927 елгы санында унтугыз яшьлек егетнең беренче шигырьләре басылып чыга.

1933 елда Казан финанс-экономика институтын тәмамлый. Армия хезмәтеннән соң, журналист буларак, төрле газета редакцияләрендә эшли. Утызынчы елларда Ф. Хөсни хикәя жанрында аеруча актив иҗат итә. Мәшһүр артист-гармунчы Фәйзулла Туишев турында «Гармунчы» (1939) повестен яза.

Ватан сугышы чорында әдип «Сталин байрагы» исемле фронт газетасында беркадәр эшләп ала. 1942 елда язылган «Йөзек кашы» повесте, югары кимәлдә язылган художество әсәре буларак, бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмаган. «Җәяүле кеше сукмагы», «Утызынчы ел», «Гыйльмениса һәм аның күршеләре», «Мәйдан» кебек киң полотналы, социаль-психологик пландагы повесть һәм романнары илленче-алтмышынчы еллардагы татар прозасының күренекле казанышларыннан санала.

Ф. Хөсни—Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның халык язучысы.

**Альфред ӘБДРӘШИТОВ**

## Россиянең халык иң күп яши торган шәһәрләре

| № | Шәһәр | 2006 ел (мең кеше) | 1989 ел (мең кеше) | 1989 елдан башлап үзгәреш (процентларда) |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Мәскәү | 10425 | 8677 | 20,15 |
| 2 | Санкт-Петербург | 4581 | 4435 | 3,29 |
| 3 | Новосибирск | 1397 | 1436 | -2,72 |
| 4 | Екатеринбург | 1308 | 1363 | -4,04 |
| 5 | Түбән Новгород | 1284 | 1435 | -10,52 |
| 6 | Самара | 1143 | 1257 | -9,07 |
| 7 | Омск | 1139 | 1149 | -0,87 |
| 8 | Казан | 1113 | 1085 | 2,58 |
| 9 | Чиләбе | 1093 | 1142 | -4,29 |
| 10 | Ростов-Дон | 1055 | 1008 | 4,66 |
| 11 | Уфа | 1030 | 1080 | -4,63 |
| 12 | Пермь | 993 | 1092 | -9,07 |
| 13 | Волгоград | 992 | 995 | -0,30 |
| 14 | Красноярск | 921 | 912 | 0,99 |
| 15 | Саратов | 850 | 902 | -5,76 |
| 16 | Воронеж | 846 | 882 | -4,08 |
| 17 | Краснодар | 710 | 619 | 14,7 |
| 18 | Тольятти | 705 | 629 | 12,08 |
| 19 | Ижевск | 620 | 635 | -2,36 |
| 20 | Ульяновск | 617 | 624 | -1,12 |
| 21 | Барнаул | 604 | 599 | 0,83 |
| 22 | Ярославль | 604 | 629 | -3,97 |
| 23 | Владивосток | 584 | 631 | -7,45 |
| 24 | Иркутск | 578 | 622 | -7,07 |
| 25 | Хабаровск | 578 | 598 | -3,34 |
| 26 | Новокузнецк | 562 | 602 | -6,64 |
| 27 | Төмән | 543 | 476 | 14,08 |
| 28 | Оренбург | 534 | 544 | -1,84 |
| 29 | Кемерово | 520 | 518 | 0,39 |
| 30 | Рязань | 513 | 512 | 0,2 |
| 31 | Пенза | 510 | 538 | -5,20 |
| 32 | Тула | 509 | 536 | -5,04 |
| 33 | Чаллы | 507 | 505 | 0,4 |
| 34 | Липецк | 503 | 447 | 12,53 |
| 35 | Әстерхан | 499 | 505 | -1,19 |
| 36 | Томск | 490 | 502 | -2,39 |
| 37 | Киров | 469 | 440 | 6,59 |
| 38 | Махачкала | 466 | 315 | 47,94 |
| 39 | Чебоксар | 442 | 420 | 5,24 |
| 40 | Калининград | 424 | 401 | 5,74 |
| 41 | Брянск | 420 | 448 | -6,25 |
| 42 | Иваново | 413 | 478 | -13,60 |
| 43 | Магнитогорск | 413 | 439 | -5,92 |
| 44 | Курск | 406 | 420 | -3,33 |
| 45 | Тверь | 406 | 446 | -8,97 |
| 46 | Түбән Тагил | 380 | 439 | -13,44 |
| 47 | Ставрополь | 358 | 317 | 12,93 |
| 48 | Архангельск | 350 | 417 | -16,07 |
| 49 | Улан-Удэ | 348 | 352 | -1,14 |
| 50 | Белгород | 344 | 298 | 15,44 |
| 51 | Владимир | 341 | 347 | -1,73 |
| 52 | Курган | 330 | 354 | -6,78 |
| 53 | Сочи | 330 | 312 | 5,77 |
| 54 | Калуга | 329 | 310 | 6,13 |
| 55 | Орел | 326 | 333 | -2,10 |
| 56 | Мурманск | 321 | 472 | -31,99 |
| 57 | Смоленск | 318 | 339 | -6,19 |
| 58 | Владикавказ | 314 | 299 | 5,02 |
| 59 | Волжский | 309 | 267 | 15,73 |
| 60 | Череповец | 308 | 310 | -0,65 |
| 61 | Чита | 306 | 363 | -15,70 |
| 62 | Саранск | 297 | 313 | -5,11 |
| 63 | Сургут | 291 | 250 | 16,4 |
| 64 | Вологда | 287 | 280 | 2,5 |
| 65 | Тамбов | 285 | 304 | -6,25 |
| 66 | Кострома | 275 | 278 | -1,08 |
| 67 | Комсомольск-на Амуре | 273 | 316 | -13,61 |
| 68 | Нальчик | 271 | 231 | 17,32 |
| 69 | Таганрог | 269 | 291 | -7,56 |
| 70 | Стәрлетамак | 266 | 248 | 7,26 |
| 71 | Петрозаводск | 265 | 270 | -1,85 |
| 72 | Братск | 255 | 258 | -1,16 |
| 73 | Дзержинск | 253 | 285 | -11,23 |
| 74 | Йошкар-Ола | 251 | 242 | 3,72 |

## Азат Әхмәдуллинга 75 яшь



Күренекле әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче, филология фәннәре докторы, Казан дәүләт университеты профессоры, Татарстан Язучылар берлегенең Җамал Вәлиди исемендәге премиясе лауреаты Азат Әхмәдуллинга шушы елның октябрь аенда 75 яшь тулды.

Азат Гыйльмулла улы Әхмәдуллин 1932 елның 13 октябрендә Саба районы Байлар Сабасы авылында журналист гаиләсендә туган. Шул авылда урта мәктәпне тәмамлагач бер ел якындагы Шекше авылы мәктәбендә укыта, 1951—1956 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Аннан соң А. Әхмәдуллин Татарстан китап нәшриятында—редактор, 1956—1958 елларда исә Төмән өлкәсенең Тобол педагогия институтында өлкән укытучы булып эшли.

1958—1961 елларда ул СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы аспиранты. Аспирантураны тәмамлагач, ике елга якын Татарстан радиокомитетында баш редактор, аннары Тел, әдәбият һәм тарих институтында кече фәнни хезмәткәр булып эшли. 1964 елда «Фәтхи Бурнаш драматургиясе» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. 1965 елдан ул шул ук институтта гыйльми секретарь, ә 1972 елдан 1981 елга кадәр директорның фәнни эшләр буенча урынбасары булып эшли. 1981 елның февраленнән А. Әхмәдуллин Казан дәүләт университетында эшли.

Ул әдәби тәнкыйть өлкәсендә илленче елларда шөгыльләнә башлый. Аның беренче мәкаләләре «Совет әдәбияты» журналында басыла. А. Әхмәдуллин хәзер филология фәннәре докторы, профессор.

Аның «Фәтхи Бурнаш» (1967), «Ничек сурәтләргә сине, замандаш?» (1976), «Сәхнә әдәбияты һәм тормыш» (1980), «Горизонты татарской драмы» (1983), «Татарская драматургия» (1983), «Дәреслеккә ирешү юлында» (1993), «Офыклар киңәйгәндә» (2002), «Күңелләрне уятыр» (2007) һ. б. китаплары бар.

А. Әхмәдуллин—шулай ук урта мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен татар әдәбияты буенча күпсанлы дәреслекләр авторы да.

Юбилярны олы бәйрәме белән кайнар котлыйбыз, аңа яңа иҗади уңышлар, сәламәтлек телибез!

## Юныс Сафиуллинга 60 яшь



Танылган драматург, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1996) Юныс Сафиуллинга бу айда 60 яшь тула.

Юныс Габдулла улы Сафиуллин 1947 елның 18 октябрендә Яшел Үзән төбәгенең Бакырчы авылында туган. Башта үз авылында, аннары күрше Акжегет мәктәбендә укый. 1962 елда Казан театр училищесына кабул ителә. Укыганда Г. Камал исемендәге театр спектакльләрендә актер булып катнаша башлый, театр белән ил буенча гастрольләргә чыга. 1966 елда Республика күчмә театрында эшли башлый. 1976 елда ГИТИС (Мәскәү) каршындагы югары курсларны тәмамлый.

1981 елның февраленнән башлап ул Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында актер булып эшли.

Хәзер Ю. Сафиуллин—театрның әдәби бүлек мөдире.

Ул драматургиягә үткән гасырның җитмешенче елларында килә. Аның беренче әсәрләре «Әллә өйләнергә инде?» (1977), «Менә без дә үсеп җиттек...» (1979), «Ни булган бу ирләргә?» (1981), «Әбидә кунак егетләр» (1981) Татар дәүләт драма һәм комедия театры, Әлмәт, Минзәлә театры сәхнәләрендә уйнала.

Юныс Сафиуллин—«Менә без дә үсеп җиттек...» (1983), «Пар канат» (1997), «Чәчәкләр һәм күз яшьләре» (1999), «Әллә өйләнергә инде?» (2004) һ. б. китаплар авторы.

Драматургны олы юбилее белән кайнар котлыйбыз һәм аңа яңа иҗат уңышлары, сәламәтлек телибез!

---

*Алхәбәр*

## Рәшит Фәтхрахманов

АВЫЛ УКЫТУЧЫСЫ ЯЗМАЛАРЫ
(истәлекләр, уйланулар, анализ).

*Моңарчы журналда әдәби тәнкыйть мәкаләләре генә чыгарган авторыбызның хәзерге заман турындагы бу кызыклы һәм үткен язмалары киләсе елның беренче яртысында басылачак.*

«...Дөньяның барышына карыйм да тоталитаризмның яңадан баш калкытуын күрәм. Сүз иреге акрынлап кысылып килә, матбугатта дөреслеккә караганда ялган күбрәк. Эфир да «су кушылган» хәбәрләр белән тулы. Хөр фикерләләр өчен психиатрик сырхауханәләр яңадан ишекләрен ача башладылар шикелле. Боларга өстәп киллерләр дә сәяси заказлар үтәүдән бушамый. Мәктәпләрдә укытучыларның бугазына басып партиягә димлиләр. Бу кадәресе тоталитар КПСС чорында да күзәтелмәгән иде. Кыскасы, яңадан диссидентлар заманы җитте, җәмәгать. Кайда сез, сәламәтлекләрен һәм гомерләрен корбан итәргә әзер торучы татар зыялылары? Халыкка бүген сезнең хак сүзегез кирәк!..»

# Г

**ГАТАУЛЛИН** Рәдиф Кәшфулла улы (псевд. Гаташ) (30.3.1941, Башкортстан АССРның Кушнаренко р-ны Марс а.), шагыйрь. ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1982), ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2001). Казан ун-тын (1964) һәм Әдәбият ин-ты каршында Югары әдәби курслар (Мәскәү, 1969) тәмамлый. 1966-71 елларда (өзеклек б-н) Татарстан китап нәшриятында матур әдәбият бүлеге мөхәррире, 1973-74 тә «Ялкын» ж-лы редакциясендә әдәби хезмәткәр. 1975 тән «Казан утлары» ж-лының шигърият бүлеге мөдире. Шигырьләре 1962 дән «Азат хатын», «Ялкын», «Совет әдәбияты» ж-лларында басыла башлый. «Гөлләр су сорый» исемле беренче җыентыгы 1966 да дөнья күрә. «Кояшлы утрау» (1967), «Ирләр булыйк» (1978), «Чакыру» (1980), «Мәхәббәткә мәрхәмәт» (1987) җыентыкларына кергән шигырьләренә романтик күтәренкелек, ихласлык хас; метафораларга бай. Г. иҗатында лирик геройның күңел дөньясын, аның уй-кичерешләрен тулылыгы белән ачып бирергә омтыла. Ул хатын-кызның матурлыгына, нәфислегенә, игелеклелеккә, мәхәббәт һәм тугрылыкка дан җырлый. Татар халкының язмышы, буыннан-буыннарга күчкән тарихи үткәне, рухи күңел байлыгы – Г. лирикасының төп темаларыннан берсе. Г. шигъриятендә рус һәм дөнья әдәбиятлары йогынтысы чагыла. Төрле поэтик формаларда иҗат итсә дә, күбрәк иркле шигырьгә (верлибр) мөрәҗәгать итә. 1990 еллардан Г. иҗатында классик шәрекъ шигъриятенең йогынтысы көчәя. Бу чордагы мәхәббәт лирикасы нигездә газәлләр һәм робагыйлардан тора («Бу - сиңа кылган догам», 1997; «Газәллар», 2001; «Гамь шәрабы», 2001 һ.б.). Публицистик һәм әдәбитәнкыйть мәкаләләре дә яза. Шигырьләре рус, башкорт, украин, әзербайҗан., каракалпак, латыш, литва, төрек, инглиз, поляк, телләренә тәрҗемә ителә.

Әсәр.: Гөлләр су сорый: Сайланма лирика. К., 1998; Мәңгелек сусау. К., 2005.

Әд.: Хәким С. Җырның җире // Халык язмышы - шагыйрь язмышы. К., 1979; Галиуллин Т. Йокы юк шагыйрьгә // Гомер учагы. К., 1991; Миңнуллин Р. Гаташның «гамь шәрабы» // Казан утлары. 2001. N3.

*Р.Ә.Мостафин, Х.Й.Миңнегулов.*

**ГАТТАР** Фәридеддин (тулы исеме Фәридеддин Мөхәммәд ибне Ибраһим ән-Нишапури (1119-1223 тирәсе), фарсы телле суфи шагыйрь. Тумышы б-н Нишапур шәһәреннән (Иран). Зур гыйлем иясе, гамәли тыйб гыйльме (медицина), фармакология б-н шөгыльләнгән. Урта һәм Якын Көнчыгыш илләрендә (Мисыр, Ирак, Һиндстан һ.б.) булган. Күп санлы әдәби һәм гыйльми әсәрләр авторы. Гомуми күләме 202 меңнән артык бәйтне (икеюллык шигырь) үз эченә алган кырыклап шигъри китап язган, шул бәйтләрдән хәзерге көндә 120 меңләбе билгеле. Аеруча популярлык казанган поэмалары: «Хәйдәрнамә», «Пәнднамә» («Үгет-гыйбрәтләр китабы»), «Әсрарнамә» («Серләр китабы»), «Җөмҗемәнамә»», «Шигырьләр диваны», «Тәзкират әл-әүлиа» («Изгеләр тормышы»). Г.ның шигъри иҗаты суфичылык рухы, дөньялыкта Аллаһыны эзләү, Алла гыйшкына дан җырлау б-н сугарылган. Г. үзенең иҗатында шәркый халыклар фольклорына еш мөрәҗәгать итә, әсәрләре тукымасына халык арасында туган гыйбрәтле хикәятләрне кертеп җибәрә. Г.ның әдәби мирасы фарсы һәм төрки телле әдәбиятларга көчле йогынты ясый. Мәс., Галишер Нәвои үзенең «Лисан әд-тайур» («Кошлар теле», 1499) исемле әсәрен Г.ның «Мантыйк әт-тайур» («Кошлар әңгәмәсе») дигән әсәренә нәзыйрә итеп яза. Татар әдәбиятында Г.ның шигъри тәэсире Мәхмүд Болгари, Хисам Кятиб, бигрәк тә Әбелмәних Каргалый, Шәмсетдин Зәки, Һибатулла Салихов һ.б. суфи шагыйрьләрнең иҗатында көчле күзәтелә. Г.ның «Пәнднамә» поэмасы татарчага тәрҗемә ителеп, Казанда берничә тапкыр (1872, 1880, 1884, 1885) аерым китап булып басылып чыга.

Әсәр.: «Пәнднамә», ягъни Шәйх әл-Гаттар тәсныйфе «Хәмде бихәдд...»нең тәрҗемәсе. К., 1872; Пәнднамәи Гаттар. К., 1885; Китабе хамд-и би-хадд. К., 1896.

Әд.: Бертельс Е.Э. Суфизм и суфийская литература. М., 1965; Тагирджанов А.Г. Рукописи поэм Аттара в собрании библиотеки Восточного факультета // Письменные памятники и проблемы истории культуры народов Востока. XVI годичная науч. сессия Ленингр. отд-ния Ин-та востоковедения АН СССР. М., 1982. Ч. II; Миннегулов Х. Татарская литература и Восточная классика: Вопр. взаимосвязей и поэтики. К., 1993; Islam Ansiklopedisi. Ist., 1942. 2 cilt.

*Х.Й.Миңнегулов.*

*Дәвамы. Журналыбызның 2005 ел, 4 санынннан басылып килә.*

**ГАФУРИ** (Гафуров) Мәҗит (Габделмәҗит) Нургани улы (20.7.1880. Уфа губ., Эстәрлетамак өязе Җилем-Каран а. - 28.10.1934, Уфа ш.), язучы, публицист, Башкорстан АССРның халык язучысы (1923). Татар һәм башкорт әдәбиятлары классигы. Авыл укытучысы гаиләсендә туа. Яшли ятим кала. Авыл мәдрәсәсендә укый. Уралда төрле эшләрдә (ш.и. Рәмиевләрнең алтын приискаларында) эшли. 1898 елдан Троицк шәһәрендә «Рәсүлия» мәдрәсәсендә укый. Җәйләрен приискаларда, казакъ җәйләүләрендә хезмәт куя. 1905 тә Казанга килә, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга керә. 1906-1909 да Уфадагы «Галия» мәдрәсәсендә укый. 1902 дә «Ишан хәзрәтләренә» исемле дини фанатизмны фаш иткән беренче сатирик шигырен яза. «Себер тимер юлы, яки Әхвале милләт» (1904) шигырендә, «Ярлылар, яки Өйдәш хатын» (1909) хикәясендә, «Фәкыйрьлек берлә үткән тереклек» (1904) повестенда Г. гади халык тормышын тасвирлый. Алга таба иҗатының тәнкыйди юнәлеше көчәя бара. «Яшь гомерем» (1906), «Милләт мәхәббәте» (1907) җыентыклары патша властьлары тарафыннан тартып алына, чөнки аларда самодержавиене бәреп төшерүгә өндәү сизелә.

Башлангыч чор лирикасы «Гафури шигырьләре» (1909), «Тәэссоратым» (1909), «Моң вә зар» (1911) җыентыкларында тупланган. Шигырьләренә социаль мотивларның төрлелеге һәм лирик кичерешләргә бай булуы хас. Тора-бара Г. шигъриятендә психологизм көчәя, ләкин беркадәр дидактик агым да сакланып килә. Милли-тарихи романтикага, табигатькә табыну өстәлә. «Кырда» (1909) шигыренең лирик герое фикеренчә, камиллеккә нигезләнгән табигатьтә илаһи көч хөкем сөрә һәм анда башбаштаклыкка, законсызлыкка урын булырга тиеш түгел.

Татар мәгърифәтчел әдәбият традицияләре, Шәрекъ әдәбиятының реалистик элементлары, татар һәм башкорт фольклорының казанышлары Г. иҗатында 20 йөз башындагы революцион идеяләр б-н баетыла. Җәмгыятьне үзгәртү көче итеп Г. мәгърифәтле булуны исәпли («Себер тимер юлы:», «Яшь гомерем», икесе дә 1906). Башлангыч чор иҗатында ук ул үзен реалист язучы итеп таныта. 1905-07 еллар вакыйгалары аның милли-азатлык идеяләре б-н кызыксынуын арттыра төшә. Милли мәсьәләләрне Г. халыкларның царизмга каршы көрәше б-н бергә бәйләп карарга тырыша («Алмашыну», 1905; «1906 нчы елдан 1907 елга васыять», 1906 һ.б.). Соңыннан, реакциянең һөҗүменә җавап итеп, Г. халыкның аяныч хәле проблемасын кискенләштерә бара («Базарга чыктым», 1907; «Бай һәм хезмәтче», 1909; «Хәерче», 1909; «Кызганам!», 1910 һ.б.). Г. иҗатының гуманизмын һәм демократизмын кимсетелгәннәрнең хокукын яклаудан аерып булмый. Газап чиккән халыкка карата булган битарафлыкны гаепләп, ул болай яза:

*Күзе күрмәсә милләтнең изелгән, артта калганын,*
*Хәмият килмәсә күргән вакыт аның талпынганын;*
*Йөрәк сызламаса мескен вә мәзлумнарны күргәндә, -*
*Хәкыйкатән дә «үлгән йөрәктер» мондаен бәндә.*

(«Үлгән йөрәк», 1910)

Шул ук елларда Г., мәсәл жанрына мөрәҗәгать итеп, бер төркем сатирик персонажлар тудыра. 1907-17 дә ул 25 мәсәл яза. Аларның кайберләрендә И.А.Крылов йогынтысы сизелә, аерым мәсәлләрдә «Кәлилә вә Димнә» сюжетлары кулланыла. «Үгез б-н бүре» (1912), «Сарыкны кем ашаган?» (1912), «Эт белән куян» (1912) мәсәлләре социаль юнәлешләре б-н аерылып торалар. «Сандугач» (1906), «Кошларның патша сайлаулары» (1909), «Кара җылан белән Бакалар патшасы» (1912) мәсәлләрендә хөкемдар һәм халык мөнәсәбәтләре проблемасын образлы рәвештә, аллегориягә нигезләнеп хәл итә.

Мәгърифәтчелек идеяләренең законча-лыклы дәвамы буларак, Г.ның атропологизмы берничә әсәрдә, аеруча «Хәмитнең хәяты» (1910) повестенда ачык чагылыш таба. Ямьсез тормыш күренешләре беркадәр күбрәк кулланылса да, әсәрдә реалистик дөреслек хөкем сөрә.

Г.ның алга таба әдәби эзләнүләре трагизмнан оптимизмга таба кискен борылыш ясый. Г.ның шигъри дөньясында, гуманизм идеалларының тантанасы һәм акыллы көч урнашуының чагылышы буларак мәхәббәт романтикасы үзен нык сиздерә башлый. «Мәхәббәт хатлары» (1912) повестенда шулай ук мәхәббәт культы, бәхет идеаллары тантана итә. «Беренче мәхәббәт» (1915), «Янган йөрәк» (1914), «Таң яктысы» (1913) шигырьләре оптимизм б-н сугарылган.

1 нче бөтендөнья сугышы башлану б-н мәхәббәт һәм дуслык романтикасын хәсрәт, көч куллануны гаепләү алмаштыра. 1915 тә Г. үзенең атаклы «Юктырсың ла, Алла!.. һәм «Кем ул?» шигырьләрен яза. Ул аларда сугышка карата халыкның ачы нәфрәтен белдерә, аны кешелек алдында иң зур җинаять дип фаш итә. «Солдат хатыны Хәмидә» (1915) хикәясендә дә туган-туганын үтерүгә корылган сугышка каршы ризасызлык белдерә.

1917 елгы Революция вакыйгаларын шатланып каршы ала, аңа «Кызыл байрак» (1917), «Хөррият иртәсе» (1917), «Хисап көне» (1917), «Безнең юл» (1919), «Нур» (1919) шигырьләрен багышлый. М.Вахитов истәлегенә багышланган «Нур» шигырендә Г. көрәштә революционерларның үзләрен корбан итүләренә басым ясый. Г. иҗатының өзлексез тема-

ларының берсе - үткәннәрдә калган коллар хезмәтен иректә хезмәт идеалыннан чыгып күрсәтү. Бу тема аның «Эшче» (1920) поэмасында яңа сыйфатта калка. 1927 дә ул кабат бу поэмага әйләнеп кайта һәм аның драматик вариантын яза. Бу сюжетка композиторлар Г.С.Әлмөхәммәдев, С.Х.Габәши һәм В.И.Виноградов, татар музыкаль мәдәниятендә беренче буларак, шул исемдә опера язалар (1930 да Татар академия театрында куела). «Кызыл йолдыз» пьесасын (1925) Гражданнар сугышына һәм җимерелгән авыл хуҗалыгын торгызуны күрсәтүгә багышлана. 1921-23 еллардагы ачлык «Ачлык тырнагында» (1923) исемле җыентыкка кергән «Сулган гөлләр» (1921), «Ач» (1921), «Җылыйлар» (1922) шигырьләрдә, «Кеше ашаучылар» (1922) поэмасында сурәтләнә.

1927 дә язылган «Кара йөзләр» повесте Г.ны күренекле язучы итеп таныта. Повестьта геройларга төгәл психологик сурәт, социаль күренешләргә тирән анализ бирелә. Сюжет нигезендә 19 йөз ахырында язучының туган авылында булып узган фаҗигале вакыйгалар ята. Повестьнең төп героинясы Галимә иске тормышның караңгылыгы, мәрхәмәтсезлеге б-н каршылыкка килә һәм ахырда һәлак була. Галимә кичергән фаҗиганең бөтен тирәнлеген күрсәтер өчен автор антитеза һәм контраст алымнарын оста куллана. Бу повестька нигезләнеп 1981 дә композитор Б.Г.Мулюков шул исемдә опера яза (Гәрәй Рәхим либреттосы, 1982 дә Татар опера һәм балет театрында куела). 1917 гә кадәр язылган «Фәкыйрьлек берлә үткән тереклек», «Ярлылар, яки Өйдәш хатын», «Үги балалар» (1908), «Зәйнәп сабыр иткән иде, сабыр итә алмады» (1911), «Онытылган җинаять, яки Үткәнне искә төшерү (1911) хикәя һәм повестьләрендә Г. татар хатынының фаҗигале язмышына басым ясый. «Кара йөзләр» повестендә социаль гомумиләштерү юлында яңа югарылыкка күтәрелүгә ирешә.

«Тормыш баскычлары» (1927) повестенда Г. 1 нче бөтендөнья сугышы һәм 1917 елгы Революция вакыйгаларына кабат әйләнеп кайта. Автор повестьнең төп герое Вахитның характеры формалашуын, аның хезмәт иляре хокукы өчен чын көрәшче булып китүен күрсәтә. «Шагыйрьнең алтын приискасында» (1929) автобиографик повестендә Г. алтын приискасында эшләгән эшчеләрнең авыр тормышларын чагылдырганда әсәр эчтәлеген тирәнәйтеп, зурайтып күрсәтүгә ирешә. Гади халыкның югары әхлаки сыйфатларын чын җылылык белән тасвирлый.

Г. һәрвакыт татар һәм башкорт матбугатында актив язышa. Аның «Шәрекъ ярлылары», «Безнең юл» г-таларында, «Яңа юл», «Кызыл юл», «Совет әдәбияты» ж-лларында басылган очеркларында кыска язмаларында татар һәм башкорт халыклары язмышлары ачык чагылыш табалар.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр. К., 1939; Һайланма әсәрзәр. Өфө, 1950; Әсәрләр: 4 томда. К., 1980-83; Избранное. Уфа, 1955.

Әд.: Башкуров Р. Маджит Гафури // История татарской советской литературы. М., 1965; Рамазанов Г. Творчество Маджита Гафури. Уфа, 1970; Магдеев М. Маджит Гафури. К., 1980; Хисмәтуллин Г. Мәҗит Гафури // Татар совет әдәбияты тарихы: Очерклар. К., 1960; Нигъмәтуллин Ә. Мәҗит Гафури: Иҗаты турында очерк. К., 1969; Халит Г. Тормыш һәм ирек җырчысы: Мәҗит Гафуриның тормышы һәм иҗаты турындагы очерк. К., 1980.

*Р.Х.Сверигин.*

**ГАФУРОВ-ЧЫГЪТАЙ** Галиәсгар Мөгыйн улы (16.9.1867, Казан губ., Чистай өязе Яңа Ибрай а. - 20.8.1942, Аксубай р-ны Иске Ибрай а.), язучы, журналист. 1883-91 елларда Чистай мәдрәсәсендә белем ала. 1891-99 да укытучылык итә. 1899 дан Бузулук шәһәрендә имам булып тора. 1915 тән Казанда яши, «Кояш» г-тасында эшли, 1916 дан Уфада, «Тормыш» г-тасында. 1924 тән Мәскәүдә яши. СССР халыклары Үзәк нәшриятында эшли, 1925-32 дә «Фән һәм дин» ж-лының җаваплы сәркәтибе була. 1941 нең язында Иске Ибрай авылына күчеп кайта.

Г.-Ч. - «Тутам» повесте авторы. Аның 1 нче кисәге 1898 дә языла, ул 1902 дә Ф.Кәриминең матди ярдәме б-н Оренбургта әсәрнең төп герое Галимә исеме б-н басыла. Әсәр Галимәнең ире б-н әңгәмәсенә корылып язылган. Әңгәмәләрдә гаиләдәге патриархаль яшәү рәвеше тәнкыйтьләнә, хатын-кызның җәмәгать эшчәнлегендә катнашу хокукы яклана. Повесть татар һәм рус җәмәгатьчелеге тарафыннан уңай бәяләнә (Р.Фәхретдинев, Н.И.Ашмарин). 1906 ның июнендә «Әлгасрелҗәдид» ж-лында повестьнең 2 нче кисәге басыла. 1908 дә Г.Тукай инициативасы б-н әсәрнең ике кисәге дә аерым китап булып чыга. Г.-Ч. ның исламның төп кагыйдәләренә каршы чыккан «Исабәт» исемле публицистик китабы (1909) Коръән һәм шәригатьнең күп кенә кагыйдәләрен шик астына куя. Бу китап өчен автор руханилык дәрәҗәсеннән мәхрүм ителә.

Әсәр.: Мин нидән динсезләндем. М., 1924; Дини корбаннар. М., 1927; Дин хорафатлары. М., 1929.

Әд.: Гайнуллин М. Татарская литература XIX в. К., 1975; шунысы ук. Татарская литература и публицистика начала XX в. К., 1983; Рахманкулов З. «Исабәт» китабы хакында мөляхәзә // Шура. 1910. N1.

*А.М.Ахунов.*

*Дәвамы киләсе саннарда*

## Якташымны таныдым

Яраткан журналымның быелгы 6 нчы һәм 7 нче саннарында урын алган, фамилиядәшем Камил Кәримов язган «Уен» романы үзенең тирән эчтәлеге белән мине, тормышның ачысын да, төчесен дә кичергән олы яшьтәге кешене дә тетрәндерде һәм әсәрдә күтәрелгән мәсьәләләргә карата үземнең фикерләремне язарга мәҗбүр итте.

Автор сәләт ияләре-шәхесләрнең язмышлары хәзер дә, советлар чорындагыча, үз агымнарында гына баруын, акчалы кеше генә музыкага заказ биргәнен, илнең дилбегәсе кемнәр кулында икәнлеген зур кыюлык белән, әдәби образлар аша безгә—журнал укучыларга житкерә.

Дөрестән дә, сыналган сәләт ияләре жир асты хәзинәләредәй илебезнең, халкыбызның байлыгы бит. Без аларны дәүләт дәрәҗәсендә сакларга тиешбез. Бигрәк тә хәзерге катлаулы чорда. Акчалы, ышанычсыз, хөсетле, ялганчы, әдәпсез, мәрхәмәтсез, имансыз бәндәләргә ярап, безнең сәләт ияләребезнең яман гадәтләргә бирелеп юкка чыгуына юл куймаска тиешбез. Әмма, тарих безне күпме өйрәтсә дә, ялгышыбызны таный алмыйбыз. Шәхесләребез үз агымында баруларын дәвам итәләр. Хәзер дә кайбер танылган җырчыларыбыз начар (яман) гадәтләргә бирелеп, тавышларын, үз йөзләрен жуялар. Дистәләгән көннәр концертларда, фонограмма әйләндереп, хәрәм байлык җыялар. Моңа нокта куярга вакыт. Республикабызның Мәдәният министрлыгы каршында сәләтле шәхесләребез белән эшләү бүлеге яисә бүлекчәсе булдырырга кирәк.

Әсәрнең бер герое Марат Гомәр образында мин, шикләнмичә, якташым, танылган баянчы, «Саз» халык ансамблен оештыручы, аның белән ун еллап житәкчелек итүче, Кремльнең Съездлар сараенда КПССның Генераль секретаре Брежневны аягүрә бастырып кул чаптырган татар егете Рифкать Гомәровны (Гумеровны) таныдым. Дөрестән дә, тырыш хезмәте, сәләте белән олы уңышлар казанган бу татар егетенең бернинди мактаулы исемгә дә лаек булмыйча дөньядан китеп баруы мине генә түгел, меңләгән музыка сөюче милләттәшләремне дә борчыйдыр дип уйлыйм...

Әсәрнең кимчелекләрен искә алып, мин авторның хокук саклау, хөкем итү хезмәткәрләренең эшләренә тискәре каравын әйтер идем. Дәүләтебезнең идарә итү системасы кулындагы корал, кушканны үтәүчеләр генә бит алар.

**Нариман КӘРИМОВ,**
*хәрби хезмәт ветераны.*
*Казан*



*Аксакаллар. Сулдан уңга—Касыйм Хәмзин, икенче кеше—?, Лотфи Яфаров, Фазылҗан Хәмидуллин, Исмәгыйль Рәми, Бакый Урманче, Әхмәт Булатов. 60 нчы еллар.*



*Сулдан уңга—Рабит Батулла, Хатыйп Газизов (район башлыгы), Гариф Ахунов, Мансур Шиһапов. Балык Бистәсе районында үткән әдәбият көннәре истәлеге. 1994 ел.*



*Үз заманының эстрада йолдызлары. Сулдан уңга—нәфис сүз остасы Фәйзи Йосыпов, җырчы Разыя Тимерханова, баянчы Мохтар Әхмәдиев. Үткән гасырның 50 нче еллары.*



*Бер төркем язучылар «Казан утлары» журналы редакциясе хезмәткәрләре белән бергә. Сулдан уңга—Наис Гамбәр, Марсель Зарипов, Мәгъсүм Хуҗин (артта), Булат Солтанбәков, Хатыйп Миңнегулов, Марс Шабаев, Харрас Әюпов, Мансур Вәлиев. 1998 ел.*



*Шагыйрь Зиннур Насыйбуллин (1937-1986)*



*Татарстан язучыларының Россия Югары Советы рәисе Борис Ельцин белән очрашу күренеше. 9 август 1990 ел.*

## РЕСПУБЛИКА БӘЙРӘМ ИТТЕ

30 август—үзен татар дип санаган һәр кеше өчен олуг бәйрәм көне. Ул, шулай ук Татарстанда яшәүче бүтән милләт вәкилләре өчен дә кадерле көн. Ул көн—Республика көне! Соңгы елларда аны Казан шәһәре бәйрәме дип тә атый башладылар. Бу көнне Казанда һәм республикада байтак тантаналар булып узды. Шәһәр Ратушасында берничә мәртәбәле шәхескә «Казанның мактаулы гражданины» исеме бирелде, икенче бер төркем олуг затлар Казан шәһәренең Мактау китабына кертелде. Алар арасында укучыларыбызга яхшы мәгълүм кешеләр дә бар: академик М. Мәхмүтов, артист Р. Таҗетдинов, балет остасы Н. Юлтыева.

Казан читендәге Залесный һәм Юдино бистәләре арасында (озынлыгы 4,2 км) балалар өчен махсус тимер юл ачылды. Анда Президент М. Шәймиев, «Россия тимер юллары» ачык акционерлар җәмгыяте президенты В. Якунин, РФ Хисап палатасы рәисе С. Степашин, Горький тимер юлы башлыгы С. Козырев һ. б. катнашты.

Казансу аша «Миллениум» күперенең икенче полосасын ачу турында инде күптән сүз бара иде. Ниһаять, бәйрәм көнне ул файдалануга тапшырылды. Тантанада тәзүчеләрне Президент М. Шәймиев, Казан шәһәре башлыгы И. Метшин һәм РФ транспорт министры урынбасары Е. Москвичев котлады.

Казансу елгасы буенда ачылган аквапарк башкалабызда икенчесе булды. Ул «Ривьера» күнел ачу-тамаша комплексына карый. Яңа аквапаркны беренчеләрдән булып Президент М. Шәймиев, Премьер-министр Р. Миннеханов, РФ Дәүләт Думасы Рәисенен беренче урынбасары О. Морозов, РФ Хисап палатасы рәисе С. Степашин, «Россия тимер юллары» ачык акционерлар җәмгыяте президенты В. Якунин, Казан шәһәре башлыгы И. Метшин карады.

Көн уртасында Казанның үзәгендә—Тукай мәйданында, шагыйрь һәйкәле янында халык күп җыелган иде. Алар шагыйрьләр, җырчылар, музыкантлар чыгышын тыңладылар. ТР Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева ачып җибәргән бу бәйрәмдә байтак шагыйрьләр, шул исәптән, Р. Фәйзуллин, Л. Шагыйрьҗан, Р. Миңнуллин, З. Мансуров, Р. Гаташ, Х. Әюп, М. Мирза, Ф. Гыйззәтуллина, С. Гәрәева, Р. Аймәт һ. б. чыгыш ясады.

Көндезге сәгать икедә Камал театры каршында тантаналы шартларда Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев быелның иң истәлекле бүләкләре—республиканың Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләрен шагыйрь Р. Вәлиевкә, композитор Р. Кәлимуллинга, сынчылар төркеме—Р. Нигъмәтуллина, И. Рогожина һәм М. Нигъмәтуллиналарга тапшырды.

Аннары РФ Хисап палатасы рәисе С. Степашин бәйрәм уңаеннан котлау сүзе белән чыкты. Тантанада РФ Дәүләт Думасы Рәисенең беренче урынбасары О. Морозов, ТР Премьер-министрының беренче урынбасары Р. Моратов, Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева һ. б. рәсми кешеләр катнашты.

Татарстанның кайсы гына бәйрәме атлар узышыннан башка үтә икән! Бу юлы да «Казан» халыкара ат спорты комплексында Татарстан Президенты кубогына узышлар булды. Әлеге призга һәм 3 миллион сум бүләккә Роялвуд кушаматлы юртагы белән А. Ляхов лаек булды.

Халыкара ат комплексында тагын бер тантана булды—Президент М. Шәймиевкә авыл эшчәннәре исеменнән быелгы ашлыктан пешерелгән икмәк тәкъдим ителде. Аны Илбашына Премьер-министр урынбасары—авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры М. Әхмәтов тапшырды.

Бәйрәм тантаналары барлык район үзәкләрендә гөрләп узды.

## МЕҢЬЯШЬЛЕК БОРЫНГЫ ЯШЬ КАЛА

Татарның дәүләтчелеге бик борыңгыдан килә. Алтын Урда дәүләте, Казан, Себер һәм Әстерхан ханлыклары... Ә бит алардан элеккерәк чордагы Хазар каганаты һәм Бөек Болгар дәүләте дә тарихта безнең төрки бабайлар ватаны буларак билгеле.

Август аенда Алабуга шәһәренең 1000 еллыгын бәйрәм иткәндә татар халкы тарихы, аның дәүләтчелеге тарихы кат-кат телгә алынды. Шунсыз мөмкин дә түгел, чөнки Кама елгасы ярындагы бу шәһәр урынында кайчандыр Идел буе Болгар дәүләтенең

төньяк чигендәге ныгытма булган.

«Чулман буенын энже бөртеге» саналган Алабугада бәйрәм өч көн буе барды. Юбилей тантаналарында Татарстан Президенты М. Шәймиев, Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, Премьер-министрнын беренче урынбасары Р. Моратов, Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева, РФ Дәүләт Думасы Рәисенен беренче урынбасары О. Морозов, РФ Президентынын Идел буе федераль округындагы Вәкаләтле вәкиле урынбасары В. Зорин һ. б. катнашты.

Тантаналарнын беренче көне шәһәрләрне балансы үстерү буенча халыкара форум эше белән башланды. Бу форумда 12 илдән һәм Россиянен төрле төбәкләреннән вәкилләр катнашты. Әлеге эшлекле сөйләшүне Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, РФ Дәүләт Думасы Рәисенен беренче урынбасары О. Морозов һәм РФ Федерация Советынын Җирле үзидарәләр буенча комитеты рәисе урынбасары А. Салтыков, Евразия буенча Бөтендөнья мирасы шәһәрләре оешмасынын төбәк координаторы Р. Сәгыйтов алып барды. Ф. Мөхәммәтшин форумда катнашучыларга Президент М. Шәймиевнен котлавын ирештерде.

«Өченче меңьеллык башында калалар тормышы тиз үзгәрә. Заманча торак йортлар төзелә, транспорт камилләшә, зарарлы житештерү калдыклары шәһәр читенә чыгарыла, фән һәм мәгариф өлкәсендә көндәшлек арта. Бу шартларда калаларнын гармоник үсешенә дәүләт һәм муниципаль хакимиятләренен, иҗтимагый оешмалар һәм барлык гражданнарнын үзара тыгыз хезмәттәшлеге хисабына гына ирешергә мөмкин. Без Татарстанда үз эшчәнлегебезне нәкъ менә шул принципларга нигезләнеп оештырырга тырышабыз»,—диелгән иде әлеге котлауда. Форумда Алабуга муниципаль районы башлыгы И. Гафуров эшлекле доклад белән чыгыш ясады. Ул шәһәр һәм районда бүгенге көн проблемаларынын ничек хәл ителүе турында сөйләде. РФ Дәүләт Думасы Рәисенен беренче урынбасары О. Морозов үз чыгышында төбәкләрдә яшәүчеләрнен тормыш дәрәҗәсен күтәрү—ин беренче чираттагы бурыч булуын ассызыклады. Р. Сәгыйтов исә Алабуга муниципаль районы башлыгына БМО-Хабибат программасы житәкчелегенен тарихи-мәдәни ядкәрләрне кадерләп саклаган өчен бирелә торган дипломын тапшырды.

Юбилей көннәрендә Алабугада истә калырлык вакыйгалар күп булды. Шуларнын берсе—яңа стадион ачылу. Анда спортнын күп төрләре өчен мәйданчыклар бар. Шәһәр шулай ук ябык җинел атлетика залына һәм Боз сараена да ия булды. Аларга Президент М. Шәймиев һәм тантанага килгән мөхтәрәм кунаклар да зур бәя бирде. Алабуга командаларынын киләчәктәге җинүенә ишарә итеп, ул көнне стадион өстендә Сочида узасы Олимпиада-2014 флагы җилфердәде.

Алабуганын 1000 еллыгы бәйрәмендә ин истәлекле вакыйгаларнын берсе—Идел буе Болгар дәүләте әмире Ибраһим бин Мөхәммәдкә багышланган скульптура монументын ачу булгандыр. Риваятьләргә караганда, Алабугага кальга буларак нигез салуда ул житәкчелек иткән. Әлеге монументнын архитекторы—Ф. Халиков, скульпторы—М. Гасыймов. Һәйкәлне ачканда Президент М. Шәймиев чыгыш ясады. Ул тарихны шулай оста гәүдәләндергән өчен монумент авторларына зур рәхмәт белдерде. Соныннан шунда ук «Борынгы болгарлар» дигән театрлаштырылган хәрби-тарихи тамаша булды.

«Алабуга» махсус икътисадый зонасында «Северсталь-авто-Алабуга» заводларын ачу да бәйрәмнен зур вакыйгасы саналырлык. Анда Президент М. Шәймиев, РФ Президентынын Идел буе федераль округындагы Вәкаләтле вәкиле В. Зорин, Татарстан Президенты аппараты житәкчесе Ю. Камалтынов һ. б. катнашты. «Северсталь-авто» оешмасынын генераль директоры В. Швецов үз чыгышында Алабугадагы заводларда «Фиат Дукато» җинел автомобильләре һәм «Исудзу» йөк машиналары чыгарылачагын әйтте һәм ниятләнгән проектта төрле типтагы автобуслар чыгару булуын да искә төшерде.

«Алабуга» махсус икътисадый зонасы—яна төр машиналар гына түгел, хәзерге катлаулы заманда күпләгән кешегә хезмәт һәм яшәү урыны да дигән сүз ул. Димәк, Кама буендагы борынгы шәһәргә киләчәктә үсәргә, колач җәергә зур терәк булачак.

Рәсми делегация Алабуганын туган якны өйрәнү музее (Алабуга—рәссам И. Шишкин, язучы Н. Дурова, галим В. Бехтеров, сәүдәгәр Стахиевлар һәм башка күренекле шәхесләрнен ватаны да бит әле!) ачылу тантанасында да булды. Аннары «Молодежный» стадионында Россиянен төрле шәһәрләреннән килгән хәрби-тарихи клублар катнашында зур тантана тәкъдим ителде.

Бәйрәмдә катнашучылар Президент М. Шәймиевнен «Алабуганын мактаулы гражданины» дигән исемгә лаек булуын шатланып кабул итте. Алабуга муниципаль районы башлыгы И. Гафуров күренекле рус шагыйрәсе М Цветаева исемендәге әдәби премия булдырылуын да белдерде һәм анын беренче бүләкләрен ияләренә тапшырды.

Шулай итеп, Казаннан сон тагын бер борынгы шәһәребез үзенен 1000 еллык юбилеен уздырды, халкыбызнын данын еракларга янгыратты.

## ӨЧ МИЛЛИАРД СУЫРЫЛДЫ

Татарстан җирендә 3 миллиард тонна нефть чыгарылу уңаеннан Әлмәттә зур тантаналар булып үтте. Анда Президент Минтимер Шәймиев катнашты.

Хәзер кара алтын республиканың күп районнарында чыгарыла. Шуңа күрә әлеге бәйрәм Кама аръягында яшәүчеләр өчен генә түгел, бөтен Татарстан халкы өчен уртак бәйрәм булды. «Татнефть»—яңа технологияләр куллану буенча Россиянең ин алга киткән компанияләре исемлегендә»,—диде Илбашы нефтьчеләр алдында ясаган чыгышында.

Президент М. Шәймиев үз чыгышында «дүртенче миллиард тонна» дигән сүзне еш кабатлады. «Татнефть» ачык акционерлар җәмгыяте коллективы, аның фәнни институтлары хәзер шул биеклек турында уйлап эшли, Татарстан җирендә, белгечләр әйтүенчә, нефть запасы күп әле. Битум нефте катламнары да миллиард тонналар белән исәпләнә. Әгәр шулай икән, 4 миллиард тонна кара алтын табу реаль сан булып чыга.

«Татнефть» ачык акционерлар җәмгыяте генераль директоры Шәфәгать Тәхаутдинов та үз чыгышында моны бик дәлилләп әйтте. Нефть чыгару буенча «Татнефть» компаниясе Россиядә 6 нчы, дөньяда 32 нче урынны били. Җир куенындагы 7 миллиард тонна битум нефте запасы белән Татарстан Канада, АКШ һәм Венесуэла белән тиңләшә.

### ИСКЕ БИСТӘ ЯҢАРЫШ КӨТӘ

Казан Ратушасында башкалабызның Иске Татар бистәсен яңарту һәм үстерү концепциясен тәкъдир итү булды. Анда Президент М. Шәймиев шәһәрнең әлеге борынгы өлешен үстерү концепциясе белән танышты.

Тәкъдир итүдә шулай ук ТР Премьер-министры Р. Миңнеханов, Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, Казан шәһәре башлыгы И. Метшин һ. б. катнашты. Концепция белән проект җитәкчесе—Барселонаның баш архитекторы Хосе Асибилло таныштырды.

«Казан шәһәренә үзенең башкалардан аерып торучы үзенчәлекләрен җуймау мөһим. Бу бистәдәге шуның кадәр күп борынгы ядкарьләр Россиядә башка беркайда да юктыр, мөгаен,—диде күренекле архитектор.—Яңа дәвер архитектурасы ядкарьләрне каплап калдырса, шәһәр тарихының үлеменә тиң булачак бу».

Архитектор бистә аша узучы тимер юлларны күчерү ягында булуын да әйтте. Алардан файдалануның бистәдәге сәнәгать зонасына бәйлелегеннән чыгып, Х. Асибилло биредәге авыр сәнәгать предприятиеләрен шәһәр читенә күчерергә тәкъдим итәргә исәпли.

Проектның төп өлеше исә тиңдәшсез дүрт биек бина (эшлекле үзәк) комплексыннан гыйбарәт булачак. Ул шәһәрнең тарихи үзәгенә үзенчәлекле капка ролен үтәргә тиеш дип уйланыла. Концепциянең тагын бер үзенчәлеге—уңайлы ял зоналары булдыру, шулай ук аз катлы торак йортлар төзү. Моннан тыш, районның төп юлларын төзекләндерү, 12 чакрым озынлыкта урамнар челтәрен булдыру күздә тотыла. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры янындагы мәйданчыкка килгәндә, Х. Асибилло, Кабан күленең ике ярын тоташтыручы җәяүлеләр юлы төзергә, автомобильләр өчен махсус тоннель салырга тәкъдим итә.

Тәкъдир итү барышында М. Шәймиев проект авторларына Иске Татар бистәсенең мәдәни мирас объектларын саклап калуга кагылышлы кайбер сораулар бирде. Х. Асибилло, республика хакимиятенең барлык теләкләре искә алыначак, дип җавап бирде.

### КАҺАРМАННАРНЫ ИСКӘ АЛУ

1944 елның 25 августында Германиянең Плетцензее төрмәсендә унбер җәлилче җәзалап үтерелә. Бу уңайдан байтак еллар инде Казанның 1 Май мәйданында каһарман шагыйрь Муса Җәлил һәйкәле һәм җәлилчеләр барельефлары янында хәтер җыены үткәрелә.

Быелгы искә алу мәрәсимен Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе шагыйрь Илфак Ибраһимов ачып җибәрде. Аннары Татарстан мәдәният министры урынбасары Айрат Җаббаров сүз алды. Хәтер җыенында шулай ук Муса Җәлилнең кызы Чулпан ханым, М. Җәлил исемендәге республика премиясенә төрле елларда лаек булган каләм әһелләре—Татарстанның халык язучысы Туфан Миңнуллин, Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис, әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин, драматург Ризван Хәмид, шагыйрьләр Ләбиб Лерон, Газинур Морат чыгыш ясады.

Искә алу мәрәсимендә Чуашстанның халык шагыйре Педер Хузангай, күренекле язучылар Варлам Шаламов һәм Семен Липкинның Җәлил турындагы истәлекләре аларның үз язмаларында яңгырады.

Әдәби-музыкаль хәтер мәрәсимендә җырчылар Айдар Габетдинов, Зөлфия Зарипова, Айгөл Бариева Муса Җәлил шигырьләренә язылган җырларны башкарды.

Хәтер җыенын шагыйрь Ркаил Зәйдулла алып барды.

Шул ук көнне Татарстан Милли музеенда «Батыр үлә, үлмәс ат алып» дигән күргәзмә ачылды. Биредә Муса Җәлилнең каләмдәш дусты Гази Кашшафка юллаган васыять хаты, Абдулла Алишның хатынына соңгы хаты, Рәхим Саттарның улы Илгә язган хаты, шулай ук җәлилчеләр Гариф Шабаев белән Әхәт Атнашевның сугышка кадәр төшкән фотосурәтләре, кадерле тарихи документлар куелган иде.

### АВЫЛЛАР—БЕЗНЕҢ БИШЕГЕБЕЗ

Урып-җыю чорында язучыларның районнарга чыгып, авыл хезмәтчәннәре—игенчеләр белән очрашулар үткәрүе күркәм традициягә әйләнеп килә. Татарстан Язу-

чылар берлеге, Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән берлектә, мондый чараны өченче ел үткәрә инде. Шушы традицияне дәвам итеп, Язучылар берлеге (җитәкчеләре—И. Ибраһимов, В. Нуриев) быел да районнарга язучылар «десанты» оештырды. Язучыларыбыз Норлат, Аксубай, Ютазы, Баулы, Актаныш, Буа, Апас, Саба, Арча районнарында булып игенчеләр һәм авыл интеллегенциясе вәкилләре белән очраштылар, район җитәкчеләре белән һәммәбез өчен дә актуаль булган проблемалар турында сөйләшеп фикер алыштылар. Бу очрашуларда Т. Миннуллин, М. Хәбибуллин, Т. Галиуллин, Р. Миннуллин, Р. Мостафин, М. Галиев, Х. Әюпов, В. Имамов, Р. Фәизов, Г. Морат, Р. Зәйдулла, К. Кәримов, Ш. Мостафин, Р. Корбан, Ә. Салах, Ш. Җиһангирова, И. Иксанова, Д. Салихов, Ф. Тарханова, Л. Янсуар, Г. Садә, Ф. Мөслимова, М. Разов, Ә. Моталлапов, Х. Бәдыгый, К. Сәгъдәтшин һ. б. катнашты.

### СЕЗОН АЧЫЛУ УҢАЕННАН

Яңа сезон ачылу уңаеннан С. Сәйдәшев исемендәге Дәүләт зур концерт залының М. Җәлил һәм Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иләре, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артистлары Ш. Монасыйпов, К. Монасыйпов, М. Зарипов, А. Әсәдуллин катнашындагы Татарстан Республикасының дәүләт кыллы уен кораллары квартеты, «Туган тел» татар иҗтимагый үзәге чакыруы белән, 1 сентябрьдә Самара шәһәрендә зур концерт куеп кайтты. Анда татар композиторлары һәм дөнья музыка классикларының әсәрләре башкарылды. Төбәкнең танылган җырчысы Җәлил Мифтаховның, квартетка кушылып, Р. Яхин романсларын җырлавын тамашачылар яратып кабул итте.

Квартетның иҗади эшчәнлеген тәкъдим итеп, программаны Зур концерт залы директоры, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, шагыйрь Мансур Шиһапов алып барды, тамашачыларга үзенең яңа шигырьләрен укыды.

### «СӘЙДӘШ АЛАНЫ»НДА БӘЙРӘМ

Сигезенче ел рәттән Югары Ослан районының «Кызыл байрак» авылында әдәбият һәм сәнгать бәйрәме үткәрелә. Елдан-ел киңрәк колач алган бу бәйрәмнең иҗтимагый әһәмияте арта бара.

Ул музыка әһелләрен генә берләштереп калмыйча, күптән инде сәнгатькәрләрнең, шагыйрь, язучыларның иҗади аралашу урынына әверелде. Халык та яраткан шагыйрьләрен, җырчы, музыкантларын якыннан күрергә Сәйдәш аланына елдан-ел күбрәк килә. Бәйрәм башланган елларда елга портыннан Югары Осланга бер теплоход кузгала торган булса, быел теплоходлар саны өчкә житте, һәркайсы халык белән шыгрым тулы иде. Рәсми затлар да Сәйдәш иҗатына битараф түгеллеген күрсәтте. Кунакларны мәдәният министры урынбасары Айрат Җаббаров, Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты рәисе урынбасары Владимир Осянин сәламләде. Алар бертөркем иҗатчылар белән бергә Салих Сәйдәшев рухына багышлап куелган истәлек ташына чәчәкләр салды.

Бу сәнгать бәйрәме тууына быел 120 ел тулган мәшһүр драматург Кәрим Тинчурин истәлегенә багышланган иде. Бу табигый да: чөнки Сәйдәш һәм Тинчурин иҗатларын бер-берсеннән аерып карау кыен. Алар күп әсәрләрен бергәләп иҗат иткәннәр.

Бәйрәмдә татар әдәбияты һәм сәнгатенең күренекле вәкилләре Туфан Миннуллин, Равил Фәйзуллин, Фуат Мансуров, Римма Ибраһимова, Фәрит Бикчәнтәев, Идрис Газиев, Рафаэль Сәхәбиев һ. б. катнашты. Бәйрәмнең төп оештыручысы, башка еллардагыча, әлбәттә, Камал театры иде (директоры Шамил Закиров). Бәйрәм концертын шагыйрә-журналист Флүрә Низамова алып барды.

### ОЛҖАС БЕЛӘН ОЧРАШУ

Казакъ халкының мәшһүр улы, төрки дөньяның күренекле шәхесе, шагыйрь, галим, дипломат Олҗас Сөләйманов Казанга—III Халыкара мөселман киносы фестивале—«Алтын мөнбәр»гә дәрәҗәле кунак итеп чакырылган иде. 11 сентябрьдә С. Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында ул Казан җәмәгатьчелеге белән очрашты. Иң әүвәл аның турында «Олҗас» дигән документаль фильм күрсәтелде (бу фильм үткән ел фестиваль кысаларында Казан тамашачысына тәкъдим ителгән иде инде. Кичә ахырында О. Сөләйманов очрашуга килгән кешеләрнең байтак сорауларына җавап бирде. Тиздән «Ленфильм» студиясендә аның сценариясендә яңа фильм эшләнеп бетәчәк. Төп рольләрнең берничәсендә татар халкы вәкилләренә дә урын бирелгән.

### БЕЛЛА ӘХӘТ КЫЗЫН ОЛЫЛАУ

Россия Президенты Владимир Путин шагыйрә Белла Әхмәдуллинаны II дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләде.

Быелның апрель аенда күренекле шагыйрә үзенең 70 яшьлеген бәйрәм иткән иде. Юбилейга аның «Путник» исемле җыентыгы дөнья күрде. Шагыйрәнең беренче китабы исә 1962 елда басылып чыга.

Белла Әхмәдуллина шулай ук Россия Дәүләт, Триумф һәм Пушкин премияләре лауреаты да.

## НӘШРИЯТЛАР КҮЧТЕ

Татарстан китап һәм «Мәгариф» нәшриятлары Бауман урамыннан яңа урынга күчте. Яңа адреслары—Оренбург тракты, йорт 21а (элеккеге халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсе, ягъни хәзерге «Казан ярминкәсе» белән янәшә йортларның берсендә). Шулай ук, «Мәдәни җомга» атналык газета редакциясе дә Матбугат йортыннан китәргә мәҗбүр булды. Хәзер ул «Идел-Пресс» китап басу комбинаты (Декабристлар урамы, 2) бинасында эшли башлады. Күченүләрнең төп сәбәбе: 30 нчы елларда салынган Матбугат йортының тузып, авария булу куркынычы хәленә килүе. 70 елдан артык татар матбугаты һәм әдәбиятының үзәге булган бу бинаның киләчәк язмышы киң җәмәгатьчелеккә әлегә мәгълүм түгел.

***

Татарстан Республикасы халкына күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткән өчен шагыйрә **Шәрифуллина Эльмира Мөхәммәт кызы** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына лаек булды.

## РӘИС ДАУТОВ

Татар әдәбияты зур югалтуга дучар булды. Танылган язучы, тәрҗемәче, күренекле әдәбият белгече һәм текстолог Рәис Нәүширвән улы Даутов 28 августта озакка сузылган каты авырудан соң арабыздан мәңгегә китте.

Р. Н. Даутов 1928 елның 15 мартында Татарстан АССРның Мамадыш районы Шәмәк авылында дөньяга килә. 1948 елда Казан укытучылар институтын тәмамлый. Р. Даутов 1953—1980 елларда Татарстан китап нәшрияты хезмәткәре, балалар һәм яшьләр әдәбияты мөхәррире, матур әдәбият редакциясенең өлкән мөхәррире. 1963 елда ул Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты факультетын тәмамлый.

Р. Даутов соңгы елларда Татар энциклопедиясен булдыруга үзеннән зур өлеш кертте, Татарстан Республикасы язучылары турында белешмә өстендә эшләде.

Иҗат эшчәнлеге башында Р. Даутов сәләтле тәрҗемәче буларак танылды. 1958 елда аның бу өлкәдәге тәүге эшләреннән берсе—М. Твенның «Янки король Артур сараенда» повесте тәрҗемәсе басылып чыкты. Шуннан соң Р. Даутов тәрҗемәсендә чит ил һәм рус классиклары, күп милләтле совет әдәбияты әсәрләреннән дистәдән артык җыентыгы дөнья күрде. Р. Даутов эшләре, бик оста тәрҗемә үрнәгенә әйләнеп, әдәби тәнкыйтьчеләр тарафыннан югары бәяләнде.

Рәис Даутов татар классиклары әсәрләрен бастыруга әзерләүгә үзеннән зур өлеш кертте, аларның текстларын камилләштерү буенча армый-талмый эшләде. Кол Галинең Кыйссаи Йосыф поэмасы кебек мәшһүр татар әдәбияты үрнәкләре, Утыз Имәни әл-Болгари, Акмулла, Дәрдмәнд, Г. Тукай, Г. Камал, Г. Ибраһимов әсәрләре турыдан-туры аның катнашында бастыруга әзерләнде.

Р. Даутов Язучылар берлегенең иҗтимагый тормышында актив катнашты. Озак еллар буе Татарстан Язучылар берлеге каршында кабул итү комиссиясе секретаре, РСФСР Язучылар берлеге идарәсенең тәрҗемәчеләр советы әгъзасы булып торды.

Әдәбият өлкәсендәге казанышлары өчен 1978 елда Р. Даутовка ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исем бирелде. Ул—Г. Исхакый исемендәге премия лауреаты, Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнгән шәхес.

Рәис Даутов әдәбиятчыларның яшь буынын тәрбияләүгә һәрвакыт аеруча зур игътибар биреп килде. Аның күп санлы укучылары тормышта үзләренә лаеклы урын табып, әдәбият өлкәсендә атаклы кешеләргә әйләнде. Р. Даутов күп кенә язучылар һәм шагыйрьләрнең сөекле остазы булды.

Р. Даутовның якты истәлеге күңелләребездә озак сакланыр.

***Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы,***
***Татарстан Республикасы Язучылар берлеге***

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Борынгы Казан». **Н. Хаҗиәхмәтов эше.**

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Сәйдә Зыялы**.

# Яңа китаплар




**Азат Әхмәдуллин.** Күнелләрне уятыр: Хәзерге татар драматургиясе: Монография.—Казан: «Мәгариф» нәшр., 2007.—223 б.: фот. белән. Тиражы—1000 данә.

Китап өч бүлектән тора: «Үзгәрешләргә китергән сәбәпләр», «Үзгәртеп корулар чоры алдыннан», «Янарыш чорында татар драматургиясе». Исемнәреннән үк күренгәнчә, сүз бүгенге драматургия проблемалары турында. Китапта XX гасырның 60 нчы елларыннан башлап бүгенге көннәргә хәтле милли сәхнә әдәбиятында барган вәзгыять анализлана, кайбер әсәрләрнең театр тормышында тоткан урыны карала һәм бәяләнә. Шулай ук, китапта авторның кереш сүзе һәм файдаланылган әдәбият исемлеге бирелә.




**Мәхмүт Әхмәтҗанов.** Яманны юлдаш итмә: мәкаләләр, очерклар, эсселар.—Казан: Тат. кит. нәшр., 2007.—223 б. Тиражы—1000 данә.

Язучы-публицист, галим Мәхмүт Әхмәтҗановның укучыларга тәкъдим ителә торган бу китабы яшәешебезнең мөһим проблемаларына: сәясәт һәм милләт язмышы, гаилә һәм тәрбия, тарих һәм дин кебек катлаулы мәсьәләләргә багышланган. «Әдәбият безгә юл яра» бүлегендә язучы-әдипләрнең (Н. Исәнбәт, Г. Бәширов, М. Львов, Ә. Кәримуллин, Р. Фәйзуллин, Х. Әюп, З. Мансуров, Г. Морат, М. Әмирханов, Ф. Баттал һ. б.) иҗатларына багышланган мәкаләләр тупланган. Китап авторның 80 яшьлек юбилее уңаеннан нәшер ителгән.



Сәйдә Зыялы

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)